# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Зиннур МАНСУРОВ. Бәгырьдәге гамьнәр төенләнә... *Шигырьләр*. ..........3

Зөлфәт ХӘКИМ. Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?.. *Роман*. ..........9

Мөхәммәт МИРЗА. Мәңгелек юлында. *Поэма-кыйсса*. ..........76

Халисә ШИРМӘН. Кулъязмалар – тормыш көзгесе... *Шигырьләр*. ..........115

Нәзифә КӘРИМОВА. Изге ат. *Хикәя*. ..........119

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА. Ник яңара җанда шушы моң? *Шигырьләр*. ..........128

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Кара батыр. *Документаль повесть*. ..........88

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Сырбай МӘУЛӘНОВ. Җырлы Казан. *Бер сәфәр тарихы. (Кереш сүз авторы һәм казакъчадан тәрҗемә итүче – Лирон ХӘМИДУЛЛИН.*) ..........132

ФӘН

Ринат СӘФӘРОВ. Тел – мәдәниятнең таҗы, сүзлек исә – телнең таҗы *(Алты томлы аңлатмалы сүзлек басылып чыгу уңаеннан)*. ..........141

МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Гомер бүләк итүче галим. ..........147

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Казан ханлыгында ислам дине. ..........153

БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ. Киләчәктән килгән малай. *Үсмерләр өчен повесть*. ..........162

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Аңламас акылсыз, ассаң да дарга... *(Мөхәммәдьярның тууына – 525 ел)*. *Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара*. ..........186

ПЕЧӘН БАЗАРЫ

Рөстәм АРИФУЛЛИН. Әрем бирсәм дә – риза. *Шигырьләр*..........188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..........190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 7 (1197) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**


✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.06.2022, график буенча 28.06.2022, басылып чыгу вакыты 01.07.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1943. Тираж 7523.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Зиннур
Мансуров

# БӘГЫРЬДӘГЕ ГАМЬНӘР ТӨЕНЛӘНӘ...

## Төнге сынау

...Кинәт кенә моң-зар белән иңрәп куйдым,
ишетелде пайтәхетнең ай-вае.
Әллә инде, Тәгаләллаһ, шулай тетрәп,
Сөембикә манарасы авамы?!

Изрәр тәңгә көтелмәстән тәшвиш өстәп,
хозурымда убыр уты гөлт итте.
Зәһәр чәчкән гыйфрит кебек астан йөри,
дулап уза үзәк өзгеч гөрелте!

Шомландырып атылучы йолдызлардан
йөрәк итен өтеп торыр куз кала.
Аермачык күрәм барсын: мәйдандагы
Җәлил сыны... урыныннан кузгала.

Төнге күктә өнсез яшен уйнап алды,
кара болыт арасыннан ай чыкты.
Чәчәк тулы пьедесталдан җәһәт төшеп,
Тукай кирмән тарафына ашыкты.

Милләт рухын турайтырлык күпме гайрәт
Мулланурны өскә чөйгән тау-таշта!
Егылачак горур кыя ялварына –
гыйсъянчыдай кубарылды Такташ та.

Сөембикә җанын ничек сөендерер
дәрелфөнүн каршындагы Ульянов?..
Патшалыкның татар канлы Державины
көрсиендә утырадыр уйланып.

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) – *Татарстанның халык шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе; «Ваем», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Күңелдә фидаи яшәсә», «Дөреслек икегә төрләнмәс» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Мәгърур кавем төп-төз килеш басып калыр,
эчтән сынмас мәхшәрише сынауда.
Идел-йортның әләмедәй илекмәнне[1]
иңнәренә күтәрмәкче сыннар да.

...Ярым йокы халәтендә үрә катам,
күзләремнән ихтыярсыз яшь чыга.
Иблис үзе коткы салган сәер төшне
юрыйм бары, юрыйм фәкать яхшыга.

## Койрыклы йолдыз[2] хитабы

Әлмисактан алып әйләнүем,
җитмеш алты еллык юлым бар.
Ямчы кебек барсын барлап үтәм,
җыеп йөрмим төрле йолымнар.

Иңләгәндә сезнең киңлекләрне,
янә караш ташлыйм Җиргә дә.
Мәңгелекнең серле әманәте
авыр йөктәй тора җилкәдә.

Кешелекнең кылтым кыланышын
инде өстән кат-кат күзәттем;
үзалдыма озак өзәләнеп,
ризасызлык сүзен йөз әйттем.

Ярсытучан уйлар ябырыла
биләмәмне гизеп кайтуга.
Аллаһ колы нигә шулай шашып
ыруглыктан бирле кан түгә?

Котырынып, кылыч күтәрүнең
күренмидер һаман ахыры.
Кыргыйлыкка карап көрсенгәндәй,
улап куя, әнә, Ак бүре...

Таңга калам тыныч тормыш белән
сугыш арасында чик юкка.
Гөсләләрнең кылы әверелә
чәнечкеле тимерчыбыкка.

Галәмемә сыймас галәмәтләр
буталыша кояш алдында.
Явызлыкны кем соң авызлыклар –
ә ул артка чүкми адым да.

Мәгарәдән чыккан мәхлуклары
аждаһадай хәзер ут ора.
Тотанаксыз илләр тәхетенә
шамакайлар килеп утыра.

Күкрәк сөте сихри көчен җуяр
берсен берсе ашар инсанда.
Болар курка белмәс, иблис булып,
яман төшләренә иңсәң дә.

Ялган, мәкер, үчлек, рия, гайбәт
күпме фәрештәне качырган!
Тәһарәтсез адәм тәганәсе
тәүбә кыла башлар кай чордан?!

Аналарның күккә ялваруын
тыңлап бакмый һичбер иләмән...
Әлмисактан алып әйләнүем,
эчтән сызып, ничә ел янам!

Үкенечкә берни үзгәрмидер –
җентекләдем Җирнең бар төшен.
Мондый хәлдән тәмам гайрәт чигеп,
чиксезлеккә китеп барышым.

## Ышанмыйм

*Не верю, что в чак-чаке нет кукурузы!*
Н.Хрущёв

Хакыйкатьтә татар хакын хакимнәрчә
төрле яклап даулый алыр инсан мин...
Өммәтләргә Аллаһ җир-су өләшкәндә,
аның йоклап калырына ышанмыйм.

---

[1] Илекмән – манара мәгънәсендә.
[2] Галәми киңлекләрдә гизеп йөргәннән соң, 76 ел үткәч, Җиргә кабат-кабат якынайган Галлей кометасы.

Кайчак тарих катламнарын җәһәт кенә
айкап чыгар телмәтләргә охшаш мин.
Мәмләкәтчел падишаһлар тамырында
татар каны булмавына ышанмыйм.

Вакыт-вакыт мөритләре арасында
гыйрфан нуры таратучы ишан мин.
Гадәләтле гарше әгъля галәменең
татар телен белмәвенә ышанмыйм.

Ара-тирә киләчәкне оракулдай
күзаллаган аяктагы ис-аң мин.
Терек җанлы татар халкын борчып торыр
инкыйразның җитәсенә ышанмыйм.
Ышанмыйм!..

## Зинһарлау

Гаҗәп түгел: җирдә төрле төсләр
бер-берсенә китә кушылып;
оркестрның өнле өермәсе
ишетелә шундый хуш булып!

Бал-бәлзәмле исләр болганыша,
болын буйлап җылы җил искәч.
Күпме сулар катыш хәлгә керә,
диңгезләргә барып елышкач.

Бәгырьдәге гамьнәр төенләнә,
барсын берәмтекләп җыйсаң да...
Аралашып тора үзаралай
байтак нәрсә безнең җиһанда.

Шулай дәвам итәр, Аллаһ колы
нинди генә уйлар кормасын.
...Ерак бабам миңа хитап кыла:
«Канны гына бутый күрмә син,
милләт канын бутый күрмә син!..»

## Имтихан тәртибе

Җирдә бериш гаҗәбәләр озак яши,
адәм заты кабат-кабат таң кала, –
аңны бутар чеп-чи ялган дөнья буйлап
кояш нуры тизлегендә тарала!

Кадимидә тормыш шулай корылгандыр,
сәер хәлдән тәмам гаҗиз һәр бәндә, –
әһле галәм зарыгышып көткән хаклык
килеп җитә урау юллы кәрванда...

Каршы төшмик: хәят үзе барсын белә,
болар өчен кирәк түгел чик-чара, –
ялган сине ашыкмыйча даим сыный,
аннан хаклык тәҗел хөкем чыгара.

## Чиктән ашу

*...Күкләр минем биләмә түгел.*
Екатерина II

Гаҗәп хәлләр тулып ашкан чорда
искә төшә шушы сүз һаман, –

Әби патша кулы җитмәс күккә
бидгатьләрчә нәфес сузмаган.

Хәзер инде бүтән төрле үлчәм
шул ук чакрым, аршын,  карышта.
Заманында иман зәгыйфьләнгәч
түбәнәя кебек гареш тә.

Ачыттыргыч бугаз төерендә
тыпырчынып куя зар-нида.
Туймас адәм, әнә, бүлеп алган
бозлык астындагы җирне дә.

Мәнсезлеккә тәңгәл галәмәтне
яңа җиһангирлар уң саный.
Андый затлар михнәт чиккән илгә
бәхет индерергә уйламый...

Кыйтгаларның ничә кишәрлеккә
теленүен, йәгез, кем әйтә?
Кысан гына гүргә сыяр хаким
һәнүз биләмәсен киңәйтә.

Комсыз бәндә, шулай зурдан кубып,
күкне бүлгәләргә тотынды.
Тәнбиһ итә һатиф[3]:  «Ходай орган,
үз-үзеңне тыйнак тот инде!»

Галәбәле гөруһ гамәленнән
сискәнәдер сымак галәм дә.
...Әби патша сүзе үлеп ята
җанны чәнчеп торган каләмдә.

## Алкын дәрья хәтере

Инде ничә тапкыр басып торам
күпне күргән Идел ярында.
Авыр итеп сулыш ала дәрья,
ишетелеп куя зар-моң да.

Исәннәрне шулай искәргәндәй,
бер-бер артлы агып ел килә.
Сәйяр рухлы дулкын, гафу сорап,
тагы аягыма егыла:
«Истигъфар!..»

Олы суга һичкем гаеп такмый,
безне бәйли уртак сөйдергеч.
Татарларны елга тирәсеннән
җиргә туймас патша сөрде ич.

...Бабайларның барлыйм биләмәсен,
җанга имдәй тансык юнь кирә.
Дуылдашкан Идел дулкыннары
дәррәү миңа табан йөгерә.

## Ялгышасым килә

Дөрес чорда тудым микән, диеп,
дәшкән чагым булды язмышка.
Соңра эчтән дога укып куйдым:
үсмер сүзе чыксын ялгышка.

Үзгәртергә күпме азапланма –
бездән тормый яшәү барышы.
Әмма үзен хаксыз хәлдә тоеп,
ялгышырга тели бар кеше.

[3] Күктән иңгән аваз кисәтүе мәгънәсендә.

Күрәзәләр Җирне куркыткалап,
бүген ничек кенә фал ачмый.
Алар белән бергә тәүбә кылып,
ялгышасым килә, валлаһи!
Ялгышасым килә...

## Бүләк бирсәң...

Арттан килер чабышкыны санлап бүләк биргәндә,
синең боек күңелеңне изеп тормас бер гамь дә.

Ал-ял белмәс йөрәгеңә гайрәт иңәр агылып,
Сабан туе сөлгеләре балкыр шундый ак булып!

Инде яшьсез күзләреңнән тулып ашар ямь генә,
төшкә кергән балачагың сафлык өстәр җаныңа.

Кырыс чынлык мөмкинлеге тотмас кыска тезгендә,
бөтен мөһим гамәлләрең алга китәр тиз көндә.

Арттан килер чабышкыга бүләк бирсәң хөрмәтләп...

## Мунча исеме

*(Этнографик дәфтәрдән)*

Элгәрләрем мунча иясенә
инәлгәндер: «Нинди бәла син!»
Үзенеке белән алмаштырып
куя каһәр ... милләт баласын.

Ерак бабам дәшкән: «Канны бутап,
кертмә безне авыр хәлгә син!..»
Аптырашлы кавем ахырында
тәки эзләп таба хәйләсен.

Нарасыйга аны куркытырдай
сәер генә исем кушылган.
Юанычын шулай юындыру
ана күңеленә хуш килгән.

Тирләп чыккан кечтек тәрәз аша
кояш кергән парлак тас булып...
Җеннең котын алыр шартлы ат-нам
күбесенә калган тагылып.

Мондый затлар, әйдә, кара көчнең
йөрәгенә һәрчак шом салсын;
Тәкәбберләр дәррәү тәшвишләнеп,
буш сүз сөйләүчеләр шымайсын.

Бәни адәм, әйе, төрле яклап
сиздерергә тиеш ис-конын.
...Күпме татар бөтен дөнья буйлап
йөртә шундый мунча исемен.

## Тамгалау

Кайчак нәҗес нәмә килеп төшә
киек кошлар очып барганда.
Кинәт шундый кыен хәлгә таргач,
«Нишләп мине сайлап алган?» – диеп,
күккә караш ташлый бар бәндә.

Канатлылар иркен кыланганда,
көнләп куяр җирдә явыз җан, –
үчле затка шулай матур итеп
пычрак ату, баксаң, мөмкин ласа
аллы-гөлле җәйгор ягыннан.

Ялачыга канат бирелмәгән,
бусы һәркем өчен ачыктыр.
Сиңа инде, ләгыйнь, кулай тәкъдим:
кошлар үткән мәлне өскә карап,
авызыңны гына ачып тор.

## Серле күчеш

Җир-суны озаклап күзәткәч,
төрлечә хисләнәм: әллә-лә!..
Аһ, җәйне яшәткән яшел төс
акрынлап сарыга әйләнә.

Моңарчы илтифат итмәдем –
ниндидер илаһи могҗиза.
Әфсенгә бирелгән шикелле,
күңелдән сөзелеп, моң уза.

Шушындый сихерле күчештә
хәяти хикмәт тә, гамь дә бар.
Яктылык нурлары сынудан
зирәк зат мөкатдәс ямь табар.

Күзлибез дәрьяның агуын,
учакның януын текәлеп.
Ә хәзер хлорофилл тибешен
тыңларга яратам тын калып.

...Яшелнең сарыга дүнүен
эчкәрәк яшереп, төн килде.
Гәрәбә дисбемнән Мәңгелек
елмаеп куйгандай тоелды...



Зөлфәт
Хәким

# БЕР СӘГАТЬТӘ НИЧӘ МИЗГЕЛ БАР?..

РОМАН*

## 1

Бәла һәрвакыт көтмәгәндә килә. Хәйдәр дә гомер кояшы баеп килгәндә, мондый сынауга дучар булырмын дип уйламаган иде.

Әбелхәят һичберәүгә үзеңә язган кыйсмәттән артыгын да, кимен дә бирми, әмма кеше барыбер яхшыга өметләнә.

Өмет гел киләчәккә карый, узган көннәр аңа инде «кызык» түгел.

Иртәгәсе көндә син әле юк. Кичәге көндә син инде юк. Син гел бүген генә яшисең һәм өметең дә синең бүгенге көнеңдә генә туарга мөмкин.

Хәйдәрнең могҗизаларга һичкайчан ышанганы булмады, вәләкин бу көннәрдә аның: «Нәрсә бу? Нигә? Нишләргә?» дигән сорауларга җавап табар өчен акылының аръягы белән бәйләнешкә керү ихтыяҗы туды.

Кеше, авыр чакта гайре табигый ярдәм эстәп, вакытның мизгелләренә таянырга тели, хәлбуки һәр мизгелнең сәбәбе аннан алда балкыган мизгелдә, ягъни һәр сәбәпнең үз сәбәбе була икәнне еш кына онытып җибәрә ул.

Мәгәр нинди генә сынаулар язмасын, барысының да чиге, азагы була, һичнинди газап, үлем түшәгенә яткырган сурәттә дә, гомернең үзеннән дә озаграк дәвам итми, чөнки кайгы-хәсрәтләр килгәнче һәркемнең яшәешендә барыбер сәгадәтле көннәре дә була бит.

Һәрхәлдә, тәкъдиреңә ни генә язылмасын, барыбер иң озакка сузылган сынау – гомер үзе инде ул!

Хәйдәр үлемнән курыкмый. Бу көннәрдә ул: «Күпме яшәп, бу дөньядан берни аңламый китеп барам бит... – дип хафалана. – Әйе, эштә абруй казандым, кызым яхшы кешегә кияүгә чыкты, оныгым бар. Шушы

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан уткәрелгән конкурсның «Роман» номинациясендә 1 урынны алган әсәр.

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) – *драматург, прозаик. Татарстанның халык язучысы. Дистәдән артык китап, иллегә якын пьеса һәм күпсанлы җырлар авторы. Казанда яши.*

гынамыни?.. Азмы?.. Шуның өчен генә яшәдем микәнни?.. Ә галим буларак нәрсәләр кырдым?.. Фән белән генә шөгыльләнәсе урынга, хөсетләр, булдыксызлар белән көрәшеп, күпме вакыт, күпме көч, күпме сәламәтлек сарыф ителде!»

Күп еллар Мәскәүдә яшәп, фәнни эзләнүләр институтында эшләде, фәннәр докторы булды. Ә бит ул югарырак максатлар өмет иткән, зуррак казанышларга омтылган иде. Хәер, иң уңышлы кеше дә үз-үзеннән тәгаен канәгать булмыйдыр инде. Башкалардан, тирә-яктагы мохиттән, гомумән, чынбарлыктан гаеп эзләү дә – үз-үзеңнән канәгать булмауның әверелеше ләбаса.

Хәйдәр институт белән килешү нигезендә эшли башларга теләк белдергәч, җитәкчеләр тарафыннан моңа каршы килүче булмады. Аны җиде-сигез елга сузылырлык эш белән тәэмин иттеләр, бу хезмәтеңне кайда башкарсаң да ярый, вакытында тапшыру гына таләп ителә дип куандырдылар, һәм Хәйдәр Казанга кайтырга карар кылды. Тормыш иптәше Гөлсинә, тумышы белән Лаештан булса да, Мәскәүдә калырга өндәде. Гөлсинә, үзсүзле буларак, һәрдаим үз киресен сукалады инде ул. Хәйдәрнең хатын ягындагы туганнар белән аралашмавы да Гөлсинә аркасында иде.

Табиблар тарафыннан сәламәтлеге хакында яман хәбәр алгач, Хәйдәр хатынының җитешсезлекләрен аеруча күбрәк барлый башлады. Бәла килгәч, кеше башкаларда гаепне күбрәк күрә, күренмәгән суратта, эзләргә һәм табарга тырыша инде ул. Хәйдәр үзенең бүгенге халәтен яхшы аңлый, узган гомеренә дә аек акыл белән карап, дөрес бәя бирә, әмма ничек кенә карасаң да, артта калган уртак тормышка күз салгач, Гөлсинә белән яшәү җиңел булды дип әйтерлек түгел иде.

Акыллы кеше буларак, Хәйдәр: «Моңа берьяклы гына карау да дөрес түгелдер. Гөлсинәгә дә минем белән гомер йөген сөйрәү җиңел булмагандыр», – дип тә уйлап куя. Ярар, яшәдек, дөресрәге, яшәлде бит инде... Куанырлык нәрсәләр дә юк түгел ләбаса. Бердәнбер кызлары Лилия Назим исемле Мәскәү татарына – акыллы, тәпле, эшмәкәр егеткә кияүгә чыкты. Хатын-кызның бәхете ирдән бит инде аның. Аллага шөкер, Лилия ирдән уңды. Оныкы, бик башлы малай, быел аңа унике яшь тула, төскә-биткә Хәйдәрләр ягына охшаган, холкы – әтисенеке, ягъни «мәскәүски-мишәрски», димәк, ул яктан да тәртип, тормышта югалып калмаячак.

Әйе, гаилә тормышы җайлы бармады, Гөлсинә белән хәтта аерылышып торган вакытлары да булды. Институтның китапханәсендә, җиңел вазифада эленке-салынкы гына эшләп йөргән хатынга гел нидер җитмәде, ник кыбырсыганын хәтта үзе дә төгәл аңлап бетерми иде бугай ул.

«Ә тирәнрәк уйлап баксаң, һәрберебез эгоист инде. Минем җаным-тәнем белән фәнгә бирелеп яшәвемнән Гөлсинә дә ләззәт алырга тиеш идемени?.. Ярлы яшәмәдек анысы, акчага кытлык кичермәдек, әмма яшәү ямен табу хәлебездән килмәде. Һәм кемгә, нәрсәгә хезмәт иткәнемне дә аңламыйм...»

Ул гел туган җирен, Татарстанны сагынып, Казанга кайтасы килеп яшәде.

Ниһаять, кайтты Казанга.

Әмма сиңа язган бәла, кайда яшәсәң дә, синеке инде ул...

«Урын өстендә, үләмәт хәлдә кеше күзенә карап ятарга туры килсә, нишләрсең... Гомер буе сине чукып яшәгән хатын кулына калу ихтималы нык куркыта, котны ала. Дөрес, һәр чарасызлыктан чыгу юллары бар.

Тупыйкка килеп төртелгәч тә, синдә сайлау иреге кала лабаса. Эвтаназия... Суицид...»

Туктале, нинди уйлар бу?! Бу – котылу түгел бит.

Шундый куркыныч диагноз куйдылар, ә мин узган гомеремнең ир-хатын мөнәсәбәтләрендә казынып утырам. Югыйсә үзе галим, акыл хезмәтен яшәвенең мәгънәсе итеп йөргән кеше. Караңгы уйларның тирәнрәкләре дә бар бит әле.

Үз халкына ярдәме тидеме соң аның? Олыгайган саен күңел үз милләтенә ныграк тартыла, җан иң якты учак та, бернинди газ казаны да, һичнинди җылыткычлар да бирә алмый торган җылылык сорый. Һәр күзәнәгеңә якын туган телең, шул телдә сөйләшүче кешеләр генә бирә ала торган җылылык кайдадыр бар бит. Кызы татарча сыкы-быкы гына сөйләшә, кияү бөтенләй белми диярлек, ә оныкны һич өйрәтә алмыйлар.

Әмма минем бу хакта һичтуктаусыз кайгыруым нәрсәне үзгәртә ала, минем мондый борсалануымның фәтвасы бармы соң?

Паникамы бу? Нишләдем мин?..

Бер профессорның күптән инде әйткәне бар иде: «Тормышта үзеңә каршы барырга ярамый. Үзенә хыянәт итеп, үзенә хас булмаган рольне уйнарга тырышып, һәрдаим үзенә каршы килеп, минлегеннән читләшеп яшәүче кеше әллә нинди яман авыруларга дучар булырга мөмкин...»

Ә бит Хәйдәр ничәмә еллар буе үз-үзенә каршы килеп яшәде. Үз фикерен әйтергә мөмкинлекләре күп булдымы? Уй-ниятләренең күпмесен гамәлгә ашыра алды? Үз фикерен әйткән очракта да, аны бик сирәк хупладылар түгелме? Үзенең хаклы икәнен ничә тапкыр исбатлый алды соң ул?

Көзге каршына килеп басты – көзгедән аңа ап-ак чырайлы берәү карап тора иде. Хәйдәр үзенең сүренке кыяфәтеннән хәтта сискәнеп китте һәм шундук барлык буталчык уйларны җил себереп аткан кебек булды. Өстәлдәге кан анализлары кәгазьләрен ул инде әллә ничәнче кат алып карады – һәр пунктта тайпылыш язылган, һәр күрсәткеч норма чикләреннән чыккан. Йөргәндә, хәл бетә, температура югары...

Шунысы гаҗәп: куелган диагноз турында гына уйлый башлагач, башка кайгылар шундук юкка чыга. Бәлки, төрле-төрле, бер-берсенә һич кенә дә бәйләнмәгән проблемаларның калкуы әйбәттер, бәлки, бу – яман чир газабыннан вөҗүдеңнең саклану чарасыдыр?..

## 2

Аны хастаханәнең гемотология бүлегенә салдылар. Җәй уртасының бик эссе көннәре, палатада суларлык түгел, һава җитми иде.

«Миелобластная лейкемия» – беренче куелган якынча диагноз шул иде. Сөяккә пункция ясап, Казанда лаборатория булмау сәбәпле, алынган җелек тукымаларын, төгәл диагноз куяр өчен Мәскәүгә курьер белән озаттылар. Генетик-цитология анализны шунда ясап, бер атнадан нәтиҗәләрен Казанга җибәрәчәкләр, имеш.

Көннәр уза торды, хәл начарая барды. Әлегә мондагы табиблар тарафыннан бернинди җиңеләйтә торган чаралар, дарулар тәкъдим ителмәде. Әгәр Мәскәүдән анализлар соңарып килсә?.. Әле бит төгәл диагноз да билгеле түгел.

Беркөнне Хәйдәр, пункция ясаган табибәне коридорда очратып, үзенең анализларына кагылышлы сүз башлады. Табибә, урта яшьләрдәге мөлаем йөзле ханым, аның сорауларын ахырга кадәр тыңлап тормады һәм як-ягына карап алды да үз фикерен ачыктан-ачык әйтеп салды:

– Мөмкинлегегез булса, дәваланырга Германиягә барыгыз.

– Әле диагноз ахырынча билгеле түгел бит, – диде Хәйдәр, бу гүзәл ханымның шундый көтелмәгән тәкъдим ясавына гаҗәпләнеп.

– Лейкоз инде сездә, анысында шик юк. Нинди формада икәнен генә әлегә төгәл белмибез, аның морфологиясен ачыклыйсы бар. – Табибә пышылдауга күчте. – Мөмкинлегегез булса, чит илгә барыгыз, шунда төп-төгәл диагноз куярлар, шунда дәваларлар.

– Ә үзебездә мондый чирне дәвалый алмыйлармыни?

– Без дә дәвалыйбыз. Дәвалау схемасы, тактикалары да чит илләрдәге кебек. Әмма шунысы бар – аларда химиотерапия өчен куллана торган препаратлар – оригиналь, үз клиникалары өчен үзләре җитештерәләр. Ә бездә аналоговый препаратлар. Аерма шунда гына. Үзегезгә карагыз.

Хәйдәр палатага кереп, караватка чалкан яткач, түшәмнең ак түгел, кызгылт төстә икәненә аптырап китте. Нык каушаудан бу. Табибәнең тәкъдиме куркытты. Әмма аның турыдан-туры, ихластан, дөресен әйтүе бик әйбәт. Нишләргә?.. Түшәм янә ак төс алгач, Хәйдәр катгый карарга килде – кичектермичә, Алман иленә юл тотарга кирәк. Германиягә!

Бу нияттән аңа хәтта бераз хәл кергәндәй булды, җанланып китте, соңгы вакыттагы чарасызлык хисе юкка чыкты. Хәйдәр, кесә телефоныннан кияве Назимга шалтыратып, кыскача гына мондагы хәлләрне аңлатканнан соң:

– Әле диагноз икеле-микеле, әмма лейкозга охшаталар, – диде. – Острыйдырмы, хроническийдырмы – Мәскәүдән хәбәр итәчәкләр. Миңа аннан хәбәр килгәнне көтеп ятарга түгел, Германиягә китәргә кирәк.

– Аңладым, – диде Назим. – Мин хәзер үк Европаның төрле клиникалары белән элемтәгә кереп, мәгълүматлар алырмын.

Назим, кичектермичә, телефоннан Татарстандагы дуслары белән киңәшләшеп, Казаннан Германиянең кайсы клиникасына ешрак йөриләр икәнне белеште. Дюссельдорфтан ерак түгел урнашкан Мюльхайм-ан-дер Рур шәһәрчегендә урнашкан «Панмедика» клиникасына Казаннан дәваланырга йөрүчеләр шактый икәнне мәгълүм кылгач, ул шундук әлеге дә баягы клиника белән элемтәгә кереп сөйләште һәм алардан рәсми чакыру сорады.

Монда куелган якынча диагнозның күчермәсен клиникага җибәргәч, күп тә үтмәде, Германиядән җентекле диагностика өчен түләнергә тиеш сумманы хәбәр иттеләр. Назим аларга акчаны күчергәннән соң, икенче көнне алман телендә язылган чакырунамә Хәйдәр исеменә килеп тә җитте. Шуннан соң Назим һава юлына билетлар алды – Казаннан Мәскәүгә, Мәскәүдән Франктфуртка, чөнки Дюссельдорфның үзенә рейслар юк иде.

Билетлар алган көнне Хәйдәр, хастаханәнең үзе яткан бүлек табиблары белән хушлашып, өйгә кайтып китте һәм ерак юлга җыена башлады.

Назим белән Лилия аны Шереметьево аэропортында каршы алдылар һәм, Хәйдәргә тынычланырга, төшенкелеккә бирелмәскә кушып, Германиягә озатып калдылар.

Самолёт күккә күтәрелгәч, бераз тынычланып, йоклап булмасмы дип уйлаган иде дә, юк, күзгә йокы кермәде.

Хәйдәр Җир белән Күк арасында язмыш алган курс буенча очты.

Җир аста. Күк өстә. Ә ул – үзендә. Хәзер ул, чын мәгънәсендә, Җир белән Күк арасында иде.

Яшәү белән үлем арасында. Җирдә басып торганда да, шул ук халәт ләбаса. Һәрбер кеше, чирлесе дә, сәламәте дә – гел ике арада.

**3**

Франкфурт-на-Майне аэропортында, төрле тикшерүләрне үткәннән соң, коридор башындагы стойка янында туктап, Хәйдәр як-ягына карады. Аның исем-фамилиясе язылган такта тотып, таксист көтәчәк дигәннәр иде, әмма каршы алучы күренмәде һәм Хәйдәр шактый вакыт, кая барырга белмичә, адашып йөрде.

Ниһаять, озак кына аймылыш булып йөргәннән соң, алар очраштылар. Таксист, утыз биш-кырык яшьләрдәге ир-егет, милләте буенча төрек, Хәйдәрне эзләп йөри-йөри тирләп чыккан иде. Ничек эзләгәнен төрекчә сөйли-сөйли, таксист аны машинасы янына алып китте.

Тип-тигез юлдан «Мерседес» офыкка таба юл алды. Табигать нәкъ бездәге кебек икән монда. Дюссельдорфка ике йөз километр чамасы, аннан Мюльхаймга тагын утыз-кырык километр барырга кирәк иде. Таксист Хәйдәрнең каян килүе белән кызыксынды, аннан соң тагын берничә буш сорау бирде, әмма Хәйдәрнең сөйләшергә теләге юк икәнне күреп, барып җиткәнчегә кадәр бүтән бер сүз дә катмады.

Юлда чакта Хәйдәрнең телефоны зеңгелдәде. Гөлсинәнең әчкелт тембрлы тавышы Татарстан белән Германия арасын мизгелләр эчендә үтеп, Хәйдәрнең колагына килеп керде:

– Сиңа Лилияләр шалтыраткан булганнар, ә син җавап бирмәгәнсең, – диде хатыны шелтәле тавыш белән.

Хәйдәрнең, мөгаен, ара ерак булгангадыр, хатынына аз гына да ачуы килмәде.

– Димәк, җавап биререгә мөмкинлегем булмаган, – диде ул битараф тавыш белән. – Димәк, самолётта очканда, телефон сүнгән вакытта шалтыратканнар.

– Барып җиттеңме әле?

– Юк әле. Барып җиткәч, үзем хәбәр бирермен, – дип, Хәйдәр телефонын сүндерергә ашыкты.

«Нишләп соңгы көннәрдә өйдә җылылык бөтенләй юкка чыкты?.. Өге-җөге килеп яшәмәсәләр дә, аралары хәзерге кебек үк салкын түгел иде бит... Нишләп менә хәзер аның белән хәтта сөйләшәсем дә килмәде? Каты авырып, урын өстендә ята калсам, Гөлсинәгә ышаныч булмаячакны сиземләүдәнме?..»

Дюссельдорф янындагы Мюльхайм ан-дер-Рур шәһәрчегенә такси шуып кергән кебек булды. Юллар тигезлегеннәнме бу, машинаның затлылыгыннанмы, шофёрның машинаны оста йөртүеннәнме, әллә... дөнья авазларына илтифатсызлыктанмы һәм дөньядан ваз кичү галәмәтеме?.. Әллә инде ул хәзер ишетмиме, күрмиме?

Юк, исән әле ул! Йөрәк турысы авыртып куя, күкрәккә пресс баскан кебек, сулавы авыр, тәндә тир бәреп чыкты. Болар үлгән кешегә хас түгел бит инде...

«Панмедика» клиникасына җитәрәк, таксист телефоннан тәрҗемәче кыз белән элемтәгә керде һәм килеп туктаганда, аларны көләч йөзле чибәр кыз каршы алды. Бу кыз – Катерина исемле утыз биш яшьлек яшь хатын булып чыкты. Ут чәчеп торучы, уртадан кечерәк буйлы, төс-битне алманнардан, буй-сынны руслардан алган бу тәти зат милләте буенча яртылаш рус, яртылаш алман иде. Ире дә икеканлы икән, икесе дә Идел буе немецларыннын, әби-бабаларын кайчандыр Казакъстанга сөргәннәр. Икесе дә, узган гасырның туксанынчы елларында Германиягә чакыру игълан ителгәч, монда күченгән гаиләләрдән икәннәре соңрак мәгълүм булды.

Русча да, немецча да камил вә матур сөйләшүче кыз (зәңгәр күзле, томшык борынлы, күперчек иренле бу гүзәлне барыбер хатын дип түгел, кыз дип әйтәсе килә иде) инде күптәнге якын танышын каршы алган сыман тотты үзен.

– Исәнмесез. Ничек килеп җиттегез? – диде ул, болай да якты җәй көненә нур өстәп.

– Исәнмесез. Рәхмәт. Сезнең догалар белән килеп җиттем менә, – диде Хәйдәр. – Килеп төшкәч, аэропортта адашып йөрергә генә туры килде.

– Сезгә паспорт контроленнән чыккач, бер урында гына торырга иде. Таксист бит үзе сезне эзләп чабып йөргән.

– Хәзер кая барабыз? – диде Хәйдәр, як-ягына каранып.

Катерина:

– Әйдәгез, палата әзер, – дип, клиниканың пыяла ишегенә ишарәләде.

– Бер сигарет тартыйм инде, – диде Хәйдәр үтенечле тавыш белән.

– Тартыгыз, тартыгыз, – диде Катерина сабыр тавыш белән.

Ни гаҗәп, Хәйдәр тынычланып китте. Менә бит, Алман иленә килеп тә җитте ул. Каршы алдылар, палата әзер. Хәзер инде Казандагы кебек билгесезлектән кот алынып ятышлы түгел. Тиз арада тикшерерләр, диагнозны төгәл белерләр...

– Рак булмаска да мөмкин бит әле, әйеме? – диде Хәйдәр, тәрҗемәче кызга өмет белән карап.

– Каян белим инде мин, – диде Катерина, көлемсерәп. – Анализларыгыз күрсәтер.

– Сез тәрҗемәче генә түгел бугай?

– Мин Россиядән килүче пациентлар белән элемтәгә керәм, килү-китүләрен оештырам, чакырулар җибәрәм һәм тәрҗемәче вазифасын да башкарам. Белүемчә, сезгә тәрҗемәче кирәк булмаячак. Нимесчә әйбәт сөйләшәсез, диделәр.

– Юк инде, кирәк булырсыз, – диде Хәйдәр. – Мин алман телендә хәйран яхшы сөйләшәм, әмма камил дәрәҗәдә үк дип әйтә алмыйм. Шуңа эч поша әле – мин җиңелчә генә килдем, әйбер-мазар күтәреп йөрмәдем. Дәвалану курсы озакка сузылса, алмашка минем кием-салым юк...

– Борчылмагыз. Казанда куелган диагнозыгыз расланып, бездә озак ятарга туры килсә, мин сезгә кибеттән киемнәр сатып алырмын.

Хәйдәр Катеринага елмайды һәм ярым шаярып:

– Әйдәгез, берәр ресторанга, – диде.

Уйнап кына әйтелгән бу тәкъдимне Катерина бик җитди кабул итте һәм күз алмаларын киңәйтеп:

– Сез нәрсә! Нинди ресторан! – дип гаҗәпләнде. – Беләсегез килсә, минем ирем, ике балам бар, – диде ул һич кенә дә үпкәләмичә. – Үзегез көчкә басып торасыз... Тәмәкегезне тартып бетерәсез дә хәзер үк палатага кереп ятасыз! Тәмәке тартуыгызны монда ташларга кирәк булыр инде, – дип өстәп куйды ул.

– Бик ташларга иде дә бит, – диде Хәйдәр. – Хәзер үк ташласам, акылдан язмам микән... Бик куркыныч диагноз бит.

– Монда сезгә бернинди дә диагноз куймадылар бит әле.

– Казан табиблары әйтте бит инде. – Катерина әйткән сүзләрдән Хәйдәрдә кинәт өмет кабынды. – Әллә рак булмаска да мөмкин микән? Казанда ялгышулары да бар бит...

– Монда җентекләп тикшерелерсез, аннары күз күрер. Әйдәгез, керәбез.

Бер урынлы палата пөхтә, якты булса да, аның караваты, әллә нинди лампалары, гомуми җиһазларының барлык детальләре гаять авыр тәэсир итте.

Хәйдәр үзе белән ике портфель генә алган иде, аларны почмакка куйды да караватка ауды һәм шундук йокыга китте. Ике сәгать чамасы йоклаганнан соң, ул уянып китте. Беләктән кан алганнар, ахрысы – тампон ябыштырылган, уколлар да кадаганнар бугай. Ә ул сизмәгән, каты йоклаган.

Хәйдәр уяу килеш озак ятмады, янә йокыга китте.

## 4

Иртәнге якта, коридордагы тавышлардан уянып, Хәйдәр беркавым аңышмый ятты – кайда ул, нинди урын-җир бу?

Ә-ә-ә, ул бит инде Германиядә. Казаннан Мәскәүгә, аннан Германиягә самолётта очты. Франкфурттан Дюссельдорф янындагы шәһәрчеккә төрек кешесе такси белән алып килде. Катерина исемле кыз каршы алды.

Олы гәүдәле хатын, ишек катыннан ук сәламләп, поднос белән иртәнге ашны кертте. Ризык әйбәт, әмма андый ризыкка күнекмәгәнлектән, Хәйдәр ашый алмады, чәй генә эчте. Туалетка кереп чыккан арада палатада базык гәүдәле, кысык күзле, алман кешесенә һич кенә дә охшамаган агай, затлы одеколон исен аңкытып, аны көтеп тора иде.

Клиниканың җитәкчесе доктор Отто Гофман илле биш-алтмыш яшьләр тирәсендәге доктор, бик тере, хәрәкәтчән кеше иде. Ул бер урында гына басып тора алмый шикелле иде. Сөйләшүе дә кызу-кызу, сорауларны, никтер, күбрәк идәнгә карап, бер-бер артлы яудыра, хәтта җавап биреп җитешеп булмый иде.

– Ничек урнаштыгыз? Мондагы шартлар сезгә уңаймы? Зарларыгыз, тәкъдимнәрегез, сорауларыгыз бармы? – дип сорады Отто Гофман.

– Монда бик уңай, бөтен шартлар бар, – диде Хәйдәр.

– Хәлегез ничек?

– Хәл әйбәт түгел инде, – диде Хәйдәр сүренке тавыш белән.

– Берәр җирегез авыртамы?

– Юк алай. Гомумән, халәт авыр... аңлатып булмый торган халәт...

– Сөяк җелегенә пункция ясап, кирәкле анализларны тикшергәч, барысы да аңлашылыр, аннары күз күрер. Берничә көннән төгәл диагноз куелачак инде, шуннан соң баш врач керер.

– Казанда куелган диагноз дөрес булмаска мөмкинме? – дип сорады Хәйдәр доктордан, «Әйе, ялгышулары ихтимал», – дигән җавапны ишетәсе килеп.

– Хәзер әле бернәрсә дә әйтә алмыйм, – диде Гофман, ниһаять, пациентка туры карап. – Безнең баш табибыбыз Ян Шредер, вакыты җиткәч, барысын да аңлатыр.

Берничә көн узгач, кичкырын әле Ян Шредер түгел, башта чандыр гәүдәле, тартынкы битенә киң кысалы күзлек кигән табибә-ассистент, үзе белән Катеринаны ияртеп керде. Аларның икесе дә үтә җитди кыяфәтле булганнан Хәйдәр аңлады – димәк, нәкъ менә хәзер төгәл диагноз игълан ителәчәк.

Кечкенә өстәл артына табибә белән кара-каршы утырганда, Катерина алар янында басып торды.

Табибә сүзен:

– Сездә нинди авыру икәнне беләсезме? – дип башлады.

– Острый лейкоздыр... – диде Хәйдәр чак кына ишетелерлек итеп. – Казанда шулай дигәннәр иде.

Хәйдәр әле һаман: «Юк, Казанда ялгышканнар», – диюләрен көтә иде. Әмма табибә коры тавыш белән:

– Әйе, кызганыч ки, сездә острый лейкоз, – диде. – Кичектермичә дәваланырга кирәк. Хәзер дәвалый башламаган очракта, сезгә яшәргә нибары дүрт атна гына кала.

– Дәвалап буламы соң аны? – диде Хәйдәр, әле генә ишеткән хәбәргә шундук күнеп.

– Без шул дәвалау белән шөгыльләнәбез бит инде. Дәвалану курсы шактый озакка сузылачак. Алты ай дәвамында сез монда ятарга тиеш булачаксыз, бәлки, сигез айга ук сузылыр. Чөнки дәвалау курслары алты өлешкә бүленә, алты цикл химиотерапия ярты ел вакытны таләп итә... Артыграк та кирәк булырга мөмкин. Кимрәк булырмы, күбрәкме – анысы сезнең хәлегездән, сезнең алга таба булачак анализларыгыздан тора. Кыскасы, организмыгызның ни кадәр нык булуына бәйле. Сез дәваланырга әзерме?

– Әзер, – диде Хәйдәр. – Шуңа үзем монда килдем бит инде.

– Финанс мәсьәләләрен доктор Гофман аңлатыр.

Хәйдәр Германиягә килгәнче үк үзен борчыган сорауны бирде:

– Никадәр акча кирәк булыр икән?

Доктор шундук күпме акча кирәк булачагын әйтеп тә бирде. Хәйдәр эчке сискәнү тойды – дәвалау өчен билгеләнгән сумма коточкыч зур булып чыкты һәм ул беравык һушсыз калып торды. Әмма инде артка чигенү юк иде, ул, ризалыгын белдереп, баш какты.

Доктор үзе белән бер папка кәгазьләр алып кергән иде. Катерина белән икәүләшеп аңлата-аңлата, Хәйдәрдән шул кәгазьләргә кул куйдырдылар. Алар чыгып китү белән үк Хәйдәр хатынына да түгел, кызына да түгел, ә киявенә шалтыратты. Күпме акча кирәклеген әйткәч, Назимның тавышы

да кинәт сүлпәнәйде, бу кадәр үк кыйммәткә төшәр дип ул да көтмәгән иде.

Алай да, кияү, рәхмәт яугыры:

– Җыярбыз ул сумманы, – дип җавап бирде. – Өчкә бүлеп күчерергә мөмкин түгел микән?

– Сорармын, сөйләшермен, – диде Хәйдәр, җанланып. – Мөмкин булыр дип уйлыйм.

Аннары Хәйдәр хатынына шалтыратты. Гөлсинә сыктанулы тавыш белән: «И Ходаем, и Ходаем», – дип, кат-кат кабатлап шыңшыды. Акчаның бу кадәр күп кирәк булачагы, әлбәттә, хатынны тирән кайгыга батырды.

Төнлә озак йокыга китә алмый ятса да, бүген җан тынычланып китте. Билгесезлек авыррак баса бит ул. Хәзер исә инде ачыклык кереп килә, алга таба нишләргә кирәклеге анык аңлашыла иде.

Иртәнге аштан соң, клиниканың иң өлкән табибы приват-доцент Ян Шредер – озын буйлы, чын алман кыяфәтле, урта яшьләрдәге ир-егет – үзе белән берничә табибәне ияртеп керде дә башта хәлне сорады, Хәйдәрнең үзен ничек хис итүе белән кызыксынды. Аннары шактый озын-озак итеп, Хәйдәргә куелган диагноз турында сөйләде.

Сүз ахырына таба Шредер көр тавыш белән:

– Сезнең очракта прогноз яхшы, – диде. – Без сезне дәвалый алачакбыз. Сезнең анализларны җентекләп өйрәндек. Анализларыгызда берничә бик уңай фактор бар. – Шуңа күрә мин алдан ук ышандырып әйтә алам: прогноз яхшы. Дәваланырга монда килеп, дөрес эшләгәнсез.

Аннары доктор дәвалау курсының ничә өлештән торачагын, нинди графиклар буенча ясалачагын сөйләде. Акчаны өчкә бүлеп түләргә мөмкин дип, ризалыгын бирде.

Икенче көнне үк Хәйдәрнең муенына катетр куйдылар һәм ул, көзге каршына килеп баскач, муеннан астарак, өңер кырыеннан түбән таба Яңа ел чыршысындагы гирлянда сыман, нәзек көпшәләр эленеп торганын күрде.

Һәм химиотерапия курсының беренче өлеше башланды.

Ике тәүлек буена берөзлексез муендагы катетр аша дару тамып торды. Һичөзлексез баш әйләнде, укшытты, атна буе авыздан кан килде, аяклар утын тумраны кебек юанаеп шешенде. Авызда җәрәхәтләр барлыкка килде, тамактан ашау үтми башлады. Бу халәт вакытлыча, түзәргә кирәк, диделәр аңа. Түзми кая барасың. Тәмәке тартмыйча гына түзеп булмады. Урамга чыгарга ярамый, ә клиникада тәмәке тарту катгый тыела. Соңгы вакытта ул айкос стиклары тарта башлаган иде, Германиягә дә үзе белән егерме төргәк алып килгән иде. Палата туалетының һава суыру системасы яхшы эшләүдән файдаланып, Хәйдәр яшертен генә стикларын шунда кереп тартты һәм аның мондый «хулиганлыгын» дәвалану курсының ахырына кадәр беркем белмәде, сизмәде.

Беренче цикл тәмамланганнан соң, канның барлык күрсәткечләре түбәнәйде, кайберләре нольгә кадәр үк төште, хәл бөтенләй бетте. Ә табиблар: «Шулай булырга тиеш, куркыныч нәрсә юк, химия шулай тәэсир итә инде ул, түзәргә кирәк, озакламый хәлегез яхшырачак», – дип тынычландырып, көн саен кан тамырына кан агыздылар, антибиотиклар тамызып тордылар.

## 5

Хәйдәргә ясалган пункциянең нәтиҗәләрен Шредер үзенең укытучысы һәм коллегасы Винфрид Мейерга да күрсәтергә булды. Профессор Винфрид Мейер Берлинда Шаритэ клиникасында хезмәт итә, Шредер анда укыды һәм үзе дә Шаритэдә шактый вакыт остазы белән бергә эшләгән иде. Шредерне «Панмедика»га баш доктор итеп килергә бик озак ялынганнан соң күндергәннәр иде. Гадәттә, җитди диагнозлар буенча ул үзенең укытучысы һәм остазы белән сөйләшә, хәтта анык аңлашылган вакытта да, хата китүгә юл куймас өчен абруе дөньяга таралган профессор белән киңәшләшеп ала иде. Бу юлы да ул «ватсапп» аша Хәйдәрнең анализларын аңа җибәрде.

Доктор Винфрид Мейер шундук пациентның фамилиясенә һәм каян килгәненә игътибар итте: «Гарипов Хәйдәр. Россиядән. Казаннан. 1958 елда туган.» Әтисенең исеме ничек икән?.. (Германия хастаханәләрендәге кәгазьләрдә, бланкларда, гадәттә, пациентның атасы исемен язмыйлар.)

Анализ нәтиҗәләрен ул игътибар белән карап чыкты. Диагноз төп-төгәл. Афәрин, Шредер! Аның диагнозларны бөтен нечкәлекләре белән куя алуы гаҗәпләндерми, ул – шәп доктор. Үз эшен яхшы белсә дә, киңәшләшә, чак кына хата китүдән дә саклана – менә шунысы сокландыра һәм куандыра. Студент чагында ук аның тирән акыллы табиб булачагы күренеп тора иде инде. Аның белән көн буе сөйләшеп утырырга мөмкин, туйдырмый, ялыктырмый. Укучысы булса да, Мейернең аңа әллә ничә тапкыр әйткәне бар: «Мин синең белән әңгәмә корганда, укытучың булсам да, синнән бик күп нәрсәләрне беләм, бик күп нәрсәләргә күзләрем ачыла. Менә шундый докторлары булганга Германиядәге медицина алдынгылардан санала бит. Бу зур нәрсә!»

Җәй Германияне кочагына алган. Табигатьнең бу фасылында бөтен дөньяда җәй җиткәндер шикелле тоела башлый. Кеше шундый инде ул – шатлык килсә, башка кешеләр дә шат булырга тиеш кебек була, бәхетле чакта – бөтен дөнья бәхетледер дип ышана. Әмма шунысы сәер: кайгы килсә, кеше үзе генә бәхетсез, ә башкалар рәхәт чигәдер дип уйлый башлый.

Винфрид кабинетның киң тәрәзәсеннән тышта кайнаган җәйге хәятне күзәтеп, әтисен искә төшерде.

Әтисе – Ортвин Мейер – җәй фасылын җаны-тәне белән ярата һәм бу вакытта бөтенләй икенче кешегә әйләнә иде. Винфрид әтисенә охшаган һәм үзен дә табигать баласы дип атый. Ул озакламый ял алачак, бер ай буе урманда, кайчандыр әтисе төзегән мәһабәт йортта цивилизациядән котылып торачак. Тизрәк җитсен инде ул көннәр!

Авыр еллар туры килгән әтисенең яшьлегенә. Сугыш үзе генә ни тора...

Гарипов Хәйдәр... Шул кеше микән? Казаннан бит... Татар... Әтисе кайсы фронтларда сугышты икән?..

Винфрид ял көне җиткәнне түземсезлек белән көтте һәм шимбәнең яп-якты иртәсендә Берлиннан үз машинасында, Мюльхайм-ан-дер-Рур шәһәренә юл алды. Машина йөртеп, биш йөз илле километр бару гәүдәне генә алҗыта, ә баш исә ял итә, бигрәк тә яхшы музыка яңгырап торганда.

Мюльхайм... Чирәп түбәләр, таш түшәлгән урамнар. Төньяк Вестфалия федераль җиренең Дюссельдорф административ округында урнашкан бу шәһәрчек кульязмаларда 1093 елда телгә алына. Хәзер монда йөз җитмеш

меңгә якын кеше яши, туксан проценты алманнар, нигездә, католиклар, протесттантлар. Ярата ул мондый шәһәрчекләрне. Җыйнак шәһәрнең җаны җылырак, күңеле киңрәк була.

Мюльхаймда Казаннан килгән пациентны күрергә теләвен шалтыратып хәбәр иткәч, Ян Шредер, ял булуга карамастан: «Клиникага килеп, сезне каршы алам», – дигән иде, Винфрид Мейер исә аңа: «Юк, юк, ял ит, аның янына үзем генә кереп чыгам!» – дип, кырт кисте.

Профессор Винфрид Мейерны Германиядә белмәгән берәр медик бар микән? Юктыр, мөгаен. Аның даны ил чикләреннән чыгып, Европага, аннан океан артына кадәр үк таралган инде.

Клиниканың сигезенче катында аны күргәч, бөтен медперсонал каушады, ә инде сигез йөз беренче палатада ятучы Гарипов фамилияле пациент белән кызыксынгач, бигрәк тә аптыраашта калдылар.

Хәйдәрнең, караватта утырып, телефон аша интернетта «казынган» чагы иде. Ишекне киереп ачу белән үк сәламләп, Винфрид Мейер палата түренә узды һәм өстәл янындагы урындыкка утырды.

– Минем исемем Винфринд Мейер, – диде ул, Хәйдәрне җентекләп күзәтеп. – Мин Шаритэ клиникасыннан. Профессор. Монда минем дустым доктор приват-доцент Ян Шредер эшли. Ул миңа сезнең анализларны җибәргән иде һәм минем сезне күрәсем килде.

– Хәлем мөшкелме әллә? – диде Хәйдәр, бөтен дөньяга танылган Шаритэ профессорының килүеннән шомраеп.

– Юк, киресенчә, прогноз яхшы, – диде профессор. – Мин кайвакыт Ян Шредер дәвалый торган пациентлар белән аралашам. Ул миңа сезнең турыда сөйләде. Сезне бик зыялы, акыллы кеше, галим, диде. Сез Казаннан икән...

– Әйе.

– Сез татармы?

– Татар.

– Болай... хәлегез ничек?

Хәйдәр көлемсерәгән сыман итеп:

– Мондый диагноз куелгач, хәлемне ничек дип әйтергә соң инде? – диде.

– Паникага урын булмаска тиеш, – диде Винфрид Мейер. – Ә химия алганнан соң, хәзерге халәтегез – табигый хәл. Шулай булырга тиеш инде, кызганычка каршы. Мөгаен, Шредер сезгә әйткәндер – анализларыгыз нәтиҗәсеннән аңлашыла – сезне дәвалап була икәнне күрсәтә торган бик мөһим факторлар бар.

– Әйе, доктор Шредер шулай дигән иде.

Профессор Мейер, тагын нинди сорау бирим икән дигән сыман, аскы иренен тешләп торганнан соң:

– Без аның белән гел элемтәдә, – диде. – Ул минем укучым гына түгел, якын дустым да. Үзара даими рәвештә киңәшләшеп торабыз. Сезгә монда уңайлымы? Палатадан канәгатьме сез?

Хәйдәр Шаритэ профессорыннан үзенең диагнозы турында көтелмәгән яңалык ишетермен дип уйлаган иде, ә аңа Винфрид Мейернең гап-гади сорауларына җавап бирергә туры килде:

– Әйе, әйе, бик уңай, бик әйбәт палата, – диде Хәйдәр.

Профессор, көтмәгәндә:

– Сезнең әтиегезнең исеме ничек? – дип сорады.

– Самат.

– Димәк, әтиегез – Гарипов Самат?.. – дип текәлеп карады Винфрид Мейер.

– Әйе, Гарипов Самат. 1968 елда вафат булды, – дип көрсенеп куйды Хәйдәр. – Миңа ун яшь иде ул вакытта.

Винфрид: «Икенче Бөтендөнья сугышында катнашканмы ул?» – дип, чак кына сорамый калды. Аннан башка да аның сораулары күп иде, Хәйдәр белән сөйләшәсе килде аның, әмма пациентның хәлсезлеген күреп, бүгенгә җитеп торыр, күрештек, таныштык, алга таба әле аралашырга мөмкин булыр дип саубуллашырга кирәк тапты. Чыгып киткәнче, лейкозларның бик күп төрле икәнен, бер үк төрлеләренең дә әллә ниндиләре булганын кыскача гына аңлатты, үз тәҗрибәсеннән чыгып, төрле мисаллар да китерде.

– Дәвалап була бу чирне, – диде ул. – Хәзер инде мондый диагнозлар – хөкем карары түгел. Кайберәүләр ремиссиядә унар, егермешәр ел яшиләр, яшәү сыйфаты сәламәт кешенекеннән һич кенә дә аерылмый. Бездә бер шофёр эшли. Аңа нәкъ сезнеке кебек диагноз куйганнар иде. Дәваладык һәм менә ун ел инде бернинди проблемасы юк. Хәзер аңа җитмеш яшь. Әлбәттә, гел контрольдә тотарга, тикшерелеп торырга кирәк.

Винфрид инде ишек катына җиткәч тә, әле гадәти тынычландыра торган сүзләр әйтергә өлгерде.

– Мин бу тарафларга төрле эшләр белән еш киләм. Хәзер инде тагын да ешрак килеп йөрермен, – диде ул чыгып китәр алдыннан. – Анализларыгыз тиздән яхшырыр. Аннан соң тагын сөяк җелеген алырлар. Минем киләсе визитым, мөгаен, шуннан соң булыр.

Хәйдәр һәрбер сүзгә ригая бирерлек хәлдә түгел иде, шуңа күрә профессорның «тагын да ешрак килеп йөрермен» дигән сүзләрен игътибарсыз калдырды.

**6**

Ун-унбиш көн узгач, Хәйдәрнең хәле бераз яхшыра башлады. Анализлар нормага якынайды, температура да утыз җиде тирәсендә торды. Әмма аны кисәтеп куйдылар – химиотерапиянең һәрбер циклында торымнан-торымга хәл бетү, анализларның начарлануы кабатланачак, моңа әзер булырга кирәк. Ахыр чиктә, һичшиксез, барысы да нормага киләчәк, рәткә керәчәк, диделәр аңа.

Тагын пункция ясадылар, сөяк җелеген алдылар, көн саен ниндидер уколлар кададылар...

Килгәненә бер ай була бит инде. Вакыт ул сәламәт кешенеке дә, авыруныкы да барыбер үтә.

Әмма яшәешне, хәятне тоемлау мизгелләре төрле булырга мөмкин. Гомер кыска, диләр. Бәлки, еллап, көнләп, сәгатьләп санаганга кыска тоеладыр ул. Аны мизгелләр белән санарга омтылсаң, бәлки, шул чагында гомер озын-озак тоелыр иде. Бер мизгелне дә тагын бихисап күп мизгелләргә бүлергә мөмкин ләбаса. Бер сәгатьтә ничә мизгел? Вакытны мизгелләр белән санарга мөмкин булса, бәхетле чакта күбрәк микән алар, әллә кайгылы вакыттамы?..

***

Август аеның яп-якты көне иде. Бүген Хәйдәрнең туган көне – аңа илле алты яшь тулды.

Иртүк Мәскәүдән, Казаннан, тагын берничә шәһәрдән таныш-белешләр телефон аша котладылар. Әлбәттә, кызы, кияве, хатыны шалтыраттылар. Бергә эшләгән коллегаларның берничәсе кичкырын гына элемтәгә кереп, җылы сүзләр әйтте. Туган көнне Германиядә, шушы диагноз белән бүлнис палатасында үткәрергә насыйп булган икән. Әмма бу көнне аңа бәһасез зур бүләк язган булып чыкты.

Көн уртасында палатага Ян Шредер, дәвалаучы табибә, ассистент кыз һәм Катерина керделәр. Өчесе дә шат йөзле икәнне күреп, Хәйдәр: минем туган көнем икәнне белгәнгә елмаялардыр, дип уйлап куйды.

Юк, сәбәп башкада булып чыкты. Аларны Хәйдәрнең анализлары яхшы булу нык куандырган иде, ә аның туган көне икәненә исә беркем дә игътибар итмәгән икән.

– Беренче химия циклыннан соң ук сезнең канда рак күзәнәкләре юкка чыкты! – дип тантаналы тавыш белән игълан итте Шредер. – Бу безнең өчен бик зур бәхет. – Хәйдәр исә әле сөенергә ашыкмады, моны күреп, Шредер әйтеп куйды: – Сез дә шатланырга тиеш. Рак күзәнәкләренең берсе дә калмады!!!

Ниһаять, бу куанычлы хәбәр Хәйдәргә «барып җитте».

– Ничек инде шатланмаска! – диде ул, җанланып. – Сез бит минем туган көнемдә шундый яхшы хәбәр белән кердегез. Миңа бүген илле алты яшь тулды.

Барысы да аптырап, тын калдылар. Шредер шелтәле тавыш белән Катеринага борылып:

– Белмәдеңмени? – диде.

Катерина читенсенеп куйды, чөнки пациентның туу датасы һәр кәгазьдә куелып килә иде.

– Игътибар итмәгәнмен шул, – диде Катерина, үзенең гаебен таныганны кашларын җыеруы белән күрсәтеп.

Барысы да бертавыштан:

– Котлыйбыз! Котлыйбыз! Котлыйбыз! – дип күмәкләшеп котлаганнан соң, Шредер:

– Берничә көннән химиотерапиянең икенче циклы башланачак, – диде. – Бу юлысы доза беренчесе кебек үк каты булмаячак, әмма хәлегез вакытлыча нәкъ хәзергедәй авыраерга мөмкин.

Докторлар чыгып киттеләр, ә Катерина палатада калды.

– Туган көнне мондый хәбәр игълан итүләре – яхшы билге!!! – диде ул, үтә җитди кыяфәт белән һәм бераз дулкынланып. – Бу бик яхшы билге. Туган көнегездә сез яңадан тудыгыз дип санарга мөмкин. Котлыйм сезне! Туган көнегез белән дә, рактан арынуыгыз белән дә! Әмма докторлар сезгә әйттеләр инде, уяу торырга һәм дәвалануны дәвам итәргә кирәк.

Катерина, балакай, якты йөзле, бер тик тормый торган гүзәл зат, ул да ихластан сөенә иде. Югыйсә Хәйдәр кем инде бу рус канлы алман кызына?!

– Һаман ышанып җитеп булмый әле, – диде Хәйдәр, көннең уңышлы булуыннан иркен сулыш алып.

– Тизрәк ышаныгыз инде, – дип елмайды Катерина һәм чыгып китмәкче иде, Хәйдәр аны туктатып:

– Катерина, Винфрид Мейер дигән кешене беләсезме сез? – дип сорады.

– Шаритэ профессорынмы?

– Әйе.

– Ничек инде белмәскә. Танылган, данлыклы профессор, Ян Шредернең дусты. Ул аны укыткан. Монда килгәләп йөри ул.

– Әйе, беркөнне минем янга керде ул.

– Ник? – диде Катерина, гаҗәпләнеп.

– Хәлләремне белергә. Тагын килермен диде.

– Кызык, – дип беравык уйга калып торды Катерина. – Ул, гадәттә, безнең пациентлар янына керми. Шредер янына гына килә. Кызык, бик кызык, – дип кабатлады Катерина.

Хәйдәр аның аптыравына ригая бирмәде. Ул бүген, үзенең туган көнендә яхшы хәбәр алды һәм аның күңелендә хәзер өмет кошы канат кагына иде. Катерина исә, аның туган көнен кәгазьләрдә абайламаса да, бүген тагын да нәзакәтлерәк, чибәррәк, затлырак булып күренде.

***

Ә менә Винфрид Мейер аның туу датасына игътибар иткән булган һәм исендә калдырган иде һәм кичкә таба ул килеп тә җитте.

Мейер елмаеп палатага кергәндә, Хәйдәр дә күтәренке кәефтә иде.

– Мин беләм – сезнең анализлар тәртиптә, – диде профессор, чын күңелдән сөенеп. – Лейкемия юк! Китте ул! Хәзер инде аны кире китермәү өчен көрәшергә кирәк. Сез көчле кеше, хәлегездән килер дип ышанам. Сез бит моннан җитмеш биш ел элек шундый зур сугышта җиңдегез... – дип елмайды ул. – Бу чирне генә җиңеп булыр.

– Сугышларда җиңүгә караганда, үз-үзеңне җиңү авыррактыр шул, – диде Хәйдәр. – Аннары, сугышта безнең буын түгел, безнең бабайлар, этиләр җиңде.

Винфрид Мейер әңгәмәнең бу юнәлештән китүен бик көткән иде. Сугышта җиңү турында үзе дә махсус әйтте бит ул.

– Әтиегез гаскәрләрнең нинди төрендә хезмәт иткән? – дип кызыксынды Винфрид.

– Пехотада.

– Кайсы фронтта булган?

– Украина фронтында. Аңарчы кайсы фронтта икәнен белмим. Фронтларның исемнәре алышынгалап торган. Украина фронтлары да икәү булган бугай...

– Димәк, Украина территориясендә сугышырга туры килгән?

– Әйе, Украина турында күп сөйли иде ул.

– Минем эти дә катнашкан бит сугышта, – диде профессор. – Ул да Украина җирләрендә булган. Андагы маҗараларны, коточкыч хәлләрне гел сөйли иде ул. Әтиегезнең исеме Гарипов Самат... Берәр әсирне, конвоир буларак, саклаганы булмады микән аның?

Хәйдәр гаҗәпкә калды.

– Булган андый хәл, – диде ул, Винфридка текәлеп. – Аның бер

вакыйганы миңа әллә ничә тапкыр сөйләгәне булды. Ун яшемдә генә булсам да, аермачык хәтерлим. Аны бер әсир радистны сакларга кушканнар, соңрак аларны килеп алырга тиеш булганнар, әмма килмәгәннәр. Алар, икәүләшеп, фронтның кайда икәнен, кай тарафта кем гаскәре икәнне белмичә, адашып, төрле михнәтләр күреп йөргәннәр.

– Минем эти дә шундый ук вакыйганы гел сөйли иде, – диде профессор, кинәт җитдиләнеп. – Безнең этиләребез булмады микән ул?..

Хәйдәрнең йөрәге дерт итеп куйды:

– Әтиегезнең исеме ничек? – ди сорады ул, беравык дәшми торганнан соң.

– Ортвин, – диде профессор. – Ортвин Мейер.

Хәйдәр шаккатып, телсез калды. Әллә чынлап та... Болай булырга мөмкинме соң?!

– Мейер әфәнде! Әтинең сугыштан алып кайткан кул сәгате бар, – диде Хәйдәр, йөрәк тибешенең ешайганын тоеп. – Ул сәгать һаман да исән. Ул аны миңа бирде. Ул сәгатьнең артында «Ортвин Мейер» дип чокып язылган язуы бар.

Палатада шактый вакыт тынлык хөкем сөрде.

## 7

Соңгы вакытта вермахт гаскәрләре чигенә дә чигенә. Украина җирләрен азат итү Сталинградтагы җиңүдән соң ук башланды – инде 1943 елның башында ук Донбасс якларыннан дошман куылды. Курск дугасындагы бәрелештән соң, бөтен Украинаны немец-фашист оккупантларыннан арындыру киң фронтлап, көнбатыш тарафларына күчә-күчә дәвам итте.

Саны аз калган дивизиядәге бер полкның җыйнак кына авыл янында ял иткән чагы иде. Дивизия командиры һәм аның ике ярдәмчесе утырган җиңел машина, үтеп барышлый туктагач, полк командиры, йөгереп килеп, полкның хәле, күпме кеше калуы турында доклад ясады. Шуннан соң ул комдивка дошман радистын әсир иткәннәрен һәм аның өр-яңа рациясе барлыгын әйтте.

– Рациясе өр-яңа, минем андыйны күргәнем юк, – дип өстәде полк командиры.

– Кайда ул? – диде комдив.

– Әнә теге келәт янында саклыйлар аны, – дип, полк командиры, авыл урамы уртасында әллә каян беленеп торган кызгылт төстәге корылмага күрсәтте. – Элек бер байның келәте булган, хәзер амбар бугай анда. Алып килсеннәрме?

– Кирәкми. – Комдив беравык уйланып торды. – Сез бит хәзер туп-туры елга кичүенә барасыз?

– Так точно!

– Безнең Смерш отделы әлегә Верхнегорскида калды. Мин анда хәбәр бирермен. Монда бер сакчы белән әсирне калдыр, бер-ике сәгатьтән особистлар килеп алырлар. Верхнегорскига егерме биш чакрым гына моннан. Әнә теге кызыл кирпечле корылманы әйтәсеңме син, шулмы амбар?

– Так точно.

– Шунда көтсеннәр. Сезнең киләсе привалыгыз елга буенда гына була бит инде?

– Так точно.

– Елгага җиткәнче бүтән туктамагыз.

– Есть!

Комдив машинасы кузгалып киткәч, полк командиры шундук взводларның берсеннән әсирне сакларга солдат бирергә кушты.

Артына авыр рюкзак аскан радистны качып котылырга маташучы немец батальонын эзәрлекләгәндә тоттылар. Иптәшләреннән артта калган бу солдат яраланып түгел, әллә абынып, аягын тайдырганнан, әллә сеңере тартылганнан аксый иде.

Взвод командиры түшенә Кызыл Йолдыз ордены һәм ике медаль таккан солдатка кат-кат аңлатты:

– Гарипов! Бу дивизия командирының приказы. Әсир радистны бер-ике сәгатьтән Смерш кешеләре килеп алырлар, ә сине үзебезнең полкка елга буена илтерләр. Алар килгәнче, син әсирне сакларга тиеш. Келәт яныннан беркая да китмә. Менә аның документы, кесәңә тыгып куй.

Гарипов Самат – Казанда туып-үскән эре гәүдәле, гаярь егет, иптәшләреннән аерылып каласы килмәгәнен әйтүдән файда булмасын белеп, бары тик чыраен сытты һәм борын астына гына нидер мыгырдап куйды.

Әсирне сакларга взвод командиры тикмәгә Гариповны сайламады. Ышанычлы, батыр йөрәкле бу солдатка ул гел иң җаваплы заданиеләрне бирә иде. 1943 елның апрель аенда Гариповның бөтен ротаны коткарганын дивизиядә белмәгән кеше булмагандыр, мөгаен.

Рота засадада ятарга фәрман алган иде. Ике сәгать засадада торганнан соң, ул-бу булмаган очракта, рота, оборона сызыгына барып, үзләренең полкына кушылырга тиеш иде. Бөтенләй көтмәгәндә, арттан немец батальоны килеп чыкты һәм атыш башланды. Самат пулемёты белән ярым җимерек чиркәүгә кереп, өстән ут ачты. Дошман батальонының күбесе кырылып, калганнары качып котылды. Ә алары инде оборона сызыгына баручы безнең полкка юлыгып, тар-мар ителде. Моның өчен Самат Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.

Үзенә, шаярып, «Казан бандиты» диюләренә Самат һич кенә дә үпкәләми, ачуланмый, чөнки җитез, батыр йөрәкле, орден-медальле бу егет иптәшләренең хөрмәт-ярату белән шулай диюләрен белә иде. Казаннан булуы белән һәрвакыт горурлана, «бандит» кына дисәләр, бәлки ачуы килер иде, әмма «Казан бандиты» булгач, моңа сөенә генә иде.

Аның хәзер тизрәк елгага барып җитәргә һәм, мөмкинлек табып, су коенырга хыялы бар иде. Хәзер инде, су керәсе урынга, бу мәхлукны саклап торырга тиеш ул. Менә каршында чын, тере дошман басып тора. Фрицның хәлсез, мескен кыяфәтендә җанварларча курку катыш чарасызлык күренә.

Колоннага тезелеп, елан кебек боргаланып сузылган полкның койрыгы авыл читендәге калкулык артында югалды. Үзәк урамда урнашкан нык нигезле, әмма инде кыршыла, җимерелә башлаган келәт буенда ике солдат калдылар.

Немец йончыган, яланбаш, күптән кыркылмаган саргылт чәче арыш саламын хәтерләтә иде. Үз чырае өчен бераз кыскарак төз борынлы, кечкенә соры күзле, юка иренле, яңак сөякләре чыкканрак әсиргә Самат җирәнеп карады. Озын-какча гәүдәле бу немецның төссез чыраенда курку юк, бары

тик дошман кулына эләккәненә эчке әрнүе сизелә иде. Самат аның борын төбендәге, шакмакланыбрак торган иягендәге сирәк кыл сакал-мыегы гына түгел, керфек-кашлары да сары төстә икәненә игътибар итеп: «Дуңгыз керфек!» – дип куйды.

Радист, торымнан-торымга чыраен сытып, авырткан аягының балтырын ике куллап угалап куя. Күнитеге, киеме әле таушалмаган – әллә фронтка күптән түгел килгән, әллә иске формасы урынына әле генә яңаны биргән булганнар. Йодрыкларын төйнәп, кыжрый-кыжрый үз телендә сүгенүче кызылармеецка әсир шүрләү катыш нәфрәт һәм шул ук вакытта ниндидер өмет белән карап-карап ала.

Самат исә, күңел түреннән аты-юлы белән татарчалап-русчалап сүгенеп, келәт буенда кукраеп утыручы немец янында әрле-бирле йөри. Берничә тапкыр, туктап, немецка винтовкасын төбәде, тегесе «Ы-ы-ы» дип иңрәп, куллары белән битен каплады.

Урам буйлап ике хатын боларга сәерсенеп карап үтеп баралар иде, берсенең кулында буш чиләк икәнне абайлап, Самат:

– Күрәсеңме, буш чиләкле кеше үтеп бара, юньлегә түгел бу. Б...т, атып үтерәсе генә бар сине! – дип, немецка винтовка прикладлы белән кизәнде. – Каян килеп чыктың син! Ник тоттылар сине! Чуртыма кирәкмени син – көчкә йөрисең, аксак тәре! – Самат рюкзакка күз ташлады. – Рация белән нишләмәкче булдың, сука?! Күрмәгәнегезне күрсәтteләр бит инде Мәскәү янында, Сталинградта, Курскида. Хәзер Германиягә барып, бөтенегезне...

Каршы йорт капкасыннан какча гәүдәле хатын чыгып, авыл башына карый-карый атлады һәм үтеп барышлый боларга якынрак килеп:

– Улым күрше авылга киткән иде, Матрёна түтәй янына, – диде, улы өчен борчылуын кем беләндер уртаклашасы килеп. – Һаман кайтмый. – Моны кайда тоттыгыз? – дип сорап куйды ул соңыннан.

– Кем белгән, – диде Самат. – Мин тотмадым аны. Мин булсам, аны тоткан урында ук атып үтерер идем. Сакларга калдырдылар. – Самат пилоткасын салып, битендәге тирне сөртте. – Су эчәсе килә. Су алып килмәссеңме икән?

Хатын җавап бирмичә генә кире китеп барды һәм, күп тә үтмәде, капкадан бидон тотып чыкты. Хәйдәр бидонны күтәреп, салкын кое суын йотлыгып эчте. Бидонны кире хатынга бирәм дигәндә, немец кыюсыз гына ялварулы тавыш белән:

– Geben sie mir bitte Wasser, – диде.

(«Миңа да су бирегез, зинһар», дию иде аның.)

– Шиш сиңа! – дип җикерде Самат. – Бирмим. Чукынып кат! – Әмма беравык уйланып торганнан соң: – Мә, фашист, эч. Йә, үләрсең дә, мине гаепләрләр, – дип, калган суны әсиргә бирде.

Су әле күп калган иде, немец тончыга-тончыга аны эчеп бетерде. Бидонда су калмаганны күреп, хатын шаккатты:

– Кай җиренә шушы кадәр су сыйды икән? – диде ул.

– Чөнки ул кеше түгел. Җен! – диде Самат, хатын янында сүгенүдән үзен көчкә тыеп. – Рәхмәт сиңа. Суыгыз бик тәмле икән.

Хатын бидонны алып, өенә таба юнәлгәч, Самат ашарга да сорарgamы әллә дип уйлап куйган иде, әмма кыймады.

Ул келәт буенда янтаеп утырган әсирне усал караш белән җентекләп күзәтте. Аның күз карашыннан «качыр» өчен немец, башын читкә борып, урман ягына карады.

– Сәгатең шәп икән синең, – диде Самат. – Ур... Армбандур... – Су эчерткәнем өчен сәгатеңне бир. Сиңа хәзер сәгать кирәк булмаячак инде.

Немец аңлады һәм, борын төбенә нидер мыгырдап, кулындагы сәгатен салды, әмма бирергә ашыкмады. Самат сәгатьне аның кулыннан йолкып алды, әйләндергәләп тикшерде, колагына терәп тыңлап карады. Шуннан соң канәгать кыяфәт белән сул кулына тагып куйды да, берничә адым читкә китеп, чирәм куерак үскән җиргә барып утырды. Аның сәгатькә сокланып карап утыруын күреп, немец читкә төкереп куйды.

– Нәрсә, фашист, төкеренеп утырасың! – дип җикерде Самат. – Сәгатьсез калганыңамы? Рәхмәт әйт шундук атып үтермәгәнебезгә. Сәгатеңне барыбер Смерш кешеләре алырлар иде. Синең өчен аерма юк бит – аларныкы буламы сәгатең, минекеме.

Самат, күнитекләрен салып, чолгауларын яңадан җайлап урап куйгач, аңа карап, немец та авырткан аягының итеген салды һәм, ыңгырашып, балтырын уарга тотынды. Аның аягындагы оекбашларны күреп, Самат гаҗәпләнде һәм шундук моңа ачуы кабарды.

– Симулянт! – диде аңа Самат. – Шешмәгән-нитмәгән, ярасы да күренми... Шыңшып утырасың, хәшәрәт!

Әсир, конвоирның яман усал кыяфәтеннән шүрләп, итеген кияргә ашыкты.

Инде бер сәгать, аннан ике сәгать, өч сәгать вакыт узды, әмма Смерш вәкилләре һаман күренмәде. Саматның күңеленә шом керде, ул, каугаланып, әрле-бирле йөрергә тотынды.

Нишләргә?.. Немец аксак булса да, озын буйлы, хәйран тыгыз гәүдәле, җегәрлегә охшаган. Ни уйлаганын кем белгән. Монда бит әле рация дә бар. Иң мөһиме – командованиенең приказы бар – әсирне исән килеш Смерш отделына тапшырырга. Немец дөньядан ваз кичкән кыяфәттә, аркасы белән келәт стенасына терәлеп, үзен сырган чебеннәрне дә кумыйча, тик утыра иде. Самат аның тынычлыгына хәтта гаҗәпләнеп тә куйды.

Урам буйлап көрәк сакаллы карт, әкрен генә үтеп барышлый, украинча:

– Әсирме? – дип сорады.

– Так точно, бабай, – диде Самат, үзенең кәефен күтәрер өчен шаярган булып кыланып.

– Сезнекеләр китте бит, – диде карт.

– Аны син әйтмәсәң дә беләм, бабай, – диде Самат русча. – Хәзер безне килеп алып китәргә тиешләр. Башка кайгың булмаса, безнең өчен борчылма. Алай бик борчылсаң инде, бабай, минем ашыйсым килә. Берәр сынык ипи алып килмәссеңме икән?

– Мин үзем дә соңгы тапкыр кайчан ипи ашаганымны оныттым инде. – диде бабай төксе тавыш белән һәм, туктап, як-ягына каранды. – Тизрәк алып китсеннәр инде сезне. Урман янәшә генә, бандерачыларның килүе ихтимал. Бу тирәдә бүредән дә күбрәк алар. Килеп чыксалар, икегезгә дә капут булачак.

Карт борын төбенә мыгырдый-мыгырдый китеп барды. Сүзләре

аңлашылмады, әмма бабайның немецны да, кызылармеецны да, бандерачыларны да күралмавын аңларлык иде.

Немец үз телендә:

– Du hast meine Handuhr genommen… Lass mich gehen. – дип шыңшыды. (Сәгатьне алдың бит, шуның өчен җибәр мине, дип әйтүе иде аның.)

– Нәрсә хау-хаулыйсың, сука?! – дип Самат, аңа винтовкасы белән кизәнде.

Немец бүтән дәшмәде.

Тагын шактый вакыт узды. Көннең икенче яртысы бит инде, караңгы төшкәнче килмәсәләр, нишләмәк кирәк, – дип борсаланды Самат.

Кинәт авыл артында, якында гына атыш башланды, ара-тирә акырышкан авазлар да тонык кына ишетелеп куйды. Өч минут чамасы алмаш-тилмәш винтовка тавышы белән автомат такылдавы яңгырап торганнан соң, тынлык урнашты. Самат, винтовкасын ике куллап кысып тотып, әсир белән янәшә чүгәләде һәм шул вакытны авыл башыннан урам буйлап ун-унбер яшьлек малай йөгереп килгәне күренде.

Самат, торып, аны туктатты:

– Әй, малай, белмисеңме, нинди атыш булды анда? – дип сорады ул котсыз калып күзләре акайган малайдан.

– Авылга җитәрәк машинага һөҗүм иттеләр... Офицерны, шофёрны, дүрт солдатны үтерделәр, – диде малай, еш-еш сулап. Аның чыраеннан төс качкан, куллары, ялан аяклары сыдырылып беткән иде. – Мин күрше авылдан кайтып бара идем.... Куаклар арасына качып, күреп яттым.

– Машинада безнекеләр идеме?

– Әйе.

– Нимесләр һөҗүм иттемени?

– Юк. Алар украинча кычкырдылар.

– Алар хәзер кая киттеләр соң?

– Белмим. Мин качып яткан җиремнән чыгып йөгердем. Урманга киткәннәрдер алар. Урман ягыннан килгәннәр иде.

– Безне алырга килүчеләргә һөҗүм иттеләр микәнни? – диде Самат үзалдына, бу коточкыч уйдан үзәге куырылып һәм тәненең эсселе-суыклы булып куйганын тоеп.

Какча гәүдәле хатын капкадан чыгып, улының каршына йөгерде:

– Витя, улым! – дип кычкырды ул. – Витенька, нишләп болай озак? Өйгә кер тизрәк!

Әнисе малайны әйләндергәләп, хәтта капшап карады һәм аннары, иңennән кочып, кызу-кызу адымнар белән өйгә алып кереп китте.

Самат авыл башына күз ташлады да немецны торгызырга тотынды:

– Штеет ауф, хайван!

Немец теләр-теләмәс кенә торды, авырткан аягына баскач, чыраен җыерып, иңрәп куйды.

– Симулянт! Ал рацияңне! Геен минем арттан!

Рацияле рюкзакны келәт янындагы иске librталар арасына яшергән арада авылга биш бандерачы килеп керделәр һәм саклык белән генә, як-якка карый-карый, тирә-якны күзәтеп, урам буйлап атладылар.

Самат әле аларны абайлап өлгермәгән, немецның рацияне такталар янына куйганын карап тора иде.

– Такталар арасына яшер! – дип боерды Самат, әмма теге аңламады.

Самат, винтовкасын җилкәсенә асып, үзе бер тактаны рюкзак өстенә куйгач, немец, ниһаять, аңлады һәм ул аппаратны такталар белән бөтенләй каплады.

Келәт артыннан чыкканда, аларны коралллы биш кеше көтеп тора иде инде. Кигән киемнәреннән, кыяфәтләреннән аларның урман кешеләре икәне әллә каян күренеп тора иде. Биш кешегә әллә ничә корал үзләрендә, ике ППШ автоматы белән офицер планшеты да бар. «Болары үтерелгән кызыл армеецларныкыдыр, мөгаен», дигән уй Саматның башында чыңлап үтте.

Берсе – озын буйлы, сары сакаллы, күзләрен челт-челт йома, башына әллә нинди уңган пилотка кигән, өстендә иске китель – кайсы гаскәрнеке икәнне дә чамаларлык түгел иде. Икенчесе – базык гәүдәле, шулай ук сакаллы, ике күзе ялт-йолт килә, сәвит солдатының гимнастёркасын кигән, башындагы чәче чуаланып беткән. Өченчесе – немец формасыннан. Ябык, урта гәүдәле, зәп-зәңгәр күзле, гел йөткереп тора. Дүртенчесе – чегәнгә охшаган ябь-яшь егет, эре сөякле, кара чәчле. Аның киеме дә базарда әйбер чәлдереп йөрүчеләрнеке кебек – киң балаклы чалбар, иңнәре асылынып торган куртка, козырёгы урталайга чатнаган кепка. Бишенчесе – сакалына, чәченә чал кергән олы яшьтәге агай. Ул читтәрәк басып тора иде.

1943 ел башында Украина милләтчеләре «Сәвитләрдән һәм немецлардан азат ителгән Украина» лозунгын игълан иттеләр. Шулай итеп, УПА дип кыскача әйтелгән (Украинская повстанческая армия) оешма барлыкка килгән иде. Ике ел эчендә алар инде утыз меңлек гаскәр тәшкил итәләр һәм, Бандера үзе бу вакытта лагерьда булса да, аларны бандерачылар дип атый башлаганнар иде.

– Хенде хох! – дип кычкырды озын буйлысы усал һәм шул ук вакытта шат тавыш белән.

– Ташла винтовкаңны! – диде төптән юан гәүдәлесе. – Бу нинди дуэт тагын? Дөньяда сугыш бара, ә монда фашист белән красноперый күләгәдә ял итәләр.

– Син кем? – диде немец формасы кигәне, Саматка текәлеп.

– Самат.

– Казахмыни? – дип сорады чал сакаллысы.

– Татар.

– Кырымнанмы?

– Юк, Казаннан. Казан татары.

– Монда нишлисез? – диде озын буйлысы.

– Әсирне саклыйм.

– Сезнекеләр авылда тагын бармы?

– Юк.

– Кемнәрне көтәсез?

– Безне килеп алырга тиешләр иде.

– Особый отделдандыр инде...

– Әйе. Смерштан.

– Алар хәзер кырда яталар, монда килә алмаслар инде. Офицер мәрхүмнең документы Смершныкы иде. Шул, сезне килеп алырга тиешле кешеләр булгандыр.

Бандерачылар немецны да, Саматны да җентекләп тентеделәр һәм икесенең дә документларын алдылар.

– Боларны атып үтерик тә, эше бетте, – диде арадан кайсысыдыр. – Икесе дә дошман.

Озын гәүдәлесе Саматның кызылармеец кенәгәсен ачып карады:

– Минем дустым бар иде, – диде ул Саматка. – Татар егете. Кырымнан. Сугышка кадәр Одессада бергә эшләр майтарган идек. Үтерделәр аны. Он урлаганда тоттылар. Мин качтым. Аны үтергәнче кыйнаганнар. – Ул документларны пинжәгенең эчке кесәсенә тыгып куйды. – Кирәге чыгар бу документларның. – Шуннан соң ул әсиргә кизәнде: – Ә син, фашист, хәзер бу дөньядан китәсең! Шәһәребезне бомбага тоттыгыз, йортсыз калдык, әнкәм, сеңлем һәлак булдылар.

Шуннан соң ул приклад белән әсирнең башына каты гына орды. Немецның шундук бите буйлап кан агып төште, ул егылмас өчен келәт стенасына терәлмәкче булды, әмма аякларында тора алмыйча, гөрселдәп, җиргә чалкан ауды. Бандерачы винтовканың затворын тарткач, Самат:

– Зинһар, атма! – дип, үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде.

Барысы да аптырап, аңа карадылар һәм бишесе дә шаркылдап көләргә тотындылар.

– Нәрсә-ә? – диде озын гәүдәлесе, кинәт көлүдән туктап. – Син үзең өчен кайгыр. Мин бит сине дә теге дөньяга озата алам.

Базык бандит, әле һаман көлүдән туктамыйча, әкрен генә килде дә йодрыгы белән бар көченә Саматның эченә сукты.

– Син дә нимес ягындамы әллә? – диде ул, тешләре арасыннан ысылдап.

Самат ике куллап, эчен тотып бөгелде һәм төнтәйгән килеш:

– Тукта, атмый тор! – дип ыңгыраашты. – Аның рациясе бар... Яңа төрле рация... Бу нимес бик оста радист... Аның сезгә кирәге чыгуы ихтимал... Аны атып, сезгә ни файда?..

Әлбәттә, Саматның ялваруы немецны кызганудан түгел иде, аның башында бу минутларда да полк командирының приказы гына чыңлап тора иде. Ул әле барыбер, бандерачылардан котылып, радистны Смершка тапшыра алырмын дип өметләнде. Рациясе кадалып китсен. Бәлки, немец аппараты бу урман этләренең игътибарын җәлеп итәр дә, әсирне үтермәсләр, бәлки, урман буендагы юлда боларга очраган машина особистларныкы булмагандыр, башка частьныкыдыр. Бәлки, күп тә үтмәс, Смерш кешеләре килеп җитәр һәм коткарырлар.

– Карале, бу мәхлуклар безгә кирәк булырлар әле, – диде иң өлкән яшьтәге бандерачы. – Икенче урынга күчкәндә, әйберләрне ташырлар. Землянка казытырбыз үзләренә. Шуннан соң да үтерергә җитешербез.

Чегәнгә охшаган бандерачы немец өстенә иелеп:

– Штейт ауф[1], падла! – дип кычкырды.

Шулай итеп, бандерачылар Саматны һәм икеләтә әсир төшкән радистны, эткәләп-төрткәләп, авылдан алып чыгып киттеләр. Немец бөтенләй үләмәткә әйләнде, ныграк аксый башлады, шуңа күрә рацияне Саматка күтәрттеләр.

Менә авылдан алып чыгарлар да икесен дә атып үтерерләр дип,

[1] Штейт ауф – немецчадан: торып бас.

Саматның аяк астындагы җир убылган кебек булган иде. Әмма тора-бара үзәктә өмет уты кабынды – юк, әле үтерергә җыенмыйлар, аларны болын буйлап, урманга таба алып баралар.

Авыл артта калды. Алда урман. Болынның уң ягы буйлап, елга ага. Урманга кергәч, качып булмасмы дип уйлады Самат. Мөмкин булса да, үзе генә котыла алыр инде ул, немец бөтенләй абынкыланды. Котыла алса, дөресен сөйләячәк – әсир бандерачылар кулында калды, диячәк һәм аңа һичшиксез ышанырлар, аңларлар. Приказны үти алмавында аның гаебе юк лабаса. Рация бик авыр нәрсә булып чыкты, йөгергәндә ташларга кирәк булыр...

Болын уртасына җитәрәк, кинәт урман эчендә башта берән-сәрән, аннары көчле атыш тавышлары яңгырады. Барысы да шып туктадылар һәм бандерачылар, коралларын әзерлектә тотып, нишләргә белмичә тордылар. Ниһаять, бандерачыларның озын гәүдәлесе:

– Безнең базага һөҗүм иткәннәр, ахрысы, – диде. – Фрицлар микән?

– Юктыр, нимес монда калмады инде, – диде базар карагына охшаганы. – Зачисткадыр.

Атыш якынайды һәм отыры инде болында каты яңгырый башлады.

– Кире авылга китәбез! – дип боерды озын буйлы бандерачы. – Тизрәк!

– Ә болар? – диде базык гәүдәлесе, Самат белән немецка күрсәтеп.

– Ташла! Нигә алар безгә?!

Бандерачылар бишесе дә кире авылга йөгерделәр, ә Самат белән немец, шомраеп, болын уртасында калдылар. Урманда кемнәр атыша – белгән юк. Немецлар белән безнекеләр бәрелешәме анда? Бандерачыларга немецлар һөҗүм итәме, әллә бандерачыларга каршы безнекеләр сугышамы?.. Атыш башланганда, урман өстенә парсыман күкселлек күтәрелгән иде, хәзер инде, берничә каты шартлаудан соң, агач араларыннан куе каралҗым төтен саркыды.

– Геен![2] – диде Самат елга ягына ишарәләп һәм әсирне беләгеннән тотып: – Шнель![3] – дип җикерде.

Урманнан чыгучы күренмәде, әмма анда атыш көчәйгәннән-көчәя бара иде. Елга ерак булмаган икән, алар тиз арада су буена килеп җиттеләр.

Ярның сөзәк урыныннан елга кырына төшкәч, немец, каны күп агудан хәле бетеп, аяктан егылды һәм, Саматның утыруын күреп, шактый вакыт хәл җыеп ятты. Самат, аңа әйбер-кара әйтмичә генә, торып, елга аккан тарафка карап торды. Немец, ниһаять, тезләнгән килеш кенә, башын, битен юды, болганчык суны эчте. Атыш тавышлары әле һаман ерактан ишетелеп тора иде, шуңа күрә бу тирәдән ераккарак китү мәслихәт, яр өстенә күтәрелмичә генә, су буйлап кына барырга кирәк, дип уйлады Самат. Рацияне ул һаман үзе күтәреп барырга мәҗбүр булды, чөнки немец аякларын да көчкә сөйри иде.

Яр буйлап бара торгач, алар тал агачына бау белән эләктереп куелган иске көймәгә юлыктылар. Самат көймә эченә күз салды – төбе коры, димәк, тишек түгел, кыска гына саплы бер ишкәге дә бар иде.

Самат немецка:

– Утыр көймәгә! – дип боерды.

[2] Геен – немецчадан: атла.
[3] Шнель – немецчадан: тиз.

Әсирне көймә түренә урнаштырып, рюкзакны куйгач, Самат бауны ычкындырып, үзе белән алды. Ул тагын беравык елганың кайларга акканын чамаламакчы булып карап торды, әмма агымсу бер йөз метрдан соң кискен борылыш ясаганга күрә, аның кая илтеп чыгарасын аңларлык түгел иде. Ни булса шул, башка чара юк дип, Самат, көймәне агымга этеп, үзе дә көймәгә утырды һәм тын гына аккан елга шундук аларны үзе белән билгесезлеккә алып китте.

Самат бердәнбер ишкәк ярдәмендә, көймәне ярга якынрак тотарга тырышты. Шактый вакыт шулай йөзеп баргач, Самат, ишкәкне көймә эченә ташлады да, агымга буйсынып, беркавым хәл җыеп утырды.

Немецның башыннан чак кына кан саркыганга игътибар итеп, ул: «Ярый катырак кыйнадылар әле моны, – дип уйлап куйды. – Качарга ниятләсә, хәле юк, мине җиңә алмаячак». Дөрес, үзенең дә эченә каты гына ордылар аның, әмма түзәрлек иде. Иң мөһиме – ул әле исән һәм әсир дә исән.

Немецның кыяфәтендә элеккеге нәфрәт калмаган иде. Самат аны үлемнән коткарды, ул булмаса, бандерачы атып үтерә иде аны. Шуңадыр, күрәсең, әсирнең күзләрендә Саматка карата хәзер ышаныч бар иде.

Көтмәгәндә, немец елмайды:

– Danke dir[4].

Самат, аңа җавап итеп, ишкәк белән кизәнде:

– Хәзер бирәм мин сиңа данке, хәзер бирәм рәхмәтеңне! Мыскыл итеп көләсеңме?!

Немец, куркып, артка кайшалды. Ә Саматның сугарга исәбе дә юк иде, тар гына көймәдә фриц үзе миңа ташлана күрмәсен дип шүрләп, өркетер өчен генә кизәнгән булды ул.

Ике яр арасындагы агымсу ике солдатны кечкенә бер көймәдә билгесез киләчәккә алып китте. Көймә агымга буйсына, көймәдәге ике җан иясе шул агымга ияргән... Ә бит елга да үз ихтыяры белән акмый. Ә кем, нәрсә үз ихтыяры белән яши бу дөньяда?..

Алып китсен иде шушы елга сугышсыз җирләргә, кайгысыз тарафларга. Туйганчы йокларга иде, хуш исле болында, күкнең чиксез тирәнлегенә күзләрне төбәп, рәхәтләнеп ятарга иде.

Елга ага. Ул – censor бербөтен. Аккан су тамчылардан торган шикелле, вакыт агышы да мизгелләрдән тора. Бәла дә, шатлык та бербөтен төшенчәләр, әмма алар бер мизгелдә генә була алмый, алар өчен вакыт кирәк, кайсысы төшәр газиз башкаеңа – бер мизгелдә хәл ителергә мөмкин.

Дошманны юк итеп була, хәтта үзеңне дә җиңү мөмкин, әмма бу бөек агым алдында син – көчсез.

Самат моннан берничә еллар элек Казансу елгасында су коенганнан соң куен дәфтәренә: «Агымга каршы йөзсәң дә, елга юлы – шул ук кала.

Кайларга таба йөзсәң дә, ул гел үзенчә ага...» дип язып куйган иде.

**8**

Елганың уң ягында суга терәлеп үк урнашкан авыл күренгәч, Самат кулларын як-якка ишарәләп:

– Монда сезнекеләр, фрицлар нихт, кайн, найн[5]... – дип аңлатырга

[4] Danke dir – немецчадан: рәхмәт сиңа.

[5] Нихт, кайн, найн – немецчадан: юк

маташты. – Монда без... вир... Алай-болай качарга маташсаң, сиңа капут, пиф-паф. Ферштейн[6]?

Әлбәттә, немец аңлады. Амбар янында бандерачы аны үтерергә җыенгач, Саматның өзгәләнеп атмауларын үтенгәнне, сүзләрен аңламаса да, шулай ук аңлаган иде ул. Шуңа күрә Саматка ул хәзер инде рәхмәтле, үзен коткаручыга караган кебек карый һәм аның һәр боерыгына, һәр ишарәсенә кабаланып буйсына иде.

Авыл турысында Самат көймәне ярга юнәлтте һәм ярга килеп төртелгәч, немецны торгызып, рацияне аның җилкәсенә асты:

– Үзең күтәреп йөр, хайван! – диде Самат, әсир чайкалып куйгач, егылмасын өчен аның ике иңбашыннан тотып.

Көймәне кер юар өчен ясалган тайгак корылма субаена бау белән бәйләп куйгач, алар тар гына тыкрыкның сукмагыннан авыл урамына күтәрелделәр. Ярдан беренче йортның ишегалдына аяк баскач, Самат, өйгә кергәнче, каралты-кура тирәсендә берәрсе юк микән дип, колак салып торды.

– Берәр кеше бармы монда? – дип эндәште.

Сарай артыннан, җәйнең эссе көне булса да, телогрейка кигән урта буйлы агай килеп чыкты. Ул олы яшьтә, әмма ничә яшьтә икәнен чамаларлык түгел иде. Ямаулы чалбарының балаклары кыска, аягындагы иске ботинкаларының икесе дә «авызын ачкан», телогрейкасын, никтер, ялан тәнгә кигән иде. Алдан пеләш башы кызарган, сирәк кенә сакал-мыегы, тир агып төшептер инде, юешләнеп тора иде.

– Исәнме, агай! – дип сәламләде аны Самат.

Немец белән кызылармеецны бергә күреп, йорт-җир хуҗасы ни уйларга да белмәде.

Исәнләшүенә агайдан җавап алмагач, Самат:

– Сездә нинди влач? – дип сорыйсы итте.

– Хәзер монда бернинди влач та юк, – диде агай, әле аңа, әле немецка карап. – Сиңа нинди влач кирәк?

– Безнең хәрбиләр бармы бу тирәдә?

– Сез кайсы гаскәрдән соң?

– Ник, минем форманы күрмисеңмени? – диде Самат ачулы тавыш белән, кулы белән такыр башын капшап һәм шунда гына йолдызчыклы пилоткасының бандерачылардан качканда төшеп калганын белде.

– Мин моның формасын да күрәм, – диде агай, бирчәйгән кулы белән немецка ишарәләп.

– Бу әсир, – диде Самат. – Безнекеләр еракмы?

– Каян белим мин. Авылда бернинди хәрбиләр юк. Иртәгә ничек булыр, белмим.

– Миңа үзебезнекеләрне табарга кирәк.

– Алар кайдадыр аста елганы кичәргә тиешләр, – диде агай, елга аккан юнәлешкә ымлап.

– Аны мин син әйтмәсәң дә беләм, – диде Самат, агайның теләр-теләмәс кенә сөйләшүенә ачуы кабарып.

– Шулай булгач, елга буйлап аска төшегез, – диде агай, көчсез тавыш белән.

[6] Ферштейн – немецчадан: аңлашылды.

Самат бу кеше белән озак сөйләшеп торуның мәгънәсе юк икәнне аңлады, ләкин шулай да:

– Син безгә ашарга бирәр нәрсә бирә алмыйсыңмы? – дип сорады.

– Бернәрсә дә юк, – дип җавап бирде агай коры гына.

Самат немецка:

– Геен! – дип боерды.

Әсир капка янына җиткәч:

– Хальт![7] – диде ул. Аннан агайга борылып: – Тыкрыктан төшү белән, көймә тора. Минем көймә. Без көймә белән килдек монда. Мин сиңа шул көймәне бирәм, ә син миңа шуның өчен ипи бир, – дигән тәкъдим ясады.

Көймә дигәч, агайның йолкыш кыяфәтендә шундук җанлану сизелде:

– Ипи юк... Пешкән бәрәңге бар, – диде ул. – Дүрт бәрәңге бирә алам.

– Ичмаса алтыны бир инде, – диде Самат. – Без бит икәү.

– Ник, моны да ашатасыңмыни? – диде агай, немецка усал караш ташлап.

– Ашатмасам, үлә бит ул. Радист бу. Смерш отделына тапшырырга кирәк аны.

– Алай икән, – дип, агай акрын гына өйалдына кереп китте.

– Су да бир, – дип кычкырды аның артыннан Самат.

Агай башта чүмеч белән су алып чыкты. Саматның голт-голт итеп эчкәнен немец йотлыгып күзәтеп торды. Самат, моны абайлап, чүмеч төбендә калган суны әсиргә бирде:

– Эч, дуңгыз.

Болар су эчкән арада, йорт хуҗасы ике учына икешәр пешкән чикмәнле бәрәңге алып килде. Самат бер бәрәңгене әсиргә бирде, икесен чалбар кесәсенә тыкты, берсен, кабыгын әрчемичә генә ашый башлады. Немец, ашыга-ашыга, бөрешкән салкын бәрәңгене кабыгы-ние белән ике кабуда йотты да тончыгып йөткерергә тотынды.

– Ач тәре! – дип куйды Самат ямьсез тавыш белән.

– Диверсантмы ул? – дип кызыксынды агай.

– Шайтан белсенме аны, – диде Самат, ашый-ашый. – Фашист ул. Ә синдә, агай, оят юк бугай, – диде Самат, авызындагы бәрәңгесен йоткач.

– Ник алай дисең? – диде йорт хуҗасы, сагаеп һәм аптырап.

– Бер көймә өчен дүрт кенә бәрәңге бирдең.

– Мин синнән көймә сорамадым бит, – диде агай.

– Мин – җитди задание үтәп йөрүче кызылармеец, синең бөтен бәрәңгеңне конфисковать итә алам, – диде Самат, бераз кукраеп.

Агай шәмәхә иренле ерынкы авызын чалшайтып, һич кенә дә исе китмичә:

– Итеп кара, – диде.

– Курыкмыйсың син, ә... – дип көлемсерәде Самат.

– Мин күргәннәрне күрсәң, син дә бернәрсәдән, беркемнән курыкмый башларсың, – диде агай, ачу катыш сагышлы тавыш белән. – Большевиклар канны эчсәләр дә, минем ике улым да сугышта... Хатын урын өстендә ята, күпме яшәр, белгән юк... Миндә конфисковать итәрлек нәрсә булсын, иптәш солдат?!

Самат килеш-килбәтеннән үк ябагайлыгы күренеп торган бу агай белән

---

[7] Хальт – немецчадан: тукта.

дорфа сөйләшкәненә үкенеп, читенсенеп куйды. Шулчакны авыл эченнән машина тавышлары ишетелде.

– Нинди машиналар ул? – диде Самат.

– Белмим.

– Авыл аша үтәләрмени?

– Безнең авыл аша олы юл уза. Барыгыз шунда, юлга чыгыгыз.

– Нимес машиналары түгел микән соң ул?

– Каян белим мин. Кемнең кайсы тарафка барганы миңа нигә? Немецлар бу тирәдә юктыр дип уйлыйм. Алар инде хәзер елганың теге ягындадыр.

– Геен! – дип боерды Самат әсиргә.

Алар урамнан барганда, ара-тирә читән артыннан, тәрәзәдән ике сәер солдатка аптырап караучылар булды. Урам аркылы сузылган олы юл күренгәч, Самат, кемнәр килеп чыгасын белгән юк дип, турыдан-туры юлга чыгарга җөрьәт итмәде. Юллар кисешкән почмакта чалшайган, бер як стенаның бүрәнәләре черегән һәм түбә уртасы аска иңгән җимерек йорт күренде. Снаряд тигәннән, яисә якында бомба шартлаудан түгел, (монда атыш-мазар бөтенләй булмаган, ахрысы), искерү сәбәпле, кемдер ташлап киткән йортка охшаган иде. Күренеп тора: аны, әкренләп, утынга сүтеп ташый башлаганнар инде һәм өйнең үзенә кирәрлек тә түгел иде. Мөгаен, каршыдагы лапаста урнашсак яхшырак, аннан юлны күзәтергә дә җайлыдыр, дип уйлады Самат.

Лапасның эчендәге ис борынны бик «иркәләмәсә» дә монда салкынча, рәхәт иде. Күз ияләшкәч, почмакта тәгәрмәчсез кул арбасы абайланды. Стенага күгәреп беткән көрәк сөялгән, чыбыклары ашалып беткән себерке...

Озакламый караңгы төшәчәк. Юлдан үтүче машиналар бүтән күренмәгәч, Саматның, юл буена чыгып, берәрсеннән авылдагы хәлләрне белешергә кирәк дигән уе бар иде, әмма кире уйлады, чөнки күптән түгел үтеп киткән машиналар безнекеме, яки дошманныкымы икәнне белми торып, хәзер үк күренергә ярамый иде.

Ул, кесәсендә ике бәрәңге барлыгын исенә төшереп, лапасның стенасындагы ярыклардан төшкән көннең актык яктылыгында җиргә утырды һәм бәрәңгенең берсен ашарга җыенды.

Немец, янәшә утырып, күз кырые белән генә аңа карап-карап алгач, Самат, бәрәңгесен ашый-ашый, кырыс итеп:

– Мин сезгә әсир төшеп, шушы хәлдә булсам, мине ашатыр идең микән? – диде.

Немец моңсу итеп елмайды:

– Danke dir… Wenn du mich nicht beschutzt hattest, hatten sie mich getotet. (Син якламаган булсаң, алар мине үтергән булырлар иде).

Самат әсирнең ни өчен рәхмәт әйткәнен аңлады һәм аның кинәт күңеле йомшарып китте. Ул кесәсеннән калган бердәнбер бәрәңгене алып, әсиргә бирде:

– Мә, аша.

– Danke schon[8], – диде әсир һәм бөрешеп, кечерәеп калган салкын бәрәңгене шундук кабып йотты.

– Шоон... телегез тел түгел, – диде Самат ачусыз гына. – Һәр сүзегездә шом бар, сөйләшүегез эт өргән шикелле.

[8] Danke schon – немецчадан: рәхмәт.

Немец, стенага аркасы белән терәлеп утырды һәм, күп тә үтмәде, йокыга китте, ә бераздан кырыйга түнтәеп үк төште. Лапасның җир-идәне дымлы вә салкын, монда болай гына йоклап булырлык түгел иде. Самат, биштәрен лапас түренә күчергәннән соң, йорт яныннан берничә койма тактасы алып килеп, янәшә куйды, аннары шулар өстенә ятты һәм шундук йокыга талды.

**9**

Самат авыл этләре өргән тавышка уянганда, тышта инде таң беленеп килә иде. «Нишләргә икән?» дигән бердәнбер уй аны яткан җиреннән калкытты, ул торып утырды һәм күзләре белән әсирне эзли башлады. Теге күренмәгәч, Самат берни уйларга җитешмәде – лапас эчендәге караңгылыктан:

– Гутен морген! – дигән тавыш ишетелде.

Самат сикереп торды. Немец алданрак уянган! Кайда соң ул, күренми? Ниһаять, Самат лапас түрендә утырган әсирне абайлады. Немец та, төнлә берничә такта кисәге алып кереп, үзенә ятак ясаган булган икән.

«Бигрәк шәп конвоир мин, – дип, үзен үзе битәрләп алды Самат. – Дөньямны онытып йоклап ятам, әсир исә керә-чыга йөргән... Көрәк белән орып үтергән булса?.. – Аның йөрәге жу итеп куйды, әмма шундук тынычланды: – Моннан чыгып, әсир кая кача алсын? Аның аягы һаман авырта, хәле чамалы, хәзер инде ул бандерачылардан да курка, кайсы якка барасын да белми, өстәвенә, мин дә аңа бу тирәдә безнекеләр генә, дип аңлаттым».

Еракта тонык кына булып, машина тавышы ишетелгәч, Самат, лапас стенасындагы ярыктан карап, солдатлар төялгән берничә машина үтеп киткәнне күрде. «Безнекеләр!» – дип канатланып, Самат урамга йөгереп чыкты, әмма җитешә алмады – машиналар зур тизлектә ерагайдылар һәм авыл читендәге юл борылышында күздән югалдылар.

Урам очыннан тагын машина тавышы килгәч, Самат юлның уртасына ук чыгып басты һәм туктарга сорап, кулларын болгады. Буш арбалы полуторканың кабина ишеген сакал-мыегы күптән кырылмаган, куе кызыл көрән чырайлы, урта яшьтәге шофёр киереп ачты.

– Тиле мәллә син?! – дип, йокысызлыктан кызарган зур күзләрен акайтып кычкырды ул.

Самат аның янына йөгереп килде:

– Син кая юл тотасың?

– Березнякка.

– Син кайсы частьтан?

– Сиңа анысы нигә? – диде шофёр, машинасын кузгатырга җыенып.

Самат ике куллап кабина ишегенә ябышып:

– Мин Гаврилов дивизиясеннән, икенче полктан, – диде. – Безнең полк елганы кичәргә тора. Шунда илт мине.

– Юк, мин башка якка – Березнякка барам, – диде шофёр. – Частька билгеләнгән продуктны алырга җибәрделәр. Безнең тагын бер машина барырга тиеш иде анда. Алар шундадыр инде. Кит, мин кузгалам.

– Туктале, туктале, – диде Самат ялварулы тавыш белән. – Верхнегорски Березняктан еракмы?

– Егерме километр чамасы.

– Алайса безне дә Березнякка алып бар! – дип үтенде Самат. – Мине дивизиянең Смерш бүлегендә көтәләр. Алар Верхнегорскида иде...

– Верхнегорскига бармыйм мин, – диде шофёр, кузгалмакчы булып.

– Верхнегорскига димим бит, Березнякка хәтле генә. Киреләнмә! Особистлар минем нинди фәрман буенча йөргәнемне беләләр. Алмасаң, үзеңә начар булачак. Ал безне Березнякка!

– Кемнәрне ул – безне?

– Мине әсир нимесне сакларга калдырганнар иде...

– Шуннан?

– Ул менә бу лапаста, рациясе дә шунда. Тизрәк илтеп тапшырырга кирәк аны... Дивизия командиры фәрманы... Гаврилов үзе приказ бирде.

– Кайда соң ул?

– Кем?

– Әсир.

– Әнә теге лапаста дим бит. Ишетмисеңмени? Хәзер алып киләм мин аны. Зинһар, китмә. Көт!

Самат, сүгенә-сүгенә, рацияне үзенең иңенә асты да әсирне лапастан этәләп, юлга алып чыкты.

– Рюкзагыңда нәрсә синең? – диде шофёр.

– Рация.

– Документыңны күрсәт әле, – диде шофёр, кырыс кыяфәт белән.

– Нинди документ?! – дип җикерде Самат.

– Кызылармеец кенәгәңне.

– Документны бандерачылар алды. Без алардан көчкә качтык. Кеше бул инде! – диде Самат, ачыргаланып.

– Конвоир булгач, коралың кайда соң синең? – дип төпченә башлады шофёр.

Самат шофёрга нәфрәтле караш ташлады:

– Бандерачылар кулына эләктек без... Коралым да, кенәгәм дә аларда калды.

– Ә ничек котылдың соң син алардан? – диде шофёр, күзләрен чекрәйтеп.

– Урманда зачистка башлангач, алар безне үзләре ташлап качтылар, – диде Самат. – Ник төпченәсең инде! – дип кинәт кычкырды ул. – Алып бар безне Березнякка! Әгәр дә безне монда калдырасың икән, сине хөкемгә тартачаклар!

Шофёр беравык уйланып торганнан соң, каядыр еракка – Березняк урнашкан тарафка карап торды да, ниһаять:

– Менегез кузовка, – диде.

Рюкзакны үрелеп кузовка куйгач, Самат әсиргә:

– Мен! – дип җикерде.

Немец, бортка ябышып, менә алмый җәфаланды. Самат аны сүгенә-сүгенә артыннан этте. Әсир, ахылдап, арба төбенә яткач, Самат үзе җәһәт кенә кузовка сикереп менде һәм машина, кузгалып, авылдан чыгып китте.

Машина ачык кырны урталайга ярып чапканда, күктә немец самолёты күренде һәм, Җиргә җан өшеткеч тавыш иңдереп, берничә тапкыр әйләнеп килгәннән соң, машинага төбәп пулемёттан сиптерергә тотынды. Беренче очередьтан үк машинаның кабинасы тишкәләнде, арба такталары чәрдәкләнде.

Машина чаба да чаба, ә самолёт аны инде әллә ничәнче кат әйләнеп-бөтерелеп килеп, пулемёттан утка тота. Самат гәүдәсен җыеп бөрешкән килеш әсирне күздән ычкындырмады – тегенең авыртудан чырае кыйшайган, самолёт якынайган саен ике куллап, башын кыса иде.

Бервакытны машина, бара торгач, юлдан тайпылып кырыйга каерылды. Самолёт югка чыкты, лётчик эшемне башкардым, максатыма ирештем дип уйлады, ахрысы, ә полуторка әле тавышсыз калып, кыр буйлап әкрен генә бара иде.

Ниһаять, машина туктады. Рацияле биштәр кузов артына тәгәрәгән, немец янтайган килеш иңбашын тотып, каты ыңгыраша, аның бармак араларыннан кан саркый иде. Самат торып басты һәм капот астыннан күксел төстәге төтенме, пармы күтәрелгәнне күрде.

Самат әрҗәдән сикереп төште. Машинаның капоты тишкәләнеп беткән, ә шофёр рульгә йөзтүбән капланып кымшанмыйча утыра иде. Кабина ишеген каерып ачкач, Самат шофёрның авыз-борыныннан тезләренә, идәнгә өзлексез кан тамганны күреп, йөзен чытты. Шофёр кырыендагы утыргычта «вальтер» пистолеты ятканны абайлап, ул икенче яктагы ишекне барып ачты һәм обоймасында алты патроны калган коралны алып, чалбар кесәсенә тыгып куйды. Шофёр трофей пистолетның икесен йә аткан, йә тапканда ук, алты патрон булган, күрәсең.

– Төш! – дип кычкырды Самат әсиргә.

Немец бөтенләй шәлперәйгән һәм аның кузовтан сикерерлек тә хәле юк иде, Саматка машина арбасының бортын ачарга туры килде. Немец кузов идәненнән әкрен генә җиргә шуып төште һәм ыңгырашып, җиргә ятты, ул хәйран каты яраланганга охшаган – пуля иңбашына тигән иде.

Самат беркавым шофёрны кабинадан тартып чыгара алмыйча җәфалангач, немецка:

– Ярдәм ит, сука! Хилфен! – дип кычкырды.

Радист, аякларын көчкә сөйрәп, әкрен генә килде һәм, икәүләшеп, ниһаять, шофёрны җиргә сөйрәп төшерделәр.

Самолёт бүтән күренмәде.

Шофёр инде суламый, һичнинди ың-шыңсыз рульгә башын салган һәм, беренче карашка, ул йоклап кына киткәндер, эндәшсәң, уяныр сыман иде. Муенына тигән... Башын игәндәдер... Җилкәсе теткәләнгән, пуляларның алары инде рульгә каплангач эләккәндер... Аны кабинадан чыгарганда, Самат та, немец та канга буялып беттеләр. Немецның үзенең ярасыннан да кан күп аккан, чырае ап-ак, ул хәлсезләнеп, җиргә утырды, хәтта ятмакчы да иде, әмма базмады, Саматтан шүрләде.

Самат шофёрның тышы канга буялган солдат кенәгәсен алып үзенең кесәсенә тыкты да, нишләргә белмичә, машина тирәли йөреп чыккач, кукраеп басып торган мәхбүс янына килде һәм «вальтер»ны аның борын төбенә терәп диярлек:

– Менә, күрдеңме! Нәрсә килеп чыкты! – дип кыжрады. – Ә сине, падла, үзегезнекеләр яралады. Менә бу пистолет та сезнеке. Бәлки сине бөтенләй теге дөньяга олактырыргадыр?!.

Әсирнең исә куркырлык та чамасы юк иде, ул үләмәт кыяфәттә беркавым шаңкаеп торды да, ыңгырашып, җиргә чалкан ятты. Самат үзе дә бу

дошманнан җиксенеп, ужарлануының һичнинди мәгънәсе юклыгын аңлап, читкә китте һәм каугаланып, үрсәләнеп әрле-бирле йөрде.

Күпмедер вакыт узгач, чабып килгән арбалы атны шәйләп, Самат юлга таба йөгерде.

– Тукта! Тукта! – дип кычкырды ул.

Арбадагы малай, дилбегәне тартып, артка кайшалды. Күрәсең, самолёттан аңа да аткан булганнардыр – чепи күзле, бетчә баскан битле унөч-ундүрт яшьлек бу малай, дер-дер калтырап, Саматның үзенә түгел, кулындагы пистолетка карап катты.

– Березняк еракмы моннан? – диде Самат.

– Алты чакрым, – диде малай, әле Саматка, әле машина ягына карап.

– Анда немесләр түгелме?

– Юк дип беләм, – диде малай, кузгалырга омтылган атны тыеп.

– Безне шунда алып бар.

– Мин анда бармыйм бит, – диде малай, кыюсыз гына.

– Барасың! – диде Самат яман усал кыяфәт белән. – Шофёрны андагы зиратта күмәрләр. – Ул әсиргә кычкырды. – Геен монда!

Яткан җиреннән әкрен генә торып килүче немецны күргәч, малай «Но-о-о!» дип атны куаларга тотынды. Атка, әйтерсең лә, шул гына кирәк булган – торган урыныннан алга ыргылды һәм Самат «вальтер»дан өскә аткач та, малай атны туктатмады.

Самат аның артыннан ярсып:

– Хайван малае! Шакал! – дип кычкырып калды. – Очратсам, атып үтерәм! Селәгәй көчек!

Бу вакытта, атка утырып барырбыз дип уйлап, радист аның янына килеп баскан иде, Самат аңа тешләрен кысып кизәнде:

– Геен машина янына!

Әсир, кулы белән иңбашын кысып, парланып-төтенләп торган машина янына титаклады.

Самат, нишләргә белмичә, әйле-шәйле уйлардан хафаланды. Каян кемне, ничек итеп ярдәмгә чакырырга мөмкин монда?.. Җәяүләп, Верхнегорскига киткәнче, бу шофёрны йә кая булса да тапшырырга, йә һич югы шушында җирләргә кирәк. Көн эсселәнеп килә, озакламый кояш өтә башлаячак. Әсирнең дә ярасы хәйран җитдигә охшаган – чыраеннан төс тәмам качкан, торымнан-торымга иңрәп куя. Монда машина бар бит әле...

Әсирнең иңбашыннан кан бертуктамый ага иде. Самат «вальтер»ны алганда, кабинадагы утыргычта чиста чолгау күргән иде (шофёрга алмашка биргән булганнардыр, күрәсең), шуны искә төшереп, чолгауны барып алды һәм немецның култык астыннан ике кат үткәреп бәйләп, иңбашында төйнәп куйды.

Сәгать-сәгать ярым вакыт узгандыр, болар килгән авыл ягыннан машина тавышы ишетелде.

Юл буйлап тузан куптарып килгән полуторкада, шофёрдан кала, кабинада әзмәвер старшина һәм кузовта дүрт яшь солдат утыралар иде. Самат юлга чыгып та тормады, чөнки машина үзе ерактан ук тизлеген акрынайткан иде.

Алар да Березнякка баручылар булып чыкты, анда аларның частена әзерләп куелган провизия бар икән, шуны алырга барулары, имеш. Үлгән

шофёрны алар шундук таныдылар, ул да бит Березнякка болар барган йомыш белән юл тоткан булган. Машинадан төшкән солдатларның немецны шундук үтерергә талпынганнарын күреп, Самат нинди задание алганын һәм әсиргә тимәүләрен үтенеп, старшинага хәлне тиз-тиз аңлатты.

Саматны тыңлаганнан соң, старшина, әле һаман парланып торган машинаның капотын ачып карады һәм сыктанып:

– Эх, Егор, Егор, – дип куйды. – Ник ашыктың, никләр бездән алдан чыгып киттең? Соңрак чыккан булсаң, бәлки, үлмәс идең.

Солдатларның берсе винтовкасының затворын тартып, әсиргә таба атлагач, старшина корыч тавыш белән:

– Отставить! – дип кычкырды. – Бездән башка да аны нишләтергә икәнне хәл итүчеләр бар.

Старшина барысыннан да хәбәрдар икән – Смерш отделениесенә бандерачыларның һөҗүм иткәнен дә белә булып чыкты ул һәм Самат украина милләтчеләренә каршы урманда зачистканы нәкъ боларның батальоны үткәргән икәнне дә мәгълүм кылды.

– Березнякта здравпункт бар. Хәзер эшлидерме, юкмы, белгән юк, – диде старшина сүнек кыяфәт белән. – Сугышка кадәр Березнякның бүлнисе иде инде ул, элегрәк анда ятып та дәваланалар иде... Сезне үзебез белән шунда алып барырбыз. Бүлнис эшләмәсә, бигайбә, әсирең белән сине шунда калдырабыз. – Старшина солдатларына дәште: – Егорны тизрәк алып кайтып җирләргә кирәк. Продуктны бушаткач, Егор машинасын буксирлап алып кайтырбыз. Карасёв!

– Мин! – дип килеп басты түгәрәк йөзле, урта буйлы солдат.

– Машина йөрешле булмаса да, мародёрлар аның каерып-йолкып алыр нәрсәләрен табарлар. Шуңа күрә син әлегә монда машинаны сакларга калып торасың.

– Есть!

Старшина Саматка борылып:

– Березняктан елгага унбиш чакрым тирәсе, Верхнегорскига – егерме. Кая барырга икәнне үзең хәл итәрсең, – диде. – Аннары хафалы тавыш белән: – Егетләр! Егорны кузовка салыгыз! – дип боерды.

Сугышка кадәр алтмыш меңләп кеше яшәгән авылсыман җыйнак шәһәргә машина тиз барып җитте. Хәзер инде монда кеше аз калган, әмма киткән-качкан кешеләр кире кайта башлагач, сугыштан исән кайткан фронтовиклар белән бергә, халык саны артачагы һәм монда тиздән җан керәчәге сизелә иде.

Оккупация вакытында мондагы комендант гаять кансыз залим кеше булган, диделәр. Партизаннар гел һөҗүм итеп, монда немецларга тынгылык бирмәгәннәр, күпмедер вакыт дәвамында бандерачылар да немецларга каршы сугышканнар. Әмма фашистлар, чарасыз калып, барысы өчен дә җирле халыктан – ярдәмсез картлардан, хатын-кыздан, бала-чагадан аяусыз рәвештә үч ала торган булганнар.

Машина ике катлы озынча бина янына килеп туктады. Якында гына бомба төшкән булган – здравпункт дигәннәренең тәрәзәләре коелган, стеналары кыршылган, кыйпылчыклардан шадраланган, кайбер урыннарда үтәли җимерелгән, олы-олы тишекләр хасил булган иде.

Кабинадан чыккач, старшина үзалдына:

– Кеше бармы соң монда? – дип куйды.

Хастаханә ишегеннән алтмыш яшьләрдәге ябык кына ир кеше пәйда булды. Өстенә караңгы зәңгәр төстәге халатсыман нәрсә, башына таушалган сары эшләпә кигән агай ташландык хәлдәге бүлнистә калган бердәнбер табиб булып чыкты.

– Ә-ә-ә, син мондамыни? – диде старшина, табибны танып.

– Кайда булыйм инде мин тагын? – диде табиб.

Старшина аңа тиз генә хәлне аңлатты һәм сүз ахырында:

– Монда безнең частьның провизиясе калган иде, без шуны алырга килдек. Бу солдат белән әсирне сиңа калдырабыз, – диде ул, Самат белән немецка күрсәтеп. – Әсир яралы...

– Монда дарулар да, бернәрсә дә юк, – диде табиб тонык тавыш белән.

– Немецларны дәвалаганда, даруларың булгандыр бит... – диде аңа старшина яман усал тавыш белән.

– Алар мондагы бөтен нәрсәне кулланып, калганнарын алып киттеләр... – диде табиб, бераз каушап. – Аннары, алардан соң безнең часть торганда, полк санитарларының медикаментларын кулланган идек...

– Бу әсир исән калырга тиеш, – диде старшина, Саматка нинди мөһим фәрман бирелгәнне аңлап. – Аның иңбашы гына яраланган. Кара, яме!

– Ник аны үзегез белән алып китмисез? – диде табиб.

– Безгә аның кирәге юк.

– Ә миңа?

Старшина сүгенүдән чак кына тыелып калды.

– Син болай да инде монда немесләрне дәвалап яткансың, – диде ул, нәфрәтен көчкә йөгәнләп. – Тагын берсен генә дәваларсың әле. Кузовта безнең бер солдатыбыз үле ята. Тизрәк кайтып, аны күмәсебез бар. Кырдагы машинаны частька кайтарырга кирәк әле. Син, әйдә, киреләнмә, әйткәнне үтә!

Немецны кузовтан төшергәч, машина борылды һәм тузан туздырып китеп барды.

– Мин Иван Константинович булам, – диде табиб, никтер, Саматка түгел, әсиргә карап. – Шуннан соң ул Саматка борылды. – Исемегез ничек?

– Самат. Гарипов.

**10**

Винфрид белән Хәйдәр бер-берсенә шактый вакыт елмаеп карап тордылар. Әле күптән түгел генә танышуларына карамастан, алар бу минутларда үзләрен озак вакыт очрашмый торганнан соң, бер-берсен сагынган һәм, ниһаять, менә хәзер очрашкан якын кешеләрдәй хис иттеләр.

Бу дөньяда могҗизалар булмый дип санаган Хәйдәр бүген башкачарак уйлап куйды. Әтисе немец радисты турында сөйләгәндә, үзе ун яшьлек бала гына булса да, Хәйдәр аның бәянын яхшы хәтерли иде. Күрәсең, озакламый бу дөньядан китәчәген сизенгән булган – әтисе ул вакыйганы аңа кат-кат сөйләгән иде.

Инде шик калмады, әсир радист профессор Винфрид Мейернең әтисе Ортвин Мейер булган. Винфрид та инанды, кызылармеец Гарипов

Саматның улы хәзер Германиядә дәваланып ятучы пациент Гарипов Хәйдәр булып чыкты.

1944 елда булган бу вакыйганы Ортвин Мейер да улына күп тапкыр бәян иткән булган.

Шулай итеп, боларның һәр икесенә әтиләре кичергән хәлләр яхшы таныш, хәлбуки, Хәйдәрдән аермалы буларак, Винфрид ул вакыйганың нечкәлекләрен күбрәк белә иде.

– Гәрчә пленга эләккән булса да, ул көннәр әтиемнең сугыш елларыннан калган якты хатирәләре булып сакланды, – диде Винфрид.

– Шулай булмый ни... Чөнки исән калган, әсирлектән котылган, – диде Хәйдәр.

– Кеше киләчәккә дәртләнеп омтылсын өчен, Хәтер якты мизгелләрне саклыйдыр, күрәсең, – диде Винфрид, уйга калып. – Кайгылы мизгелләрне исә Хәтер якты мизгелләр инкарь ителмәсен өчен барлап торадыр. Нинди сынаулар аша үтәргә туры килгән әтиләребезгә, – дип куйды ул.

– Кешелек дөньясы сугышмыйча тора алмас инде ул, – диде Хәйдәр. – Сугыш стихия ул, буран кебек, җир тетрәү шикелле, су басу, янгыннар сыман. Әмма сугыш мәхшәрендә күпме аерым кеше язмышы – сөйләп, аңлап бетерерлек түгел.

– Шулай шул. Язмышлар – һәркемнең үзенеке. Гади кешенең күргәннәрен, кичергәннәрен, ул кеше фәкать үзе генә белә. Тарих өчен гади кеше язмышы берни түгел һәм тарихта уелып калыр өчен син йә изге кеше, йә канечкеч тиран булырга тиеш. Кеше генә булсаң, кемгә кызык син?.. Кайсы шәхеснең чынында нинди булганын дистә еллар узгач кем белсен...

– Аны үз вакытында да төгәл билгеләү мөмкин түгелдер инде, – диде Хәйдәр. – Кайчак, явыз ният белән, кеше игелек кыла, кайвакыт, игелек эшлим дип, кеше явызлык кыла. Шуңа күрә мин тарих фәнен яратмыйм һәм аны фән дип тә атыйсым килми. Тарих – берөзлексез языла торган зур бер бәян. Аңа һәр буын үзеннән ниндидер сюжетлар өсти.

– Килешәм, – диде Винфрид. – Моннан илле ел элек син яшәгән чор әле тарих түгел. Синнән соң килүче буыннар өчен тарихка әйләнәчәк ул. Чөнки алар ул чорны күрмәгән һәм үзләренә җайлы итеп язарга мөмкинлекләре булачак. Шунысы кызганыч, тарих кешеләрне бернәрсәгә дә өйрәтми һәм бернәрсәгә өйрәтмәгәнен дә аңлата алмый. Бу дөньяда тынычлык, тынгылык өмет итмә, дөнья бертуктаусыз хәрәкәтләнә. Хәтта син диваныңда тыныч кына ятам дигәндә дә, Җир шары сине мизгел саен үз күчәрендә әйләндерә һәм үз орбитасында йөртә. Зур көч, бөек бер хәрәкәт сине үзенә буйсындыра, син үзең һич аңламаган кануннар буенча кечкенә бер Җир шарында көн күрәсең. Синең уй-хисләрең, тойгы-кичерешләрең, кайсы мизгелдә нинди адым ясыйсың – бу универсум өчен әһәмияткә ия түгел, кешенең үзе өчен генә кыйммәт һәм мөһим нәрсә ул. Ясаган адымың киләчәкнең миллионлаган сукмакларының кайсысына баса – кеше өчен менә шунысы мөһим.

– Кешене ялгыш ясаган адымы өчен дә хөкем итү дөрес түгелдер, минемчә. Кеше үз теләге белән килми бу дөньяга. Шуңа күрә беркем беркемне гаепләргә тиеш түгел.

– Димәк, сезнеңчә, дөньяда гаепле кешеләр юк? – диде Винфрид, көлемсерәп.

– Шекспирга ияреп, Лев Толстой да: «Дөньяда гаепле кешеләр юк», – дигән.

Винфрид, кулын селтәп:

– Аларның да һәрберсе фәкать кеше генә бит, – диде. – Бу кадәре вәхши дөньяда гаеплеләрне билгеләп булмаса, димәк, кешеләрнең барысы да гаепле һәм һәркем гаепле. Кайберәүләрнең: «Кешеләрне яратам!» – дигәннәрен еш ишетәм. Ә мин моңа ышанмыйм. Минемчә, кешелек дөньясын яратырлык түгел. Гомумән алганда, инсаният мәхәббәткә лаеклы түгел. Аерым алган кешеләрне генә ярату мөмкин. Аерым алган шәхес бөтен кешелек дөньясына караганда кызыграк. Моңарчы яшәп килгән әдәбият, сәнгать тә бит аерым кешеләр турында иҗат ителгән. Халык төркеме түгел, шәхес кызыграк. Әле бөтен дөнья халкы турында әсәр иҗат иткәннәре юк.

– Сез хаклыдыр, – дип килеште Хәйдәр. – Әнә, Юлиус Фучик кешеләрне бик яраткан. Ә кешеләр аны барыбер асып үтергәннәр.

– Явызлыкка каршы көрәш игълан итәр өчен, үзеңә дә явыз булу кирәк шул, – диде Винфрид, беркавым дәшми торганнан соң. – Җиңәр өчен исә явызлыктан да явызрак булу зарур. Димәк, явызлыкны һич кенә дә җиңү мөмкин түгел.

Әңгәмә озак дәвам итте һәм бу сөхбәт аларны һичничек ардырмады һәм отыры тагын җиңел генә 1944 елның августындагы вакыйгага алып китте.

– Әле, бәлки, ул вакыйганың син белеп бетермәгән өлешләре дә бардыр, – дип куйды Винфрид.

**11**

Иван Константинович Самат белән әсирне икенче катка алып менеп китте. Бүлнис нык тетрәгән, бөтен җирдә пыяла ватыклары, кирпеч кисәкләре, чүп-чар ята, соргылт тузан куе катлам булып бөтен җиргә кунган иде.

Рацияне, әлбәттә, Саматка күтәреп менәргә туры килде, ә немец көчкә, ахылдый-вахылдый, ыңгыраша-шыңшый, көч-хәл белән менеп җитте. Шулай коридорда торганда, табиб агай, боларны кая урнаштырыйм һәм нишләтим икән диптер инде, кашларын җыерып, уйга калды.

Бу вакытта озынча, зифа буйлы бер кыз коридор башында салмак-талгын хәрәкәтләр белән идән себереп маташа иде. Боларны күреп, ул эшеннән туктады һәм зур кызыксыну белән көтелмәгән кунакларны күзәтте.

Немец, ахылдап, стена буенда ауган тумбочка өстенә утырды һәм башын салындырды. Ул гына түгел, Самат та исәнгерәгән иде, утырырга берәр урындык-мазар юк микән дип, як-ягына карады.

– Исемеңне ничек дидең әле? – дип сорады табиб, Саматка борылып.

– Самат.

– Менә шундый хәлләр, Самат, – дип, авыр сулап куйды агай. – Сугышка кадәр шәһәрнең бердәнбер здравпункты шушы иде. Шәһәр кечкенә. Кирпеч заводы, сөт-май комбинаты... Березняк халкын дәваларга хәлебездән килә иде, яткырып дәвалар өчен хәтта палаталар да бар иде. Хәзер инде моны берничек тә атарлык түгел.

Бу вакытта әлеге дә баягы кыз, боларны күзәтә-күзәтә, коридор башында идән себерүен дәвам итте. Әмма хәзер инде аның игътибары кулындагы

себерке белән чүп-чарлы идәндә түгел, ә көтмәгәндә килеп кергән ике солдатта иде.

– Нимес оккупациясе вакытындагы хәлләрдән хәзер дә йөрәк жу итеп тора, – дип, табиб сөйләвен дәвам итте. – Бөтен персонал нимес кергәнче үк качты, баш врач та фронт тарафына тайды. Минем качасым килмәде, монда калдым. Мин гомерем буе шушында хирург булып хезмәт иттем. Нимесләрне дәваларга, операцияләр ясарга туры килде. Безнекеләр килгәч, мине гаепләргә керештеләр, җавапка тартырга, хәтта атып үтерергә дә теләгәннәр иде. Полк командиры тидермәде. Шул полковник булмаса, мине, мөгаен, харап иткән булырлар иде. «Безгә бу хирург әлегә кирәк, аннары, сугыштан соң күз күрер...» – дип алып калды. Безнең полк монда озак тормады, тиз арада елганың аръягына күчте. Әлегә монда бернинди дә влач юк... – Хирург бераз пауза тотып: – Читтәрәк бомба төште, – дип куйды. Ярый әле бүлнискә төшмәде. Тәрәзәләр коелды, әнә теге яктан стена бераз җимерелде...

Беренче карашка бөтенләй табибка, хирургка охшамаган бу шыр сөякле, галәфи чалбар балакларын киң кунычлы күнитеккә кыстырган агайның эче тулы кайгыдыр сыман иде. Үзе дә кайсыдыр чит илдән килгән кешегә охшаган, яңак сөякләре беленеп, озынча борыны белән, бәләкәй күзләре, тырпаеп торган колаклары һәм юка иренле олы авызы белән бергәлектә, читтән караганда, ул карикатураны хәтерләтә иде. Әмма җентекләп карасаң, гел чалшаеп торган күзлеге артындагы күзләреннән аның чиксез сагыш һәм тирән акыл иясе икәнне абайларга мөмкин иде. Ябык булса да, кулларының көчле икәне бармак төзелешләреннән һәм хәрәкәтләреннән күренеп тора иде. Адымнарын саклык белән ясап атлый, гүя ялгыш адым ясаудан курка иде ул. Самат аның аягында вермахт солдатлары кия торган күнитек икәнне абайлады һәм дошман күнитеге турында сорау бирмәкче иде, әмма кыймады, тыелып калды.

Иван Константинович, гүя үзе белән үзе сөхбәт кыла иде, Саматка бөтенләй илтифатсыз булып, күптән түгел күргән-белгәннәрен салмак кына, бераз көйләгән шикелле итеп сөйләвен дәвам итте. Шул ук вакытта, бәян итү белән бергә, күргәннәрен, башыннан кичергәннәрен яңадан күз алдына китерә, хәтереннән үткәрә сыман иде. Кыяфәтеннән салкын битарафлык аңкып торган бу кеше өчен, күренеп тора – дошман да, дус та юк, кемнең кем яклы булуы аны бөтенләй кызыксындырмый иде.

– Гаскәрләр киткәннән соң, моннан җиһазларны да урлап бетерделәр инде. Караватларны да ташып бетерделәр, урындыклар, простынялар да юкка чыкты. Берни калмады. Бераз спиртны, берникадәр гади даруларны өйгә алып кайтып яшерергә җитештем. Бетте, юк хастаханә.

– Гаиләгез бармы? – дип сораган булды Самат, хирургның бәяны озакка сузылганга эче пошып.

– Улым да, кызым да сугышта. Улым Киевта институтта укый иде. Олы кызым – балалар врачы иде, Верхнегорскида эшләде. Кече кызым 1941 елның июнь уртасында Винницага кунакка киткән иде... Анда минем энем яши... Кызымнан да, энемнән дә бүгенге көнгә кадәр бернинди хәбәр юк. Хатыным өйдә... Бөерләре авыртып интегә. Менә шуңа күрә мин беркая да китмәдем, качмадым, монда калдым.

Иван Константинович сөйләүдән туктап, тирән уйга чумды. Самат, мөмкинлектән файдаланып, үзенең хәлен аңлатты, приказ үтисе барлыгын, ничек монда килеп чыкканнарын, немец радистын исән килеш Смерш бүлегенә тапшырырга тиеш икәнне кызып-кызып сөйләде.

Иван Константинович, килеп, беркавым әсиргә текәлеп карап торды.

– Ярасын сез бәйләдегезме? – дип сорады ул Саматтан.

– Мин, – диде Самат.

Табиб, канлы чүпрәкне чишеп, идәнгә ташлады һәм немецның иңбашын җентекләп карады, бармаклары белән яра тирәләренә баскалады. Немец берничә тапкыр ыңгырашып куйды.

– Пулясын алырга кирәк, – диде хирург.

– Алыгыз зинһар, – диде Самат. – Мин аның өчен җавап бирәм. Бик кыйммәтле әсир диделәр моны.

Көтмәгәндә, хирург коры гына:

– Документларыгызны күрсәтегез, – диде.

Самат аптырап китте.

– Мин бит сезгә сөйләдем инде! Мин сөйләгәнне тыңламадыгызмыни, ишетмәдегезмени? Ышаныгыз миңа, зинһар! Миңа бит әле үземнең полкны да куып җитәргә кирәк булачак. Минем приказ бар – моны, рациясе белән бергә, особый отделга тапшырырга. Аңлыйсызмы, юкмы?

Иван Константинович төссез күзләре белән шактый вакыт Саматка карап торды.

– Сиңа ничә яшь? – диде ул никтер.

Саматның ачуы килә башлады.

– Егерме! – дип җикерде ул һәм чалбар кесәсендәге «вальтер»ны капшап куйды.

– Минем кече кызга да егерме тула быел... – диде хирург чак кына ишетелерлек тавыш белән. – Исән микән ул?.. – Берникадәр вакыт уйга калып торганнан соң, ул коридор башында тузан туздырып маташучы кызга эндәште: – Света!

Света, күлмәк итәген җилфердәтеп, себеркесен болгабрак, йөгереп килеп җитте.

– Ташла инде ул себеркеңне! – диде хирург кызга. – Бар, спирт алып кил. Хатыным бирер. – Ләкин беравык идәнгә карап торды да кул селтәде. – Юк, үзем барып киләм. Син хәзер үк элекке баш врач бүлмәсендә операциягә урын әзерлә. – Аннары, Саматка карап, өстәп куйды: – Анда тимер рәшәткә, тимер ишек... Света, син ачкыч кайда икәнне беләсеңме?

– Миндә бит ул, – диде Света. – Янчыгымда.

Иван Константинович, әсирнең хәле тәмам бетмәсен диптер инде, кул ишарәләре белән аңа идәнгә ятарга кушты. Немец тумбочкада утыра бирде, аннары, ниһаять, аңлап, идәнгә ятты. Әмма хирург чыгып киткәч, әсир, ыңгырашып, әкрен генә гәүдәсен калкытты һәм иңбашын кулы белән тотып янә тумбочкага торып утырды.

– Идәннән җирәнәсеңме әллә, дуңгыз! – диде Самат, рацияле рюкзакны стенага терәбрәк.

Иван Константинович чыгып киткәч, Света коридор башына китмәде, Самат тирәсендә эш табарга тырышып, кем әйтмешли, юкны бушка аударып

йөрде – әле идәндә яткан кәгазьләрне алып укып караган булды, әле нидер эзләгәнгә сабышып йөрде.

Озынча буйлы, ябык, әмма коры сөякле дип әйтерлек түгел, төз гәүдәле, нечкә билле, зәңгәр күзле, кечкенә туры борынлы, хәтфә тавышлы гүзәл бу кызга төсе, чәчәкләре уңа башлаган күлмәге, аягындагы көрән туфлие, башына чөелгән ак яулыгы шундый килешеп тора иде. Җитмәсә, үзеннән күңелгә ятыш ниндидер тәмле үлән исе дә килеп тора иде. Самат бөтен дөньясын онытып, кызга карап катты.

– Синнән тәмле ис килә, – диде Самат, үзе дә сизмәстән.

Кыз моны бөтенләй көтмәгән иде. Ул шундый матур итеп елмайды.

– Мин көн саен Аглая түтәйгә дару үләннәре кайнатам. Мәрхүмә әбиемнең ерак туганы ул. Шул үлән исе сеңә. – Света үзенең кулларын нәфасәт хәрәкәт белән әкрен генә йөзенә китереп иснәп карады. – Чынлап та тәмле ис, – дип елмайды ул.

Самат кызның бармакларының төз, нәфис икәненә игътибар итте.

– Бу синең үзеңнең табигый исеңдер дип уйлаган идем, – дип шаярды ул.

Светаның җазибәле йөзе тагын да ныграк яктырып китте. Ул җәһәт кенә китеп барды һәм бүлмәләрнең берсеннән Саматка артсыз урындык алып килде.

– Утыр, – диде кыз, урындыкны стена буена куеп.

– Ә син? – диде Самат, кыздан күзләрен алмыйча.

Света кыланып, иреннәрен турсайтты да:

– Урындык берәү генә бит, – дип, көмеш кыңгырау тавышы белән көлеп куйды.

Югыйсә урындыкның берәү генә булуында нинди кызык булырга мөмкин инде?

Самат, ниндидер сихри көчкә буйсынып, урындыкка утырды, аннары, Светаның да үзенә текәлеп каравын күреп, шундук торып басты. Самат каушады. Түшендә Кызыл Йолдыз ордены, ике медале ялтырап торган батыр йөрәкле егет югалып калды. Соңгы тапкыр себерке белән тыныч кына идән себерүче нәзакәтле кызны кайчан күрде соң ул? Мондый гүзәл күренеш тә бар икән бит әле дөньяда. Сугыш бөтен нәрсәне үтереп, юкка чыгарып бетерә алмый икән. Дөньядагы барлык ямьле күренешләрне юк итү, яктылыкны тәмам сүндерү сугышның да хәленнән килми икән!

Ике күз карашы очрашты. Бу мәлдә ике яшь йөрәк, ике керсез аң уртак максатны сиземләделәр, ниндидер бөек бер мәгънә эстәп, ике җан арасында күзгә күренмәс җепләр сузылды.

Бу дөньяда бер нәрсә дә очраклы түгел икәнне кеше гомер кояшы баеганда гына аңлый башлыйдыр. Могҗизалар да юктыр, ахрысы, бу вәхши дөньяда – алар башка яссылыкта, шушы тирәдә, янәшәдә генә булырга мөмкиндер. Кайвакыт көтелмәгән хәл килеп чыга, әмма ул могҗиза була алмый. Чөнки, әгәр могҗиза чынга ашкан икән, ул инде могҗиза түгел. Тәгаен туры-тәңгәл килүләр дә сирәк була, китапларда, киноларда гына мөмкин ул. Чынбарлыкта могҗиза дип кабул ителгән нәрсәләрдән дә тирәнрәк, кыйммәтрәк хәлләр булырга мөмкин.

## 12

Сугыш тәмамлангач, еллар узгач, романнар, мемуарлар язырлар, фильмнар төшерерләр. Тетрәндергечләре, матурлары, тирән мәгънәлеләре булыр, әмма бер язучы да, бер режиссёр да, бер актёр да бүген ике кешенең – кыз белән егетнең арасында кабынган утны яңадан балкытып, укучыга, тамашачыга җиткерә алмас. Бүген, сугыш барганда, ике якты күңелдәге хисләрне еллар узгач, кемгә, ничек аңлатмак кирәк?! Бу сугыштагы газапның ни дәрәҗәдә тирән булганын да сөйләп, киләчәк буыннарны ышандыра алмаслар. Дәһшәтле елларда кичергәннәрне – газапны да, мәхәббәтне дә оныкларга аңлату мөмкин булмаячак, чөнки газап та, мәхәббәт тә халыкларга түгел, аерым кешеләргә генә хас һәм канлы еллардагы вакыйгалар аерым кешеләрнең язмышлары белән үрелгән.

Кыз белән егет бер-берсенә шактый вакыт карап тордылар, гүя алар күптән танышлар һәм, әйтерсең лә, алар бер-берсен сагынганнар иде. Әйе, алар сагынганнар. Егет – озакка сузылган окоп тормышыннан соң, ачык йөзле, җылы тәнле гүзәл кызга сусаган, кыз оккупацияләрдән качып, туганнарын югалтып, җан тынычлыгын җуйганнан соң, яшь егетне очратырга хыялланган иде.

Алар шундук икесе дә аңладылар – бу очрашу дөрес, бу кавышу булырга тиеш иде. Башкача мөмкин түгел, әгәр алар очрашмасалар, бу яшәештән ни мәгънә?!. Әгәренки алар бүген очрашмаган булсалар, табигатьтә төзәтелмәслек хата китәр иде, мөгаен. Моны аңлаулары хиссият дәрәҗәсендә тукталып, алар бу мизгелләрдә яшь акыллары белән ниндидер тирән серриятле бөек көчкә әсир төштеләр.

Самат кинәт үзен бәхетле итеп хис итте. Ярым җимерек булса да, бу хастаханәдә тыныч, монда дошман янамый, гүя ниндидер ызан сызылып сузылды да, каһәр суккан сугыш теге якта, кайдадыр еракта, ә ул дөньяның тыныч-имин тарафында калгандыр шикелле тоелды аңа. Әсир турында ул бөтенләй онытты, аның ыңгырашканы, имәнгеч тавыш белән иңрәп куюы, үз телендә нидер мыгырдавы колакны читләтеп үтә торды.

Светлана исә Иван Константинович ни кушканны онытты. Аңа да барлык михнәтләр, кайгылар, кан, күз яшьләре каядыр еракка китеп олакты кебек тоела башлады. Монда хәзер тынлык урнашты, монда тыныч, баштан кичергән бәлаләр калмады, киләчәктән куркыныч та юк шикелле иде. Фәкать менә шушы минутлар гына бар... Минутның эчендә секундлар... Секунд эчендә мизгелләр...

– Димәк, синең исемең Света? – диде Самат, кызга сокланып карап.

– Так точно! – дип матур иттереп кыланып җавап бирде Света. – Синеке?

– Самат.

– Самат? – диде Света, елмаеп. – Кызык исем... Самат... Евреймы?

– Юк, татар.

– Самат. Һем... – дип, матур итеп кашларын җыерды кыз. – Ни дигәнне аңлата?

– Самад – гарәп сүзе. «Нык, түземле, үзгәрми торган» дигән мәгънәдә. Минем исем шул гарәп сүзеннән. Соңгы хәрефе генә башка.

– Ә нишләп синең исемең гарәпчә?

– Чөнки мин – мөселман. Татарлар мөселманнар бит.

– Татар... Ә үзең русча әйбәт сөйләшәсең...

– Чөнки мин Казан егете, – диде Самат горур тавыш белән. – Син үзең хохлушкамы?

– Никак нет! – дип, тагы да матуррак әртистләнеп куйды Света. – Мин – рус кызы. Ә аның исеме ничек? – диде ул, немецка ымлап.

– Кемнеке? – дип аңламаганга сабышты Самат, кыяфәтен кинәт усалландырып.

– Әсирнеке.

– Белмим. Документын укырга өлгермәдем. Документы бандерачыларда калды.

Кыз коридорны яңгыратып, әсиргә эндәште:

– Ви һайс ду?[9]

Әсир башын калкытты, әмма дәшмәде.

– Ви һайс ду, диләр сиңа! – дип җикерде Самат. – Мөртәт! Җавап бир!

Әсир сыкраулы тавыш белән:

– Ortwin. Ortwin Meyer, – дигән аваз чыгарды.

Света немец янына якынрак килеп карап торды.

– Бигрәк әллә нинди бу, – диде ул, әсир яныннан әйләнеп килгәч. – Кайда тоттың син аны?

– Мин тотмадым аны. Кайда, ничек, кем тоткандыр, белмим. Әмма мин аңардан инде тәмам туйдым, гарык булдым.

Света, зәңгәр күз алмаларын киңәйтеп:

– Әйдә, үтерәбез аны, – дип, Саматка текәлде һәм рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Кызның күңел шатлыгы хәтта табигыйлек чикләреннән дә чыккан, әмма мондый шаяру да аңа шулкадәр килешеп тора иде. Боларның килүе кызның соңгы вакыттагы төксе көннәренә нindидер үзгәреш һәм бераз яктылык алып кергән иде. Күренеп тора – кыз боларның килүенә куана, хәтта әсир немец булганга да сөенгәне күренеп тора иде.

– Мин инде үзем дә аны әллә ничә тапкыр үтермәкче идем, – дигән булды Самат, әсир ягына күз ташлап. – Ярамый. Смерш бүлегенә тапшырырга приказ бирделәр.

Света стена буенда яткан рюкзакка туфли очы белән кагылды:

– Рюкзагың бик авыр бугай синең...

– Минеке түгел ул, – диде Самат. – Менә бу фашистныкы.

– Нәрсә соң анда?

– Рация.

Света йөзенә ясалма җитдилек чыгарып:

– Әйдә, сатабыз рацияне, – диде һәм тагын бинаны яңгыратып көлеп җибәрде. – Акчаны бүләбез.

Самат кызның оста кылануының аның үзенә бик килешеп торуына сокланып:

– Бик шаян кыз икәнсең, – диде.

– Әйе, мин шаян, – диде Света һәм кинәт җитди кыяфәткә керде. – Ә син нindидер моңсу...

– Чибәр кыз күрсәм, шундук моңаям мин, – дип елмайды Самат.

[9] Ви һайс ду – немецчадан: исемең ничек?

– Мин чибәрме? – диде Света, тагын да җитдиләнебрәк, мондый җылы сүзләрне кабат ишетәсе килеп.

– Бик гүзәл син, – диде Самат, ихлас күңелдән, соклануын яшермичә. Тавышың да искиткеч... Хәтфә тавышлы син. – Күлмәгең дә бик матур, килешеп тора үзеңә. – Һәм шаяруга күчте: – Сиңа хәтта ceберке дә килешә.

Света көлеп җибәрде.

– Менә бит, син дә шаяра башладың, – диде ул һәм кинәт пышылдауга күчеп, әсир ягына ымлады: – Карале, ничек усал карый безгә.

– Нишләсен инде ул, мескен, – диде Самат, вакытлыча булса да, немец турында онытып торасы килеп.

Светлана көлемсерәп әсиргә эндәште:

– Әй, портвейн! Ник усал карыйсың безгә?

– Ortwin! – диде әсир, исемен дөрес әйтмәгәнгә тагын да ныграк усалрак кыяфәткә кереп.

– Әсир белән чит кешеләр сөйләшергә тиеш түгел! – диде Самат коры гына.

– Матур кеше түгел бу, – диде Света әсир ягына карап һәм янына барып, аның иңбашына күз салды. – Ярасы нык түгел моның. Пулясын алгач, тиз төзәлер. Озак буласызмы монда?

– Бераз хәл алабыз да, үзебезнең частька юл тотабыз, – диде Самат. – Менә бу хәшәрәтнең хәленнән тора инде. Әллә, чынлап та, буып үтерергә генәме?..

Света тагын шаярырга тотынды:

– Әйдә! Тыпырчынмасын өчен мин аны аякларыннан тотып торырмын, син буарсың. Аннары рациясен сатып эчәрбез.

Икесе дә рәхәтләнеп көләргә тотындылар.

– Әллә нинди сүзләр чыга синнән, – диде Самат, көлә-көлә.

Көлеп арыгач, Света:

– Син кайдан? – дип сорады.

– Гаврилов дивизиясеннән, икенче полктан.

– Тумышың белән дим?

– Казаннан.

Света түшәмгә карап уйланып торды:

– Казаннан? Кайда әле ул?

– Татарстанда.

– Казакъстанда? – дип юри сорады кыз.

– Юри аңламаган булып кыланасың. Татарстанның башкаласы ул.

– Зур шәһәрме?

– Зур.

– Безнең Березняктан да зурракмы әллә? – диде Света, иреннәрен бөрештереп.

– Зуррак булмый, сезнең Березняк авыл шикелле генә бит.

Света, тагын нинди сораулар бирим икән дип уйлап, егет каршында әрле-бирле йөрде дә кинәт:

– Хәзер, алма алып киләм, – диде.

Света коридор башындагы бүлмәләрнең берсеннән өч алма алып килеп, берсен Саматка, икенчесен әсиргә бирде дә өченчесен үзе шытырдатып ашый башлады.

– Danke schon, – диде немец, кызга елмаерга тырышып. Әмма елмая алмады, ыңгырашып, алма тоткан кулын иңбашына куйды.

– Аша, тәмле булсын, – диде Света.

– Ник аңа алма бирдең? – диде Самат, кырысланып.

– Ярар инде, ашасын. Смерш аны әллә исән калдыра, әллә юк. – Ул кинәт сискәнеп китте: – Ой! Миңа бит Иван Константинович операциягә урын әзерләргә кушты. Тизрәк! Әйдә, булыш миңа!

Света каяндыр йөгереп кенә, ачкыч алып килде, аннары, коридорның икенче тарафындагы, кайчандыр баш табибныкы булып саналган бүлмәнең ишеген ачты.

Самат, кереп, бүлмәгә күз йөгерткәндә, Света:

– Карават бар, су бар... Кирәкле даруларны хәзер Константиныч алып килә, – диде. – Онытканмын бит. Син дә әйтмисең. Урын әзерләргә кирәк. Константиныч минем башымны ашаячак.

Әсирне главврач бүлмәсенә алып кереп, менә-менә таркалырга торган артсыз урындыкка утырттылар. Немецның хәле мөшкел, ярасы нык авыртканы күренеп тора, Света биргән алманы да ашый алмаган, коридор идәненә төшереп калдырган иде.

– Geben Sie mir bitte Wasser[10], – дип ыңгырашты әсир.

– Су сорый бугай, – диде Самат.

Света тиз генә банка белән су алып килеп, Ортвинга эчертте.

Стенага терәлеп торган караватны, абаланып-кабаланып, бүлмә уртасына күчерделәр. Пружиналы караватның матрас астына өч такта куелган иде – күрәсең, монда авыруларны караганда, кирәк чакта караватны кушетка урынына да файдаланганнардыр һәм баш табиб үзе дә шушында ятып ял итә торган булгандыр, мөгаен. Света, күп юуудан үтә күренмәлегә әйләнгән простыняны шкафтан алып, караватка җәйде – җәймә саф ак төстә түгел, күпне күреп, мең кат юылган чүпрәккә охшаган иде. Баш врачның шкафында, шушы җәймәдән кала, таушалып беткән иске пинжәк, бөкесез графин һәм саргаеп беткән кәгазьләр генә бар иде.

– Әсирең моннан кача алмаячак, – диде Света. – Тәрәзәдә тимер рәшәткә, ишек тә тимердән. Шуңа күрә Константиныч операцияне монда ясарга булды да инде. Пулясын алгач, перевязкалардан соң, шушында ятар.

– Өстеннән бикләргә кирәк булыр, ачкычны миңа бир, – диде Самат, әсир берәр җай табып качмагае дип шөбһәләнеп.

Света ачкычны биргәндә, Самат аның йомшак кулын, учына алып, җибәрми торды.

– Җибәр, – дигән булды Света, кырысланган булып кыланып. Ә үзенең эче-тәне буйлап көчле һәм рәхәт дулкын йөгереп үтте.

Саматның каушавы юкка чыкты.

– Минем сине дә пленга аласым килә башлады, – диде ул, кыюланып һәм көлеп куйды.

Света исә:

– Син әле монысын да илтеп тапшыра алмыйсың, – дип җавап бирде, немецка ишарәләп.

– Ә мин сине беркая, беркемгә тапшырмас идем, гел үзем белән

[10] Geben Sie mir bitte Wasser – немецчадан: Зинһар су бирегез!

генә йөртер идем, – диде Самат, тавышына аз гына да шаяру төсмере кертмичә.

Бу сүзләр кызга бик көчле тәэсир итте. Ул Саматка күзләрен тутырып карады. Күренеп тора – кыз әсирлеккә риза булыр иде.

**13**

Иван Константинович әсирнең иңбашыннан алган пуляны тәрәзә яктысында әйләндергәләп карады да чиләккә ташлады. Яраны марля белән бәйләгәч, Света укол кадады һәм берничә минуттан Ортвин йокыга китте.

– Кайчан аякка баса бу? – дип сорады Самат.

– Ике-өч көннән, – диде Иван Константинович. – Канны күп югалткан. Хәлсезлеге шуннан аның.

Иван Константинович ике банка тушёнка белән ярты ипи алып килгән иде.

– Аңа ашарга кирәк, – диде ул. – Ачлыктан организмы арыкланган.

– Алайса хәл кергәнче ул монда ятсын инде, – диде Самат.

– Кайда ятсын инде ул тагын, – диде хирург. – Света, берәр караватт калдымы әле безнең?

– Ундүртенче бүлмәдә бар, – дип җавап бирде кыз.

– Матрас?

– Матрас та бар.

Ул, Саматка борылып:

– Син, иптәш солдат, шунда йокларсың, – диде. – Света, иртәгә перевязка ясарсың. Спиртны чамалап тот. Бүтән юк. Иртәгә үзем дә кереп чыгармын. Минем эшләрем күп... – дип, уйга калды ул. – Ярар, вакыт табармын, – диде хирург, тагын җанланып. – Әсирне Верхнегорскига илтергә җай эзләп карарга кирәк. Шул якка баручы машина очрамасмы. Булмаса, ат эзләп карыйм. Нигә аны монда берничә көн яткырырга?

– Ә транспорт табылмаса? – диде Самат.

– Нимес, әйткәнемчә, ике-өч көннән генә җәяү бара алачак. Верхнегорскига моннан егерме чакрым. Кызганычка каршы, телефоннар һаман эшләми, юкса шалтыратыр идек тә, килеп алырлар иде.

– Хаҗәтен ничек башкарыр икән ул? – диде Самат. – Мин бит аны өстеннән бикләячәкмен. Гел ишек төбендә утырмам бит инде.

– Света, чиләк кертеп куй, – диде Иван Константинович. – Графин белән су алып кил.

Света хирург кушканнарны үтәгән арада Самат:

– Дошманга операция ясаганда, сездә аны кызгану хисе буламы ул? – дип сорап куйды.

Хирург Саматка карап, чак кына елмайды:

– Бу дөньяда сиңа кем дошман икәнне – кем белгән...

– Ничек инде?..

– Без, кешеләр – барыбыз да, һәрберебез киләчәк буыннарга – ашлама гына.

– Мин сезне аңламадым, – диде Самат, чынлап та хирургның әйткән сүзләренә төшенә алмыйча.

– Беркем дә бу дөньяга үз теләге белән килми, хәтта бу бичара әсир дә.

Дошманнар, безнекеләр, имеш... – Ул күзләрен йомып, тирән сулыш алды. – Газапның чиге-азагы юк. Нигә бу?.. Ни хакына? Нинди гөнаһлары өчен бу сугыш дүрт яшьлек кызның ике кулын да өздерде? – Хирургның чыраеннан газап саркыды. – Ул бала, миңа карап, кулларын кайтарырмын дип өметләнде... Күз алдымнан һаман китми.

– Сез коммунистмы? – диде Самат, хирургны мондый авыр хисләрдән арындырырга теләп.

Беркавым дәшми торганнан соң, Иван Константинович:

– Минем коммунист буласым килми, – диде. – Хәзер хирург буласым да килми. Миңа инде хәзер кеше булуы да авыр. – Аның тавышы калтырап чыга башлады. – Кеше буласым килми, аңлыйсыңмы?! Минем берәр бөҗәк буласым килә!

– Сезне сугыш алҗыткан, – диде Самат.

– Сугыш кынамы... Сугышка кадәр дә кайгы, газап җитәрлек булды. Куркыныч авырулар, яман чирләр сугыштан соң да булачак. Минем хатын, бөерләре каты авырта башлагач, гөнаһларым күп булды микәнни дип, сыктанып ята. Гөнаһлар кыласы булгач, Алла бу вәхши дөньяга кешеләрне ник тудыра икән соң?.. Бомбага тотылып, нигезенә кадәр җимерелгән шәһәрдә меңәрләп кеше һәлак булган икән, нәрсә, шул кадәр күп гөнаһлы кешеләр яшәгән микәнни анда?.. Күпме кайгы, күпме кан!.. Күпме күз яше!.. Бу хәлләрдән соң да алга таба Җирдә кешеләр яши алачаклар микәнни? Бу бик сәер һәм, никтер... куркыта. Яшәү дәвам итсә дә, алга таба кешеләр рәхәт яши алмаячаклар.

– Шул тыныч, рәхәт яшәр өчен сугышабыз бит инде, – диде Самат. – Киләчәгебез имин булсын өчен дошманны дөмбибез.

Иван Константинович Саматка карап, дымлы күзләре белән елмайды.

– Син кайсы яктан?

– Казаннан.

– Әйбәт егет син, – диде хирург, Саматка туры карап. – Аста, керә торган ишектә йозак юк. Анда, ишек кырыенда күсәк сөялгән. Шуны аркылы куеп бикләрсең. Света! Киттек! Анда мин бераз ипи, ике банка тушёнка калдырдым. Берсе сиңа, берсе әсиргә.

– Аңладым, – диде Самат. – Рәхмәт, Иван Константинович.

– Монда төнлә мародёрлар керми калмас. Урларлык әйбер булмаса да, алар һаман киләләр. Син алардан курыкма. Алар үзләре синнән куркачаклар, куып җибәрерсең.

– Минем коралым бар, – дип, кесәсенән «вальтер»ны чыгарып күрсәтте Самат.

«Әйе, бу егет атарга да мөмкин», – дип уйлап куйды хирург һәм:

– Атмасаң яхшырак булыр, – диде. – Әйдә, Света, киттек. Иптәш солдат, безнең арттан ишекне бикләп кал.

Самат кызның монда булуын бик теләгән иде. Әсиргә укол кадарга, йә каны ага башласа, перевязка ясарга кирәк булмагае дигән сылтау белән, Светага здравпунктта бераз тоткарланырга мөмкин түгелме дип сорамакчы да иде ул, әмма кыймады, читенсенде.

Чыгып китәр алдыннан Иван Константинович беренче катта, коридорның уң як башында душ бүлмәсе бар икәнне әйтте.

– Су акрын ага, әмма юынырлык, – диде ул. – Анда сабын кисәге дә булырга тиеш. Сөртенергә берәр чүпрәк табарсың.

Самат, аларны озаткач, ишеккә эчке яктан күсәкне аркылыга урнаштырды да икенче катка менде.

Әсир янына керер алдыннан, ишекне ачканчы, коридордан колак салып тыңлап торды. Тынлык. Самат әкрен генә ишекне ачты. Немец йоклый иде. Сары кашлары җыерылган, авыр сулый – әллә начар төш күрә, әллә йокысы шундый... Урындыкта тишкәләнгән, берничә җирдән ертылган һәм канга буялып беткән кителе эленеп тора. Чалбарын салдырмаганнар, күнитекләре почмакта ята. Самат тушёнканың берсен һәм ипинең яртысын сындырып, караваt янындагы тумбочкага куйды, бүлмәдән чыккач, ишекне йозакка бикләп, коридор буйлап атлады. Күз алдында гел Света тора, колакта аның хәтфәле тавышы яңгырый. Бар көченә: «Света!» – дип кычкырасы килде аның.

Ул кайчандыр палата булып хезмәт иткән бүлмәләрне карап чыкты. Берсендә, хирург әйткәнчә, матраслы карават бар иде. Кулында ризык барлыгын искә төшереп, тушёнканы тәрәзә төбенә куйгач, утырып, ипине ашады һәм кранны ачып караган иде, су ага икән, рәхәтләнеп су эчте.

Бүлнистә электр уты юк иде, караңгы төшкәнче душта юынырга кирәк дип, Самат бүлмәләргә кереп сөртенер өчен чүпрәк эзләде. Җимерелгән шкаф такталары арасында иске, кайчандыр ак төстә булган җәймә тапкач, ул беренче катка төшеп китте.

Юынгач, тән рәхәтләнеп китте. Тимер карават та йомшак булып тоелды. Ә башта гел бер генә уй иде – Света!

Тышта караңгы төшеп килә иде. Тын вә сакин әбелхәят үз кочагына алды һәм Саматны әкренләп, йокы баса башлады.

Кинәт аста дөбердәгән тавыш ишетелде. Самат, уянып, беравык аңышмыйча ятты – кайда ул? Тышта инде төн, ә бүлнис эчендә тагын да караңгырак иде. Аста катырак дөбердәделәр. Ишекне кагалар түгелме?

Самат караңгыда стенага ышкыла-ышкыла, берничә тапкыр абынып, аска төшеп җитте.

– Кем анда? – дип Самат ишекнең теге ягына эндәште.

– Бу мин – Света, – дип ишетелде тыштан.

Света! Әйтерсең лә, Саматның бик якын кешесе каядыр китеп торган да менә хәзер кайтып кергән. Бүген очрашачакларына барыбер өметләнгән иде бит ул. Хыял гамәлгә ашты, теләге кабул булды. Бик нык теләгәнгәдер, бәлки...

– Ипи, сөт алып килдем, – диде Света, еш-еш сулап.

Самат, чиксез куанып, шул ук вакытта гаҗәпләнеп тә:

– Ничек курыкмадың килергә? – диде.

– Кемнән?

Самат кызның җылы сулышын тойды. Кызның тыны җылы агым булып, үзәккә үтеп керде.

Ташландык палата тәрәзәсеннән Ай яктысы төшеп, төнге дөньяның Күк тарафы кыз белән егетнең мәхәббәтенә шаһит булды. Ни гаҗәп, югыйсә төн бит, әмма Самат өчен иң якты көннән дә яктырак төн иде бу. Тар гына тимер карават та кысан түгел, иркен, йомшак, җайлы булып тоелды. Ике

сулыш бер сулышка әверелде, ике йөрәк бер көйгә типте. Ике язмыш, ике юл кушылгандай, киләчәк офыгына сузылыр кебек иде.

Света бу болгавыр елларда беренче тапкыр үзен бәхетле хис итте. Кирпеч заводының механик вазифасында хезмәт итүче әтисен 1940 елда, донос буенча нахакка хөкем итеп, Себер якларына озаттылар. Бер ай да үтмәде, шул ук завод директорының шофёры булып эшләгән абыйсын да кулга алдылар. Икесе дә сәвит властен каргауда гаепләнеп, юкка чыктылар һәм менә инде кайчаннан бирле хатлары да, хәбәр-хәтерләре дә юк. Ирен, улын хөкем итүләре әнисенең сәламәтлегенә каты китереп бәрде – йөрәге авыртып интегә башлады. Хәзер ул Верхнегорскида, сеңлесе Серафима апа янында иде. Светаның күптән Верхнегорскига әнисе янына барырга нияте бар, әмма Иван Константинович әлегә монда булырга куша – җимерек булса да, бүлнистә булырга кирәк, ди, имеш, шушы көннәрдә Березнякка хакимият билгеләнәчәк, телефон элемтәсе урнашачак.

Светаның бер кыю теләге туды – Самат белән әсиргә ияреп, Верхнегорскига барырга. Әмма Иван Константинович рөхсәт итмәячәк шул, ә аның ризалыгыннан башка китәргә ярамый иде. Ярар, тиздән әнисе дә Березнякка кайтачак инде. Әлегә ул Верхнегорскида торсын, анда дәваланырга мөмкинлекләр күбрәк, Серафима апаның район медсанчастенда дуслары бар, шунда йөртә ул аны.

Самат Светаның эче тулы моң икәнне тиз арада аңлап алды. Аның шаярулары, кылanулары кайгыдан арынырга, эчке киеренкелектән котылырга тырышканнан икән ләбаса. Тавышының моңы да күңелендәге тирән сагышыннан иде аның. Аннары... Самат кызның күңеленә бик хуш килде, шаян булып күренергә тырышуы да күбрәк шуннан иде, ахрысы.

Самат сораргамы, юкмы дип икеләнеп торганнан соң:

– Нимесләр монда чакта кайда идең? – диде.

– Мин, алар килгәнче үк, ерак авылга качтым, әтинең туганнан туган апасында яшәдем. Әни монда үзе генә калды, ул үзе мине, немецлардан куркып, анда озатты. Әни өчен борчылып, гел ут йотып яттым. Җитмәсә, апа бик кырыс, усал кеше, әтиләр нәселеннән димәссең. Аллага шөкер, безнең өйгә нимесләр кермәгән, әни үзе өйдән бик сирәк чыга торган булган... Аннары, оккупация тәмамлангач, кайттым. Әни йөрәк белән нык бимазалана башлагач, Верхнегорскига сеңлесе янына бардык. Монда үзебезнең бүлнисне күрәсең бит инде – врачлар да, дарулар да юк. Әнине Верхнегорскида калдырып, кире монда кайттым, чөнки Иван Константинович монда калуымны үтенеп сорады. Верхнегорскидан бер нәчәлник кисәге килеп, тиздән Березнякта сәвит власте яңадан урнаша, бөтен нәрсәне торгызабыз, фәлән-фәсмәтән, диде. Миңа зур хезмәт хакы вәгъдә итте. Бу ярым җимерек бинада нишләргә тиеш икәнебезне генә әйтмәде... Иван Константинович үзен барыбер харап итәчәкләр дип йөри. Тимәсәләр ярар иде аңа... Шундый әйбәт кеше...

Саматның сүзне икенчегә борасы килде.

– Мародёрлар килми, нишләптер, – диде ул, көлемсерәгән булып.

– Шулар гына җитмәгәние монда, – диде Света, егеткә ныграк елышып.

Самат, кызны кочагына алып:

– Безнең җитди эш белән шөгыльләнүебезне чамалаганнардыр, мөгаен, – дип пышылдады.

– Бәлки бүтән килмәсләр инде, монда урларлык әйбер калмады бит, – диде Света, иреннәрен чак кына кыймылдатып.

Света егет кочагында изрәп йокыга китте, бераздан Самат үзе дә төшләр дөньясына чумды.

Самат уянуга, Света инде торып, аның гимнастёркасын, чалбарын юган һәм аларны ачык тәрәзә капкачларына киптерергә элеп куйган иде.

– Хәерле иртә, иптәш красноармеец! – дип сәламләде Света, караватъ кырына утырып.

Самат, елмаеп:

– Хәерле иртә, – дип җавап бирде һәм торып утырды.

Света йомшак кулы белән аның такыр башын сыпырып:

– Синең пилоткаң кайда? – диде.

– Бандерачылардан качканда төшеп калды, – диде Самат.

Ул Светаны кочаклап, караватка яткырмакчы булды, әмма кыз аның кулларыннан җитез генә шуып чыгып сикереп торды һәм оста итеп кыланып:

– Отставить, иптәш красноармеец! – дип, буш бүлмәне яңгыратты. – Һәр эшнең үз вакыты була.

Ул ишек капкачында эленгән гимнастёрка белән чалбарны барып капшап карады:

– Боларын, кипкәч, киярсең дә, күлмәк-ыштаныңны юармын, – диде Света, тәрәзә капкачларын киңрәк ачып.

– Безнең фашист ничек икән анда? – диде Самат, киерелеп.

Әсир кичәгечә чалкан яткан, кыяфәте дә шул ук иде. Самат белән Света кергәч, ул күзләрен ачты.

Аңа ипи белән сөт бирделәр. Аннары, тамак ялгаганнан соң, Света аның иңбашын яңадан чиста марля белән бәйләп куйды.

– Danke schon, – диде Ортвин, моңсу елмаеп.

– Исән бул, – диде аңа Света.

Саматның моңа ачуы килде:

– Чык тизрәк, ишекне биклим! – дип җикерде ул. – Исән бул, имеш...

– Ярар инде, ул да кеше бит, – диде Света, Самат ишекне йозакка бикләгәндә.

– Кеше... Тапкан кешене... Хәзер тотам да караватында яткан килеш атып үтерәм!

Света ягымлы итеп елмайды һәм Саматка елышты:

– Юк, син хәлсез кешене тик торганда үтермисең. Син бит герой... Орденың, медальләрең бар. Син чирле-чинке кешегә кул күтәрә торганнардан түгел. Син бик әйбәт, олы җанлы... Син... ниндидер... җылы кеше...

Шул сүзләр белән Света аңа күзләрен тутырып карады. Самат эреп китте – кызның әйткән сүзләренең ихласлыгы аның күз карашыннан күренеп тора иде.

Самат уңайсызланып куйды. Светаның әсир белән ягымлы сөйләшкәненә ачулануының сәбәбе бер генә ләбаса – көнләшү. Эшсөяр, җанҗылымлы бу кыз аңа бик якын бит хәзер. Матур булмаган бер генә хәрәкәте дә, ягымлы булмаган бер генә чалымы да, җанга ятмаслык бер генә сыйфаты да юк бит аның! Һәрьяктан мөкаммәл бу кыз асылда һич кенә дә чәпчек түгел,

танышканда уенчак булып кыланган гына иде бит ул. Хәер, шуклык та килешә иде үзенә, шаянланганда да, аның нәзафәтле кыз икәне күренеп тора һәм килеш-килбәте, бәрхетле тавышы, үзен тотышы – гүзәл, кызык һәм үзенә магнит сыман тарту көченә ия иде.

Коридор буйлап бергә әрле-бирле сөйләшеп йөрү дә рәхәт иде аларга. Чәчәкле күлмәк кигән кыз белән янәшә ак күлмәк-ыштанлы кешене читтән күзәтүчегә бу күренеш мәзәгрәк күренер иде, мөгаен. Яшьләр бу турыда уйламадылар да. Шулай да Света, исенә төшереп:

– Гимнастёрка белән чалбарың кипкәндер инде, – диде. – Хәзер «белуганы» юармын. (Солдатның эчке киемен «белуга» диләр иде).

Шул вакытны шыпырт кына Иван Константинович пәйда булды һәм боларга шактый вакыт дәшмичә карап торды. Света гына түгел, Самат та уңайсызланып куйды – хирург теләсә кайсы вакытта килергә мөмкин икәнне онытканнар, чөнки алар инде үзләрен бу дөньяда икесе генә калган кебек хис итәләр иде.

Бүген Иван Константинович эшләпәсен кимәгән иде, Самат аның артка тарап яткырылган ап-ак чәченең үзенә бик килешеп торуына игътибар итте – иске эшләпәсе генә аны сәләмә итеп күрсәткән булган икән, бүген исә килеш-килбәтеннән аның гаять фәһемле кеше икәнлеге әллә каян күзгә ташланырлык иде.

Үткен күзле хирург, килеп керүгә үк, егет белән кыз арасында нидер булганны сизенде. Ул тагын ике банка тушёнка алып килгән иде, шуны биргәндә, Саматка кырыс караш ташлап:

– Сезне илтергә транспорт табалмадым, – диде. – Хәер, булса да, аны кем миңа бирә... Элемтә дә юк, телефоннар дәшми...

Света, беравык нишләргә һәм ни әйтергә белми торганнан соң:

– Мин бәрәңге пешереп алып киләм, – дип, тиз генә чыгып китте.

Иван Константинович, кереп, әсирнең ярасын карады, йөрәген, тын юлларын, үпкәсен тыңлады. Аннары, бер сүз дәшми, аска төшеп китте. Кичә бик күп сөйләшкән иде, ә бүген никтер дәшми... Самат, бераз пошаманга калып, аңа ияреп төште.

Ишегалдына чыккач, Иван Константинович, каядыр алга карап:

– Кыерсытма Светаны, – диде.

Самат аптырап китте.

– Ник кыерсытыйм, ди, мин аны?..

«Ник алай диде икән Иван Константинович? Светаның монда кунганын сизде бугай», – дип уйлап куйды Самат.

– Рацияне, бәлки, монда яшереп калдырырсыз, – диде Иван Константинович. – Миндә ярамас. Мине бүген-иртәгә алып китүләре ихтимал. Оккупациядә чакта немесләрне дәвалаганым өчен җавапка тартмый калмаслар. Рацияне миндә тапсалар, тагын әллә нинди коточкыч җинаятьләрдә гаепләячәкләр. Светалар йортында калдыру да ярамас – әтисе, абыйсы хөкемгә тартылганны исәпкә алып, кызга әлләниләр тагулары мөмкин. Монда, бүлнистә яшерерлек урын да юк инде... Уйларга кирәк.

Ә Саматның яралы немец белән җансыз рация турында бөтенләй уйлыйсы килмәде һәм полк командирының фәрманын барыбер үтәячәкмен дигән ышаныч белән, шул ук вакытта, әлеге дә баягы приказга үзеннән-

үзе җиңел генә хәл ителәчәк нәрсәгә караган кебек карый башлады. Аның бөтен җанын-тәнен мәхәббәт яулап алды. Хәзер ул үзе тоткын хәлендә иде. Җиңеп булмый торган көчле хис аны кулга алды, әсир итте.

**14**

Бүген әле мәхәббәтнең икенче төне иде.

Мәхәббәт кабынсын өчен күп вакыт кирәкми. Бу бөек хис, очкыннан ялкын кабынган сыман, мизгелләр эчендә туарга мөмкин. Ә инде соңыннан, вакыт узгач, ләззәтне дә, сагышны да, илһамны да, газапны да үзенә алган шул сөюнең тәэссораты өчен Күк тарафларыннан айлар, еллар сарыф ителергә мөмкин.

Мародёрлар килмәде, кыз белән егеткә беркем комачауламады, хәтта төнлә палата тәрәзәләрен киереп ачкач, черкиләр дә кермәде.

Алар бер-берсенә нык гашыйк булдылар. Уртак бер хис-уй икесендә берьюлы туды – әйтерсең лә, бу дөньяга бер-берсен табар өчен туганнар, гүя сугыш та алар өчен башланган һәм Ортвин Мейер дә аларны очраштырырга дип әсир төшкән...

Самат Светаның йөрәк тибешен тыңларга ярата. Шул тынгысыз йөрәк-кошчыкны ике учына алып үбәргә иде... Каяндыр һичничек барып җиталмаслык тирәнлектән мизгелләрне саный-саный типкән йөрәгенең канатлары да бардыр шикелле. Бу бәхетле минутлар, якты мизгелләр тиз арада үтеп китәчәк бит... Туктатырга иде Вакытны. Бик озакка булмаса да, ничек тә туктатып торырга иде аны.

Үтә шул, тиз үтеп китә сәгадәтле минутлар. Гомер дә үтеп китәчәк бит. Әле кайчан гына Самат бала иде, күптән түгел генә үсмер чагы гөрләп үтте, урамда еш сугышканы өчен «Чукмар» кушаматын алган иде... Хәзер инде дарыны күп иснәгән, атакаларга күтәрелгән, разведкаларга йөргән, окопларда күшеккән солдат ул.

Света башын Саматның күкрәгенә салган. Кызның таралган чәче тәнне кытыклап ала. Кызның җылы сулышы да беркая китми, егетнең тәненә сарыла.

– Шушы караватт, һаваларга күтәрелеп, Казанга очып алып китсен иде, – диде Самат, хыялланып.

– Казан зур каламы?

– Зу-у-ур, – диде Самат, тавышын калынайтып, – гаҗәеп зур!

– Мәскәүдән дә зуррак түгелдер әле, – диде Света, үчеклисе килеп.

– Мәскәүдән зуррак түгелдер, әмма Мәскәүгә караганда күпкә гүзәлрәк, ямьлерәк.

– Ышанмыйм, – диде Света. – Синең Мәскәүдә булганың бармыни?

– Юк.

– Алайса ничек инде Мәскәүдән матуррак дип әйтә аласың?

Самат, кинәт илһамланып:

– Чөнки Казан бит ул! – диде. – Мәскәү Казаннан һич кенә дә ямьлерәк була алмый.

Аның болай дию е Светага бик ошады. Бу егеттән үзенең туып-үскән каласы хакында башка җавапны көтмәгән иде ул.

– Мин сине йөз ел беләм шикелле, – дип пышылдады Света, Саматның колагын кайнар сулышы белән «өтеп».

– Алай ук карт күренмисең бит син, – дип шаярды Самат һәм икесе дә рәхәтләнеп көлеп куйдылар.

– Синең иңбашыңда кечкенә миң бар... Кичә үк күрдем... Җилкәңдә ике җөй бар, яраланган идеңме әллә?

– Кыйпылчыклардан, – диде Самат. – Яра дип әйтерлек түгел.

Света аның борынына бармагы белән кагылды:

– Борының сикертмәле...

– Ундүрт яшемдә... сугышканнан калды ул. – Самат киерелеп куйды. – Их, шул көннәргә кире кайтырга иде.

Света көлеп җибәрде:

– Борыныңа суккан көнгәме?

– Сугышкан чаклар да сагындыра, бөтенесе сагындыра... – Самат кызны кочагына алды. – Әй, юк, ул көннәргә кире кайтмас идем. Чөнки анда, ул көннәрдә син юк. Ә менә бүгенге көндә мәңгегә калырга иде!

Самат кызны кайнар иттереп иреннәреннән, битеннән, күзләреннән үпте. Шуннан соң үсмер чагында ук язган кыска гына шигырен әйтеп куйды:

Һаваларда ак болытлар,
Җил көенә ага алар,
Шулар белән минем көннәр
Офыкларга агылалар.
Бертуктамый гомер ага,
Безнең гомер мизгел генә, –
Ак болыттай барып иңәр
Әбелхәят итәгенә.

Татарча булгач, Света, әлбәттә, аңламады һәм:

– Шигырьме? – дип сорады.

– Әйе, – диде Самат. – Унбиш яшемдә язган шигырем.

– Син шигырьләр язасыңмыни? – диде Света, гаҗәпләнеп.

– Язгалыйм. Татарча.

– Бу шигырең ни турында?

Самат аңа русча аңлатты:

– Болытлар белән көннәрем офыкларга агыла... Бертуктамас бу агымда гомер бер генә мизгел ул... Минем гомер дә ак болыт булып, Мәңгелекнең итәгенә бер барып иңәр...

– Бигрәк ямансу. Унбиш яшьтә шундый шигырь язгансың... Гомернең үтүе турында... – Света аңа ныграк елышты. – Минем турыда берәр шигырь яз әле.

– Шигырьне мин татар телендә генә яза алам. Русча да язып караганым бар... Әмма килеп чыкмый, дөресрәге, кытыршы языла, чын шигырьгә охшамый.

– Булсын, – диде Света. – Минем турыда да татарча яз. Аннары, русчага тәрҗемә итеп, миңа аңлатырсың.

– Ярар.

Самат әсир яткан бүлмәнең түр почмагына куелган рацияне исенә төшереп:

– Рацияне күтәреп йөрмәбез, – диде. – Монда, берәр җирдә яшереп

калдырырга кирәк булыр. Верхнегорскида әсирне тапшырганда әйтермен, килеп алырлар. Монда подвал бармы?

– Бар.

– Подвалда яшереп калдырырга мөмкин микән?

– Анда төшәргә куркыныч, – диде Света, шомлы тавыш белән. Безнекеләр килгәч, анда сигез мәет таптылар. Партизаннарга үч итеп, фашистлар сигез кешене шунда алып төшеп үтергәннәр.

– Кайда калдырып торырга соң аны?

– Миндә, миндә, безнең өйдә! – диде Света, җанланып.

Рация үзләренең өендә булса, Самат белән элемтә өзелмәс кебек тоелды Светага. Рацияне алырга, бәлки, машина белән Самат үзе дә килер, ничек кенә булмасын, рация аның өендә торса, Самат белән тагын очрашырга мөмкинлек чыгар дип ышанасы килде кызның.

Самат шәрә тәнгә гимнастёркасын, чалбарын киеп, күлмәк-ыштанын Света юып элгәч, Ортвин янына кереп чыктылар. Әсир Света алып килгән бәрәңгене ашаган, болар кергәндә, ул тәрәзәдән тышка карап тора иде. Самат Иван Константинович алып килгән фонарьны кабызгач, Ортвин яктылыктан йөзен чытты һәм әкрен генә барып, караватка ятты.

– Хәле яхшыра, ахрысы, – диде Самат.

– Аллес гут?[11] – дип кызыксынды Света.

Әсир дәшмәде. Саматның башына кинәт: «Озаграк хәлсез ятса ярар иде...» – дигән уй килде, чөнки аның монда, Света янында буласы килә иде. Һәм шундук бу уйны башыннан куды. Приказ бар! Приказны үтәргә кирәк!

***

Төн уртасында Самат фонарьне Светага тоттырды, үзе аркасына рацияне асты һәм алар здравпункттан чыгып киттеләр.

Березняк тып-тын. Ара-тирә ерактан этләр өргән тавышлар гына ишетелеп куя. Рәхәтләнеп сулый торган саф, рәхәт һава тәнне генә түгел, җанны иркәләде. Борынга каяндыр бөтнек исе килеп керде. Бер адәм заты күренми. Тәрәзәләрдә ут юк.

Самат, туктап, аркасына аскан рацияле рюкзакны җайлабрак куйды.

– Авырмы? – диде Света.

– Юк ла, – диде Самат. – Тиздән синең белән аерылабыз – менә анысы авыр булачак.

Алар шактый вакыт дәшми атладылар.

– Казанда сине берәр кыз көтәме? – дип сорады Света.

– Юк, – диде Самат. – Үзебезнең урамдагы бер кыз белән йөргән идек... Аралар ничектер үзеннән-үзе өзелде. Аңардан соң башка кыз белән танышырга өлгермәдем, сугыш башланды. Әтине сугышның беренче көннәрендә үк алып киттеләр, егерменче елгы абыемны – октябрьдә.

– Алар исәндер бит? – дип куркып кына сорады Света.

Самат шактый вакыт җавап бирми торды.

– Әтинең похоронкасын кырык беренче елның декабрендә алдык... – диде ул сүренке тавыш белән. – Абыемныкы 1942 елның сентябрендә килгән... Ул вакытта мин инде сугышка киткән идем.... Әни хатта язып

[11] Аллес гут? – немецчадан: бар да яхшымы?

хәбәр итте. – Самат шактый вакыт дәшмичә барганнан соң: – Әти бик оста сварщик иде, Казандагы иң зур төзелешләрдә эшләде, – дип куйды. – Абый төзүче-инженер иде.

– Тагын кемнәрең бар гаиләдә?

– Хәзер инде әнием генә.

Төн тынлыгында Светаның көрсенеп куйганы ишетелде.

– Синең егетең сугыштадыр? – дип сорады Самат.

– Юк. Фронтка минем ерак туганнарымнан гына берничә кеше китте. Минем егетем бар иде... Әмма безнең җитди мәхәббәт булмады. Бала-чагаларча гына...

– Ул кайда соң хәзер?

– Аны Германиягә алып киттеләр. Харап булгандыр инде ул анда. Ул синең кебек көчле егет түгел иде.

– Сагынасыңмы аны?

– Сагынам дип... Кызганам мин аны.

– Сине күргәч, гашыйк булмый калучы юктыр.

– Алай очраган берсе гашыйк була дип әйтмәс идем.

– Син бик чибәр. Бик матур кеше син.

– Яратасың син мине, Самат, – диде Света, чак кына ишетелерлек итеп. – Шуңа шулай тоеладыр. – Самат дәшмәгәч, Света: – Яратасыңмы мине? – диде, егетнең «яратам» дигәнен үзеннән ишетәсе килеп.

– Яратам! – дип, Самат Светаны бер кулы белән иңеннән кочты. – Шулай тиз арада болай гашыйк булырмын дип уйламаган идем, болай нык ярату мөмкиндер дип, башыма да килмәгән иде.

– Их син! Мин үзем сорагач кына яратам дидең, – диде Света, үпкәләгән сыман итеп.

Самат, тавышына хәйләкәрлек төсмерен кертеп:

– Мин синең сораганыңны көттем дә инде, – диде. – Ә син мине яратасыңмы?

– Мин сине күрү белән үк ярата башладым, – диде Света, һич кенә дә тартынмыйча. – Синең үзеңә кызлар адым саен гашыйк булалардыр...

– Белмим.

– Татарлар мондыйдыр дип уйламаган идем мин, – диде Света, көлемсерәп.

– Нинди?

– Синең кебек.

– Ничек соң ул – минем кебек?

– Әллә тагы...

Света Саматка сеныбрак атларга тырышты һәм бер мәлне, караңгыда егетнең йөзен күрергә теләп, фонарьне аңа терәп диярлек төбәде.

– Сукырайтасың бит, – диде Самат, башын читкә борып.

Хәл алырга туктагач, Самат рюкзакны салып, җиргә куйды.

– Сүндер фонарьне, – диде ул һәм кызны кочагына алып кайнар иттереп үпте.

Ике кайнар тән салкынча төнне җылытырлык көчкә ия иде. Алар әле араларындагы якынлыкны үзләре аңлап бетермиләр, аң белән эшкәртеп җиткермиләр иде.

– Син мине тиз онытырсың, – диде Самат, көтмәгәндә үзенә хас булмаган боек тавыш белән.

– Ник алай дисең?

– Кызларның хәтере кыска бит аларның...

– Юк, сине оныту мөмкин булмас, – дип пышылдады Света. – Мин сине югалтудан куркам.

– Сугыштан мине көтәрсеңме?

– Көтәм, көтәм, көтәм! – диде Света дулкынланып.

– Чын әйтәсеңме?

– Самат! Синеке бит инде мин! – диде Света, егетне үзе үбеп.

Йолдызлы төн. Дөм караңгы. Әмма алар арасындагы яктылыкны иң караңгы төннәр дә сүндерә алырлык түгел иде. Егермешәр яшьлек кыз белән егет арасындагы мәхәббәтне беркем күрми, белми, аңламый, бу илаһи халәт фәкать икесе өчен генә, икесенеке генә иде. Ике кешенең мәхәббәте башкаларга беркайчан да аңлашылмый. Ике йөрәк бер көйгә типкәндә, бер үк мизгел уртак була һәм бары тик аларныкы гына ул. Уртак мизгелләр Мәңгелекнең аерым бер өлешенә барып иңәдер һәм шунда сакланадыр. Ике кешенең уртак хисләре кайнаган мизгелләр гади мизгелләр түгел, яшәешнең асылына бәйле, кыз белән егет өчен генә түгел, гомумән, кешелек дөньясына гаять кыйммәт һәм бөек мәгънә салынган мизгелләрдер.

Света Саматның хыялларында, күңел төпкелендә, кайдадыр аң астында үзеннән-үзе яшәгән инде ул. Син бу дөньяда үзеңдә алдан ук яшәгән кешене генә очратып ярата аласың, аны очратканчы син бу хакта белмисең генә.

Мәхәббәттә кешене ни өчен яратканыңны әйтү мөмкин түгел, дөресрәге, белеп булмый. Чөнки сөю – бәһасез нәрсә – кешенең барлык сыйфатларыннан да өстенрәк, үлчәп, бәяләп, ярлык тагып булмый торган, хәтта аңлап бетермәслек бөек төшенчә. Дөньяда коточкыч сугыш барганда, кан, күз яше Җиргә сеңгән бу чорда да бәхетле булырга мөмкин икән!

Ярый әле бу вәхши дөньяда бәхетле булырга беркемнән дә рөхсәт алу кирәкми – Сталиннан, сиңа пулемёттан ут сиптерүче дошманнан, полк командирыннан, Смерш офицерларыннан, окопта янәшә яткан иптәшләреңнән, өстән бомба яудыручы очучылардан...

Рөхсәт алырга кирәк булса, беркайчан бәхетле була алмас идең.

Саматның барган юлны, урамнарның як-ягындагы йортларны күрәсе һәм барысын да хәтерендә калдырасы килде, әмма берни күренми, тирә-юньдә ерып чыккысыз караңгылык иде.

Саматның үсмер чагында язган шигъри юллары исенә төште:

...Төн белән көн арасында сызык булмый;
Бу Җиһанның бер төшен дә сызып булмый...

Ниһаять, алар Света яши торган йортка килеп җиттеләр. Кечкенә капка: «Ник төн уртасында борчыйсыз инде!» – дигән сыман, зарлы тавыш белән чак кына шыгырдап ачылды. Света өйалды ишегенең яңагы артына яшерелгән ачкычны алды.

Өйгә керү белән үк, биткә Саматның күңеленә хуш килгән үлән исе бөркелде – таныш, тәмле, якын, Светадан гел килеп торган, җанга ятыш хуш ис.

Света керосин лампасын кабызгач, шактый киң, иркен йортның эче азмы-күпме яктырып китте. Аермачык күреп булмаса да, өй эчендәге җиһазларны, әйберләрне абайлап, бу йортта кайчандыр ризыклы, тулы канлы, имин тормыш кайнаган икәнне чамаларлык иде.

Светага Аглая түтәй катык биреп җибәргән булган. Алар агач кашыклар белән, маңгайларын терәшеп, көлешә-көлешә катык ашадылар.

– Әнине сагындым, – дип, авыр сулап куйды Света. – Әллә, барысына кул селтәп, сезнең белән мин дә Верхнегорскига барыйм микән... – дип, уйга калды ул. – Иван Константинович орышыр инде. Район үзәгеннән күн папка тотып килгән нәчәлник минем аркада Константинычка каты бәрелергә мөмкин. Күп итеп хезмәт хакы түләргә вәгъдә биргәннәре өчен түгел, Иван Константинович сораганга гына әлегә монда мин. Акча түлиселәренә ышанмыйм. – Света тагын көрсенеп куйды. – Ә Иван Константиновичны алда ниләр көтә – бөтенләй билгесез. Ичмаса үзе дә телен тыя белми, кайвакыт, сәясәткә кереп, артыгын әйтеп ташлый торган гадәте бар.

Иван Константинович аңа бик якын кеше, Светаның әтисе, ашказаны авыртып, хастаханәгә килгәч танышканнар, шуннан аралаша башлаганнар, дуслашып киткәннәр иде. Света Верхнегорскида фельдшер курсларында укыганнан соң, эшкә Березнякка кайтуны Иван Константинович кайгырткан иде. Сугыш башлангач, Света хәрби пункттан чакыру көтте. Әнисен котсыз калдырып, мобилизация пунктына үзем барам, дип тә йөргән иде әле ул. Ире, улы бер гаепсезгә хөкем ителгәннән соң, ана кеше сөекле кызының фронтка омтылуына каршы килде. Дөресен әйткәндә, Света үзе дә икеле-микеле уйлар белән хафаланды. Мин дә китсәм, әни берүзе нишләр... Әни бөтенләй ялгыз калачак лабаса. Шулай ниндидер бер катгый карарга килә алмый йөргәндә, оккупация башланды һәм Света Березняктан ерак авылга китеп барды.

Агач караватат киң, аңа йомшак матрас җәелгән, бу матрасны, әнисе каты чирли башлагач, Иван Константинович аларга здравпункт складыннан алып биргән иде.

Керосинкадан төшкән яктылык алар өчен кояш кебек, ике яшь йөрәк өчен бу минутларда лампасыз да яктылык җитәр иде.

– Света, – дип пышылдады Самат. – Мин сине яратам!

Аның пышылдап әйтүе бу кыйммәтле өч сүзне кыздан башка беркем дә ишетмәсен һәм алар фәкать Светага гына аталган дигәнне аңлата сыман иде.

– Мин дә сине шундый яратам, – дип пышылдап җавап бирде Света. – Минем белән мондый хәлнең моңарчы әле беркайчан да булганы юк иде.

Света, шәрәтән килеш торып, тумбочканы ачты да нидер эзли башлады. Светаның буй-сыны керосинка яктысында тагын да матуррак һәм серлерәк булып күренде, бу күренеш өндә кабатланмый торган төш кебек иде.

Света өстәлгә тумбочкадан нәрсәдер алып куйды да эчке күлмәген киде.

– Блокнот белән карандаш бирәм сиңа, – диде ул. – Онытканчы бирим әле. – Кирәге чыгар. Минем турында берәр шигырь яза калсаң, шушы блокнотка язарсың. Үзем биргән блокнот булгач, бәлки, шигырең шәп чыгар. Адресымны язып куйыйм әле. – Ул Саматка борылып карады. – Хат язарсыңмы миңа?

– Минем инде хәзер үк сиңа хат яза башларга теләгем туды, – дип, Самат

чалбарын киде. – Адресыңны блокнотның уртасынарак яз. Беренче битләр тиз юешләнә, ныграк таушала.

Блокнотның урта битләренең берсенә үзенең адресын язып куйгач, Света:

– Бу сугышта күпме адреслар буталып, чуалып, юкка чыгып беткәндер, – дип, уйга калды.

– Сугыш кайчан да булса бетә, – диде Самат, янәшә утырып. – Адресларны яңадан барлап, табып була.

– Адресларын табып буладыр, кешеләре табылмаска мөмкин, – диде Света. – Беркөнне тәрәзә төбендәге гөлемнең, тамырлары көчле булсын өчен өске ботак-яфракларын кыркыдым... Ботакларын кискәч, гөл нигә тамырларын тирәнгәрәк суза икән?.. Якты дөньяга өметен җуеп, аска таба үсә башлый микән әллә ул?..

– Якты дөньядан ваз кичәргә ярамый, – диде Самат йомшак тавыш белән. – Минем инде фронтларда күрмәгәнем калмады, ә шулай да тулаем алганда дөнья ямьле дип саныйм. Менә бит, көтмәгәндә, синең белән очраштык.

– И Ходаем, яңа көн ниләр алып килер икән? – дип, олыларча әйтеп куйды Света.

– Һәрбер көнне көтеп алырга, аңа куанырга кирәк. Һәр яңа көн – бөек һәм кабатланмас. Чөнки һәрбер көн – кемнеңдер туган яки туасы көне. Кемнеңдер үлгән яки үләсе көне. Һәр көн үзенең бөек серләренә ия.

– Бик матур сөйлисең, Самат. Син гади генә нәрсәләрне матур иттереп әйтә беләсең. – Света Саматның ишек катындагы рюкзакка карап куйганын сизеп алгач: – Рацияне базга яшерәбезме? – диде.

– Күгәрмәс микән ул анда? – диде Самат.

– Тычкан кимермәс микән? – диде Света, көлемсерәп.

– Кимерсеннәр. Тычканга жәл түгел. Тычканнар үзебезнекеләр, – диде Самат, көлеп.

Света башын Саматның иңенә салды һәм алар шактый вакыт шулай тып-тын, бер-берсенең сулышын тыңлап утырдылар.

– Рацияне яшерик, – диде Света, иреннәрен чак кына кыймылдатып. – Яңа көн туып килә бит...

– Кая яшерәбез?

– Түбәгә менгерсәк, яхшырак булыр, – диде Света.

Самат кузгалып:

– Яктыра башлаганчы, яшерергә кирәк, – диде.

Алар, кабаланып, рацияне өй түбәсенә алып менеп, түр почмакка куйдылар, Света рюкзакны иске япма белән каплап, аның өстенә тагын ниндидер чүпрәк-чапрак ташлады.

Түбәдән төшкәч, алма исле, җанга рәхәт һавалы дымсу бакчада йөрделәр. Дөньяның бөтенләй тынлыкка чумуын теләмәгәндәй, җәйге төн ара-тирә үзенең төрле авазларын бирә – алмагачтан өзелгән алмалар тып-тып итеп җиргә төшә, әнә, гаҗәеп тизлек белән песи йөгереп үтте, еракта, бер-берсенә хәбәр биреп, этләр өрә һәм тагын күптөрле кыштырдавык тавышлар ишетелеп куя иде.

Бөтен җирдә, хәтта төнлә дә яшәү дәвам итте.

– Дөньяның рәхәт урыннары, якты мизгелләре беркая да китмәгән, – диде

Самат. – Менә бит, сезнең бакчада сакланып калган ул. Мондый хозурлыкны бернинди сугыш та җиңә алмаячак.

Кыз белән егет туачак көнне кочаклашып каршыладылар. Яңа беленеп килгән таң исә аларның икесен дә үзенең назлы кочагына алды.

**15**

Әйе, Җир йөзендә миллиардларча тапкыр булган котылгысызлык кабатланды – яңа таң ата башлады. Өйгә кереп, бераз йоклап булмасмы дип уйлаганнар иде... Кая ул! Нинди йокы?!

– Безнең Ортвин ничек икән анда? – дип куйды Света.

Светаның әсир немецны «безнең» дип әйтүенә Саматның ачуы килмәде. Хәзер инде Ортвинга карата Саматның нәфрәте бөтенләй калмаган иде. Бу бәхетле очрашуда әсир фрицның да өлеше бар бит. Әгәр дошман радисты булмаса, хәзер татыган илаһи мизгелләр насыйп булыр иде микән?..

Светаның әсир турында әйтүе Саматны һавалардан җиргә төшерде.

– Миңа бүлнискә барырга кирәк, – диде Самат. – Чынлап та анда әсир берүзе ята бит.

Саматның Светаны үзе белән бүлнискә алып барасы килә, әмма әйтергә генә кыймый иде. Аерыласы килми, бәгырьләр серле җепләр белән бер-берсенә бәйләнде, китеп барсаң, элемтә өзелер дә, шарлап кан агар төсле иде.

Ә Света егетнең: «Әйдә минем белән», – дип әйтүен көткән иде.

– Иртәгә... Әй, бүген бит инде... Киләсеңдер бит минем янга? – диде Самат басынкы тавыш белән.

Света исә тыйнакланып тормады (шундый якынлыктан соң нишләп үз кешесеннән оялсын инде!) – ярым караңгылыкта Саматның күзләрен «табып»:

– Самат! Мине хәзер үзең белән алып бармыйсыңмыни? – диде.

Алар кинәт кочаклаштылар һәм шактый озак шулай басып тордылар. Самат кызны битеннән, күзләреннән, чәчләреннән үпте:

– Әйдә минем белән, дип әйтергә читенсендем, – диде ул. – Синең йокың туймыйдыр, ял итәргә кирәктер...

– Нинди йокы, нинди ял?! Самат!

Света, кабаланып, мич янындагы чиләктән кәрҗингә алма тутыра башлады.

– Быел алма бик мул уңды, коелып әрәм була. Алманың коелганы тәмлерәк тә әле, – дип сөйләнә-сөйләнә, Света бакчада кичә генә җыелган алмаларны тутырды да тутырды.

Аннары әлүмин котелокка калган катыкны салды һәм, Саматның кыл сакал-мыегы җитеп килгәнне истә тотып, әтисенең кырыну пәкесен дә үзе белән алырга онытмады.

***

Алар кергәндә, Ортвин ың-шыңсыз ята иде.

– Йоклый, – диде Света, пышылдап.

– Нишләсен инде ул? – диде Самат, озакламый әсирне Верхнегорскига алып барасын исенә төшереп һәм шуңа сөмсере коелып.

Света әсир яткан караватянындагы тумбочка өстенә дүрт алма куйды, катык салынган котелокны да шунда калдырды.

– Уянгач, ашар, – диде Света. – Аннары мин аңа перевязка ясармын. Соңрак бәрәңге пешереп алып килермен... Бәрәңге ярата бугай ул.

Саматның моңа һич кенә дә ачуы килмәде. Әле кичә генә, җавап итеп, берәр авыр сүз әйтеп ташлар иде, хәзер исә, киресенчә, Светаның якты күңелле, игелекле булуына сокланып карады. Аның уйлары хәзер гел Светада гына иде. Кызларча, аналарча, хатыннарча җанҗылымлы бу кыз бөтен нәрсәне дөрес эшлидер, кешеләр менә шушындый затларны тыңлап, алар кушканча яшәргә тиештер дигән хис бар иде Саматта бу минутларда.

Алар беренче төнне кунган бүлмәдәге караватта янәшә утырып, алма ашаганда, Иван Константинович килеп керде.

– Сез ишекне эчтән бикләргә оныткансыз, – диде хирург, килеп кергән уңайга.

– Монда хәзер керүче юк инде, – диде Света, каушап.

– Тушёнкам бүтән юк, – диде Иван Константинович, Саматка туры карап. – Тегеләрен миңа немецләр калдырган булгандыр дип уйлама. Мин алар киткәч, подвалда бер коробка тапкан идем. Бетте. Соңгы икесен кичә сезгә алып килдем. Ә сохарием әле бар.

Иван Константинович гәҗит кәгазенә төрелгән сохарине тәрәзә төбенә куйды. Бу юлысы Иван Константиновичның килеп керүе никтер Саматның ачуын китерде:

– Сохари дә фашистлардан калдымы? – дип, чәнчүле тавыш белән әйткәнен ул үзе дә сизми калды.

Хирург дәшмәде, ә Самат андый сорау биргәненә шундук эчтән генә үкенеп куйды.

– Рацияне яшерергә кирәк, – диде Иван Константинович тыныч кына.

– Мин яшердем инде аны, – диде Самат.

– Кайда?

Самат сорауны ишетмәгәнгә сабышты. Дошман рациясен Светада калдырганын Саматның әйтәсе килмәде, ә Иван Константинович исә кабат сорап, төпченеп тормады.

– Иртәгә иртән юлга кузгалыгыз, – диде хирург. – Әсирнең егерме чакрымны үтәрлек кенә көче бар. Елганы кичәргә җыенган совет частьларының тылына немецләр чыгарга маташа дигән хәбәр ишеттем. Хәзер үз частеңа барсаң, немецләргә юлыгуың ихтимал.

– Тылга барырга кирәк – Верхнегорскига. Мин шунда барырга җыенган идем дә инде. Смерш отделы шунда бит. – Самат уйга калды. – Алар да дивизия артыннан елга буена китмәделәр микән... Ярар... Комендатура бар бит анда, шунда тапшырырмын. Немеснең хәле барыбер әйбәт түгел шул әле...

– Район үзәгенә моннан егерме чакрым. Сезгә ничек булса да барып җитәргә кирәк инде, – диде Иван Константинович.

Света коридорга чыгып киткәч, Иван Константинович Саматка текәлеп карады:

– Их, егет, егет... Нишләттең син Светаны? – диде ул хафалы тавыш белән.

Самат дерт итеп куйды:

– Ник алай дисез?

Иван Константинович тәрәзә янына барып басты.

– Ник дип... Тагын нәрсә дип әйтим соң инде... Яшьлек, яшьлек диген... Ул миңа үз кызым кебек бит... Шундый саф күңелле кыз бала... Әтисе дә, абыйсы да исән түгелләрдер инде балакайның... Әти-әнисе белән тыныч кына яшәп, яраткан кешесенә кияүгә чыгып, бәхетле булырга язмаган микәнни аңа?! Менә син хәзер китәрсең, ә аның күңелендә синең белән булган мизгелләр тын гына, әмма каты газап булып яшәячәк. Син аны, вакыт узгач, бәлки, онытырсың да, ә башка берәү аны «җилбәзәк» дип битәрләячәк.

– Мин яратам аны, – диде Самат, хирургка таба атлап.

– Һәркем үзен генә ярата, – диде Иван Константинович. – Кешенең табигате шундый. Юкса Җирдә сугышлар булмас иде.

– Алай димәгез. Сугыштан соң мин монда киләм. Мин аны Казанга алып китәм.

– Әгәр син бу сугышта исән калмасаң?..

– Мин һәлак булмаячакмын! – диде Самат, нык дулкынланып. – Мин исән калачакмын!

– Сугыш беркемнән дә үтеримме-юкмы дип рөхсәт сорап тормый. Үлем синең яшисе килүеңә төкерә ул.

– Мин үлмим!

Иван Константинович елмайды:

– Син әле малай гына бит. Сабый гына. Әмма бик яхшы егет син. Сөю белән нәфрәт хисләре кешенең үз теләге белән түгел, ихтыярсыз туа торган хисләр. Алар кешедә берьюлы бергә яши алмыйлар. Кеше көчле сөю хисләре кичергәндә, беркемне дә дошман италмыйдыр. Шулаймы?

– Белмим.

– Син бу радистны да хәзер дошман итмисең бит инде...

– Барыбер дошман ул. Мин инде аны берничә тапкыр атып үтерергә дә теләдем, – дигән булды Самат, чынында андый теләге булмаса да.

– Хәзер атмыйсың инде син аңа. Нык ярата белгән кеше үтерергә ашыкмый ул. Син дә белмисең, бу әсир дә белми – киләчәктә нинди язмыш көтә... Һәр икегез белән нәрсә булыр – иртәгә, бер ел узгач, гомер кояшы баеганда... Исән булсагыз инде... Балаларыгызны нинди язмыш көтә... Әгәр балаларыгыз булса инде... Үтермәскә кечкенә генә сәбәп, мөмкинлек булса да, үтермә. Ашыкма үтерергә. Кем белгән, бәлки, балаларыгыз киләчәктә дуслар булырлар, бер-берсенә кирәк булырлар, бер-берсенә ярдәм итәрләр... Дөнья бик киң түгел ул, планета зур түгел...

– Син бу фәлсәфәләреңне, әнә, аңа укы, – диде Самат, әсир яткан бүлмә ягына ишарәләп. – Нимесчә аңлат, русча аңламаячак.

– Җибәр син аны. Теләсә кайсы якка китсен. Киләчәгегез менә бүген нинди гамәл кылуыгыздан торырга мөмкин.

Еллар узгач, Самат хирург әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенәчәк. Ә 1944 елның августында Самат әле яшь иде. Хәер, шул чагында ук Иван Константиновичның ни әйтергә теләгәнен аңлаган суратта дә, әсирне иреккә җибәрә алмас иде ул. Аның өчен приказ һәм шуны үтәү барлык фәлсәфәләрдән өстен иде.

– Мине моның өчен хөкемгә тартачаклар, – диде ул ачулы тавыш белән. – Трибунал!

– Мин болай да синең өчен куркам әле, – диде Иван Константинович тонык кына тавыш белән. – Верхнегорск комендатурасында бу нимесне генә түгел, сине дә, кем икәнеңне ачыклаганчы, ябып куячаклар. Аннары, махсус кешеләр килеп, нишләп әле атна буе нимес радисты белән татар егете адашып йөргәннәр дип тикшерергә тотыначаклар. Сиңа приказ биргән кешеләр һәлак булсалар?.. Андый приказ алганыңны исбатлый алмасаң?.. Син хәзер документсыз... Коралың юк... Рацияне дә монда калдырасың...

Саматның кыяфәте кинәт усалланды.

– Син, Иван Константинович, дошманнар белән озаграк булгансың бугай, – диде ул, хирургка якынрак килеп. – Мине куркытырга маташасың, радистны азат итәргә өндисең...

– Юк ла, дөрес аңламыйсың. Мин бит синең өчен дә борчылам.

– Ничек булса да, әсирне азат итәргә минем хакым юк. Мин аны Смершка тапшырам.

– Булдыра алсаң ярый да... Сугыш барыбер иртәме-соңмы тәмамланачак. Рус та, нимес тә, татар да, япон да тыныч яши башлаячаклар, дуслашачаклар, алар барысы да бер-берсенә кирәк булачаклар. Әлбәттә, дошманның башкалары табылачак. Бүгенге дус, еллар узгач, дошманга әйләнергә мөмкин, хәзерге дошман, бәлки, дустың булыр...

– Киләчәктә ни буласын уйлап утыра торган вакыт түгел, – диде Самат, мондый нотыклы әңгәмәдән туеп.

– Икегез дә харап булмассыз микән?..

– Булмабыз. Нишләп мин харап булыйм, ди! Мин үз җиремдә, фашистлардан азат ителгән территориядә йөрим. Һәм мин әсир дошманны тиешле органнарга илтеп тапшырачакмын.

Иван Константинович көлемсерәп куйды:

– Нинди дошман инде ул. Син аның кыяфәтен кара?

Саматның ачуы чыга башлады:

– Ник яклыйсың син аны?!

– Мин Беренче Бөтендөнья сугышында Германиядә пленда булган кеше... – диде Иван Константинович. – Фронт госпиталендә хирург идем мин. Чолганышта калдык, әсир төштем. Германиядә без, ун кеше, көн саен андагы бер байга эшләдек. Яхшы ашаттылар, бернинди кыерсыту, кимсетү күрмәдек. Брест-Литовск килешүеннән соң, азат иттеләр һәм Россиягә, өйгә кайттым. Фронтка патша Россиясеннән киткән идем, пленнан большевиклар иленә кайтып төштем...

Самат кызып китте һәм хирургның сүзен бүлеп:

– Пленда тәмле ашаганыңа күрә, монда дошманнарны дәвалап яттыңмы? – дип әйтеп ташлады. – Шуңа бу әсирне кызганасыңмы?

– Берничә дистә ел эчендә халык вәхшигә әйләнә дип ышанмыйм мин. Сәбәбе тирәндәрәктер, без аны аңлый алмабыз, мөгаен. Дошман – кешенең үзендә ул. Тумыштан ук кеше булсаң да, кеше икәнеңне гомер буе исбатлап яшәргә кирәк. Язмыш шуның өчен кешегә сынаулар биреп тора. Мул итеп бирә язмыш сынауларны – хәлле булсаң да, хәлсез булсаң да. Аны хәйләли алмыйсың, чөнки үзеңнән дә хәйләкәррәк булу мөмкин түгел. Беркем дә

үз иреге белән генә үтми гомер юлын. Бу дөньяда бөтен нәрсә мәҗбүри. Хәтта үлгәч тә син котыла алмыйсың, чөнки үлгәч тә, Киләчәк сине үз кочагына алачак.

– Син миңа боларны ник сөйлисең? – диде Самат, аптыраштa калып.

– Чөнки синең күзләреңдә нур бар, – диде Иван Константинович, бу җавабы белән Саматны бераз гаҗәпләндереп. – «Дошманнарны дәвалап яттыңмы», – дидең... Мин бу дөньяда кайда дошман, кайда дус – аңламый башладым инде.

Самат, үзен кулга алып:

– Профессияңнән туймадыңмы, иптәш хирург? – диде. – Арымадыңмы?

– Мине яшәү алҗытты. Авыру хатыным бар... Балаларымны күрергә әле өметләнәм... Мине шулар гына тота бу дөньяда. Кеше – гомере буе үзеннән үзе качарга хыялланучы тоткын. Беләсеңме, кеше, яши-яши, ник үзгәрә? Ул яшьлегеннән китмәскә тырыша кебек, ә аның вөҗүде акылына караганда да «акыллырак» һәм элекке халәтеннән, кичәге «мин»еннән качарга омтыла.

– Иван Константинович, сез мине гафу итегез инде, – диде Самат соңгы вакытта хирургка «син» ди эндәшә башлаганнан соң, янә «сез»гә күчеп. – Мин ике ел инде фашистларга каршы сугышам, миндә нәфрәт көчле... Ачуланмагыз миңа, зинһар. Сезнең бу фәлсәфәләрегез үзегезгә хилафлык китермәс микән, шуны уйлап куйдым әле мин.

Беравык дәшми торганнан соң, хирург Саматка елмаеп карады:

– Энем, бу сугышта исән калсаң, синең дәвамың затлы булачак... Балаларың үзеңә охшаячаклар.

– Фашист заразасын бетерәсе бар әле башта, – диде Самат. – «Исән калсаң» дип дөрес әйтмәдең. Мин исән калачакмын! – Самат тагын «син»гә күчте. – Синең, иптәш хирург, шушы заманда беркемне дә дошман итмәвең бик сәер, әлбәттә... Шикле кеше син...

Иван Константиновичның «Бу сугышта исән калсаң, синең дәвамың затлы булачак... Балаларың үзеңә охшаячаклар», диюен Самат төчелек дип кабул итте һәм кинәт, үзе дә сизмәстән, тагын кыза башлады:

– Төкерәм мин теге Герман сугышында ниләр булганына! Сине алар азат итеп, өеңә кайтарганнар икән, әле немесләр әйбәт дигән сүз түгел ул. Бу Ортвин Мейер атлы кабахәт безгә сугыш белән килгән – үтерергә, яндырырга, таларга, көчләргә. Без болай да инде кирәгеннән артык игелек күрсәтәбез бугай...

– Аны бит мәҗбүр иткәннәр. Ул берәр кешене үтерде микән, юкмы – син белмисең бит.

– Ә бәлки үтергәндер.

– Үтерсә дә, мәҗбүр иткәннәр аны, тирәнрәк уйлап баксаң.

– Бәлки, мин аңа бирелергә, аның әсиренә әйләнергә тиештер?..

– Син үзең дә әсир инде, – диде хирург тыныч кына.

– Аңламадым?..

– Сез икегез дә әсирләр. Әмма хәзер үк икегез дә азат була аласыз. Синнән тора.

– Гафу ит, Иван Константинович, син бигүк тулы түгел бугай, – диде Самат, тәмам аптырашта калып.

– Тулы белән тулы түгелнең чиген хәтта медицина да төгәл билгели

алмый. Кеше психикасында норма кайда тәмамлана, каян тайпылыш башлана – моңа әле иң бөек профессорлар да төшенмәде.

Самат инде тагын кыжрый башлаган иде, әмма Иван Константинович палатадан чыгып, коридорда борчылып торган Светага игътибар итмичә, баскычтан әкрен генә беренче катка төшеп китте. Бераз бөкрәебрәк, ябык булса да, гәүдәсен авырлык белән тоткан бу агайга Саматның шундук бер ачуы да калмады. Балаларының язмышын белми, хатыны урын өстендә авырып ята... Әсирлекнең ни икәнен үзе татыган бу кеше, дөньяда яшәп, нинди рәхәт күргән соң?.. «Миңа бу кешедән игелек кенә тиде бит, ник аңа ачуым кабара? – дип уйлап куйды Самат. – Дошман болай да җитәрлек, тагын монда дошман эзлим түгелме?..» Самат, гафу үтенергә ниятләп, коридорга йөгереп чыкты һәм аның артыннан эндәште:

– Иван Константинович!

Астан җавап ишетелмәде.

Бераздан Самат бүлнис тәрәзәсеннән күрде – хирург, посёлок уртасыннан сузылган юлдан, кулларын артка куеп, әкрен генә атлап китеп бара иде.

Иван Константиновичны Самат бүтән беркайчан да күрмәде.

## 16

Хафаланып көткән сәгать сукты – Саматның да, Светаның да хәтерендә гомер буе сакланачак өч көн, өч төн бер минуттай узып китте. Хәер, хәтердә мәңге сакланасы булгач, узып китте дип әйтү дөрес микән?..

Ике кешенең җан якынлыгы кушылганда түгел, аерылганда аңлашыла, диләр. Моны кыз белән егет бүген үзләрендә татыдылар.

Света, көз көне оча алмый калган кош шикелле, хастаханә янында боегып басып тора иде. Шулкадәр якын, кадерле һәм үз кешесенә әйләнгән бу гүзәл кызга Самат әйтер сүзләр таба алмый торды – үзәктәге сагышны сүзләр белән җиткерү мөмкин түгел иде.

– Мин сине бүтән күрмәячәкмен, – диде Света, еламсырап.

– Сугыш тиздән бетәчәк. Сугыш бетү белән үк мин синең яныңа киләм, – диде Самат, кызны кочагына алып.

– Без инде бүтән беркайчан да очрашмаячакбыз, – диде Света күз яшьләре аша.

– Ник алай дисең?

– Шулай тоела.

– Юк, юк. Без очрашачакбыз. Мин сине Казанга алып китәм.

Света, шаярырга тырышып:

– Мондый «трофей»ны синекеләр ничек кабул итәрләр икән? – диде.

– Бик яхшы каршы алачаклар, – диде Самат. – Минем әнием бик әйбәт кеше. Сине яратачак ул.

– Мин сине бүтән беркайчан да күрмәячәкмен, – дип кат-кат кабатлады Света.

– Алай димә.

– Мине дә үзең белән ал, – диде Света, аның белән әллә кайларга китәргә әзер булып.

– Юк, мөмкин түгел, – диде Самат, йөрәгенең ярсуын тоеп. – Мин бит әсирне Смершка тапшыргач, передовойга, үз частема юл тотам.

– Мин дә синең белән передовойга барам. Мин сезнең частьта санитарка булырмын.

– Юк, юк, анда коточкыч сугыш бара. Сине үтерсәләр, нишләрмен...

– Анда бит сине дә үтерүләре мөмкин, – диде Света, сыктанып. – Без янәшә булсак, икебез дә исән калырбыз.

– Мин исән калам! – диде Самат. – Чөнки монда син бар. Сугыш бетү белән мин монда киләчәкмен.

Светаның ышанасы килә иде – Самат алдамас һәм, чынлап та, аңа үлем тимәс, читләтеп үтәр, бу егеткә әҗәлнең кулы күтәрелмәс, чөнки аны харап итәргә беркемнең хакы юк!!!

– Фриц егерме чакрым үтә алыр микән? – диде Света, читтәрәк басып торган Ортвинга ымлап.

– Үтәр, – диде Самат. – Машина яки ат очрамый калмас әле.

Ортвинның алама кителен ташлап, аңа баш табибның шкафта эленеп торган иске пинжәген кигерткәннәр иде. Ортвин каршы килгән иде дә, Самат татарча-русча сүгенеп җикергәч күнде, киеп куйды. Пинжәк таман үзенә, үлчәп теккәннәрмени. Бүген аның чыраена бераз төс кергән, өстәвенә, Света алып килгән пәке белән аңа да кырынырга рөхсәт иткәннәр иде.

– Ун чакрымнан чат булыр – аркылыга кисеп, урманга ат юлы кереп китә. Шул юлдан уңга ярты чакрым баргач, аланга килеп чыгасың, – диде Света. – Шунда хәл алырга мөмкин... Анда иске йорт бар, лесник йорты... Ташландык йорт... Аның артындагы калкулык астыннан чишмә ага.

– Ярар, – диде Самат. – Әсирнең хәленә карарбыз.

– Җибәрәсем килми сине, – диде Света, егеткә сыенып.

Аның күз яшьләре тып-тын гына акты да акты.

– Елама, Света. Иң мөһиме, без синең белән очраштык. Без хәзер бер-беребезнең бу дөньяда барлыгын беләбез.

– Мин инде очрашканыбызга бераз үкенеп тә куям, – диде Света сагыш тулы тавыш белән. – Сине очратканыма бәхетле мин... Әмма бу очрашу, вакыт узгач, кайгыга батырыр шикелле...

Аларның кочаклашып үбешкәннәрен Ортвин тын да алмыйча күзәтеп торды. Күренеп тора, кыз белән егетнең мөнәсәбәтләре әсирнең дә күңеленә хуш килгән, аның аксыл чырае хәтта бераз нурланып киткән кебек иде.

Әсир белән конвоир юлга кузгалдылар. Света Самат артыннан йөгерүдән үзен көчкә тыеп, юл уртасында басып калды.

Шәһәрдән чыкканда, Ортвин хәйран җитез атлады, әмма ике-өч чакрым үткәннән соң, акрынайды, тагын нык аксый башлады һәм Саматтан кат-кат су сорады. Бара торгач, ул инде тәмам хәлсезләнде. Самат торымнан-торымга, машина, ат ише нәрсә күренмәсме дип, артка борылып карады, әмма, кызганычка каршы, алдан килүче дә күренмәде, арттан куып җитүче дә юк иде.

Саматның фляжкасындагы су ике кешегә бик аз иде шул, ярты юлны узганда инде, суның тамчысы да калмаган иде. Света биргән янчыкка шешә белән су алырга баш җитмәде, кыз үзе дә аерылышу кайгысыннан бу турыда оныткан, ипи кисәге белән алма гына тутырган иде. Ат юлы буйлап уңга каерылып, Света әйткән чишмәне табарга кирәк булыр, юкса тагын ун чакрым үтү немецның хәленнән килмәячәк, дип уйлый башлады Самат.

Ортвин тәмам бармас булып, җиргә утырды. Саматның моңа аз гына да ачуы килмәде, киресенчә, әсирне тынычландырырга теләп, алга таба ишарәләде һәм:

– Геен... Вассер[12]. Там вода, вассер, – дип кат-кат кабатлады.

Менә ул – юллар кисешкән урын. Ат юлы аркылыга олы юлны кисә, сулга болын буйлап китә, уңга – урманга алып керә. Света шушы урын турында әйткәндер. Самат урманга керергә карар кылды, чөнки үзе дә нык арыган иде. Өч төн Света белән булып, йокы турында бөтенләй диярлек оныткан иде бит ул. Өстәвенә, көне эссе, табигатьнең көчле яңгыр алдыннан була торган тынчу һавалы чагы иде.

**17**

Ниһаять, алар кайчандыр урманчы йорты булып хезмәт иткән ташландык корылмага барып җиттеләр. Хуш исле ямьле аланда чишмә тавышы җанны иркәләп әллә каян ишетелеп тора иде. Алар рәхәтләнеп салкын су эчтеләр, кулларын, аякларын, битләрен юдылар.

Чишмә буенда утырып, хәл алганнан соң, Самат алга таба нишләргә дип, баш ватты. Чишмәдән ерак китәсе килми. Монда борылып, алар дөрес эшләделәр. Әнә бит, күренеп тора – хәзер кузгалсалар, әсир Верхнегорскига барып җитәрлек түгел. Урманчы йортында йоклап алсын микән әллә?..

Икесе дә теләр-теләмәс кенә, чишмә яныннан китәселәре килмичә, торып, ташландык йортка таба юнәлделәр. Кинәт йортның ишеге киерелеп ачылды. Аннан чыгып килүче агайны күреп, икесе дә берьюлы шып туктадылар.

– Агай! – дип аваз салды Самат.

Йорттан чыккан кеше сискәнеп куйды. Таушалган эшләпәсе астындагы сакал-мыек баскан чыраенда күрән күзләре уйнаклап торган, тукмак борынлы, базык гәүдәсе үзенә авыр шикелле күренгән, акрын хәрәкәтле, аягына иске күнитек, өстенә брезент плащ кигән олы яшьтәге агай якынлашып килүчеләргә сагаеп карап торды, әмма аның кыяфәтендә курку сизелмәде.

– Исәнме, агай! – диде Самат, аңа таба атлап.

– Сез кемнәр буласыз соң? – диде агай, беравык дәшми торганнан соң.

– Кем булсак та, исәнләшүгә җавап бирергә кирәк, – дип якынайды аңа Самат. – Ул сорауны мин бирергә тиеш – син кем?

– Урманчы... идем. Сугыш башлангач, урманчылыгым шуның кадәр генә... Йортның рәте беткән... Күптән килгәнем юк иде бу тирәгә.

Агай әле Саматка, әле арттарак басып торган Ортвинга карап, аларның кем икәнлекләрен аңларга тырышты һәм ни уйларга да белмәде.

– Исемең бармы синең? – диде Самат чәнчүле тавыш белән. Аның болай соравы үзенә кыюлык өстәр өчен иде.

– Бу ни дигән сүз инде, – дип мыгырдады агай. – Моны шаяру дип аңларгамы?

– Мин – кызылармеец Гарипов, бу – әсир фриц. Мин аны Верхнегорскига алып барам. Яраланганнан соң аның хәле чамалы, шуңа күрә чишмәгә килергә мәҗбүр булдык.

[12] Вассер – немецчадан: су.

– Тимофей минем исемем. Тимофей абыең булам.

Самат урманчыны очратуына куанып, барысын да аңа тәфсилләп аңлатты. Тимофей игътибар белән тыңлады, әмма Саматның сөйләгәннәренә ышаныргамы-юкмы дип, әйле-шәйле уйлар белән сәер юлчыларны җентекләп күзәтте.

Самат үзенең үтенечен белдерде:

– Район үзәгенә тагын ун чакрым чамасы бугай. Минем хәлем җитәчәк, ә менә бу дуңгызныкы хөрти. Яраланган иде ул, аягы да әллә нишләгән, аксый, өстәвенә, берничә көн элек бандерачылар да кыйнадылар үзен. Монда хәл алсак буламы? Бераз ял иткәч, юлны дәвам итәрбез... Тизрәк котылырга инде бу ниместән... Минем үзебезнең полкка кайтасым бар, передовойга... Болай да инде бу хәшәрәт белән атна буе йөрим.

– Нишләп берүзеңә генә калдырдылар соң аны?

– Ике сәгатьтән особистлар киләсе булганга. Бу аксак хайван өчен тулы бер взвод калдырмаслар бит инде. Күрәм, син миннән шикләнәсең бугай?

– Сугыш вакытында кешеләр бер-берсеннән нык шикләнәләр инде ул.

– Мине нимес диверсанты дип уйлыйсыңмы әллә?..

– Ә миңа барыбер, – дигән булды агай кыю булып күренер өчен.

Самат күзләрен чекрәйтте:

– Ничек инде сиңа барыбер?!

– Син кем булсаң да, сез кем булсагыз да, мин нишләтә алам һәм нишли алам?

– Син миннән шикләнмә. Менә бу адресны Березняк бүлнисендә эшләүче Света үз кулы белән язып куйды. – Самат блокнотын янчыктан алып, Светаның адресын күрсәтте. Бу аның агайга күрсәтерлек бердәнбер «документ»ы иде. – Дөресен әйткәндә, атып кына үтерергә иде дә бу хәшәрәтне... Приказ бар бит. – Бу соңгы сүзләрен ул Ортвинга нәфрәтләнеп түгел, агайны ышандырырга тырышудан гына әйтте.

– Әйдәгез, өйгә керегез, – диде Тимофей.

Өй дигәне, тыштан кечкенә булып күренсә дә, кергәч шактый киң булып тоелды. Керү белән, сул якта тимер мич, өстендә корымланып беткән чәйнек тора иде. Агай, җәй булса да, мичкә яккан булган, димәк, чәй кайнаткан. Уң як стенада тар гына тәрәзәдән яктылык әйбәт төшә – ул яктан агачлар кояшны капламый иде. Бер сәке тәрәзәле стена буенда, икенчесе түрдә, уртада кыршалып беткән өстәл урын алган иде. Урындыклар булып, өч бүкән хезмәт итә, ишекнең уң тарафында киштә, анда ике кружка, сабы кәкрәйгән әлүмин кашык, тагын нindидер вак-төяк әйберләр ята иде.

Кайнаткан чәйдән өйгә пешкән үлән исе таралган иде. Агай кружкаларга чәй салды һәм көтелмәгән кунакларны «табын»га чакырып:

– Эчегезгә җылы керер, – диде һәм, янчыгыннан ипи кисәген алып, урталайга сындырды да яртысын Саматка бирде.

Самат үзенең өлешеннән Ортвинга да бераз ипи биргәч, агай беравык аптырап карап торды.

– Ничек курыкмыйча берүзең бу фашист белән йөрисең? – диде ул, тәрәзә буендагы сәкегә утырып. – Җитмәсә, урманга килеп кергәнсез...

– Күрәсең бит, аңардан куркырлык түгел, – диде Самат, чәй йотып. – Мин приказны үти алмавымнан куркам. Болай да инде документларсыз калдым,

коралымны талап алдылар. Рациясе бар иде, Березнякта калдырдым. Хәзер үзен Смершка тапшыра алмасам, трибунал яный бит миңа. Бандерачылар атырга җыенганда, мин аны якладым, «Кирәге чыгар, атмагыз», – дидем. Атырга теләүченең татар дусты булган, Кырым татары, шуңа күрә ул миңа артык нык кыҗрамады.

– Син моны командирларыңа аңлата алырмын дип уйлыйсыңмы? Ышаначаклармы синә?

– Ышанырлар, – диде Самат, ипи кабып. – Ник, дөресе шул бит.

– Дөресе... – дип мыгырдап куйды урманчы. – Кайда соң бу дөньяның дөресе?!

– Ничек кенә булмасын, барыбер иртәме-соңмы дөреслек өскә калка, – диде Самат, комсомолларга хас рух күтәренкелеге белән.

Ортвин, Самат биргән ипи кисәген кабып, кружкасындагы чәен тиз генә эчеп бетерде һәм боларның ни турында сөйләшкәннәрен аңларга тырышып утырды.

– Башың бик яшь әле синең, – диде Тимофей, Саматны бала-чагага санап. – Шуңа күрә алай уйлыйсың. «Дөреслек җиңәргә тиеш!» дигән сүз мине һәрвакыт сагайта. Чөнки бу мөмкин түгел. Кешелек дөньясында дөреслек белән ялган һәрвакыт бергә, бер бәйләмдә йөри. Һәр яңа көн шундый бер бәйләмне сиңа тапшыра. Дөреслек өчен революцияләр ясадык... Әнә, нәрсә килеп чыкты... – Ул яман ачы иттереп сүгенеп куйды. – Кешеләр бер-берсен көне-төне үтереп торгач, синең дөреслеккә ышануыңнан ни мәгънә?!

Самат үз киресен сөрде:

– Иптәш Сталинның әйткәнен оныттыңмыни – без хаклы, шуңа күрә без җиңәчәкбез!

– Без, без, без... – диде Тимофей, кызып. – Шул без дип, аерым кеше турында оныталар да инде ул.

Самат кайнарлана башлады:

– Син, агай, нишләп кирле-мырлы сукалыйсың?! – диде ул усал кыяфәт белән. – Мин игътибар иттем – бу тирәдә барыгыз да кылтый-пылтый сөйләшәсез. Сез монда сәвит влачы яңадан урнашасына ышанмыйсызмы әллә?

Тимофей тыныч кына:

– Үземне җәберләмәсәләр, миңа нинди влач та ярый, – дип куйды.

– Бөтен сәвит халкы дошманга каршы күтәрелде, ә син... – диде Самат, агайның каушый башлавыннан бераз ләззәт алып.

– Нәрсә мин?.. Халык... Халык мәнфәгатьләренә синең шәхси мәнфәгатьләрең кирә микән?..

– Нимес белән Бандера синдә Ватан хисен бетергән, ахрысы, – диде Самат, Тимофейга күз карашын кадап.

Агай, каушавын җиңеп, үз фикерләрен әйтергә кирәк дип тапты:

– Туган илең сине ярата дип уйласаң, ялгышасың. Сине аерым кешеләр генә яратырга мөмкин. Туган илең сине яратмый дип уйласаң да, ялгышасың. Сине аерым кешеләр генә өнәмәскә мөмкин. Туган ил сиңа карата илтифатсыз ул, әллә бар син аңа, әллә юк. Син үзең генә аны йә яратасың, йә яратмыйсың. Моңа да Туган илең битараф. Дәүләт өчен син бары тик организмдагы бер күзәнәк кенә.

– Нишләптер, бу районда философлар бик күп, – диде Самат, көлемсерәп. – Син алай-болай бандерачы түгелме?

Агай кыюланып китте һәм, өстәл янына килеп, буш бүкәнгә утырды:

– Мин – кеше, – диде ул. – Нинди бандерачы булыйм мин! Гомер буе урманчы булып эшләдем. Менә син кем икән? – Ул әсиргә ымлады. – Моның кем икәне чыраеннан ук күренеп тора. Ә син...

– Әйт, әйт, дәвам ит.

Тимофей Саматның кулындагы сәгатькә ымлады:

– Сәгатең дә синең немеснеке бугай...

Самат үзенең кулындагы «ZENITH» дип язылган сәгатькә карап алгач:

– Анда синең ни эшең бар?! – диде. – Ә синең чыраең – чын бандерачыныкы!

– Бәхәсләшеп тормыйм, – дип, кул селтәде агай. – Синең нинди юлда йөрүеңне әлегә аңлап бетермәдем мин.

– Аңларсың. Верхнегорскига баргач, бу тирәдә зачистка ясарга кирәк диярмен дә, тотып алып килерләр үзеңне. Допросны шунда үзем ясармын. Син минем белән чамалап сөйләш.

Саматның чәнчүле-төрттерүле итеп кырыс сөйләшүе ясалма икәнне Тимофей аңламады. Самат исә үзе бераз шүрли дә башлады. Кем бу? Үзен урманчы дип атаган бу шикле кеше белән, бәлки, иркенләп сөйләшеп утырырга ярамыйдыр. Бәлки, урмандагы берәр банданың кешеседер ул һәм бу тирәдә күзәтче буларак йөридер. Шуңа күрә сөйләшкәндә, Самат гел тәрәзәдән тышка күз салып утырды.

Урманчы агай, шулай ук, кыю булып күренергә тырышса да, эчтән шөбһәләнә иде – бу егет чынлап та конвоирмы, әллә немец яклы диверсантмы?..

Алар шактый вакыт шулай бер-берсеннән шикләнеп, кемнең кем икәненә төшенә алмыйча, бер-берсеннән куркып утырдылар, әмма икесе дә, сер бирмичә, кыю һәм дорфа сөйләшергә тырыштылар.

«Коралы бар микән бу агайның?.. – дип уйлады Самат. – Бәлки пистолетым барлыгын белгертергәдер?.. Коралсыз дип уйлыйдыр, бәлки, шуңа күрә аркылы-торкылы сөйләшәдер...»

– Моны атып үтерергә генә кирәк, – диде агай, Ортвинга күз белән ымлап.

«Әһә, мине сынап карый, бу тәкъдименең ничек тәэсир итүен тикшерә», дигән уй йөгереп үтте Саматның башында.

– Хәзер дөресен әйтәм сиңа. Монда тагын бер отделение килергә тиеш, – дип ялганларга кереште Самат. – Шушында очрашырга сүз куештык. Рацияне алып киләләр дә, элемтәгә чыгачакбыз. Бу әсир аша фашистларга дезинформация җибәреп ятачакбыз.

Тимофей кет-кет-кет итеп көлеп куйды.

– Синең башың яшь әле мине алдарга, – диде ул, авызын кыйшайтып. – Адашып йөрүчеләргә охшагансыз. Ярар, миңа барыбер, – дип, башын читкә борды ул.

– Син беркемнән дә курыкмыйсыңмы әллә? – диде Самат, усал итеп көлемсерәп.

– Ник алай дисең?

– Минем кем икәнемне белмәгән килеш, килделе-киттеле сөйләшәсең.

– Мин аңладым инде кем икәнеңне, – диде Тимофей тыныч кына.

Саматның нindидер бер олы яшьтәге йонлач кешенең дорфа сөйләшүенә ачуы килә башлады:

– Син нишләп фронтта түгел? – диде ул аңа, каты тавыш белән. – Ә?!

– Син башта миңа ничә яшь икәнне сора, – дип, тавышын күтәрде урманчы.

– Ничә яшьтә булсаң да, син – суксаң, тимер өзәрлек ир кеше. Башкалар, җаннарын фида кылып, дошманга каршы сугышканда, син урманда качып йөрисең.

Тимофейның бу сүзләргә һич кенә дә исе китмәде:

– Син дә фронтның алгы сафында түгел, безнең урманда ятасың бит әле.

– Син минем орден белән медальләремне күрмисеңмени?! – диде Самат, орден-медальләре белән мактанырга яратмаса да, агайны урынына утыртыр өчен.

Агай Саматның түшенә карап торганнан соң:

– Мин бит сиңа аларны ни өчен биргәннәрен белмим, – диде.

Самат кинәт утырган урыныннан сикереп торды һәм чалбар кесәсеннән пистолетын чыгарды:

– Ә сиңа анысын белү кирәкми, – диде ул «вальтер»ны Тимофейга төбәп. – Кулларыңны күтәр! Хенде хох!

«Хенде хох»дигәч, Ортвин, гадәт буенча, кинәт сикереп торды һәм ике кулын да өскә күтәрде. Боерык аңа аталмаганны аңлагач, кулларын төшереп, өстәл яныннан әкрен генә китте дә түр сәкегә барып утырды.

Тимофей, торып, кулларын күтәрде:

– Әй, әй, шаярма, – диде ул калтыравык тавыш белән. – Нишләмәкче буласың?

– Сәвит влачына каршы бик күп нәрсә әйтеп ташладың! Мин сине расходка җибәрәм!

– Синең хакың юк, – диде Тимофей.

– Мин Смерш вәкиле, – диде Самат. – Мондый әңгәмәдән соң, минем сине атып үтерергә хакым бар. Мин махсус рәвештә рядовой формасыннан йөрим. Мин Смершның өлкән лейтенанты. Документларың бармы?

– Үзем белән юк.

– Кайда яшисең?

– Болотное авылында.

– Фамилия?

– Захарчук.

– Атаңның исеме?

– Фёдор.

– Гаиләң зурмы?

– Хатыным да, карт әнием... Мине дә әсир итмәкче буласыңмы әллә? – диде Тимофей, аптырашта калып.

– Әйе.

– Тиләләнмә, егет. Мин сиңа бернинди начарлык эшләмәдем бит.

– Кем син?

– Синең кебек үк бер җан иясе инде, – диде Тимофей. – Патроннарыңны

сакла, миңа атып әрәм итмә. Сиңа әле алга таба патроннарың кирәк булыр. Син монда урман эчендә, фронттан читтә үзеңә дошман эзләп йөрмә. Кызылармеец булсаң, бар, дошманны Германиягә таба ку. Әгәр син сәвитләргә каршы сугышасың икән, бу очракта да мине үтерү сиңа берни бирми.

– Миңа синең сөйләшүең ошамады, – диде Самат, тынычланып.

– Сөйләшү ошамады дип, наган төбәмиләр инде. Әсиреңне тизрәк илтеп тапшыру турында уйла.

Саматта кинәт нәфрәт юкка чыкты. Үлем белән ничә тапкыр күзгә күз караршты бит инде ул. Ник бу агайга ачуы чыкты соң әле аның? Ул пистолетын чалбар кесәсенә тыкты һәм, утырып, кружкадан суынган чәен йотып куйды.

– Хатыным да, карт әнием, дисең... Балаларың? – дип кызыксынды ул, салмак кына тавыш белән.

– Балаларыбыз юк, – диде Тимофей, көрсенеп. Аның чыраеннан газаплы сагыш саркыды. – Ходай балалар бирмәде миңа. Бик әйбәт. Бу дөньяга тумавың яхшырактыр. Мондый кайгы-хәсрәтләрне татып яшәгәнче, бу дөньяга тумау үзе бәхеттер...

Юк ла, бу миңа дошман кеше түгел, дип уйлап куйды Самат. Минем кызылармеец икәнемә ышанмый, шуңа гына сагаеп һәм кыланыбрак кукраеп алды бугай ул. Юк, юк, бандерачы мондый булмый.

– Рәхмәт чәең өчен, – диде Самат, пистолетын чыгарып селкегәненә үкенеп.

– Мин китимме? – диде Тимофей, баскан урыныннан кузгалырга шүрләп.

– Бар, – диде Самат, тәрәзәдән тышка карап.

Тимофей, ишек катында туктап, нидер әйтмәкче иде, әмма дәшмәде, бер мәлгә уйланып торды да чыгып китте һәм урман тирәнлегенә сузылган ат юлыннан әкрен генә атлады. Шулай да, кем бу – шайтан белсен, дип уйлап куйды Самат.

Кызып китеп, Самат ипи белән җылы чәйнең тәнгә рәхәтлек биргәнен дә тоймаган булган икән. Агай белән булган шомлы әңгәмәнең киеренкелеге кинәт юкка чыкты. Урман тыныч. Әсир үзен тыйнак тота, сабыр, тыны да чыкмый. Әнә, ул тәрәзәле стена буендагы сәкегә күчкән, Самат белән урманчы агайның ник талашканнарын аңламый калганга охшаган һәм, язмыштан узмыш юк, дигән сыман кыяфәттә чалкан яткан.

Саматның күңелендә иминлек урнашты.

Света!!!

Аның Светасы бар бит!!!

Әллә булды монда Тимофей атлы кеше, әллә юк. Светага булган хисләр әле генә кайнап алган кызулыкны кинәт бөтенләй юкка чыгарды. Мең бәла, мең куркыныч янаса да, өч көн, өч төн эчендә дөрләп янган ялкын мәңге сүнмәячәк. Света, Света, Света! Ул каядыр шушында, бу тирәдә. Юк, юк, хәзер ул – йөрәк түрендә!

Яңгыр сибәли башлады. Җәйге яңгыр нәгъмәсе җанга-тәнгә җәйрәде. Шул көйгә немец сәкедә чалкан яткан килеш йокыга китте. Самат түр сәкегә барып ятты һәм, өч төн аз йоклаганга күрә, үзе дә шундук татлы йокыга талды.

*(Ахыры киләсе санда)*



Мөхәммәт
Мирза

# МӘҢГЕЛЕК ЮЛЫНДА

ПОЭМА-КЫЙССА

*ТАССР төзелүгә 100 ел тулу уңаеннан*

## 1. Агыйдел каты ага

Дәүләтемә йөз ел икән,
Бер гасыр бит – азмыни?
Җәлилдән дә яшьрәк дәүләт,
Ә Тукай – абзый инде.

Йөз яшьлек, дәү дәүләтемнең
Узганында ниләр, ни?
– Имәндә, энем, чикләвек, –
дигән Утыз Имәни.

Нигә мең ел түгел? – диеп,
Рәнҗемәсме Мәрҗани?
Кич буе Сак-Сок бәетен
Елап җырлый дәү әни.

Дәүләтем атын йөр(е)ткән
Халкымның шәҗәрәсен,
Тарих төпкеленә төшеп,
Кем генә эзләмәсен?!

Танып, белеп, белмәмешкә
Салышалар күпләре.
Кем әйтә: «Килгән килмешәк!..»
Сәбәбе бар – үпкәле.

Бер гасырлык дәүләтемнең
Чыгып аргы ягына,
Аягым сузып утырдым
Агыйделнең ярына.

Агыйделнең уртасыннан
Агып бара бер каек...
Бер карт җырлый, әллә җылый:
«Аерылмаек, дускаем...»

Карурманның уртасында
Гомер кичкән агам бу...
Урал урманын аударып,
Сал агызган бабам бу.

Салларга салып сагышын,
Агызган ул диңгезгә.
Биш гасыр элек куылып
Үзе корган нигездән.

Агыйдел, Чулман кушылган
Текә яр мәгарәсе.
Бозлык чорында язылган
Халкымның шәҗәрәсен

---

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Биш томлык «Сайланма әсәрләр», «Киек каз юлында», «Тере су», «Адәм баласы» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Кабат яшерде тарихның
Ак таплар чоңгылына.
Мәгарәгә чордаш кальга
Кирмәнчек шаһит моңа.

Дәүләтемә йөз ел, хуплап,
Елъязмасын кем язган?
Ханнар зиратында туктап,
Уйланып бак беразга?!

Бертынга тын калып тыңла
Багraж тавының җилен.
Ханнар адашып чыкканмы,
Барлап килгәнме илен?..

...Пётр патша, монда килеп,
Кырдырган алагаем, –
«Субайга, шәт, яраклы» дип,
Чулманның карагаен.

...Татар атлары Лашманда
Мең чакрым араларны,
Ял күрми, агач ташыган,
Ташымый чара бармы?!

Мәңгелек баткак сазында
Быгырдап бата-бата,
Тарткан илем карагаен, –
Яраклы, дип, корабка.

Лашманчы татарның юлы
Булган бары бер якка:
Атын, үзен, карагаен
Алып калганнар ятлар.

Агыйделнең аръягында
«Бер инәгә бер дөя»...
Дөя арбасы – иңендә,
Кәрваннар йөген төя.

Кәрваннар кичкән чүлләрне,
Үткелләр, дәрьяларны.
Ап-ак мәрмәрдән корылган
Кирмәнле калаларны.

Кәрваннар ташып баеткан
Тоташтырган юлларны.
– Йә, йөзьеллык елъязмачы,
Оныттыңмы боларны?

Агыйдел яры таш-кыя,
Агыйдел каты ага.
Бертында аргы ягына
Колачлап йөзеп барам.

Дәрьяның аргы ягы да –
Борынгыдан үз җирем.
Дәүләте алышынса да,
Көнем күргән үз илем.

Дәрьяның аргы ягыннан
Урап кайту ансаттыр.
Гасырның аргы ягына
Чакырып тора хәтер.

Гасырларның аръягында
Йөз дәрья кичәсе бар.
Дулкыннарын кисә-кисә,
Киерелеп ишәсе бар.

## 2. Төсле, санлы татар иле

Гасырларның аръягында
Тугыз айлык юл ара.
Килерен фаразлыйм дисәң,
Үткәнен сүтеп кара.

Үткәнеңне барлап бак син
Гасырларның катыннан.
Юлыңны башла һич югы
Алтай тавы артыннан.

Туксан ике төрки кавем –
Тамырдаш, кардәш ыру.
Түрек баба түбастына
Тупланган дәүләт булып.

Юк тарихта бер халыкның
Сан сугылган дәүләте:
Сигез татар, тугыз, утыз...
Угызлары нихәтле?!

Кайсы халыкның тарихта
Төсле атамалары:
Кара татар, чаган татар,
Алчын-ак татарлары.

Һәр кавемнең үз дәүләте,
Үз тәхете, үз ханы.
Шагыйрьләре ташка чокып
Калдырган ни кылганын.

Үзалдына берләшкәннәр,
Аркадаш, кулдаш булып.
Барыш-алыш юлларында
Тормаган тузан кунып.

Түрек баба түбастында
Тугыз айлык юл-ара:
Сан җитмәс тау-үзәннәре
Җәелгән чиксез дала.

Туксан ике үзал дәүләт,
Үз җире, үз чикләре.
Берләшеп саклый белгәннәр
Алар үз милекләрен.

Тугыз татарның иленә
Басып кергәч күктөрек,
Утыз татарның яугире –
Күлтәгин җиткән килеп.

Шагыйре – данлы яугире
Ташка чокып яздырган:
«Кылыч белән илгә кергән
Кисек башын калдырган».

Ташларга язып тездергән,
Күрсеннәр, дип, чикләрен.
«Чикләрен бозып кергәннәр
Күрерләр ни җикләрен».

Шагыйре санлы дәүләтнең
Яугире булыр данлы:
Кол Галиләр, Кол Шәрифләр
Юкка гына туганмы?

Дәүләтенә яу килгәндә,
Калкан булып басканнар
Җәлилләрнең бабалары...
Башларын да чапканнар.

Алишларның, Кормашларның
Бабаларының даны
Язылган каннары белән,
Кабатланыр дип тагы.

Тарихында һәркайсының
Үз төсе, үз туграсы.
Бер таралган, бер укмашкан
Түрек баба урдасы.

Туксан ике төрки кавем –
Татар, төрек, угызы,
Кыргыз, уйгур, чаган, дага,
Төн ягында тунгузы.

Бер бүленгән, бер укмашкан
Тәкъдире тарихында.
Саннар җуелып, тоташтан
Күчкән кушаматында.

Татарга яткан «Тарагай»,
Биләмәсе таралгач.
«Тар-тар» булып киткән, имеш,
Ала карга каргагач...

Таланган иле, байлыгы,
Бүленгән биләмәсе...
Тәкъдире куласасында
Туктаусыз иләнәсе...

Куласаның бер басарын
Көтеп, гасырлар үтә.
Өмет дигәнең үлемсез:
И татар, башың күтәр.

Хәтер-тарих катламында
Язган, язылмаганы.
Сабак алыр өчен фарыз –
Эзлә, тап син аларны!

Эзләп тап та, тотып кара,
Татар тотмый ышанмас,
Чакырылмаган кунак дип,
Һичкем куып чыгармас.

## 3. Базарлы ил – Болгар ул

Яралышыннан санап салынган,
Язылганы исәп-хисапта:
Сәбәпсез һични артмас, кимемәс,
Югалмас, ди Изге Китап та.

Тәкъдирләрен язган: үлчәмендә –
Кайда туып, кайда торасы...
Тәкъдиренә ышанмаган бәндә
Инде шайтаныннан сорасын...

Тәкъдирләрен санга сукмас иде,
Исәп-хисап көнен куймаса.
Дөньялыкка килү-китү ансат...
Калу мөмкинме соң, уйласаң.

Исәп-хисап – язып барылганы
Каш белән күз арасындадыр.
«Ышанмыймын» дигән тәкәбберләр
Көзгедән бер карасынгадыр...

Исәп-хисап базарларда хаҗәт,
Очсыз алып, кыйммәт сатарга...
Базарда кол саткан көннән дучар
Кешелек култыры батарга.

Базарында барсы да сатыла,
Гөрәнкәләп, потлап, олаулап.
Кирәк икән эзли, таптыра, йә
Яу чаптыра ала ул даулап.

Базарында барсы да сатыла,
Елкы кизәге дә, алтын да.
Һәрберенең сату-алуына
Һәркайсының хәләл хакы бар.

Базарына кергән һич чыгалмас,
Комарлы бер уендыр – базар.
Белеп торыр отып алданасын,
Алдап отса – нәфесе азар...

Иле базар: кала, салалары,
Атна көннәренә бүленгән:
Дүшәмбедән атна кичкә кадәр
Бизмәннәргә тауар эленгән.

Җомга көндә оеп намазында,
Дога кылып савап арттырган,
Шимбә, якшәмбедә Ага-Базар
Кабат барсын җыеп чакырган.

«Базар мәңгелек зар» дисәләр дә,
«Үсә, дип, мал хакы-бәясе»,
Зары арткан саен ымсындыра, –
Йә, базарсыз яшәп кара син?!

«Базар тота» дигән даны чыккан,
Кыйммәт йөргән көмеш тәңкәсе.
Базарында һәркем җаен тапкан, –
Телен аның белгән һәммәсе.

Тылмач кирәкмәгән, күрше ыру
Йөргән үз телендә эндәшеп.
Татар белән кодалашкан алар,
Ул-кызларын аңа ярәшеп...

Сатлык малның ихтыяҗын корып,
Барлап, санап торган килерен.
Базарына кергән чыгалмаган
Калдырмыйча тәңкә, тиенен.

Алыш-бирешләрдә даны чыккан
Базарларын тоткан татарның
Җиде җир читенә чыгып чапкан
Гурдлап* куган куй, елкы малы.

Ел тәүлеге «Ефәк юллары»нда
Ефәк, парчаларын ташыган.
Кәрваннары елга, диңгез, күлен,
Дала, чүлен кичеп талчыккан.

Әмир, морза, бәкләр авызына
Җәннәт җимешләрен каптырган.
Абага чәчәге маен таптырган да,
Дәртсезләрнең дәртен арттырган.

Хак бәясен белгән зәр-алтынның,
Уптым саткан бодай-тарысын.
Сатулашып саткан тун, хөлләсен,
Сатмый гына кем соң баесын?

Базарына җыйган биш кыйтгадан,
Дүрт тарафтан кемнәр килмәгән?!
Биләр, Сувар, ашлы Ибраһимны
Илдә кемнәр генә белмәгән?!

Сәүдә солын** белгән Йорт-Ил башы,
Салым тутырган ил казнасын...
Казнасында сәмән арткан саен,
Фән, мәгърифәт ачкан капкасын.

Болгар – гыйлемдарлар башкаласы,
Идел-йортның гыйлем мәркәзе...
Шәһәрләрдә яңгыраган азан
Иманга чакырган һәммәсен.

## 4. Үткәннән хак хәбәр бар

Тотам калма, күзәт, теркә
Һәр ымын, һәрбер тынын:
Сунарына-авына чык,
Калмасыннар онтылып.

Бабаң белән явына чап, –
Яшь яугир, елгыр чагың;
Тоярсың тояк чыңында
Йөрәк тибешен аның...

Арысаң, күч арбасына,
Тибеп төшермәс кем дә,
Сорасалар, яшерми әйт:
«Килдем, – дип, – килер көннән!»

Узып бак Алтай, Саянны,
Байкүлендә бер тын ал.
Хәсән күленең ярында
Чатыр корып кунып кал.

* Гурдлап – олы көтү белән.
** Сол – ысул.

Кунып кал, чиксез даланың
Җиле сөйләр бар серен.
Күзалларсың хак ил-көнен,
Бабаңнарың төсмерен...

Җиле сөйләр – көен көйләр,
Учагы очкыннары.
Мәңге зәңгәр күк иленең
Ярылып атар таңы...

Таң белән уяныр әле,
Җыелыр чатырлары.
Аннан кузгалыр далага...
Сан җитмәс чакрымнарны

Үтеп, ният кылган якта
Тупланыр җир табарлар.
Дәүләт булып оешырлар –
Үткәннән хак хәбәр бар!

Дистә гасыр дәүләт тоткан
Кала, кирмәннәрендә.
Иксез-чиксез дала гизеп
Исән килгәннәрендә.

Ачыклыйсы сорау хәтсез.
Йөрмәсәң, эзләмәсәң,
Ятлар язган ялганнарның
Ятьмәсенә (э)ләгәсең!

Ниятеңнән кайтмас булсаң,
Талчыкмассың, армассың.
Алмаш тулпар яныңда бит, –
Берсен тотып атлан соң?

Атлан да атның биленә,
Урап кайт калаларын...
Таш каланың – баш каланың
Күреп чык базарларын!..

Акча суккан, базар тоткан,
Шөһрәте киткән ерак,
Татарга сол-белем йоккан
Сәүдәдә булган мотлак...

## 5. Тугыз айлык юл биләмәсе

Мәңге күкләр иле ихтыяры, –
Җирдә, күктә бер көч юк тыярлык:
Атка менгән ыру ауда булды,
Ил-дәүләтле булгач, яуда булды.

Мәңге зәңгәр күкле дала иле,
Ак болытлар эреп ага иде,
Офыктан офыккача тояк чыңы,
Елкы кешнәвендә кала иде.

Мәңге атлы ыру арбасында
Алмаш аты янда – армасынга...
Тәүлегенә йөзәр чакрым үтә –
Ниятеннән артта калмасынга.

Мәңге зәңгәр күкле дала иле,
Чиру булып иңләп бара иде...
Җәйрәп яткан яшел чиксезлек тә
Кара көеп янып кала иде.

Ир-ат, Егет-җилән иярендә
Өлешенә көмеш тияреп дә
Ауда, яуда көн дә табар иде –
Дала чиксез, табып кинәнергә...

Дала иркен, дала киң дисәк тә,
Бүлгәләнеп беткән ун кисәккә...
Якты көндә, кара төндә, һәрвакытта
Һәр биләмә, һәрбер ыру гел исәптә.

Тугыз айлык юлы – биләмәсе:
Чикләр – казык кагып чөйләнәсе.
Чикләренә чиннар дивар корды, –
Чебен очып кермәсен, янәсе...

Тугыз айлык юлы – биләмәсе:
Котыбыннан алып чүлләренә...
Чирү-чирү үткән юллар илтә
Дала кичеп диңгез, күлләренә.

Дала иркен, дала киң дисәк тә,
Һәр чакрымы бүленгән кисәкләргә...
Меңәрләгән елкы, куй көтүен
Ел тәүлеге кирәк исәпләргә.

Дала иркен, урман-тугайлары
Утрау-утрау булып утырганнар.
Һәр җәнлекне, төрен төргә барлап,
Әйтерсең лә шыплап тутырганнар.

Дистәләгән дәрья, күлләре дә,
Сан җитмәслек елга, инешләре.
Аллаһының рәхмәтенә тарган
Бармы ыру-кавемнең ишләре?

Байкүленең суы тирән, салкын,
Ярларында йөз мең учак-ялкын.
Ир-ат, Егет-җилән ау явында, –
Ат яндырып хәбәр илтә чапкын.

Чапкын атын куа, камчы кулда,
Янып ава аты ярты юлда.
Янәшәдә чаба алмаш аты, –
Хәбәр хәтәр, коштай оча юрга.

Көн-төн сакламасаң, уяу торып,
Юлбасарлар, аннан илбасарлар
Талап туздырырлар бар ыруың:
Кол итәрләр йә дарга асарлар.

## 6. Дәүләт токкан яугире

...Чапкын чаба – юрга ава яныл,
Чапкын тагын менә бүз атына:
Чирү-чирү яу килә каралып, –
Илне-йортны кирәк кузгатырга!..

Кузгала ил, чигенүгә түгел,
Калку-уйсулыклы төбәккә...
Илбасарны кылычтан үткәреп,
Башын сөңгесенә элмәккә...

Ыру башы, тезеп бар гаскәрен,
Ант иттерде, туграсын үбеп.
Офыкларга бәрелде шан-оран:
– Яуга – яу, үлемгә – үлем!

Ауда киек күзен алган укка,
Яуда аяусызлап орышкан,
Ярып-чабып кергән урталыкка, –
Һәлакәт барлыгын да оныткан.

Ауда алган барлык күнекмәсен
Яуда үтәгән ул бер хилафсыз.
Орыш-алыш булмый бер хәйләсез,
Орыш-алыш булмый корбансыз.

Калкулыкта ярсып орышканда,
Күкләр тетрәп торган әр-сурдан...
Сафлар яуга кереп ава торган,
Уйсулыкта казан асылган...

Ут йоткан бугазга әйрән йотып,
Кулда – тулып ташкан тустаган...
Аяк өсте генә ризык кабып,
Яуга кереп киткән ул тагын.

Җәрәхәтле тәннән саркып чыккан
Каны җирне мулдан сугарган.
Әҗәл булып килгән тимер уктан
Ун кат авып, ун кат торалган.

– Ура, ура! – ярсу лаф орыннан,
Җир тетрәнеп, күк күкрәп торган...
Яуда ирләр ярсып җан кыйганда,
Уйсулыкта тулгак тотылган.

Яу кырында яшәү даулап туган,
Яуда имгән, яуда теш чыккан.
Яуда, юлда атка менгән олан, –
Алмаш яугир булып чыныккан.

...Янәшәдә чапкан алмаш аты
Садагында угы өч дистә...
Басып алган дөньяның дүрт ягын –
Куәт бирә Ходай, көч өсти...

## 7. Алтын Урда чоры татарның...

Алтын Урда – ак татарның
Алтын чоры, дәвере.
Күпләр күреп шаккатарлык
Зур дәүләткә әверелде.

Дәүләтендә аңар һичбер
Тылмач кирәкмәс булды.
«Яса» белән салым җыйды –
Казна дыңгычлап тулды.

Урда даны ерак китте –
Бар җиһанга таралды.
Дистәләгән кавем анда
Үз урынын табалды.

Дистәләгән кавем-ыру
Урда-йорт уртасында.
Саклап өммәтен, кыйбласын,
Корды йорт-курасын да.

Сәүдә юллары чатында
Шаһ-шәһәрләрен корды.
Алтын айлы манарадан
Азан яңгырап торды.

Бер чигеннән бер чигенә
Тугыз айлык юл-ара.
Ямчылары ел тәүлеге
Хәбәрен илтеп тора...

Хәбәрендә ханнарының
Әмере-күрсәтмәсе:
Әмирләр, биләр, морзалар
Ягыннан үтәләсе.

Дәүләт идарәсенең дә
Баскычлары санаулы:
Унбаш, йөз, мең, түмән башы
Вазифага яраулы...

Дәүләтенең идарәсе –
Чылбыры мең бoжралы...
Һәр бoжраның үз ярлыгы –
Үтәлеше соралыр.

Алтын Урда калалары,
Салалары бер җептә:
Дистәләгән кавем, ыру
Мөстәкыйль, тик берлектә.

Дөньяның биш кыйтгасыннан
Юллар монда китергән...
Корылтайда бар дөньяның
Барышы хәл ителгән.

Мәшрикътан Мәгърипкәчә –
Тугыз айлык юл ара.
Олыслары, аймаклары
Ныгып-укмашып бара...

Дәүләттәге һәр олысның
Тату яшәү – бурычы.
Мәркәзе Бәркә Сарайдан
Ярлык алып торышы...

Дәү дәүләтнең көч-куәте
Мөстәкыйль-бердәмлектә.
Шул корылыш бозылдисә –
Иленнең име китә...

## 8. Кол җыелып куйса бер көн баш

Җиңелгәннең җиңә җиңсез булыр,
Иле таланыр да таралыр.
Дала-кырда козгыннар туеныр,
Чүлнең соры комы каралыр.

Җирнең җиде тарафына качып
Котылалмас кол буласы баш.
Ком җыелып, таш булмасы мәгълүм,
Кол җыелып куйса бер көн баш?

Кол җыелып, юлбаш билгеләр дә:
– Ил башы бул, булалсаң, – дияр.
Иң беренче юллар басып йөрер,
Аннан илләр басар, таҗ кияр...

Ил басканчы юллар басып йөрде,
Илбаш булды – илләр яулады...
Җиһангирның уе җиткән җиргә
Кулы җитте – ялкын ялмады...

Ул өч дистә елда өч дистә ил
Калаларын камап-яндырды,
Баш имәгән барлык кавемнәрнең
Сөякләрен өеп калдырды...

Урда-йортның түренә үк үтеп,
Үз тирмәсен кора алды ул.
Биләмәле биләр, морзаларга
Сәмәрканд салымын салды ул.

...Янәшәдә чаба алмаш аты,
Садагында угы өч дистә...
Басып алган дөньяның дүрт ягын, –
Куәт бирә Ходай, бер бирсә...

Алтын Урда – аеры алты йортта,
Хан буласы килә барсының...
Чыңгыз оныклары тотам тота:
Өс чыккан туганын тарсыныр.

Атна үтмәс – кылычтан узарлар,
Баш чабучы чаба ял күрми.
Урда-йортта берсен берсе суя –
Үз башына килерен белми.

Туган туганыннан бизенгәндә,
Ятлар басып алыр күңелен.
Ил-йортының бәрәкәте китәр, –
Дошманлыгы бүсәр-күбенер.

Туган туганыннан чирканганда,
Чир-чор басар нәсел-ыруын.
Читләр чыгып канун-әхлак чиген,
Мур кыргандай кырыр ыруын...

Алтын Урда аеры алты йортта, –
Коймаларын корды биектән.
Алтыннарын урлап качмасыннар,
Басып кермәсеннәр диеп тә...

Дистә ярым елда ике дистә
Хан күтәреп, хан төшерделәр.
Урда-йортның асты өскә килсә,
Ни буласын соң төшенделәр...

Җиһангирны үзенә аударып,
Туктамыш төпләнде тәхеттә.
Әмир, бәкләр, биләмәләр бүлеп,
Кинәнгәннәр иде бәхеткә.

Иксез-чиксез иркен дала-кырда
Кала, кирмәннәрен кордырган
Батый бабасының шаһ дәүләтен
Оныклары бүлешеп котырган...

Чыңгыз бабасының ихтыярын
Йөз елдан соң кайтармак булып,
Дүрт тарафка чапты чапкыннары,
Корылтайга чакырып, сур өреп.

Тугыз айлык барыр-кайтыр юлдан
Агылды кәрваннар Сарайга.
Ярларыннан чыккан инеш, дәрья
Ярларына чигеп тарайган.

Үзән, тугайлары, болыннары...
Билдән үскән күрән, курасы...
Меңәрләгән елкы, куйларны да
Шунда гурдлап тирмә корасы.

Урман, даласында капкын корып,
Шоңкар чөеп ауга чыгасы...
Тәүлек буе тынмый, сайрый тургай, –
Күңелләрең генә чыдасын...

Табигатьнең өр-яңадан туып
Тулыланган мәле, мул чагы...
Тулпарларның, тоякларын тоеп,
Офыкларга омтылган чагы...

Хан кушканча, корылтайга чакырып,
Урда-йортның дүрт тарафына
Ямчылары ял белмичә чапты,
Чапкылар – очар канатында...

Көн белән төн офык читләренә
Таң нурларын каеп чиккәндә,
Айры алты йортның әмир бәге
Бердәй булып килеп җиткәндә,

Алтын Урда мәркәзе Сарайны
Сырып алды кәрван-станнар,
Ике дистә еллар арасында
Туганнар бик тансыклашканнар.

Яңа ай туганда күтәрәсе
Корылтайның изге әләмен...
Ике дистә елдан соң тагын да
Берләштерү – ханның таләбе...

Мәркәз Сарай-кала тупсасына
Тупланганда алты айры йорт,
Сәмәркандтан әмир Тимер генә,
Кул сузымда торып, һаман юк...

Корылтайда аның сыны кирәк,
Сүзе кирәк, басып куярлык,
Үзбаш булып, тәмам чама чиген
Чыкканнарның нәфсен тыярлык.

Үзбаш булып, айры алты йортта
Сөт тешләрен төшермәгәннәр.
Һәм баш әмир белән тиңләшерлек
Каян тапсыннар көч-әмәлләр?

Урда-йортта купкан низагларны
Туктатырга җитте бер ымы:
Сәбәпчесе юкса низагларның
Үзе иде, аты коргыры...

Сәбәпчесен ниятеннән күреп,
Белеп торды – ни хәл итәсең...
Иксез-чиксез җәелгән далада
Сызды чиген – корды киртәсен.

Чикләреннән чирек адым читкә
Атлаганнар калды аяксыз;
Башбаштаклык ярсытты Аксакны: –
Башлар очты – булды аяусыз.

Башбаштаклык, тәкәббер, мин-минлек
Чикләреннән чыкты Аксакның.
Корылтайга килмәвенең хакы:
Янә яуга чыгу максаты.

Яу – ятларга түгел, кан үченнән
Аксакка ялланган Идегәй
Кардәшләре биләмәләренә
Ташланган котырган бүредәй.

Чиксез дала чорналган ялкынга,
Янмаган бер кала калмаган.
Кардәш-ыру берсен берсе кырган –
Урдаауган, Урда таралган...

Урда-йортның соңгы ханы да ул,
Соңгы тукталышы – Туктамыш.
Туктамыштан соң да тынып тормый,
Йөз ел туктап тормый тукмалыш.

«Саклanганны саклармын» дигән ул,
Бирәм – сорасалар догада...
Туган туганыннан бизенгәндә,
Бәндә уяулыгы югала.

Туган туганыннан тарсынганда,
Ятлар каерып керә капкасын...
Түренә үк үтеп утырдисә,
Чаң сугып та чыгаралмассың...

Туган туганыннан чирканганда,
Күңеленә үтмәс чир йогар.
Терсәк якын да бит, тешли алмас,
Таянырга таягы да калмас, –
Чирлене җәяүле җил егар.

Берсен берсе күралмас туганнар
Бөлгенлеккә төшеп беткәннәр,
Бүлә-бүлә бүленгәннәрен дә
Бүре өерләре көткәндер...

Аерылып, төн ягына киткән
Ак аюга килеп юлыккан...
Алтын Урда – Ак татарның илен
Кемнәр алыр йолып коллыктан?..

Алтын Урда – Бөек күкнең
Кодрәте-ихтыяры –
Туганнарны зурлык биреп,
Муллык биреп сынады.

Дәү дәүләтнең түбә астында
Дистәләгән ыстаннар.
Тарих сызган чикләреннән
Берсен берсе кысканнар...

Берсен берсе талаганнар,
Яндырганнар Ил-йортын.
Туганлык кадерсезләнгән, –
Шайтан биләгән котын.

«Байлык – бер айлык», дигәннәр,
Бер ай тынып тормастан,
Яу чыкканнар, дус-дошманны
Аеры аяп тормастан...

Яу чапканнар гасырлардан
Килгән бөек туганлык.
Субайларын какшатканнар –
Чәчең йолкып еларлык.

Чит-ятлар үткән түренә –
Тәһарәтсез кавемнәр...
Хәләл хәрәмгә буталып,
Әрәм үтәр дәверләр...

Күреп, ишетеп барысын,
Сыкранамы күңелең?
Биш гасыр газиз халкыңның
Канлы яше түгелер...

Биш гасыр буе коллыкның
Исрафларына батып,
Хәтерендә дәүләт тоткан
Хисләрен уятырлык...

Көч табармы богауларын
Өзеп болгап атарлык?..
Коллыктан йолып алырмы
Тәрәккыйлек-татарлык?!.

## 9. Казан янган, Казан ауган, кардәшләре кыл кыймылдатмый яткан

Казан ауган, күген япкан
Канлы кара төтене.
Коллыкка дучар ителгән, –
Кем каргышы-хөкеме?

Кем күпмегә саткан аны,
Кем ачкан капкаларын?..
Казансуда шәһитләрнең
Кырык көн аккан каны...

Казан янган, көл-күмерен
Кубарык җил тараткан.
Кол Шәрифнең шәкертләре
Каерылып кылыч чапкан.

Кыяташтай кымшанмаган,
Кырык җәрәхәт алып.
Кырган дошманны шәкертләр
Каны беткәнче агып.

Казан янган, Казан ауган,
Күгең корым каралткан.
Кырымдагы кардәшләре
Кыл кыймылдатмый яткан.

Казан янган, Казан ауган...
Кыпчакның кыр баласы
Куй, елкыларын көтүдән
Ташлап кая баралсын?!

Казан янган – Әстерханның
Күген төтен каплаган...
Кардәшләрен килеп яклар
Көч-куәт табылмаган.

Казан янган, Казан ауган, –
Кырык чакрым арада
Калмаган янмаган сала,
Кол санын кем санаган?!

Колның хәлен тик кол белер,
Коллык каһәре ачы.
Кайсы кая таралышкан,
Коллыктан киткән качып.

Кара көздән таралышкан,
Ак кышка кергән йончып,
Уралга, Себергә чапкан,
Коръән-Кәримен кочып...

Юл газабы – гүр газабы
Көтеп торган чатларда.
Котыпларга сөргән үзен,
Чукындырган чакларда.

Тәкъдиреңнән булмый качып,
Котып җирен кот иткән:
Тундраның туңын арчып,
Җир куышын йорт иткән.

Тәкъдиреңнән булмый качып, –
Ниләр генә күрмәгән!
Тик... Сүндермәгән учагын, –
Өмет уты үрләгән.

Дәүләтен югалткан көздән
Тибелепләр таралган...
Таралып, нигезен корган,
Тау-ташларны аралап.

Куралардан корыштырган
Кош-кортының оясын,
Карурманның уртасында –
Дүртпочмаклап бурасын.

Бура түбәсен ябуга,
Күтәргән манарасын:
Дәүләтен җуйса да татар,
Һич җуймаган кыйбласын!

Кыйбласын җуймаган татар –
Таянган бер Аллага...
Ун егылып, ун кат баскан –
Ниятеннән калмаган.

Җан биргәнгә җүнен бирә,
Юлын күрсәтә үзе...
Хәтерен генә җуймасын,
Йоммасын күңел күзен.

Җан биргәнгә җүнен бирә,
Бирә сынауларын да...
Морзалары сынаттылар,
Казан янып ауганда...

Ун егылып ун басканда,
Ниятеннән калмаган.
Кыйбласын җуймаган татар –
Таянган бер Аллага...

## 10. Хөр мәмләкәт – һәр татарның Иманы һәм кыйбласы...

Дәүләтемә йөз ел икән –
Мизгеле дә аз түгел.
Тыгызлап кысылган вакыт
Гасырга тәңгәл көне...

Тыгызлап кысылган вакыт,
Бер тотам буш ара юк.
Шыплап тулган җир катында, –
Җәелергә чама юк...

Шыплап тулган чиксез галәм
Чикләрендә чөйләнгән
Ил-дәүләтләре кыйбласы
Кай тарафка юнәлгән?..

Әллә инде дәүләтләрнең
Хаҗәте калмаганмы?
Җирдә дәүләт коручылар
Җәннәттән куылып чыккан
Ялганчы аллалармы?

Шулар бүлгәнме кишәрләп
Тау, иңкүлек, суларны?
Алар корыштырганнармы
Кол итү кануннарын?

Дәүләтне төзи патшасы,
Тормышын кора халык,
Канун, әхлагы какшаса,
Калалмас беркем алып.

Зилзилә кубар илендә,
Ачларны кырыр туклар...
Ачның ачуы ямандыр, –
Туклар шуны оныткан?!

Ачның хәлен тук белсә дә,
Бирми сынык-саныгын...
Ачудан иле күгендә
Үч ялкыны кабыныр.

Бурдан кала, уттан калмый, –
Сабак алмый, алмаса...
Хәрабәдә кала дәүләт,
Үч ялкыны ялмаса...

Дәүләтемә йөз ел икән...
Тулы гасыр – аз түгел.
Утыз гасыр кол биләгән
Фиргавеннәр канунынннан
Азатмы халкым бүген?..

Кануннарны үзгәртәләр,
Тик үзгәрми үзләре...
Тукларның тулы базлары, –
Туя белми күзләре.

Дәүләт дисең, дәүләт ни ул –
Җигүле дәү арбамы?
Дилбегәсе кем кулында,
Аты ару, арганмы?

Дәүләтенең бөтен йөген
Арбасына салганмы?
Дилбегә тоткан беләме
Кай тарафка барганын?

Дәүләт ни ул, башлангычы
Бер гаилә, бер бәндәме?
Алла бәндәсе дәүләтен
Тәкъдир итәр хәлдәме?

Дәүләтендә бармы икән
Өлешенең көмеше?..
Тегермәне тау кадәрле –
Ни чыгара көшеле?

Дәүләтемә йөз яшь инде,
Тукайдан да яшь үзе.
Уяткан шагыйрь милләтен,
Томаланса да күзе.

Күргән, тойган Хөрриятен,
Атар таңын, Ватанын...
Мөстәкыйль дәүләт төзергә
Хакы бар, дип, татарның...

Янган шагыйрь, йөрәгенә
Кайнар ялкынын йоткан.
Сулышы-тынын суык суккан,
Үпкәсен ялкынсыткан.

Аяктан екса да чире,
Чикмәгән ниятеннән:
Хөр мәмләкәт идеясе
Әләм шигъриятендә.

Мәрттән уяткан милләтен,
Котына өргән тынын.
Күтәреп хәтер төбеннән,
Күрсәткән шанлы чорын.

– Хакың бар! – дигән. Югалтма
Бабаңнар әманәтен.
Хөр мәмләкәт – хак Ватаның,
Кайтар үзал дәүләтең!

– Китмибез, – дип торып баскан,
Куганда туган җирдән.
– Туган телдә җырлап үләм
Җәсәдем күмгәндә дә...

...Җәсәдең җирләгәнгә дә
Йөз елдан артып киткән.
Әй, мөкатдәс моңлы сазың,
Бәгырьне телеп үткән...

Елата да, җылыта да
Тукай моңы, аһәңе.
Елый-елый җырласак та,
Җырлый-җырлый еласак та,
Рухың тоябыз әле...

Хөр мәмләкәт – һәр татарның
Иманы һәм кыйбласы...
Тамырларын тырнап ага, –
Аны кемнәр тыялсын...

Дәүләтенә йөз ел аның,
Йөз көне дә аз түгел...
Милләтен мәрттән уятты, –
Йокымсырамый бүген...

Күзләре ачык милләтнең,
Колагы сау, ишетә:

Көчен туплар, чигендерер
Инкыйразын ничек тә...

Чигендереп кенә калмас
(Чиге юк мәңгелекнең),
Ниятендә – яшьнәп яшәү
Тукайлы милләтемнең!

## 11. Җанисәп ала ил

*(эпилог)*

Ил җанисәп ала көзен,
Ала саны-исәбен.
Аңар жаны-бәгыреннән
Кыйммәт тәннең исәне!

Аңар мотлак белү фарыз
Кем ниләр майтарасын...
Нияте – таралган илен
Ничек тә кайтарасы!..

Нияте – аккан дәрьяны
Бору кирегә табан...
Кемгә нинди йөк төясен
Белеп торуы алдан.

Җанисәп кирәкми аңа,
Аңа кирәк тән исәп;
Кулына кәйлә тоттыргач,
Тауны күчерер исәр...

Корал эшләр – ир мактаныр,
Гыйбарәсе – татардан.
Онытма син, сан алучы,
Татар барда хәтәр бар!

Җан исәбен, ал исәбен, –
Коралларга кул кирәк...
Талап таралган дәүләтне
Укмаштырып тизрәк.

«Бүлгәлә дә идарә ит»
Дигән юкса бабасы,
Бабасыннан калган мирас –
Шыр шәрә, буш саласы.

Бабасыннан калган мирас –
Коргаксыган тагарак...
Корал-кодрәтең барында
Йоклап ятма, талап ал.

Җан исәбен алмакта тик
Алыр тәннәр исәбен,
Артмас һәм кимемәс татар –
Сүнмәс тәмуг кисәве...

Дәүләтемә йөз ел – беләм:
Йөз көне дә аз түгел.
Йөз кабат йөз дисәләр дә,
Тирәндәрәктер төбе.

Йөз кабат санап баксыннар,
Кирәксә – азайтсыннар...
Рухның көчен озайтырга
Бер хак фатихасы бар.

Дәүләтемә йөз ел тулган
Тукайлы гасыр бит ул.
Алтын тәңкә зурдан булмый,
Шуңа да асыл бит ул!

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы*



Лилия
Гыйбадуллина

# КАРА БАТЫР*

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

Көн йөзен бизәп, кояш балкыды. Җәйге җил авылны каймалап тезелгән имәннәрнең иңнәренә кагылып узды да басуга үрләде. Яңа игеннәргә бәрәкәт юрап, туфракны үпте, күккә баккан нәни башакларның башларыннан сөеп үтте. Басу читләтеп, авылның бердәнбер урамына керә торган юл өстендәге җилкапкага сөялеп тын алды да туфрак исен, имән шавын, ипекәй исен куенына сеңдереп, урманга ашыкты.

Бу – Сабан туе җиле иде. Татар җирендә ул бик күптәннән, бик борынгы заманнардан бирле исә. Яңа Мусабай авылы кешеләре, һичшиксез, ул җилне таныйлар, аңа йөз куеп елмаялар, үзләре генә белгән сагыш-өметләр белән аны сәламлиләр. Хатын-кызлар аңа чишмә суында пакьләп юган, Сабан туена кияргә саклаган күлмәк-яулыкларын чыгарып элә. Ир-егетләр, авыр эштән тупасланган каты куллары белән ат ялын тараганда, туган җир тыны булып тибрәлгән шушы җилне дә иркәли. Мең мәшәкате, мең хәсрәте, мең өмете белән авыл иртәгәсе Сабан туен көтә.

Мусабай Сабан туена күрше-тирә авыллардан да киләләр. Якын-тирәдә бәйрәмнәр үткәч, иң ахырдан җыен монда булып, үзенә күрә сабан туйларын шушында җөпләп куялар. Сабан туеның ни рәвешле үтүенә карап, һәр авылның тарихын, холык-менәзен, ныклыгын чамаларга мөмкин. Җыены нинди – халкы шундый. Яңа Мусабай Сабан туе башкалардан соңрак үткәрелә икән, моның үз тарихы, үз хикмәте бар.

Тарих димәктән, гасыр башында, «Рәсәйнең тамагын туйдырам»

* Журнал варианты. Тулы вариантын «Казан утлары» китапханәсеннән» сериясендә чыга торган «Рәкыйп Хәмитов. Копчёный» дип аталган кесә китабыннан укырга мөмкин.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА (1987) – *шагыйрә; «Белла» халыкара әдәби премия лауреаты. «Мин бәхетне күрәм!..», «Тынлык кайтавазы», «Кайту» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

дип, Пётр Столыпин атлы берәү оештырган «җир реформасы» Минзәлә өязенә, Чулман буе татар җирләренә дә килеп җитә. Түбән Суыксу авылы яныннан урман буендагы урынга Мусабай, Иштирәк, Биклән, Мөршетамак авылларыннан дистәгә якын гаилә килеп төпләнә. Башлап күченүче өч гаилә Мусабайдан булып, авылга Яңа Мусабай исеме ябышып кала. Җәмгысе сигез йөз гектар җир кишәрлегенә дүрт яктан имән багана кагылган, көйдереп язган язуы да бар – авылның чиге шушы. Өч чишмәдән гайре бүтән сулыгы-мазар булмаган урында кеше саны, йорт саны әлеге биләмәдән артып чыгарга тиеш түгел. Күченүчеләр, киң бер урам ясап, як-якка каралты-кура сала башлыйлар. Шулай итеп, урман сызыгында – йөзьяшәр имәннәр куенында бер мең тугыз йөз ундүртенче елны Яңа Мусабай авылы тарихы гамәл дәфтәренә язылып китә.

Татар кая гына барып төпләнмәсен, иң тәүдә мәчет-мәдрәсә салып куяр һәм дә, нәүрузгә кереп, туфракка орлыклар иңдергәч, ил-көнгә иминлек юрап, үз гаярьлеген дә күрсәтеп, тугарылып Сабантуй үткәрер. Шунсыз җир сине танымас, бәрәкәте белән бүлешмәс. Сабан туе – үз йөзеннән адәм итеп йөрткән җир-туфрагыңның көчен, олылыгын тану, аны данлау бәйрәме ул. Кыш кырыслыгын сындырып, кояш җиргә яктырак карый башладымы, һәр тере җан бәгырендә яшәүгә сусау кабына. Үпкәләр киң сулыш алырга, йөрәк кызурак тибәргә, күзләр ераккарак карарга тырыша – адәм баласы җир белән күк арасында хакы барлыгын расларга омтыла. Сабан туе – тормышка дәгъва, фани алгарыш мәйданы ул.

Менә кешеләр мәйдан әзерлиләр. Аның уртасына колга кадап куялар. Колга башында – чигүле сөлге. Кояш, абайла син аны – кара җир белән зәңгәр күкне тоташтырып-кавыштырып торган багананы күр! Адәм балаларының Сиңа дан-хөрмәте, якты теләк-хыяллары, матур-имин тормышка дәгъвасы булып, галәмне сәламли ул. Кабул кыл, бәндәләреңә илтифатлы бул, Күк-Тәңре!

Сабантуй – тормыш бәйрәме. Уртасына утыртылган колга әйләнәсендә – күчәр тирәли мәйдан гөрли, тормыш әйләнә. Шушы әйлән-бәйләндә батырлыкта, матурлыкта, чичәнлектә, җитезлектә көч сынашу бара. Сынатырдай булсаң, хәрәмләшергә уйласаң – мәйданнан ерак йөр. Нәсел-ыруың, ил картлары, ак әбиләр күреп-сынап тора. Ил күзендә күркәм күреним дисәң, намусыңа сыен, йөрәгеңә ышан да беләгеңә таян. Сабантуй – гадел күргәзмә мәйданы.

Сабантуй алдыннан өйләрнең тәрәзәләре яктырак балкый, кадерләп сакланган күчтәнәч-сыйлар өстәл түренә менә, ишек-капкалар киңрәк ачыла. Үпкә сүзләр онытыла, йөзләрдә кояш нурлары уйнаклый, елмаясы-көләсе килә. Бәйрәм белән котлау, уен-көлкеле сүз, җыр-моң яңгырап тора. Бизәнеп-төзәнеп, ару атын җигеп, тарантасы түренә тальянын салып, күрше-тирә авыллардан кунаклар килә. Кардәш-ыру күрешә, кул бирешә. Сабантуй – туганлык, дуслык бәйрәме. Яңа Мусабайга күчеп утырган кешеләр, башка авылда калган туган-тумачасын, күрше-күләнен олылап, кунакка дәшә, үз мәйдан-табынына чакыра. Шуңа күрә дә монда Сабан туе иң ахырдан уза.

Кунак чакыруның да үз гадәт-йоласы, хикмәте бар. Уңышларың, күркәм эшләрең белән мәгънәле-матур итеп мактанырлыгың, шатлык-

куанычың белән бүлешерлегең булса – кунак алдында абруең бар, йөзең ак. Кунагың сөенеп, сокланып кайтып китәрлек булсын. Мусабайның тәүге кешеләре нәкъ шулай фикерләгәндер: электән үк өйләр зурдан салынган, хуҗалыклар кинәнеп эшләнгән монда. Кеше алдында ким-хур булмасын. Солтан булырдай киткәннәр иде, олтан булып яталар, димәсен агай-эне. Кардәшләрне көендермик, көндәшләрне сөендермик, матур яшик, дигәннәрдер. Сабантуй мәйданы итеп, чишмәле иркен алан сайланган. Мәйданда ут уйнат, үкчәңнән очкын чәчрәсен, телеңдә былбыл сайрасын да – кызуыңны чишмә суы белән басарсың, рәхим ит.

Кунаклар, туган-тумача авыл башындагы Сабантуй мәйданына юнәлә. Менә мәйданда яшь балалар чабулый: йөгерү ярышы, капчык сугышы, малайлар көрәше, кашык кабып чабулар. Күр, Садыйк малае колгага келәшәдәйябеште, үрмәләпме үрмәли!.. Бу оста көрәшүче олан Шәйхразыйныкы, ахры, атасы чалымнары бар… Хөснулла улы да ныгып, тәмам егет булып бара икән... Әхтәм кызыдыр – бигрәк моңлы җырлый… Кунакка килгән агайлар, апалар мәйдандагы балаларны шулай чалымлап таный, башларыннан сыйпап, аркаларыннан сөеп кала. Мусабайда сабыйлар туа, яңа буын үсеп килә. Сабантуй – өмет бәйрәме.

Сабантуй батырсыз булмый. Сабантуйда мәйдан тотмаган егет беркайчан да батыр саналмый. Җыенның иң кызган мәле – көрәш. Күзләр көрәшчеләргә төбәлгән, мәйданда киеренкелек, халык тын да алмый күзәтә. Менә, ниһаять, баш батыр ачыклана. Ул шактый арган, әмма киң җилкәсенә иң олы бүләк – тәкәне салып, мәйдан әйләнгәндә, җиңү куанычы аны тагын да көчлерәк итә сыман. Тәкә – бүләк кенә түгел, халыкның үз батырын зурлавы һәм яклавы билгесе дә. Ул – явыз көчләрдән, яманлыклардан саклый, дип ышанган борынгылар, Кояшка, Тәңрегә корбан итеп китерә торган булганнар. Андый тәкәгә – «Алланың кашка тәкәсенә» кулың белән генә кагылсаң да, ният-теләкләрең чынга аша, дип инанганнар. Тәкәне җилкәсенә салып, батырын яман күздән, начарлыктан каплап-аралап куйгандыр халык. Шушы матур йола, Сабантуй белән бергә, гасырдан-гасырга, буыннан-буынга күчә килгән. Халык үз батыр улларын сакларга тырыша – халык үзен киләчәккә батыр итеп сакларга тырыша. Татарга батырлар кирәк. Сабантуй – батырлык тантанасы ул.

Авылны нигезләп, Иске Мусабайдан күченүче беренче кешеләр Шәймәрдән, Садыйк һәм Хәмит атлы булган. Дүрт тарафында дүрт баганадан гайре казык та кагылмаган буш урынга йөрәкле һәм беләкле ир заты гына килеп утырыр. Хәмитнең гаярьлеге хакында авылда әле дә тел шартлатып сөйлиләр. Гәүдәгә калку адәм булмаса да, Сабан туйларында мәйдан тоткан, диләр. Җиргә нык басып йөри, аяк терәп яши торган ир булган Хәмит бабай. Йорты җитеш, ихатасы мал-туар белән тулы торган, алты аты булган. Ат менүен да кызык итеп сөйли картлар. Атына арттан сикереп кенә менеп атлана торган иде, диләр. Ике потлы герне урыс капка аша уйнатып кына атуы, аткан герен тотып калулары турында да үзенә күрә бер горурлык катыш соклану белән телгә ала бу як халкы. Менә нинди кешеләр нигезләгән безнең авылны, янәсе. Һәр авылның шулай матур итеп, батыр итеп, масаеп искә алына торган каһарманнары бар. Яңа Мусабайлыларның андый батыры Хәмит бабай иде.

Яңа җиргә кубарылып чыгып киткәндә, Хәмитнең Салих атлы яшүсмер улы, аннан соң туган ике кызы бар иде. Төпчек улы Хатыйпның кендек каны Яңа Мусабай туфрагына тамды. Имәннәр шаулап үскән бу җирдә аның белән яңа көрәшчеләр, яңа батырлар тарихы да яралды. Яралды да имән урманнары куенынннан киләчәккә, Сабантуйларга – татар мәйданына үрләде.

* * *

Көн шактый эссе иде. Күк чалт аяз. Арбага елышкан кара чутыр малай әле күккә бага, әле дилбегә тоткан атасына күз сирпеп ала да урманга карый. Тизрәк барып җитәсе иде бит! Арба төбендә чүпрәк япма астынарак яшерелгән балта һәм аркылы пычкы, өскәрәк җайлап куелган сигезле чалгы белән бергәләп, түмгәк саен сикергәләп бару шактый җайсыз булса да, малайга бик күңелле. Масаюлы караш белән, мине күрәсезме, әткәй белән кая баруымны беләсезме, дигәндәй, әледән-әле авыл тарафына күз сала. Нәкъ әткәсе сыман итеп, дүрт почмагыннан бөкләп, башына кулъяулык япкан. Аның таз башына болай бик үк җайлы түгел, күрәсең. Арба сикергән саен, «баш киеме» малайның күзенә төшә дә, ул аны тагын рәтләп куя, әмма салмый.

Арбадагы чалгы – болай гына, күрсәтмәгә генә. Моны ата белән ул да, авылдашлар да бик яхшы белә белүен. Бу якларда агай-эне беркайчан да арбасына чалгы салмый юлга кузгалмый, кая гына юнәлсә дә. Гадәте-йоласы шул, дигәндәй. Берәүгә дә сер түгел, Хатыйп имән аударырга бара.

Моңарчы урманга олы улы Нәкыйп белән йөрде ул. Ихатада да, читтә дә әткәсенең уң кулы иде Нәкыйп. Буй җиткән, белгәненә көч кергән улың булу һай рәхәт икән ул. Эшлим дисә эш рәтен, сөйлим дисә сүз рәтен белә торган егет булып бара бит бу олан дип, эчтән генә куанып йөри иде ата кеше. Куанычына көя төште шул. Менә атна-ун көн инде – Нәкыйбе армиягә киткәннән бирле Хатыйп абзыйның бер эшкә дә күңеле үсми, кәефе кителеп тора әле. Күгәрчендәй гөрләп, уен-көлке белән генә сөйләшә торган хәләле Дөрлекамал да боекты. Көтелмәгән хәл түгел иде түгелен. Нәкыйпнең хәрби хезмәткә алынасын чамалап, шактый вакыт эчтән көеп йөрсәләр дә, балаңны читкә чыгарып җибәрүләр барыбер бик авыр икән. Дөрлекамалы да, өстәл хәстәрләгәндә, ашын һаман алты савытка бүлеп тилмерә.

Исән булса, кайтыр. Дөньялар имин торсын да, сугыш-мазар чыга күрмәсен. Сугышның ни икәнен Хатыйп бик яхшы белә, үзегенә үтәрлек, ачысы җиде буын оныгына җитәрлек итеп аңлаттылар… Утыз тугызынчы елны фин сугышына алынганнан, герман сугышын да кичеп, кырык алтыда гына кайтып егылды. Ул кайтты, ә кайталмаганнар күпме... Абыйсы Салихның йорты турыннан үткән саен йөрәк сызлап куя. Салих кайталмады, «хәбәрсез югалды» дигән кәгазе генә кайтты илгә. Имәндәй ирләрне йотты бу сугыш. Ятим-ятимә белән авыл тулы, сугыш имгәтмәгән бер генә нәсел дә юк. Һәр йортка җир йөзендәге иң кабахәт, иң куркыныч тарих булып, сугыш күләгәсе эленеп калган... Һе, безнекеләр күккә менмәкчеләр, ди. Айга җитә торган очкыч ясыйлар, янәсе. Айга үрләгәнче, җиреңне тәртипкә китерәсе иде дә бит… Ә җир тыныч түгел. Әнә, Әмрикә безгә каршы чыгымчылап маташа, ди анда. Ракеталарын төбәп үк куйган икән. Агай-эненең сүзе шул турыда гына. Сугыш күргән ир-атларның яралары сызлый бүген. Нәкыйбе шул тирәгә эләгә күрмәсен берүк. Менә бит хикмәт нидә…

Болдырда чал башын аска иеп, берникадәр утырганнан соң, Хатыйп авыр көрсенде дә, шомлы уйларын куып таратырга теләгәндәй, тезләренә шапылт сугып торып басты. Тураебрак, күкрәген киеребрәк калкынырга тырышты. «Йә, ярар, Аллага тапшырдык!» – дип, көр тавыш белән үзалдына әйтеп бетерергә өлгермәде, шомланып, тирә-ягына күз йөртеп алды. Аз сүзле ирнең болай «тугарылып» сөйләнүен, бәхеткә, берәү дә ишетмәде кебек...

Ишегалдында малайлары әвәрә килә иде. Берсеннән-берсе бәләкәй өч ташбашның чыр-чу килеп уйнауларын аталарча басынкы-яшерен соклану белән, ипле генә елмаеп карап торды Хатыйп. Берсе чыгып китсә, итәктә тагын өчесе калды лабаса. Нәкыйбе туганда, үзе сугышта иде. Олысының терекөмештәй мондый чакларын күрү насыйп булмаган. Анасы карынында гына калган нарасыеның, Хатыйп яудан кайтып кергәндә, алты яше тулган иде. Бер-берсенә шактый озак ияләште алар. Аннан соң туган игезәк малайлар гомерле булмадылар. Шул хәсрәттән соң, юаныч булып, илле икенең июлендә Рәкыйп туды, аннан бер-бер артлы Рафис, Раиф. Өч малай матур гына тәгәрәшеп үсеп киләләр, шөкер. Кара син аны, ике яше тулыр-тулмас Раифы да абыйларына махы бирми, йодрык төйнәп маташа түгелме?

Ата кеше, болдырдан төшеп, оланнарның пеләш башларыннан сыйпагандай итте дә абзарга юнәлде. Эштән кайткач, җирән айгырны тугарып торасы булмаган икән лә.

Рафис белән Раиф уенга мавыгып калды, өлкәнрәкләре – җиде яшьлек Рәкыйп әткәсе артыннан иярде.

– Әткәй, кая барасың?

– Урманга.

– Мин дә барам.

– Анда сиңа ни калган?

– Имән аударам.

Хатыйп көлемсерәп, малаена каш астыннан күз ташлады:

– Көчең җитәрме соң?

– Җитәр, – дип, борын тартып куйды малай. – Кичә күрше Шакирҗанны җиңдем мин. Көрәшеп караган идек.

– Әйтәм аны, ыштаның җыртылган. Ярар, барырсың. Елап кайтасы түгел, матри.

Иптәш булыр, атның кигәвенен булса да куып торыр, дип уйлады ата кеше. Барам дигәч, барып карасын әйдә.

Чимал өчен имәнне кышын аудару мәслихәт. Чаначы Хатыйп моны яхшы белә. Кара көз үтеп, кар яткач, кыш кышлыгын итә башлаган бер вакытта җилсез-нисез көннәрне чамалап, урманга юнәлә ул. Чана өчен имәннән дә кулае юк. Мусабайлар кебек имәнлеккә тиенмәгән якларда чананы чаганнан да ясыйлар, әмма бәрәкәте булмый инде андый нәрсәнең. Чана түгел инде ул. Чана өчен имән кирәк. Имән! Вәләкин имәннең тегенди-мондые гына бармый. Киң булсын, утыз икеле, ким дигәндә, егерме сигезле булсын ул булгачтын. Ел исәбе белән санасаң, җитмеш-сиксән яшьтән дә аз түгелдер чаначыга гамәлгә яраклы имәннәрнең яше. Буе-сыны да килешле булу кирәк: боргаланып, бөтерелеп үсмәгән булсын ул, төз-төзек кәүсәле, һәрбер җепселе шәм шикелле туры торсын. Менә шундыен табалсаң, бисмилласыны әйтеп, пычкыңа тотынсаң да ярый. Агачың уфылдап җиргә аугач, күкрәк

тутырып, тын алып куясың да җайлап кына, ботакларын чабарга керешәсең – алары утынга ярап тора.

Шуннан имәнне чана табаны озынлыгы чамасында бүрәнәләргә турыйсы. Монысын хәстәрләгәч, бүрәнә башына чөй кагып, урманда ук ярып куйсаң яхшы. Беләк юанлыгы булдымы, имәнне сындырырмын димә, әмма тиз ярыла ул. Табанын гына түгел, чананың «тырнакларын» да имәннән ясау тиеш. Шуннан инде әзерләгән чималыңны өештереп, урнаштырып куясың да, иркен сулап, кайтып китсәң дә була. Аударган агачыңны авылга алып кайтырга иртәрәк әле. Караңгы төшсен, йортларга йокы кереп, тәрәзәләрнең күзләре сүнсен. Ә сиңа йокларга ярамый. Төнге икеләр тирәсендә көндез әзерләгәнеңне ихатаңа кайтарып бушатасың. Чаналык имәннәрне тирес астына күмеп куюдан да кулае юк. Кеше-кара күзеннән читтә, җылыда, бөгәрлек булып өлгереп ятачаклар алар шунда.

Тик бүген агач аударудан битәр, күңел өчен бара урманга Хатыйп. Җәйге тынчу чилләләрдә урман сулышын сагына ул. Кәсебе никадәр генә авыр булмасын, күңеле ята, җаны тарта торган шөгыле шул инде – үзенеке. Ә урман! Урман – ирнең тәненә генә түгел, җанына да сихәтле сулышын бөрки торган изге урын. Шушы мең аһәңле тынлык мәйданында ул үзен чиксез иркле һәм хөр хис итә. Буталган-чорналган уйлары җай гына бер җепкә тезелеп, аңы да яктырып, күңеле тынычланып кала кебек.

Моңарчы кул арасына керүне уйламаган, урамда трай тибүдән башканы белмәгән кара чутыр улы да урманга барам дип чәпчегәч, алгысынып чыгып китте бит менә. Хәерлегә булсын. Урман йөрмәгән малай – малаймы ла, урман кичмәгән ир – ирме.

Ата кеше, авыр эштән каткан көрәктәй кулларын чандыр улының җилкәсенә салды да җай гына сөеп куйды:

– Имән аударыр өчен көч кенә җитми шул, улым. Сол кирәк, сол...

* * *

Урман хөр, урман мәгърур. Ябалдашлары астына яшерә дә меңәрләгән җан иясен, үсемлекләрне, кош-корт, хайваннарны үз биләмәләренә сыендыра. Бәгыренә торган саен ныграк кул сузарга ашкынган адәмнәр дөньясын бар дип тә белми. Үз кануннары, үз моңнары, үз вакыты-җае белән гасырларны кичә бирә. Кичә генә туфрак төбеннән тибеп чыккан яшь үсентеләр бүген яңа көнне яңа яфраклар, яңа буыннары белән сәламли. Иртәгә инде алар көр тавышлы, калкандай куе урман булып калкынган була. Көзен төбе генә тилмереп калган агачларның җанын язын тын бөреләре уята. Урман – хөр, урман – мәңгелек.

Урман серле, урман төрле. Кыбырсык усаклары, ак сыйраклы каеннары, чыраш чыршылары һәм сабыр имәннәре бар аның. Кара туфрак төбенә тамырлары белән кадакланган, зәңгәр күк йөзенә тыннары белән үрелгән агачларның ым-сагышын аңлар өчен, урман түренә үк кереп, нәкъ агачлар кебек җиргә басып, күккә карарга кирәктер.

Агачларның күктә тын гына чайкалуын сихерләнгән сыман күзәтте малай. Кулъяулык-түбәтәенең башыннан шуып төшүен дә сизми калган. Урман эченнән күзләгәндә, күк шулкадәр тансык зәңгәр икән. Агачлар шундый да биек, шулкадәр дә көчле! Рәкыйп, урман түренә кергәч

үрелеп, күккә текәлде, күңелен серле ашкыну биләп алды. Аның агачлар кебек буласы, күккә кадәр җитәсе, шундый ук көчле һәм хөр буласы килә иде.

Көчле янында көчле буласы, матур янында матур буласы килә шул. Шуңадыр, мөгаен, кешеләр-халыклар үзләренең батырларын һәм матурларын саклыйлар, хәтерләреннән чыгармыйлар. Үзләре дөньядан киткәч тә, алар турында җырлар җырлана, картиналар, китаплар языла, телдән-телгә риваятьләр күчә. Гөл янында гөл буласы, имән янәшәсендә имән буласы килә…

Җирән айгырны урман аланында тугардылар да чалгы һәм балтаны алып, имәннәр үскән якка атладылар. Салкынча урман һавасы киемнән үтеп, эчкәрәк үрмәләде, тәндәге мең күзәнәкне уятып-чеметеп чыкты. Җиләс рәхәт салкынлык канны кыздыра, тән җегәрен уята, хәрәкәткә, яшәүгә өнди. Хатыйп эре-эре адымнар белән алдан бара, Рәкыйп, атасына чак ияреп, арттан чабулый. Малайның урман эченә – түренә үк беренче кат керүе. Беренче тапкыр! Бу көнне, бу халәтне гомерлеккә исендә калдырачак, төшләрендә күреп саташачак әле ул. Әлегә йөгерә-атлый әткәсе артыннан баруы. Җирдә яткан ботак-сатакка абынып егыла, җәһәт кенә сикереп тора да йөгерергә үк тотына. Үзе мыш-мыш сулый, кояш үпкән кара-кучкыл битләрендә, борын очында тир бөртекләре биешә. Чем-кара күзләре кояштан да яктырак балкый төсле.

Әткәсе, исе дә китми, урамангa берүзе килгәндәй, Рәкыйпкә борылып та карамый, алга атлавын белә. Кайвакыт берәр агач янында туктап, гадәтенчә кулын маңгай өстенә куеп, агач кәүсәсе буйлап күз йөртеп чыга, кайрысына кул тидереп, суккалап ала да тагын ары китә. Атлаулары ныклы, адымнары киң. Гаҗәп, бераз бөкрәебрәк, түбән карап йөри торган әткәсе монда, урманда, төп-төз гәүдәле, алыптай зур һәм көчле тоелды малайга.

Менә ул тагын туктап калды. Шәп кенә бер имәнне күздән үткәрде, як-ягын әйләнеп чыкты, кәүсәсенә шап-шоп суккалап алды, читкәрәк китеп, тагын бераз карап торды да Рәкыйпкә борылды:

– Синең имән шушы булыр, улым. Җә, тотындыкмы?

Рәкыйп, елмаеп, баш какты.

Әтисе, ипләп кенә, аркылы пычкының тешләрен агач кәүсәсенә батырды, эз салды. Ата белән ул, имәннең ике ягына басып, пычкы сабына ябыштылар.

Хатыйп никадәр кызуламаска тырышса да, ир көйләгән ешлыкта пычкы тарту малайга бик авыр иде. Ул бөтен көченә тартыша, пычкы сабына ике куллап тотына, аякларын да имәнгә терәп карый. Кашлары җыерылган, иреннәрен ачу белән тешләгән, пычкыдан күз дә алмый, тырышып-тырышып тарта. Бирешергә исәбе юк.

Ата кеше сынап кына, каш астыннан улын күзәтте. Юри генә ияртkән иде югыйсә, кара син аны, чытырдап ябышты, җан-фәрман пычкы тартып маташа бит бу ташбаш. Тумыштан ныклы булды бусы, эре туды. Биләүдә чакта ук тавышы көр ишетелә иде. Яшьтәшләре арасында гәүдәгә дә калкурак сыман. Рәт чыгарга ошап тора бу малайдан, дип уйлады ир кәефле генә. Урман йөргәндә ияртерлек булып килә, сөбханалла. Сабыйга сокланып, күз тидермим, дигәндәй, Хатыйп, карашын каерып, тирә-юньне

искәреп алды. Чаж-чож пычкы тавышы якындагы йөзьяшәр имәннәр кәүсәсенә барып бәрелә дә, кайтаваздай кайтып, чал чәчле ирнең колагын иркәли иде.

* * *

Иренең ат җигеп чыгып киткәнен түр як тәрәзәдән сагаеп карап калды Дөрлекамал. Җанына урын табалмый йөрүе инде, шулай булмый ни. Ат җигелгән арба урманга таба юыртты. Арбада Рәкыйп кукраеп утыра. Малайларның монысы бигрәк тиктормас, җитмәгән җире, үзенекен итми калганы юк. Бала-чага арасында кайда нинди бәрелеш-чукыш – шунда безнең Рәкыйп булыр. Әле кичә генә күрше Фатыйма кергән иде. «Рәкыйбең минем Шакирҗанымны кыйнап, борынын канаткан», – дип, каз шикелле ысылдарга маташа. Бәрәкалла, безнекен кыйнап кертмәгәннәр ләбаса. Борынын салындырып, җебеп торса да, һәйбәт булмасые шул. Дөрли (авылда аны шулай дип йөртәләр) дәшмәде, орып бәрелмәде, иплэп кенә самавырын яңартты.

Күрше-күлән белән сүзгә килеп, ачу саклап, гайбәт йөртеп яши торган хатын түгел ул. Кешегә йөзе якты, теле татлы. Сандугачлардай сайрап, чәй артында килештереп-җайлап чыгарды бу юлы да күршесен. Карасына катып килеп кергән иде, май кояшыдай балкып чыгып китте Фатыйма, менәтерә. Сүз дигәнең кара төндә дә кояш чыгара шул.

Бер матурга бер ямьсез, без телчәнгә бер телсез дигәндәй, Дөрлекамалның теле телгә йокмаса, Хатыйптан сүз дигәнне каерып та алырлык түгел кайвакыт. Алай да, үзенә кирәктә, бар иде Хатыйпның да телле чаклары. Бар иде. Торыр җире, башка чыгар каралты-курасы да булмаган егетнең баллы теленә алданып кияүгә китте түгелме соң Дөрлекамал. «Кулымнан да төшермәм, өрмәгән җиргә дә утыртмам, җанкисәгем», дип, күпме сайрады Хатыйп ул заманнарда.

Никахлашканнан соң, бәхет эзләп, читкә – Владивостокка чыгып киттеләр. И, анда күргәннәр! Ачлык, торыр җир булмау, баракларда кунып йөри торгач, бетләпләр беттеләр ләбаса. Иң авыры – сагынуга түзәр хәл юк. Абыйларын-апаларын, туып үскән өен сагынып, әткәсен-әнкәсен уйлап, көн саен елый иде яшь килен. Бу газапларның очы-кырые күренмәгәч, ахыр чиктә, ирен туган якка кайтырга үгетли башлады. Җир читендә баракларда бетләп ятар өчен җиде класс укыганмы әллә? Сәүдәгәр Ситдыйк кызы ла ул!

Әткәләре Ситдыйк бай бик уңган кеше иде. Мал табарга маһир, тиктормас, тырыш адәм иде, бахыр. Базарга барганда да, тик утырмый, чабата үрә-үрә бара дип сөйлиләр иде аның турында. Йортлары – әйләнә-тирәгә бер калай түбәле олы өй иде. Менә шул сандугач оясы кебек өйкәйләрдә әткәсе-әнкәсенең төпчеге, абый-апаларының курчак кебек сөекле сеңлесе булып үсте Дөрлекамал. Әнкәсе Сара да теле телгә йокмый торган, уңган-булган хатын иде, мәрхүмәкәй. И заманалар… Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый, дип белми әйтмәгәннәр. Башланды бит берзаман мәхшәр, бөтен хәлле кешене кулакка чыгарулар. Түбән Суыксу авылының атаклы Ситдыйк бае гаиләсен дә урап узмады ул давыл… Юкса мондый барлы-юклы тормышларда яшисе кеше идемени Дөрлекамал. Юк ла, Хатыйпның тәмле теленә ышанмады кыз. Тамчы да ышанмады. Башка чарасы юк иде аның...

Хатынның туктаусыз колак итен ашаулары килештеме, читтә бәхет тәтемәсен үзе аңладымы – йончып-арып, Хатыйпның туган авылына, Яңа Мусабайга кайтып егылдылар берзаман. Монда да аларны колач җәеп, берәү дә көтеп тормый иде. Ташландык бер өй алып, сипләп-ямап, шунда яши башладылар. Иске булса да, үз куышыбыз, дип куаныргa дә өлгермәделәр, сугыш башланды. Ирен беренчеләрдән булып алдылар. Хатынын һәм карындагы улын калдырып, Хатыйп фин сугышына китеп тә барды. Дүрт почмагыннан җил өреп торган иске өйдә көмәнен кочаклап утырып калды Дөрлекамал.

Ярый Шәех абыйсы ярдәм итте, рәхмәт яугыры. Җыйнак кына өй салып бирде. Суыксудан тиклем бозау да китерде. Хатын, ничек итсә итте, сыер итеп үстерде аны, Нәкыйбенә сөт булды. Сугыш елларында, авыл белән җыйнау ачка тилмергәндә, Дөрлекамал улын да, үзен дә саклап кала алды. Ә бит өмет дигәнең өзелер чиктә иде. Сугыш бетеп, исәннәр үзе, үлгәннәрнең үлде сүзе кайтып бетте авылга. Хатыйбыннан хәбәр-хәтәр юк та юк. Исәндер, кайтыр дигән өмет уты көннән-көн сүрелеп барганда, һай, авыр икән лә ул. Сугыштан кайткан ирләрнең, Нәкыйпне кызганып, башыннан сыйпап үтүләрен, малайны ятим санап җәлләүләрен күрү хатынның йөрәген сызып-сызып ала иде. Атасы исән аның, кайтачак, дип, йөзләренә бәреп кычкырасы килә андый чакларда. Ә күңелнең бер читен шик корты кимерә. Кайтмаса? Кайтмавы да ихтимал бит. Бу уеннан хатын үзеннән-үзе оялып, куркуыннан куырылып куя. Шик-шөбһәләрен җимерер өчен күзләрен чытырдатып йома, иреннәрен кысып тешли. Кайтачак, кайтам дип китте. Әйткәнен үти торганнардан ул Хәмитовлар. Кайтыр. Хатын тораташтай басып торган төшеннән кисәк кенә кузгала да эчке бер ярсу белән каты-каты басып китеп бара. Башындагы яулыгын салып, аны җәһәт кенә кысыбрак бәйләп куя. Бу мизгелләрдә аның кыйгач кашлары җыерылып, күзләренә ярсулы тирән сагыш сызылган була. Сабый гына булса да, әнкәсенең хәлен Нәкыйп тә аңлый иде бугай. Безнең әти кайчан кайта, дигән сорауны көннән-көн сирәгрәк бирә иде балакай.

Хатыйп кырык алтыда гына кайтты. Михнәт адәм баласын үзгәртсә дә үзгәртер икән. Финнәргә плен төшкән, күрмәгәне калмаган бахырның. Өрлектәй ирнең өрәге генә кайткан, диярсең. Ут шикелле егет булып киткән иде, чал чәчле ир булып кайтып егылды. Бер сүз тартып чыгарырмын димә, ачылып китеп сөйләшми дә бит ичмаса – гомер буе иң үзәккә үткәне дә шул. Ирең белән кара-каршы утырып, барын-югын уртага салып сөйләшә-сөйләшә чөкердәшеп, чәй дә эчмичә үтеп бара инде гомеркәйләр. Әткәләре сөйләшмәгәнгә күрә, улларым да йомыкый булып үсмәсен дип, өебез шау-гөр килеп торсын дип, сүзнең кимен куймый, күгәрченнәр булып гөрли Дөрлекамал. Сөйләшмәсә сөйләшмәсенсанә, әйтәсен барыбер әйтә ул. Иң мөһиме – кайтты, исән-төзек кайтты. Кайту белән ат караучы булып, колхоз эшенә урнашты. Атларыннан бушаган чакларда да кул кушырып утырмый, чана ясый, имән бөгә. Куллары алтын бит аның. Авыл ирләрен җыеп, күрше-тирә авылларда өйләр дә сала. Кешедән ким-хур яшәмиләр, ашсыз да, эшсез дә утырганнары юк, Аллага шөкер. Якын-тирәдәге колхозларга чана ясый Хатыйп. Утыз чана әзерләп өлгертте исәме, хакы – бер тай.

Авыллары белән шундый монда халык – бәләкәйдән эшләп, эш рәте белеп үсәләр. Ир балага бишектән үк балта тоттырып куялар Мусабайда,

валлаһи. Ярыша-ярыша өйләр сала, мал-туар, кош-корт асрый, умарта тота бу авыл кешеләре. Үзләре дә умарта күче кебек бердәм. Берәрсе каралты-кура җиткерәм диде исә, чакырып-нитеп торыш юк, хәзер бөтен авыл белән җыелып, өен күтәреп тә куялар. Узган ел, кыш чыккач, түбән оч бөтенләе белән янып бетте ләбаса. Ярты авыл көл өеме өстендә утырып калды, орлыкка дигән бәрәңгеләренә хәтле кара күмергә әйләнгән иде. Ходай бәндәләрен ташламады, бәндәләр дә бер-берсен чит итмәде. Көлгә әйләнгән җирне гөл итеп, янә өйләр салып, мантып киләләр, шөкер. Бер-береңә ярдәм итмәсәң, нишләмәк кирәк. Илгә килгәнне ил белән күтәрсәң генә. Бу авылны нигезләүчеләр, күч булып аерылып чыкканнар да урман авызында төпләнгәннәр менә. Бердәм булмый, тырыш булмый кара, нибуч, хәзер бетәсең. Тормыш – кара урман ул.

* * *

Урман – җир тарихының тере ядкаре. Гасырлар буе үз кануннары, куенындагы кара серләре белән күкрәп утыра ул. Колачы киң, күңеле хөр. Нәни-нәзберек чәчкәләрне дә, кырку куакларны да, биек агачларны да сыендыра, саклап яшәтә. Кешеләр дөньясындагы кебек кырыс кануннары да юк түгел.

Башкалардан югарырак үрелгән, хөрлек сөйгән, биеклеккә омтылган имәннәргә күк, зәңгәр күзләрен тутырып, үзе иелеп карыйдыр. Болытларның, кояш-йолдызларның теле булып, сөйләшә белсәләрме, алар иң тәүдә имәннәргә сүз катарлар иде. Имәннәр күккә артык якын. Тамырларын җир җылытса, иңнәрендә күк тыны. Имәннәргә яшен сугучан, имәннәрне күк камчылый-камчылый сыный…

Рәкыйп урман белән дуслашты кебек, көн саен шунда. Урманга арка терәп үскән, җиде яшеннән урман кискән малай монда өендәге кебек хис итә үзен. Урман да бу «җанварын» үзсенә, ахры, юлына бүре-мазар чыкканы, бәлагә тарыганы юк. Юкса, күрше Мәләкәс мәктәбенә йөреп укучы Яңа Мусабай балаларының юлы көн саен урман аша уза. Әче таңнан торып, җиде километр баралар, шуның биш чакрымы урман эченнән үтә. Башлангыч мәктәпне үз авылларында укыдылар да аннан Мәләкәскә йөри башладылар менә. Уллары торуга, әнкәләре кабартма, кыстыбый, шәңгә яки өчпочмак пешереп куярга өлгерә. Үзе йокламый да, ахры. Кыстый-кыстый ашаткач, исән-имин йөреп кайтуларын теләп, сабакка озата. Яз-көз велосипед белән җилдерсәләр, кышын чаңгы тагып чыгып китә Хатыйп уллары.

Мәләкәстә интернат барын бар да, Яңа Мусабай малайларын анда тотармын, димә инде. «Кызлар сымак интернатта кунып ятмаем», дип кенә җиффәрәләр. Бишенчедә укыган чагы иде бугай, Рәкыйп буранлы бер көнне интернат дигәннәрендә кунып калган иде дә, шул арада корчаңгы ияртеп кайткан. Энекәшләренә дә «бүләк иткән». Хатыйп аны-моны уйлап тормады, кызу мунча ягып, малайларның өчесен бер тиң акырта-акырта пиннек белән чапты. Җитмәсә селтеле әче су белән юындырды. Шуннан соң Хатыйпныкылар таш яуса да, өйгә кайтып китә торган булдылар. Җиде генә чакрымны үтмәскә, бала-чагамы әллә алар. Ихатаңда эш өелеп торганда, янәсе. «Эшләп кеше үлми, эшләсеннәр. Иң мөһиме, шәпләп ашат син боларны, әнкәсе» – Хатыйпның яратып әйтә торган сүзе шул. Үсеп

килгән өч улын сыйлау дигәндә, Дөрлекамалга куш. Ризыкны, үзалдына җыр көйли-көйли, эченнән генә шөкерана кылып, яратып пешерә ул. Яратып әзерләгәнгәдер, телеңне йотарлык була.

Эштән бушаганнары юк малайларның. Мәктәптән кайту белән тамак ялгап алалар да чыгып китәләр. Мал-туар карау, су ташу, кар көрәү, утын яру кебек эшләр алар өстендә. Урманга барганда, атасы Рәкыйпне үзеннән калдырмый. Көн саен хәрәкәттә, хезмәттә үскән малайның беләк көче көннән-көн арта, таза-матур егет булып үсеп килә. Төс-биткә эткәсе ягына тарткан, Хәмит бабасына охшаталар үзен: шундый ук кылдай каты керпе чәч, биек маңгай, калын кара кашлары астыннан елмаеп кына карый торган кысыграк коңгырт күзләр, озынча төз борын. Болай да каратут тәнле Рәкыйп, кояш күрендеме, кара-чутырга әйләнә дә куя. «Кыз бала булып туасың калган ла, авылда бер чибәр булыр идең, улым», дип шаяртып сөя оланын Дөрлекамал. Кыяфәткә Хәмитнекеләргә тартса, холкы әнкәсенеке. Ордым-бәрдем сөйләшми, сүз көрәштереп пычранмый, ачык йөзен, яхшы сүзен кешегә кызганмый.

Олы уллары Нәкыйп армия хезмәтендә өч ел йөреп, исән-имин кайтты, шөкер. Тәмам егет булып, олыгаеп, үзгәреп кайтты. Су асты көймәсендә йөзгән, менә-менә Әмрикә сугыш башлый дип көтеп ятканнар. Алтмыш икенең октябрендә сугыш башланасы булган ди дә, бер әфисәр атмыйк дигәч, башламаганнар, ди. Аздан гына калган, ди. Шул көймәләрендә иркенләп һава суларга да тилмереп яткандыр бала, башы авырта торган булып кайтты. Җирне сагынган, урман-болыннан кайтып та керми, кинәнеп печән чапты, көтү көтте. Бер җәй өйдә торды да читкә китү ягын каера башлады. Нишләрсең, өйләнер яше җиткән улыңны яныңда тоту да килешеп бетмәс. Чаллыда олы завод төзеләчәк, ди, яшьләр шунда күчү ягын чамалый хәзер. Бала күңеле далада, дип хак әйткәннәр. Ана күңеле дүрт баласын уйлап, меңгә телгәләнә иде.

Кайткан мәлләрдә, ишегалдында гер күтәреп маташты Нәкыйп. Рәкыйп тә кызыгып китте. Аннан күрмәкче, күрше Шакирҗан да кушылды. Чак кына буш вакыт таптылармы, ярыша-ярыша таш күтәрәләр. Яшь аермалары бер генә ел булып, бу ике малай бергә әвәрә килеп үстеләр. Кара-каршы күрше булып яшиләр, Рәкыйп кая – Шакирҗан шунда, ни майтарсалар да, гел бергә. Чишмәдән су ташырга да, көтү каршыларга да, ат эчертергә дә бергә йөриләр. Бу икәүгә хәтта чөгендер җирен дә янәшә бүлеп бирә бригадир – икәү булсалар, малайларның ярышып кызу-кызу эшлиселәрен чамалый. Янәшәңдә шулай терсәк төртешеп, ярышып-узышып үсәр иптәшең булу бик яхшы ул. Урманда агачлар да, иңгә-иң терәлгәч, бер-берсен узмак булып, биеккәрәк үрли, төз-ыспай булырга омтыла түгелме. Рәкыйп белән Шакирҗан да шулай кем-кемне дип, ярышып үстеләр: малайчактан Сабан туйларында бил алыштылар, узыша-узыша гер күтәрделәр. Сигезенчене бетергәндә, ике потлы герне унышар кат ата иде инде Рәкыйп, күршесе дә аннан калышмый.

Җәйләрен бу икәүнең иң яраткан урыны – җәйләү, дөресрәге, җәйләүдәге ат көтүе. Җай булдымы, сәпитләренә атланалар да шунда җилдерәләр. Түбән очка төшәсе дә басу аша сулга – урман якка каерасы. Мунчала күлен узгач, ат көтүе торган аранга ерак калмый. Малайлар өчен бу ара – ике атлап, бер сикерү. Әткәсе ат караучы булгач, Рәкыйп монда бөтенләй үз кеше.

Мең тугыз йөз алтмыш алтының язы иртә килде, апрель үтәр-үтмәс, җәй кояшы карый башлады. Көтүләр күптән чыккан, атлар да җәйләүдә иде. Рәкыйп тә шунда, төш вакыты якынлашса да, өйгә кайтасы килми, эткәсе тирәсендә чуала. Озын агач улакка су салган була, яшь тайларның йомшак ялларын тарый, маңгайларыннан иркәләп ала. Атлар янында дөньясын оныта ул, эткәсе куып җибәрмичә, кайтуны уйламый да. Тик бүген озак юанырга туры килмәде, яңгыр ява башлады. Күк йөзен иртәдән үк эленке-салынкы болытлар томалаган иде. Кыш буе тулышып торган да бүген буасы ерылган диярсең – ишә генә яңгыр. Рәкыйп сәпитенә атланды да авылга чапты. Басу юлына чыккач, авылга таба атлаучы берәүне ерактан ук шәйләп алды малай – бригадир Раббани абзый икән.

Раббаниның кызу-кызу атлап, өенә кайтып барышы иде. Атын абзарда калдырып, басуга җәяү чыгып китте ул бүген. Җирне табаннары белән тоеп, яз һавасын сулый-сулый йөреп кайтасы килеп, күңеле алгысынды. Чәчүгә төшәр чак җитеп килә. Басуларны караштырып, эскерт төпләрен яндырып шактый йөрелгән. Яңгыр ява башлагач кына кайтыр якка кузгалды. Арканы төепме төеп ява.

...Хатыны үлгән көнне дә шулай яңгырлы иде, көне буе иште генә. Әйтерсең, күкләр дә елады. Берсеннән-берсе кечкенә дүрт баласын кочаклап тол калган ирнең кайгысын яңгыр гына юарлык идеме соң! Әлфирәсенең унынчы яшь белән киткән чагы, Зәлифәсе беренче сыйныфны тәгәлләгән, Заһидәнә өч яшь тә юк, Заһидәсе бишектә… Үзе дә үги әни белән үскән Раббаниның йөрәгеннән кан тамды, төн чыкканчы чәченә чал йөгерде. Менә шундый авыр көннәрдә Ходай аның юлына Түбән Суыксу кызы Мөнҗияне чыгарып куйды. Йөрәкле дә хатын булды инде аның Мөнҗиясе, дүрт ятим өстенә килен булып төште бит. Йортка ямь кайтты, сабыйларның йөзенә елмаю кунды. Бишенчегә Зөфәр туды. Яшисе дә яшисе әле!.. Тукта, нишләп уйга чумып бара соң. Зөфәренә ике яшь тулган көн ләбаса бүген. Улының туган көне! Мөнҗиясе аш өлгертеп, ут йотып көтәдер, җәһәтрәк атларга кирәк…

Арттан сәпит белән җилдереп килгән Рәкыйпнең Раббани белән тигезләшкән һәм «Саумы, Раббани абзый!» дип сәлам бирергә авыз ачкан мәле иде. Кинәт баш өстендә коточкыч шартлау яңгырады. Бер мизгелгә дөнья күзне томаларлык тоташ яктылыкка әйләнде… Рәкыйп һушына килгәндә, аны кемдер дер селкетә, битләренә суккалый иде. Баш чатнап авырта, колак томаланган. Күзен көчкә ачып, яшүсмер шашынган кыяфәттә як-ягына каранды. Басу юлыннан егерме-утыз метр читтә ята үзе. Тирәсендә берничә кеше.

– Мин исән. Раббани абыйны карагыз...

Рәкыйп, сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, кабат аңын җуйды. Хастаханә бүлмәсендә генә һушына килде. Күкләрнең тамгасы булып, уң балтырында гомерлеккә каласы яшен эзе сызылып узган иде.

Иртәгәсен, авыл белән кан-яшь түгеп, Раббанины җирләделәр. Сукыр әнкәсен, хатынын, биш баласын, иген иккән басуларын, Мусабайның чишмәле бакчаларын, имәнле урманнарын мәңгелеккә калдырып, авылның Сабантуй батыры Раббани Шәймәрданов туган җире куенына кереп ятты. Җир йөзендә тормыш дәвам итәр. Балалары үсеп, әйбәт кешеләр булырлар,

оныклары Ауропада кул көрәше ярышларында чемпион калыр. Авылда яңа көрәшчеләр үсәр, Сабан туйлары гөрләр. Мөнҗия апа гына ел саен тәүге яшеннәрне шомланып көтәр һәм ачынып озатыр. Алар аны гомеренең унынчы дистәсен ваклаганда, балалары кадер-хөрмәтендә, түр башында яшәгән чакларында да төннәрен сискәндереп уятыр. Ак яулыклы карчык, яшен тизлегендә узган бәхетле көннәрен, мәхәббәтен искәреп, күңеленнән генә кабат елар да Раббысына шөкеранә кылыр.

* * *

Чаңгыга бастымы, Рәкыйпне арттан этә-төртә җеннәре куалый, диярсең. Аннан алда беркем дә булырга тиеш түгел – бетте-китте! Яңа яуган кардан эз ярып, иң алдан, иң беренче булып, Рәкыйп барырга тиеш. Каян килгән гадәттер, кеше аркасына карап, елышып баруны өнәми егет. Сигезенчедә укыганда ук, өлкән сыйныф укучылары арасында районда беренчелекне бирми иде. Стартта да иң соңыннан, бөтенесе китеп беткәч кенә кузгалган була. Юри шулай кылана, азактан китә дә беренче килә. Ярышу, көч сынашу дигәндә, йөрәгендә кызып, башбирмәс усаллыгы кабына егетнең. Сүндерермен, туктатырмын, димә – үзенекен итми калмый.

Радиодан спорт турында тапшыру башланды исә, Рәкыйпнең колаклары үрә тора. Тыныч кына тыңлый да алмый, йөрәге кага башлый. Егетнең күңелендә генә яшереп йөрткән хыялы – физкультура институтына укырга керү. Шунда укысамы – спортчы була инде ул тәгаен. Аннан үзе шөбһәләнеп тә кала: кая инде аңа, гап-гади авыл малаена, спортсмен булу. Профессионал спорт дөньясы – әкияти Каф тавы артындагы могҗизалы ил булып тоела кайвакыт. Бәләкәй генә бер авылда, имән урманы кочагында үскән егеткә анда барып җитәргәме соң… Әмма кан кызуы үзенекен итә: чаңгыда да чаба, гер дә күтәрә егет. Урман куенында баш төрткән яшь үсентеләр язын котырып үскән кебек, ул да биеккә, еракка, югарыга – авыл капкасыннан арьяктагы дөньяга ашкына.

Сигезенчене бетергәч, шактый яшьтәшләре кебек үк, Чаллыдагы СПТУга машина йөртүче белгечлеге буенча укырга китте Рәкыйп. Училищеда якын-тирә авыллардан егетләр байтак. Эшләп үскән, кул кушырып утыруны белмәгән яшьләрнең көч-дәрте беләккә сыймый уйнаклый. Уку йортының зур гына спорт залы бар, алар шунда ашыга. Захаров фамилияле бер абзый ирекле көрәш буенча секция ачып җибәргән икән – Рәкыйпне шул кызыктыра менә. Ничек итсә итә, шунда барып керә ул. Күбесе – Сабан туйларында үзебезчә көрәшеп үскән татар егетләре. Болар инде, көрәш дигәндә, сөлгегә ябыша. Бернишләр хәл юк: Захаров ирекле көрәш белән генә котыла алмый, җай булганда, сөлге белән дә көрәштерә, татар көрәшенең нечкәлекләрен-алымнарын да өйрәткәли. Көрәшнең ни икәнен шушы залда чамалый башлады егет.

Язмыш адәм балалары белән шаярырга ярата. Адашып, гел читкә каергандай, башка юллардан атлап киткәндәй тоеласың, әмма нindидер илаһи бер көч сине җай гына аркаңнан этеп, үз сукмагыңа бора да куя. Бу хикмәт – очраклы тоелган очрашулар, күңелеңдә йөргән сорауга җил ачып ташлаган китап битендәге җавап, ялгыш кына күрше йорт тәрәзеннән ишетелгән җыр яисә башка тамга-билгеләр рәвешендә «иңә».

Игътибарлырак булырга, вакытны ашыктырмыйча, дөньяга киң һәм ачык күңел белән карарга гына кирәктер. Берәү дә үз язмышын-миссиясен үтәмичә җирдән китми. Көрәшче булырың язмышыңа язылган икән – көрәшәчәксең. Юкса, хәрби хезмәт юлының да Рәкыйпне ахыр чиктә спорт мәйданына китерүен ничек аңлатмак кирәк?!

Мең тугыз йөз җитмешенче ел чакырылышы белән Германиянең Зеелфельд шәһәренә барып эләгә егет. Автомобиль йөртүгә укыган ачык йөзле солдатка бирелгәге хәрби хезмәткәрләрнең балаларын мәктәпкә йөртү вазифасын йөклиләр. Балаларны илтә дә, көткән арада, шул тирәдәге спорт залына керергә гадәтләнеп китә. Залда хәлле-хәлле егетләр ирекле көрәш белән шөгыльләнеп маташа, ә Рәкыйп, җанына урын таба алмый, читтән генә күзәтә.

– Якташ, келәмгә кер әйдә!

Сәерсенеп борылган иде, җыйнак кына гәүдәле берәү Рәкыйпкә елмаеп карап тора. Удмуртиядән килгән егет икән. Армиягә кадәр үк ирекле көрәш келәмендә шактый алышкан, спорт мастерына кандидат әлеге солдатка шөгыльләнер өчен иптәш кирәккәндер. Уйнап кына ега диярсең, каһәр. Алтмыш кило гәүдәсе белән сиксән килолы Рәкыйпне әйләндереп кенә сала. Данлыклы Хәмит бабай оныгы була торып, гарьлек тә соң! Баштагы мәлләрдә үртәлеп җәфаланды да аннан салкын акыл белән иптәшенең көрәш алымнарын өйрәнергә тотынды егет. Берничә айдан якташын үзе тәгәрәтеп җибәрә иде инде.

Бу хәл залдагы тренерлар күзеннән дә читтә калмый, Рәкыйпне ярышларга әзерли башлыйлар. Ирекле көрәш буенча дивизиякүләм ярышны да, кайтып китәр вакыты җитәрәк, армиякүләм бәйгене дә ота ул. Хәрби хезмәте төгәлләнгәндә, спорт остасына кандидат дәрәҗәсендәге көрәшче булып җитешә.

Нинди генә җилләр исеп, нинди генә яшен яшьнәмәсен, дөнья никадәр генә үзгәрмәсен, имән – имән булып кала. Дөньяның кайсы почмагында тамыр җәйсә дә, кай туфракта тишелеп чыкса да, имәннәрнең язмышы бер генә – сынмыйча, сыгылмыйча, имән булып калу.

* * *

Чаллы. Чулманының чая дулкыннары кебек үк чал тарихлы татар җире. Ата-баба дөнья тоткан, калканнары кала булган заманнардан алып, күпме Сабан туйларын да, яуларны да, батырларны һәм илбасарларны күргәндер бу төбәк туфрагы. Нигезеннән кала калкынучы шушы җылы туфракка татар каны, татар тире, татар яше тамган. Үзәгендәге татарлыкны бүген дә Күзкәй, Боерган, Калмия, Биклән, Суыксулар, Мусабайлар, Теләнче Тамак кебек татар авыллары саклап тормыймыни?!

Мең тугыз йөз алтмыш тугызынчы елның ундүртенче августында КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы Чаллыда автомобиль заводлары комплексы төзү турында карар кабул итә. Бирегә илнең төрле якларыннан халык агыла башлый, якын-тирә район-авыллардан күченүчеләр дә шактый була. Яңа шәһәргә, яңа тормышка бигрәк тә яшь-җилкенчәк ашкына. Үз җае белән тыныч кына яшәп яткан Иске Чаллы тирәсендә тормыш куерып, тәмам кайный башлый.

Рәкыйп тә армиядән кайтып, туган авылында бераз хәл алгач, Чаллыга ашыкты. Яңа Мусабай белән Чаллы арасы – Ерыклы авылы аша турыдан барганда унбиш чакрым тирәсе булыр. Хатыйп, ат җигеп, Чаллы базарына бәрәңге сатарга йөри иде элек. Рәкыйп тә аңа иярә, шәһәр күреп, базар күреп кайта. Әткәсе, «куян күчтәнәче» итеп, Чаллы базарыннан ала торган ак күмәчнең тәме әле дә тел очында тора. Малайчактан үз, таныш аңа бу тирәләр.

Армиядән икенче класслы автомобиль йөртүче булып кайткан Рәкыйп, башта азык-төлек ташу машинасында эшләде, аннан «Ашыгыч ярдәм» станциясенә урнашты. Биредә шофёрлар барысы да олыгаеп килгән ирләр, яшьләрдән – бер Рәкыйп кенә. Сүз дигәндә, шофёр абзыйлар кимен куймый анысы. Һәрберсе егетне дөньяга өйрәтергә, теләсә кайсы мәсьәләдә тәфсилле киңәш бирергә иренми иде. Рәкыйп – сөйләүдән битәр, тыңларга яратучылардан. Елмаеп кына тыңлап, мыегына чорнап тора. Агайларга шул гына кирәк тә. Егет тиз арада монда үз кеше булып куйды.

Мыек дигәннән, Рәкыйпкә сызылып киткән кара мыек бик килешә икән. Әллә нидән, юри генә үстереп караган иде – үзенә дә ошап китте, гел башка кешегә әйләнде дә калды. Мусабайдагы өлкәнрәк кешеләр: «Хәмит бабаңа бу чаклы да охшасаң охшарсың икән!» дип, тел шартлаткач, ничектер күңелле булып куя. Бабасы да мыек йөрткән, диләр. Төс-биткә күркәм, менә дигән һөнәрле, ачык йөзле егеткә кызлар күзе төшмәслек түгел. Кыз-кыркынның кызыксынулы карашын еш тоя ул, әмма утлы карашларның йөрәгенә кадәр төшеп җитә алганы, «минеке» дип күңел сайлаган ярны очратканы юк әле.

Апрель азаклары иде. Кояшның торган саен үткенрәк караган, яз җиленең җилбәгә чагы. Бар тереклек язгы саф һаваны йотлыгыбрак суларга, кояш яктысына сыенып, аның бәрәкәтле җылысын күбрәк татырга омтылган бер чак иде. Кышкы салкыннарда фельдшер хатын-кызларны «Ашыгыч ярдәм» станциясе бинасында көтеп утырырга ияләшкән шофёрлар бүген ишек төбендә. Кайсы тәмәке кабызган, тартмаганнары бер читтә күңелле генә сөйләшеп торалар. Станциягә таба килүче бер яшь кызны алар әллә кайдан шәйләде. Сүз куешкандай, карашлар кызга төбәлде. Кызыксынудан битәр, сокланып карадылар, ир-ат күзен иркәләрлеге бар, кыз чибәр иде. Зәңгәр күлмәге, сәдәфләре эләктерелмәгән көрәнсу плащы, аксыл туфлиләре җыйнак кына зифа гәүдәсенә бик килешле булып, кызның кыяфәтенә тыйнак матурлык өсти. Җилкәсенә яткан кабарынкы чәчләре язгы әрсез җилдә талпынып куя, аксыл битләренә бераз кызыллык йөгергән.

Ирләр сүздән бүленделәр. Ашыккан кебек тоелмаса да, үзенә төбәлгән карашлардан кыз адымнарын тизләтте. Ир затының мут карашына исе китә торганнардан түгел, үз бәясен яхшы белгәнгә охшый бу чибәркәй. Нәкъ Рәкыйпкә туп-туры карап «Исәнмесез!» диде дә, баскычлардан сикереп кенә менеп, станция ишеге артында югалды. Күзләре! Үзләре елмая, үзләре үтәли тишәрдәй карый. Ут ялкыны да, боз салкыны да бердәй сыйган бу караштан егет әллә нишләп куырылып калды.

– Менә бу кыз сиңа бара! – диде шулчак шофёр абзыйларның берсе, көлемсерәп.

– Да ну! Кит әле... – дип, исе китмәгән кыяфәттә кул гына селтәде егет.

Кызның исеме Римма икән. Фельдшерлыкка укып бетергәч, монда эшкә

җибәрелгән. Бәгырьне өтеп, күз сиртми дә, читтә йөреп тора, куймыйлар гына бит үзен Рәкыйп шофёр булган бригадага. Түзмәде егет, өлкән фельдшер булып эшләүче Саниягә сүз тиште беркөнне. Кемнең кайсы бригадада эшлисен шул апа хәл итә иде. Гәрчә егетне үз сеңлесенә димләп йөрсә дә, Сания каршы килмәде. Акыллы хатын иде ул: таш яуса да, үз дигәнен итәчәген егетнең сыңар карашыннан төшенде. Иртәгәсе көнгә үк Римманы Рәкыйп белән бер бригадага язды. Гомерлек мәхәббәт тарихы шулай башланып китте.

Иске Зәйдән Мисбахетдин агай белән Фәүзия апаның сылу кызы Римма һәм Яңа Мусабай егете Рәкыйп мең тугыз йөз җитмеш бишнең февралендә гөрләтеп туй иттеләр. Бераздан яшь парның үз куышы барлыкка килде. Менә бәхет: халык телендә «малосемейка» дип атала торган бүлмә боларга фатирның кунак бүлмәсе булырга тиешле иркенрәк бүлемтегеннән. Бер елдан ул куыш бала biләүләренә, бәби исенә күмелде – кызлары Эльмира туды. Чаллы җире кавыштырган меңәрләгән парларның фатир балконнарыннан киләчәккә сәлам булып, ак биләүләр җилфердәде. Ул биләүләр кичләрен арып эштән кайтучы ирләрне – яшь әтиләрне алны-ялны белми хезмәт куярга, юлсыз җирләрдән юллар ярырга, заводлар төзергә, көрәшергә, яңа көнгә елмаеп атларга өнди иде.

* * *

Көндезләрен эштә көн үткәрсә, кичен Рәкыйп спорт залына ашыга. Армиядән кайту белән көрәш секциясе эзләгән иде дә, ни иректә көрәш, ни татарча көрәш буенча шәһәрдә рәтле берни юк. Солдат хезмәтендә яхшы спорт заллары күреп кайткан егет шөгыльләнер өчен юньле урын табалмый тинтерәде.

Армиягә киткәнче спорт залларында танышкан егетләрне – Вася белән Наисне очратты ул беркөн. Вася Николаев – Чаллы батыры, оста көрәшче. Икесе дә – таза, көр егетләр, икесе дә – спорт мастеры. «Төзүчеләр» стадионында штанга күтәрәләр икән болар. Көчен кая куярга белми йөргән Рәкыйпне шунда чакырдылар. Вася йөз ун килолы штанга янына алып килде дә:

– Яле, күтәреп кара. Шушыны кыссаң, рәт чыга синнән, – дигән була.

Рәкыйпнең штанга тотып караганы юк, күтәрү техникасын белми дә белми инде. Шулай да сер бирмәде, «колхозча» гына күтәреп куйды. Васяның авыз – колакта, колак – еракта.

– Булды! Шөгыльләнәсең, – дип, Рәкыйпнең кулын кысты.

Шөгыльләнмиме соң! Азау ярган баһадирлардан калышмаска тырышып, җан-фәрман таш күтәрә башлый ул. Ярсуы кайнап тора. Вася Николаев, йөз туксан килоны «умыра» торган Фаил Мөхәммәтҗанов, Наис Сәйфетдинов – үрнәк алып, артларыннан үрелердәй пәһлеваннар җитәрлек Чаллыда. Менә шулар белән бергә Рәкыйп тә кулларында таш уйнатырга тотынды. Егетләрчә үзара шаярып та алгалыйлар.

– Фәлән килоны «кысам», – ди берәрсе.

Икенчесе килешә яки килешми, кул бирешәләр. Ниятләгән кадәре авырлыкны күтәрә алса, ашханәдә төшке ашын бушка ашап чыга. Булмый икән инде, бигайбә – үзенә сыйларга туры килә, бер сум егерме тиенен чыгарып сала.

Берничә елдан егетләргә шәһәрнең Гренада паркы яныннан яхшы гына спортзал бирделәр. Аның бер ягына калын-калын маталар өеп куелган. Келәм күрдеме, көрәшченең күңеле кытыкланып аладыр.

– Рәкыйп, әйдә көрәшәбез, – ди Вася. Ул – мәйдан тоткан батыр, татар көрәшенең рәтен белә, ала да сала, ала да сала. Ястык сыман маталарга ничек барып төшкәнен Рәкыйп сизми дә кала. Егылуын егыла да, көндәшенең алымнарын, көрәш җаен да өйрәнергә керешә әкренләп. Бераздан ектырмый да башлый.

Көрәш – бил алышы гына түгел ул, көрәш – татар иренең рухи җегәре. Ул рухны кылыч та алмый, чор саен үзгәреп торган әләм-байраклар да бастырып куялмый, вакыт та юалмый. Көрәш – канда, ә кан буйсынуны белми, вакыт ызаннары буйлап киләчәккә үзенчә ага ул. Татар көрәше авыллардан, салалардан, төбәкләрдән ургылып чыга да калаларга томырыла, илдә үзенә мәйдан даулый. Җитмешенче еллар ахыры. Татар ирләренең кан тамырында көрәш дәрте кымырҗып, мәйдан барлаган вакытлар.

Нык билле авыл егетләре белән бергә Чаллыга татарча көрәш килә. СПТУда Кузнецов татарча көрәш түгәрәге оештырып җибәргән. Көрәшче егетләр шәһәрнең егерме бишенче мәктәбе спорт залын арендалап, анда да бил алышалар, ди. Чаллыда Марат Бибишев төзеткән яңа спорт комплексы ачыла. Анда мең тугыз йөз җитмеш сигезенче елны, тренер булып, автомобиль заводы төзелешендә прораб вазифасында эшләүче Фрил Әхмәтов урнаша. Фрил – көрәш тәмен татыган, белә торган кеше. Казанда укыган чакта ук татарча көрәш буенча Рәсәй чемпионы калган, берничә көрәш төре буенча студентлар арасында республика чемпионы булган, Чаллы Сабан туйларында мәйдан тоткан бу егеттә тәвәккәллек тә, үҗәтлек тә җитәрлек. Үзе дә орчык урынына бөтерелә, башкаларны да әйләндерә. Шундый кешеләр була – алар янәшәсендә күбрәк йөрсәң, тормыш тымызык күл сыман басынкылана, тына башлый. Икенчеләрендә көч-куәт ташып тора, тегермән ташы сыман гел әйләнештә болар. Үзләре дә янып яши, сине дә кабыза, сине дә яндыра. Фрил Әхмәтов – әнә шундыйлар затыннан. Аның тирәсенә Сабан туйлары күргән, мәйдан тоткан таза-таза авыл егетләре җыела башлый, Рәкыйп тә шулар арасында. Китә көрәш, китә алыш, келәм бүлешү!.. Иллеләп хәлле көрәшче җыела. Көн саен шөгыльләнәләр, көн саен бергә. Болар янына туксанынчы еллар башында яманаты чыккан «егерме тугызынчы мәхәлләнекеләр» дә якын килә алмый, сәлам биреп, хөрмәтләп урап узалар.

Рәкыйп шушы мохиттә көрәш белән чын-чынлап җитди шөгыльләнә башлады. Эшкә киткәнче, иртүк торып йөгереп кайта, эштән соң спорт залына чаба. Гер күтәрергә дә вакыт таба. Өйдә дә һәрвакыт хәрәкәттә, көрәш алымнарын ныгыта. Бу вакытта яшь гаилә бер бүлмәле фатирга күчкән иде инде. Сиксән беренче елда төпчек кызлары Диләрә дөньяга килде. Курчак төсле ике кызы «Әти, барма! Өйдә генә кал» дип, тезләренә килеп сарылганда, кичләрен спортзалга чыгып китүләр газап өстенә газап. Андый чакларда Римма кызларны иплән кенә эткәләреннән аера да, иркәләп, матур әкиятләр сөйләп, юата-юата йоклата. Әкиятләре гел батырлар турында була. Ул әкиятләрдә Алып батыр, Камыр батыр, Таңбатыр, Дутан батырлар явыз албастыларны, алдакчы патшаларны җиңәләр, халыкны яклап, һәрчак гадел

һәм бәхетле гомер итәләр. Әниләре кайсы гына батыр турында сөйләсә дә, кызчыклар ул батырны һәрчак үз әтиләре төсле күз алдына китереп, шул хыяллардан тәмле йокыга китәләр иде. Сабыйларын, сабыр гына, әтиләренә ышанырга, аның белән горурланырга өйрәтеп үстерде Римма. Үзе дә иренә чиксез ышанды, таянды һәм таянычы була белде.

Вакыт дигәннең гадел бер сыйфаты бар: авыр мәлләрне дә, шатлыклы хәлләрне дә үзе белән алып китә тора. Менә генә әйләнәндә әйләнгән мизгел күз ачып йомуга үткәнгә әверелә, мәңге үтмәс тоелган мәлләр дә барыбер үтә. Зәмһәрир кышлар уза да, Сабантуйлар ел саен килеп җитә. Ел әйләнәсе спорт залында тир агызган көрәшчеләрнең урак вакыты бу, түләнә туплаган көчен бәйгедә сыный һәм сынала торган чоры. Рәкыйпнең дә күңеле җилкенә. Бер булса да тәкә алып карарга иде бит инде быел!.. Яшь-җилкенчәк чагы түгел. Һәр гамәлен бизмәнгә салып кыла, алдагысын уйлап яши торган вакыты – гомеренең өченче дистәсен түгәрәкләп килә ләбаса.

Аңа дигән тәүге тәкә Сарман районының Петровка авылы Сабан туенда көтеп торган икән. Рәкыйп тәвәккәлләп, мәйданга атлады. Түбән Кама каласыннан хәлле бер батыр килгән – җиңел генә алып салырмын, димә. Сизелеп тора: егет грек-рим көрәше белән шөгыльләнгән. Алымнары шуннан, күтәрмичә генә бросок ясарга маташа. Озак тарткалаштылар. Ахыр чиктә Рәкыйп барыбер, татарча көрәш менә болай була ул, дигәндәй, күтәреп, күкрәк аша аркасына салды. Башта өстән генә караган көндәшенең күзе маңгаена менгән:

– Кем син?! Каян син?

– Рәкыйп. Хәмитов. Чаллыдан.

Җилкәсенә тәкә салып, мәйдан әйләнгәндә, Рәкыйп кояшка карады. Сабантуй кояшы бала чактагыдай яп-якты, яңа пешкән ипекәй сыман кап-кайнар иде. Рәкыйп, ирексездән, әткәсе белән урманга барган тәүге көнне, имәнле урманнар өстендә куе ябалдашлар арасыннан малайга күз кыскан тансык кояшны хәтерләде. Беренче кат имән аударуын исенә төшерде һәм бәгырь түрендә язгы ташу купканда була торган ярсу бер хөрлек, киңлек тойгысы йомарлануын тойды. Татар мәйданында Рәкыйп Хәмитов атлы батыр пәйда булды.

Мең тугыз йөз сиксәненче еллар башы. Чаллы Сабан туе ГЭС бистәсендә уза. Мәйдан елдан-ел киңәя, шәһәр белән бергә Сабантуй да яңа киңлекләргә омтыла, үсә, киңәя иде. Мәйданга каланың Автозавод һәм Комсомол районнары спортчылары җыелган, көрәш бара. Менә келәмдә чуендай кара тәнле, кара чәчле, сызылып киткән кап-кара мыеклы көрәшче күренде. Җилкә киң, адымнар хөр, тәне – ишкән бау сыман. Ак тешләрен күрсәтеп елмаерга гына тора үзе, ә карашы – бүренеке. Шулчак мәйдан читенә тезелгән ир-егетләр арасыннан кемдер аваз салды:

– «Копчёный», көрәш әйдә!

Бергә штанга күтәрә торган егетләр үзара шулай атыйлар иде Рәкыйпне. Кояш карадымы, Сабан туйлары җиткәнче үк кара-чутырга әйләнә дә куя. Җитмәсә, гәүдәсенең бер артык төше дә юк, сеңердән генә тора диярсең. Холкы-фигыленә дә килешеп тора бу атама, үҗәтлеге җитәрлек. Кушамат кушарга дигәндә, безнекеләргә куш инде. Штангистлар арасында йөргән шушы кушаматны мәйданга ыргытулары булды, халык күтәреп тә алды.

Бәлки, колак аша гына үткәрер иде дә онытыр иде – көрәшчесе өч көнлек булырга охшамаган. Бакчы, ничек җыеп ала да әйләндереп сала, матур көрәшә. Халык үз иткән батырын атсыз-кушаматсыз тотмый, килешә торган хәл түгел.

Мәйданда һава тыгызланганнан-тыгызлана бара, заман кыза. Татарның мәйданнарга җыелган чагы, мәйданнарның киңәйгән чоры. Батырлары көрәшкә чыкканда, йөрәк кыскандай, ярсуына йомарланып, мәйдан кысылып куя.

– Билеңне бирмә, «Копчёный»!.. «Караәхмәт»!.. Бирмә билеңне!

* * *

Умыртка баганасы сыек булса, адәм баласын бөкләве җиңел. Буй-сынын сындырып буйсындыралар кешене, сының сынса, рухың да төзек калалмый. Сынсыз-сансыз булып – исәпкә бар, санга юк яшәүләр нәселеңә язмасын! Кешелекле, кечелекле була белмәгәннән дә «сансыз» дип йөз чөерә халык. Санлы булыр өчен нык сынлы, көчле һәм якты-игелекле рухлы булу да кирәк шул. Җир йөзендә, ил хәтерендә санлы һәм сынлы итеп саклаучы төп көчең – умыртка баганаңда. Умырткаң ныкмы? Әллә җил кай якка иссә, шунда авыша торган сыексыңмы?.. Ныклап уйласаң, адәм баласының фани гомере – баш имәс, бил бөкмәс, бил бирмәс өчен көрәш ул. Биләүдән кәфенгәчә көрәш бара – җир куенына туры килеш барып ятар өчен көрәш. Җирдә калучылар сине туры-тугры итеп хәтерләсен өчен көрәш. Дәвамың – онык-торыннарың төзеклеге-төзлеге өчен көрәш. Һәркемнең умырткасын һәр чор үзенчә бөгәргә тырыша: сабыйчактан ят уенчык тоттырып та, мәктәп партасы артында да, иңнәренә авыр йөк өеп тә…

Адәмнәрнең табаннары җиргә терәлгән дә, баш түбәләре күккә төбәлгән. Этләр җирдән чаба, елан туфрак буйлап үрмәли, бөҗәкләр җир-туфракта кымырҗый. Ә адәм балалары җиргә терәлеп, күккә үрелә – адәм баласының умырткасы төз. Аллаһы Тәгалә шундый да көчле, төзек итеп яраткан бәдәненең алтын уртасы, умырткасының иң көчле, иң чыдам, иң сизгер өлеше – билендә. Кешенең буй-сынын җир белән күк арасында бер ноктага, бер үзәккә тоташтырып торган кендек урыны – биле. Тиккәме, үз-үзен көчле тоярга омтылганда, кеше заты биленә таянучан. Билбау, каеш, путалар ир-егетләр өчен иң затлы бүләк, дәрәҗәсен-санын күрсәтә торган билге санала. Ә хатын-кызлар бәдәнендә бил – бала ярала, яңа җан иңә, җирдә яшәү яңара торган изге урын.

Бил алышу, татар көрәше – Җир-Ана, Күк-Тәңре рәхмәтендә тәнең белән рухың, җаныңның бербөтенлеген тоеп яшәү хикмәтедер. Борынгы бабаларыбыз шулай гомер иткән. Көрәш – ир-егетнең бил ныклыгын сынау бәйгесе генә түгел, татарны төз-нык умырткалы итә торган борынгы гадәт-йола ул. Сабантуйларда көрәш мәйданына халык иң элек малайларны ыргыта: алышсыннар, тарткалашсыннар әйдә, сыек билле булып үсмәсеннәр. Менә бераздан үзара орышып, шактый ярсыган, әмма җиңелүдән җебеп, яшь чыгарырга базмый, ireннәрен тешләгән малай-шалай мәйдан тирәсенә чүмәшә. Ир-егетләр көрәше башлана. Бил тирәсендә тастымал сыдырган урыннарның сызлавы онытыла, малайлар шым гына көрәш карый. Малайлар бүгенге батырлар көрәшендә үз киләчәкләрен

күзәтә. Малайлар халыкның көрәшкә һәм көрәшчегә булган хөрмәтен күзәтә. Мәйдан, йөрәк кыскандай, кысылып куя.

– Билеңне бирмә, «Копчёный»! Билеңне бирмә, Рәкыйп!..

Имәннәр иелә белми. Җир иссә дә, давыл дуласа да, төз кала. Җирдәге иң нык умырткалы агачлар шул алар. Таллар елгаларга иелеп, су эчкәндә, имәннәр тамырлары белән грунт суларына кадәр җитә, әмма иелми. Каеннар җилләрдә шаулап сыгылганда, шартлап сынганда, имәннәр ябалдашларын киң җәеп, нык тора. Ләкин имәннәрне дә аямый торган хәтәр хәлләр бар бу җирдә. Кырык беренче елгы суыкларда имәннәр корыды. Кырык бердә башланган сугышта имәндәй ирләр кырылды. Илдә кырлач кабатланып тора... Мең тугыз йөз җитмеш сигезнең кышы үтә салкын килде. Бу салкынга имәннәр дә биреште. Яңа Мусабай имәннәре кабат авырды, хәлсезләнеп корыдылар. Үзәк Рәсәйдәге йөзьяшәр имәннәрне кисеп карасаң, ике черек-кара бөҗра күрерсең – кырык бер, җитмеш сигез кырлачлары. Имәннәр дә авырый. Имәннәрнең умыртка баганасы да мәңгелек түгел. Әмма Яңа Мусабай авылы тирәли тезелгән колач җитмәс кара төпләрне каймалап, яшь имәннәр үсеп килә. Имән – тамырлары белән көчле ул.

* * *

Көрәшче – батыр булып өлгерсен өчен аңа көрәштәшләр кирәк. Рәкыйп моңа армиядән кайтып, көрәш келәме эзләп йөргән чакларында ук төшенгән иде. Үзенә тиң көндәшен тиз тапты ул. Марат исемле нык беләкле, җитез Актаныш егетен армиягә киткәнче үк күреп белә иде. Ирекле көрәш белән шөгыльләнә, көче дә, тыны да җитәрлек. Дуслашып киттеләр. Ирекле көрәштә тартышалар, акрынлап, Маратны татарча бил алышуга алып кереп китте Рәкыйп, тимер күтәрергә дә өйрәтте. Көндәшең көчлерәк булган саен, үзең дә гайрәтләнә барасың, синең гаярьлегең исә көндәшеңне дә көчлерәк итә. Көрәшне генә түгел, кешелекне алга әйдәкли торган хәйләкәр канун бу.

Марат Галиев та берзаман Рәкыйптән калышмый башлады, ныклы, көр көрәшче булып өлгерде. Менә бер җәйдә бу ике дус Сабантуй мәйданында баш батыр калыр өчен маңгайга-маңгай килделәр. Чаллының Комсомол районы Сабан туенда булды бу хәл. Батырларның берсен алып, икенчесен сала торган түгел, көчләре бер чама. Мәйдан кызган, агай-эне дүрт күз белән көрәш күзәтә. Ә орыш матур-кызу бара, берсе дә билен бирердәй түгел.

«Имән аударыр өчен көч кенә җитми, улым...» – Рәкыйпнең күңелендә балачакта әткәсе әйткән сүзләр кайтаваз бирде. Әйе, көрәш – көчленеке генә түгел, хәйлә дә, елгырлык та кирәк көрәш келәмендә. Батырлар һәр икесе дә шактый арган иде, тән кисәккә-кисәк таралган, инде хәл калмаган сыман. Мәгәр чын көрәшче белә: мондый чакта тынычлап, бер тын алу җитә. Бер мәлгә тынычланып, тәнне-көчне бер ноктага тупларга, җыелырга – таралып-вакланып барган көчеңне, рухыңны бер йодрык итеп кабат төйнәргә кирәк. Бары бер мизгел! Отам дип көрәшкән батыр өчен хәлиткеч кадерле мизгел ул.

Рәкыйп аяк киеме бавын төзәткәнгә салышып чүкте дә күзләрен йомды. Тирән итеп сулыш алды. Тәне-сынының бербөтенгә, бер йомарлам көчкә әйләнүен умыртка баганасыннан йөгереп узган кайнар дулкын аша тойды. Акрын гына торып басты. Сөлгесен кысыбрак тотты. Судьяның сызгырып

җибәрүе булды, көндәшен кысып алды да тотып та атты. Марат әле генә тыны кысыла башлаган «Копчёный»дан мондый елгырлыкны һич көтмәгән иде. Үзенең җиңәсенә инде ышанып ук беткән иде. Ул, әлбәттә, барысын да аңлады, әмма көндәшен котлап, кул кысудан башка чарасы калмады.

– Алдадың! – диде, усал елмаеп.

Ә Рәкыйп, гадәтенчә, сүзсез генә мыек астыннан көлеп тора. Имән аударыр өчен көч кенә җитми ул, энем…

Имәннәр янәшә үскәндә генә, төз-күркәм була. Тормышта да шулай: кем янында, нинди даирәдә кайнайсың бит. Спорт комплексында шөгыльләнә башлаган көннәреннән бирле, Фрил Әхмәтов аркадаш, терәктәш булды Рәкыйпкә. Фрилдә берни белән дә сындырып булмый торган үҗәтлек, тырышлык һәм үз-үзенә какшамас ышаныч бар иде. Бу аның бөтен килеш-килбәтенә, тавышына, хәтта күз карашына ук ягылган. Фрил – Рәкыйпнең тренеры булса да, бу ике яшьти, ничектер җеннәре килешеп, якын дусларга әйләнделәр. Бер елны Чаллының ГЭС бистәсе Сабан туе шушы ике дусны келәмдә кара-каршы бастырып куйды. Үз үлчәүләрендә икесе дә җиңүче калып, баш батыр исеменә көрәшү иде. Фрил Әхмәтов җитмеш кило булса, Рәкыйп йөз кило авырлыгында. Менә Рәкыйп көндәшен эләктерде, күтәреп тотты да эндәште:

– Атам, Фрил, – гаеп итештән булмасын, янәсе.

– Атып кара…

Көндәшенең бу сүзеннән сискәнеп куйды Рәкыйп. Чыннан да, күтәреп алуын алдың да – ектың дигән сүз түгел бит әле. Егыламы әле ул, юкмы. Аякларың җирдән аерылганда да, үз-үзеңә ышанычны югалтмаска кирәк бит! Ахыргача көрәшү, көрәшкә һәм үз-үзеңә тугрылык менә шулай буладыр. Танылган Раббани батырны җитмеш кило орчыктай гәүдәсе белән откан Фрил ул, шаярма.

Һәр орыш – тәҗрибә, һәр алыш – сабак. Рәкыйп шуңа төшенде: көрәш келәме – батырлар барлау урыны гына түгел. Халык бил алышын карыйм дип кенә килми мәйданга, үз батырының нindирәк кеше булуын, холкы-фигылен дә күреп белергә килә. Чиста, матур көрәшеңне күрсәт син аңа. Оттырасың икән, матур итеп оттыра бел: бәхәсләшеп, дау чыгарып, көлкегә калма. Бер минут бил көрәштереп, ун минут сүз көрәштереп маташасың икән, халыкта бәяң – бер тиен. Андыйларга кул гына селти ул. Батырларын күрергә килгән чал агайлар, юеш борынлы малайлар куанып, сокланып кайтып китәрлек итеп көрәш. Халыкның үз батырын көчле һәм хөр, нык рухлы итеп күрәсе килә. Көрәшең – мал өчен түгел, дан өчен булсын. Ә инде халыкта батыр дигән даның бар икән, ахыргача батыр булып кал, халкыңның рухы-ышанычы белән уйнама берүк.

* * *

Туксанынчы елларга тикле көрәшчеләр арасында Татар иленең иң абруйлы мәйданы булып, Казандагы Каенлык Сабан туе келәме санала иде. Татар батырлары шунда җыела, баш батыр шунда ачыклана, көрәшләрнең иң кызуы Каенлыкта. Чулман аръягы батырларын биредә инде шактый шөбһәләнеп көтәләр, чөнки Чаллы каласы белән бергә, анда көрәшкә игътибар үсеп килгән чак. Игътибар булганда, нәтиҗәсе дә озак

көттерми аның. Хәер, бу тирәләр элек-электән үк батырлар төбәге булган. Минзәлә кирмәне – татар батырларыннан сакланыр өчен төзелгән корылма түгелмени… Көрәш каннан килә. Ә бу җирләрдә кан тарихның үзе кебек үк куе да, хәтер сыман тозлы да.

Рәкыйп Хәмитов дигән батырын Татар иле мең тугыз йөз сиксән бишенче елны Каенлык Сабан туе мәйданында таныды. Жирәбәгә таза-таза егерме алты көрәшче җыелган, мәйдан тирәли чебен кунар урын да юк. Сабантуй тәкәсе Чаллы батыры Копчёныйның җилкәсенә менгәнче, көрәшне шактый озак тамаша кылырга туры килде халыкка. Казан халкы ул көнне сиксәннән артык орыш күзәтеп, батырларын барлады. Келәмгә атлаганчы ук, араларында Рәкыйп аерылып тора – чуендай кара, тәскә-биткә чибәр, баһадир гәүдәле. Сөйкемле сөягең, җылылыгың булмаса, салкын матурлык өшетә генә ул анысы. Бу – бүтән. Моның күзләре елмая. Нык атлап чыгып баса, һавалану-нитү юк, көндәшенә билен ничек кирәк – шулай тоттыра. «Мә, энекәш, тотып кара. Барыбер алалмыйсың син аны», – дигәндәй сызылып киткән кара мыегы астыннан елмаеп кына тора.

Көрәш мәйданы – татар сәхнәсе ул. Көрәшче – баш рольдә. Һәр тамашачы – үзе тәнкыйтьче, үзе судья монда. Республиканың төп келәмендә – Каенлык Сабан туенда Рәкыйп Хәмитов әле сиксән җидедә дә, сиксән тугызда да баш батыр сөлгесен иңенә салды. Илдә хөрмәт һәм ат казанды. Ә илнең күч булып җыелган чагы – батырларын барлаган мәлләре бу.

...Мең тугыз йөз туксанынчы елның егерме сигезенче июне. Чаллы шәһәренең капиталь төзелеш идарәсе башлыгы Фрил Әхмәтов әле анда, әле монда сугылды, булырдайларына шалтыратып та карады – юк кына бит. Юк! Машина таба алмады. Болай булмый бит инде, бармый калырга ярамый. Рәкыйп бүген Казанда – Казанның үзәгендә булырга тиеш. Ничек тә җаен табарга кирәк. Үзенең өр-яңа машинасы гаражда тора торуын да, руль артына юньле-рәтле утырып караган кеше түгел бит Фрил. Чаллы – Казан арасы сыман олы юлга чыгуны әйткән дә юк. Шулай да, башка әмәл тапмагач, тәвәккәлләргә булды. Бармый калырга ярамый. Аллага тапшырып, рульгә утырды, юлга кузгалдылар.

Мосафирлар Казанның В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Үзәк стадионына килеп җиткәндә, көрәшчеләрнең авырлыгын үлчәү вакыты тәмамланган иде. Биш минутка соңарганнар! Фрил ялт кына Фаил Әхмәдиев җитәкчелегендәге судьялар өстәленә таба чапты. Хәлне аңладылар, Рәкыйпне үлчәүгә бастырып, Бөтенсоюз фестивалендә бил алышачак көрәшчеләр исемлегенә өстәп куйдылар.

Татар илендә, Казан үзәгендә беренче тапкыр үткәрелә торган Кичке Сабантуй башланып китте. Трибуналар шыгрым тулы, егерме биш меңнән артык кеше килгән, ди. Казан үзәгендә мондый зур татар мәйданы җыелганы булдымы икән әле моңарчы. Менә умарта күчедәй мыжлап торган халык тын калды. Стадион өстендә Татар иле Президенты Минтимер Шәймиев тавышы яңгырый: «…Татарстан Республикасы бүген үзенең дәүләт суверенитетын реаль эчтәлек белән тулыландыру чорын, суверен дәүләтләр Союзын тулы хокуклы төзүчеләрнең берсе булырга омтылышында позицияләрен ныгыту чорын кичерә. Мондый шартларда республиканың күпмилләтле бөтен халкыннан тагын да зуррак сабырлык һәм ышаныч,

шушы максатларга ирешү хакына иҗат энергиясен тагын да арттыру таләп ителә...» Халык гөрләтеп, кул чаба. Мәйдан уртасында дөньяны сәламләп, татар сөлгесе җилферди. Офыкка юнәлгән кояшның соңгы нурлары ак сөлгенең чигү-бизәкләрендә уйнаклый. Бераздан Казан өстендә ай калка. Мәйданга җыр-моң, шигъри сүз тарала.

Стадион бу кичтә олимпия уеннарын хәтерләтә иде. Берьюлы берничә урында ярышлар бара: көянтә-чиләк белән су ташу, капчык киеп узышу, гер күтәрү, йөгерү, капчык сугышы… Казан ипподромының иң җитез атлары елкылдап уза. Мәйдан түренә бер-бер артлы атаклы чичән-шагыйрьләр, җырчылар, сүз осталары чыга. Илһам Шакировны алкышлап, кат-кат җырлаталар, Гәрәй Рәхимнең шигъри сүзе оран булып оча, Хәлим Җәләйнең тыйнак-көр тавышы мәйданны колачлый. Менә бәрхет баритон тавыш яңгырый – сәхнә түрендә «Сәфәр» төркеме белән Ренат Ибраһимов. Мәскәү кунагының күчтәнәче мулдан – җыр-моң һәм Сабантуй батырына «Ока» автомобиле. Бәйрәм саф татар телендә, татарча бара. Татар сүзе, мәйданга сыймыйча, төнге Казан урамнарына агыла.

Ниһаять, көрәш башланды. Мәйданга җитмешләп көрәшче җыелган. Жирәбә белән ике төркемгә бүленеп, шактый орышканнан соң, батырларның тугызы келәмдә калды. Көрәш кыза, көрәшче сөлгесе сыман мәйдан кысылганнан-кысыла. Таң сызылыр алдыннан гына, баш батыр исемен даулап, келәмгә икәү чыктылар: Рәкыйп Хәмитов һәм Рөстәм Гыйниятов. Утыз сигез яшенә җиткән, кара чәчләренә чал куна башлаган Рәкыйптән Рөстәм ундүрт яшькә яшьрәк, өстәвенә, авыррак та. Ай-һай, дип баш чайкады мәйдандагы төнге көрәшкә текәлгән агай-эне.

Көрәш – бик нәзакәтле-нечкә орыш. Көч, акыл, хәйлә, тәҗрибә, елгырлык белән генә түгел, тагын бер бик кыйммәтле сыйфатны үз итә ул. Табигать әнә шул хиссиятне умырткаңа утыртмаган, күңелеңә салмаган икән, күпме тоз ашасаң да, үзләштерәчәк түгелсең. Көрәш сизгерлекне ярата. Сөлгеңне көндәшеңнең биленә салгач та, аның хәрәкәтләреннән алга таба нишләргә, нинди алым кулланырга җыенуын сизәргә тиешсең. Көндәшеңнең йөрәк кагышыннан, тән тибрәнешеннән ниятен чамалап, көрәшне үз кануныңа буйсындыру – батырлар осталыгы. Һәммә тереклекнең үзара бәйләнештә һәм гармониядә яшәвен тоеп, урман кочагында, имәннәр ымын ишетеп үскәнгәме, Рәкыйпне Ходай андый нечкә сизү белән бүләкләгән иде. Агачларның бер генә яфрагы да юкка гына тибрәнми – ни тынгысызлый аларны? Ыңгырашып, иңрәп, имән кай якка гөрселдәп авачак? Яшенле яңгырлар кайчан явачак? Сизә-тоя белсәң, табигать серләренә ачкычлар – үз күңелеңдә.

Рәкыйп тән көченә күңел сизгерлеген дә кушып көрәшә. Кичке Сабан туенда – республиканың төп җыенында баш батыр исеме өчен бил алышканда, үзеннән күпкә яшь, җегәрле, авыррак Рөстәм Гыйниятовны егу шуңа күрә дә кыен булмады, тиз арада бер-бер артлы өч балл алды. Соңыннан газета-журналлар бу орыш хакында бәян иткәндә, «Рәкыйп Рөстәмне орчык урынына бөтереп йөртте», дип язачак.

Кичке Сабан туе Казанда туксан беренче елны да үткәрелеп, анда да Рәкыйп Хәмитовка каршы торырдай батыр табылмый. «Копчёный» Мөслим Сабан туенда аягын имгәткән» хәбәре таралган, республиканың

төп келәмендә быел алыш Хәмитовсыз гына узачак, дигән фаразлар да бар иде. Чынлап та аягын авырттырды ул. Бер атнадан Казанда төп Сабантуй, көрәшкә кермимме, дигән шик белән табибка барды. Травматолог көлде генә:

– Проблема юк! Барырсың да, отырсың да…

Авыртуны баса торган укол кадады да, елмаеп озатты. Рәкыйп тынычланып чыгып китте. Барды, күрде, отты. Икенче көнгә аяк сызлавы үзен сиздерә башлагач, кабат табиб янына китте.

– Син әйткәнчә булды, җиңеп кайттым. Авыртуы гына бетми менә.

– Чынлап сөйләвеңме, әллә шаяртасыңмы?

– Җиңәсең, диден бит – җиңдем.

– Күпме гомер эшләп, җүләрләрне байтак күрдем, әмма мондый ук дивананы күргәнем булмады. Тезеңдә кимерчәкләр өзелгән иде бит…

* * *

Үргә менү авыр, үрдә калу – тагын да авыррак. Сабантуй үтеп китә дә, иртәгәсен яңа көн туа. Тормыш дәвам итә, чәчләргә чал ята тора. Ә мәйданга чыктыңмы, кешеләрнең карашы синдә генә. «Копчёный» килгән! Көрәш матур булачак». Кырыкка җиткәндә, татар илендә бил бирмәс батыр танылып, шул даныңны саклау өчен тырышлык, үҗәтлек икеләтә артык кирәк – холык кирәк. Юкка-барга вакланмыйча, нәфесеңә баш бирмичә, максатыңа тугры кала аласыңмы? Кул-аягың имгәнеп, сеңерләрең өзелеп, хастаханәләрдә ятып чыкканнан соң да тешеңне кысып, спорт залы ишеген кабат ачып керә аласыңмы?

Тренировкалар вакытында Рәкыйп җитезлеккә омтыла, көрәш алымнарын тиз, кискен ясауга әзерләнә. Көрәшенең хикмәте дә шунда: көндәше аны-моны абайларга өлгергәнче, кӧтелмәгәнчә «һөҗүм итү». Бил алышырга чыктымы – йөзгә төрләнә. Уң яктан «зашаг» ясап, каерып сала, сул яктан килеп керә, яки уртадан суырып ала. Көндәшен тәмам бутап бетерә. Киләсе секундта «Караәхмәт»нең нинди алым кулланасын чамалармын, димә. Аның көрәше – сәнгать, мәйдан тирәли тулып, халык шул «сәнгать әсәре»н күрергә ашкына.

Туксан дүртенче ел. Татар мәйданында көчле ике пәһлеван бар – Рәкыйп Хәмитов һәм Рәшит Сәмигуллин. Көрәш келәмендә Рәкыйп күрсәткән осталык, дәрәҗә яңа көрәшчеләр үстерде – имән янында имән буласы, биегрәк, көчлерәк буласы килә. Аларның бу җәйдә беренче көрәше илле минут барды. Утыз градус эсседә ике батырның үзара тартышуын ут йотып күзәткән Акъяр авылы халкы гына түгел, тәҗрибәле судьялар да хафада: йөрәкләренең җегәре җитәрме, өзлекмәсләрме? Менә чираттагы алыш вакытында Рәшит Рәкыйпнең өстенә җайсыз барып төште дә теше белән көндәшенең уң як җилкәсенә төртелде. Ярадан кан саркып чыкты. Бер сәгатькә якын көрәшеп тә, бер-берсен ала алмадылар, көчләр тигез иде. Активрак көрәше өчен Рәшит җиңүче дип игълан ителде, Сабантуй батырын көтеп, тәмам әлсерәгән тәкә һәм өр-яңа «Ока» автомобиле аңа насыйп булган. Батырларның киләсе алышына – Чаллы Сабан туена бер атна вакыт калган иде.

Чаллыда Сабан туйларын зурлап үткәрәләр. Илдә дан тоткан үз батырларың барда шулай булмый ни. Башка төбәкләрдән көрәшчеләрнең

Чаллы җыенына килүе – «Копчёный»ны егарга ниятләп килүе инде ул. Быелгы Сабантуй хикмәтле булырга охшаган: баш батырга бүләккә «Вольво» автомобиле куйганнар. Мондый маркалы машина шәһәрдә әле беркемдә дә юк, бүләк – кәттә, кызыгырлык. Көрәшчеләр дә күп җыелган. Келәм күзләгән ир-егетләр арасында сүз китте: «Сәмигуллин да килгән. Нүжәли машина Казанга китәр инде...»

Унтугызынчы июнь көнне Чаллының җыен мәйданында алма төшәр урын да юк иде. Котлап, бәйрәм күрергә Президент Минтимер Шәймиев тә килгән. Көн шактый эссе, Сабантуй кояшы бәйрәмгә җыелган халык өстенә нурларын кызганмый коя. Мәйдан куырылып бии, уйный, тантана итә. Чаллының кинәнеп, тугарылып, үз җыры, үз көе белән үз телендә мәйдан гөрләткән чаклары. Агай-эненең күзе көрәшчеләр җыелган почмакта. Көн кичкә авышканда, ниһаять, көрәш башланып китте.

Алдагы көнне «Витязь»дә көрәшчеләр «Вольво» турында сөйләнеп, авыз суын корытканда, Рәкыйп тикмәгә генә мыек астыннан елмаеп тормаган икән. Сәмигуллинның кем икәнен белә ул, ә болар чамалап бетерми иде әле, күрәсең. Кыенсынып тормады Казан кунагы, бер-бер артлы алты көндәшен җиңде. Марат Галиевны гына очко белән, калганнарын чистага атты. Менә алар келәмдә икәү генә калдылар: кызыл сөлге белән – быелгы Татарстан батыры Рәшит Сәмигуллин, зәңгәр сөлге – Рәкыйп Хәмитовта. Батырларның ике тапкыр бишәр минут бил алышачагы хәбәр ителде. Сабан туе атнасында илдә исемнәре телдән төшмәгән ике пәһлеван кара-каршы басып тора. Күзләр – каш астыннан сөзеп карый, сөлгеләр билләргә салына, беләкләрдә кояш уйнаклый. Рәшит гәүдәгә киңрәк, авыррак та икән. Рәкыйп йөз дә биш килограмм булса, Сәмигуллин – йөз унбиш. Рәкыйпкә тиздән кырык ике, Рәшиткә утыз биш яшь туласы. «Караәхмәт»нең кара чәчләренә көмеш йөгергән. Көндәшләрнең икесе дә билен бирердәй түгел, хәрәкәтләр җитез, кискен.

Беренче биш минутта исәп ачылмады. Сөлгеләр билләргә уралды да, кабат алышырга тотындылар. Мәйданда һава киерелгән җәя төсле тартылган. Пәһлеваннар барып төшкәндә, җир селкенеп куя кебек. Рәкыйп эләктерә – ала алмый. Рәшит алмакчы булып карый – Рәкыйп елгыррак булып чыга. Шыбыр тиргә баттылар. Вакыт бетүен искәртеп, сыбызгы тавышы яңгырады, исәп – нульгә нуль. Казыйлар киңәшергә җыелды.

...Мәйдан гүли, мәйдан шаша. Дөнья, тоташ бер агымга әверелеп, Рәкыйп тирәли ага. Ул – мәйдан уртасында, ул ялгыз, ул бу мәлдә фәкать үз-үзе белән күзгә-күз. Кемнәрдер аны куәтләп кычкыралар, сәламләп, кул болгыйлар, кемнәрдер җилкәсеннән кага, колагына нидер пышылдыйлар, ләкин ул боларның берсен дә ишетми дә, күрми дә. Ул ялгыз, ул җир уртасында ялгызы басып тора. Буыннар сызлап карышалар да, ирнең ихтыярына буйсынып, тартышып куялар. Ми яшен тизлегендә эшли. Йөрәк ярсып тибә, кан кызулап ага. Көрәшче ир акрын-акрын гына тәнен, акылын, рухын бербөтен итеп җыя. Бар көчен бер йомгак итеп чорный, төйни, әйләндерә, әйләндерә, әйләндерә. Менә ул йомгак өермәгә әверелә. Тизрәк, тизрәк, тизрәк бөтерелә башлый. Кан куера, тән ашкына, йөрәк чабулый, ә акыл артканнан-арта барган шушы ярсулы кодрәтне әзерли, әзерли, әзерли… Менә ул үзе тоташ бер тын өермәгә әверелә. Ул үзенең өермә икәнен тоя, аңлый. Вакытны мизгелләп-мизгелләп саный. Тиздән,

бик тиздән бербөтен итеп укмашкан шушы көч шартларга тиеш. Бары бер мизгел, нибары бер генә мизгел. Йөрәк, әнә шул мизгелне үткәреп җибәрмәс өчен үтә сизгер. Акыл – соң чиккәчә тарттырылган кыл сыман тын, тыныч. Ирнең бөтен тәне, җаны, рухы бербөтен булып әнә шул мизгелне көтә…

Судья сызгырды, көрәшче аягын җиргә ныклап терәде һәм – шартлау! – көндәшен баш өстеннән атты. Бер балл! Тик уяулыкны җуярга ярамый. Ярамый! Хата хакы бик кыйммәткә төшәргә мөмкин. Чаллының көрәшче егетләре ут йотып күзәтә әнә, сынатасы түгел.

– Билеңне бирмә, Рәкыйп! Билеңне бирмә-ә-ә…

Ул арада Рәшит тә бер баллык алым ясый. Исәп тигез. Көчләр тигез. Дөнья гүли, мәйдан кайный, ул кайнарлык башка каба. Зиһенне, егәрлекне, рухны таркатмаска, ничек тә җыелырга, төйнәлергә, тупланырга кирәк. Өстәмә бирелгән биш минут вакыт та үтеп бара. Мизгелләп-мизгелләп, вакыт ага. Шул мизгелләр арасыннан берсе – аныкы, үткәреп җибәрмә, тоеп кал, тотып кал. Бу – аның җире, бу – аның келәме. Мәйданда аның каракучкыл битләреннән сөеп үстергән Чулман җиле исә, кайнар кояш тибрәлә. Бары бер мизгел – менә ул. Әйдә! Соңгы омтылыш! Соңгы шартлау – Рәкыйп тагын ата – тагын бер балл...

Мәйдан гүли, мәйдан баш батырны күтәп кымырҗый. Авыр, киеренке, озак алыштан соң, көрәш Рәкыйп Хәмитов файдасына икегә-бер исәбе белән тәмамлана. Чаллы үз батырын аягүрә сәламләп, тантана итә. Кешеләрне мәйданнан таратырмын, димә, йөзләрдә – елмаю, күзләрдә – Сабантуй кояшы. Чаллы мәйданы үз «Караәхмәтен» төгәл унсигез ел рәттән котлап алкышлаячак – унсигез тапкыр Чаллының баш батыры булып Рәкыйп Хәмитов кала. Чаллыда гына түгел, бихисап тапкырлар якын-тирә төбәкләрдә-авылларда, Казанда, Ижауда, Чиләбедә…

Батыр – шәхес ул. Шәхеснең төп батырлыгы – батырлар үстерүдә. Сабантуй кояшы кебек тәгәрәп кенә офыкка төшеп барган көннәр белән бергә айлар, еллар уза. Үкчәгә басып, яшьләр үсеп килә. Бил алышу тәмен, кан кызуыңны менә шуларга күчерә алсаң гына, көрәшең мәңгелек. Сөлге тотып караган Чаллы төбәге егетләре Рәкыйп тирәсенә елыша башлый, ул – кумир. Спорт залында бергә дөбер-шатыр көрәшәләр.

– Әләй! Сындырасың бит инде, Рәкыйп абый, – дип ухылдый егетләр.

Копчёныйның сүзе бер генә:

– Көрәшегез! Чынлап көрәшегез, гадел көрәшегез! Егылмагыз. Егылдыңмы – беттең. Үзеңне, «мин»легеңне бетердең. Титулларыгыз, бүләкләрегезне карарга килмәдем. Миңа көрәшеңне күрсәт! Көрәш!

Үзе дә көрәшә. Тыны кысылган сыман, инде бирешер дә кебек, тренировкаларда җиңелгән шикелле дә. Әмма Сабан туйларында Рәкыйп белән бил алышкан көрәшчеләр, баш чайкап, кичләрен тагын сөйләнә:

– Ну спортзалда алам бит… Сабантуй җиттеме – диюгә әйләнә, билләһи…

Үзе үстергән Маратлар, Ришатлар, Алмазлар Сабан туе келәмендә туры киләләр. Мыек астыннан елмаеп кына:

– Егетләр, мине җиңәсез икән, димәк, мин – әйбәт укытучы. Җиңеләсез икән, димәк, сез – начар укучылар, – дип, авыз ера Рәкыйп.

Келәм дигән сәхнәдән матур китә ул. Татарстанның биш, Россиянең дүрт

кат чемпионы, Татарстанның атказанган спорт остасы Рәкыйп Хатыйп улы Хәмитов ике мең икенче елда Чаллы Сабан туенда йөз алтмыш килолы көндәшен егып, Сабантуй батыры сөлгесен иңнәренә салып – җиңүче булып, батыр калып, матур итеп китә.

* * *

Яңа Мусабай авылы өстендә чал кояш. Җирнең бик күп орыш-алышларын, көрәшчеләрен һәм батырларын күргән борынгы кояш ул – адәм балалары тәүге кат мәйдан корганны карап торган, Сабан туйларын, кешеләрнең хәсрәт-моңнарын, шатлык-җырларын барлап торган кояш. Шул кояшның нурлары авыл урамы буйлап баручы ирне аның көмеш чәчләрендә уйнаклап озата. Ир салмак атлый, вакыт-вакыт туктап, капка төпләрендә күренгән авылдашлары белән исәнлек-саулык алыша. Ул ашыга да кебек, бик мөһим эше бар да сыман, әмма ирнең ашыгасы килмәве ипле хәрәкәтләреннән, әледән-әле офыкка таба күз салып алуыннан сизелеп тора. Әнә ул түбән очтан менгән уңайга мәчет янына тукталды, яшькелт-зәңгәр түбәле, җыйнак кына таш мәчеткә беркавым карап торды да, бисмилла әйтеп, ишек тоткасына үрелде.

Аннан чыккач, кабат югары очка таба атлады. Чишмә бакчасына җитәрәк, капка төбендәге сын-һәйкәл янына борылды. Бөек Ватан сугышы яугирләре язылган исемлектән йөзенче кат үз нәсел-нәсәбәсенең, атасының исемнәрен барлады, күңеленнән генә алар рухына дога кылды.

Чишмә бакчасындагы мәйданда кешеләр шактый җыелып, уен-көлке тавышлар яңгырап торса да, туры шунда керергә базмыйча, бакчаны урап, чишмәгә таба кузгалды. Салкын чишмәнең тере тамчылары ирнең кара-кучкыл бит яңакларын, чал чәчен, җыерчыклы киң маңгаен бер мәлгә өтеп алгандай итте. Ир, кәефе килеп, елмайды. Сусавын басып, җиңеләеп, чишмә бакчасына – мәйданга юнәлде. Бәйрәмне башлар өчен авылдашлары Сабантуй аксакалы Рәкыйп Хәмитовны көтәләр иде инде.

Римма яңа гына оныклары белән әвәрә килеп, өйдә калган иде – кай арада килеп җиткәннәр. Кызлары да монда икән инде. Энекәше Эльдар да кайтып җиткән, көрәшчеләр тирәсендә кайнаша. Матур гына үсеп килә, быел Чаллы батыры булгач, йөрәгендә көрәш дәрте ныграк кайный егетнең. Күз карашлары ук бүтән. Җирдә татар көрәше дәвам итә. Тормыш мәйданында Хәмитовларның көрәше дәвам итә, шөкер!

Рәкыйп елмаеп куйды. Горурлык та, сабыр куаныч та, сагыш та, өмет тә бар иде бу елмаюда. Чал батыр, күкрәк тутырып, туган авылы һавасын сулады, тураебрак басты һәм ирексездән, офыкка – урман ягына карады.

...Кояшлы җәйге җил колач җитмәс кара төпләр тирәли үсеп чыккан яшь имәннәрне иркәләп үтте дә басу яклап, авылга юнәлде. Яңа Мусабайның бердәнбер урамы буйлап, капка-тәрәзләргә кагылып узды, аннан мәйданга ашыкты. Кешеләрнең елмаюлы йөзләреннән сөеп үтте, колга башындагы чигүле сөлге белән уйнады, ил-җиргә бәрәкәт, иминлек юрады. Бу – Сабантуй җиле иде. Ул бу җирдә – татар галәмендә бик күптәннән, бик борынгы заманнардан исә. Ул киләчәккә ашыга.



Халисә
Ширмән

# КУЛЪЯЗМАЛАР – ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕ...

***

*Авыл —*
*Һаман шулай катык ашый...*
Һади Такташ

Һаман шулай катык ашый авыл,
Сатып ала аны кибеттән.
Калмады ла инде авылларда
Хайван асрап бүген интеккән.

Көтү чыга иртән − сигез сыер,
Дүрт-биш кәҗә, сарык бәтие.
Бер алаша йөри чирәм утлап,
Әйтерсең лә, авыл ятиме...

Әйтерсең лә, әкрен генә авыл
Карурманга керә адашып...
Ә урманда − давыл... Коты очкан
Шүрәлеләр чаба саташып...

Батыр да юк... Лунтик белән Фиксик
Сабыйларның күңелен биләгән.
Син идеңме, авылым, ана сөте
Белән бишек җырын көйләгән?!

Син идеңме тиңсез улларыңны
Шәһәрләргә елап озаткан?!
«Кеше булсын берүк!» – дия-дия,
Туган нигезеннән кузгаткан.

...Ярый әле, катык ашый авыл.
Милли ризык сеңә тамырга.
Язмасын ла татар авылына
Музейларда гына калырга!

Халисә ШИРМӘН (1969) – *шагыйрә, язучы, галимә; филология фәннәре кандидаты, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Яшәү моңы», «Ерактагы йолдызым», «Асылъяр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Таң ярала... Авыл әтәчләре
Йолдыз чүпли күк йөзеннән,
Җир ял итә, болыннарга
Томан төшә ат тезеннән.

Ишетелми урман шавы,
Җил йоклаган җиргә ятып;
Ай да, арып, күк йөзеннән
Киткән, ахры, өйгә кайтып.

Шундый матур, тын иртәдә
Томан төшә күңелемә.
Ышанасы килә җәйнең
Ахыргысы түгеленә.

***

Көн болытлы, дисең... Кешеләрнең
Йөзләре дә була болытлы.
Кичә генә йомшак һава иде,
Бүген тагы никтер суытты.

Бу салкынлык каян килә, дисең...
Без үзебез салкын, үзебез!
Кайчакта бит суык көннәрдә дә
Кояш тоткан кебек йөрибез.

Бәхет тулып ташкан чаклар була,
Андый мәлдә дөнья бик ямьле!
Биеп тора күңел дигәннәре,
Һәр тарафка җитә сәламе!

Көн болытлы, диеп, күңелеңне
Болытларга төреп суытма!
Болытлардан бик югары күктә
Кояш барын бер дә онытма!

***

Берәм-берәм календарьны ертам –
Үтәләр дә көннәр, үтәләр...
Кыштырдавык кәгазьләргә салып,
Гомеремне алып китәләр...

Кыштыр-кыштыр кыштырдыйлар, әллә
Кәгазь белән язмыш бәйләнгән?
Кәгазьләрдә – хисләр...
Кәгазьләрдә – тормыш...
Мин үзем дә
Ак кәгазьгә гүя әйләнгән...

Шул кәгазьгә һәркөн хисләр төшә,
Кулъязмалар – тормыш көзгесе.
Кемгәдер ул бары бер әкият,
Ә кемгәдер – яшәү өлгесе...

...Беркөн дөнья мине бөтереп алыр,
Һәм почмакка атар бөгәрләп.
Шуңа кадәр «Мин яшәдем!» дигән
Узган көнне ертам берәмләп...

***

Кояш бата. Шәфәкъ кызыл нурын
Яулык итеп болгый еректан.
Җир өстенә эңгер-меңгер иңә,
Дымлы бер ис аңкый туфрактан.

Белсәң иде, әнкәй, әллә нигә
Яратам соң шушы сәгатьне!
Дөнья тына. Үзәк өзгеч бер моң
Талгын гына урый йөрәкне.

Белсәң иде! Менә бүген кызың
Тагын качты шәһәр шавыннан.
Соңгы нурны тотып калыйм, диде,
Казансуның комлы ярыннан...

Әрем исе килә. Беләсеңме,
Әрем җыяр чаклар җиткәнне?
Хәтерлимсең, икәү бергәләшеп
Тау әремен җыеп төшкәнне?

Әни, әнкәй!.. Әй, пешерә идең
Мунча ташына салып әремне!
«Яңа җыйган әрем исле була,
Өздереп лә ала бәгырьне!..»

Әй лә, әнкәй! Кемнәр белсен монда
Әрем исләренең дәвасын?!
Без күнектек инде иснәп күптән
Газ-тузанлы шәһәр һавасын.

Кояш бата. Караңгылык иңгәч
Күзләр күрми шәһәр сөремен.
Авыл мунчасында парланган күк
Пакьләнә шул мәлдә күңелем.

...Кояш бата. Шәфәкъ кызыл нурын
Яулык итеп болгый еректан.
Яр буенда ялгыз берәү җырлый:
Аерылган туган туфрактан...

***

Унсигездә кызлар шундый гүзәл:
Сызмаса да кыйгач кашлары,
Зифа буе, толым-толым чәче...
Әйләнәдер егет башлары!

Утызда да матур әле алар,
Тулып пешкән чия шикелле.
Кулларында бала тибрәткәннәр
Шундый гүзәл, шундый сөйкемле!

Кырыкта да чибәр ханымнар бар,
Каян килә икән матурлык?

Ә илледә матур булу өчен
Кирәктер ул чиксез батырлык.

Исең китми усал җыерчыкка,
Күзләреңнән тамса бәхетең,
Шул буладыр алтмыш матурлыгы –
Кабул итү яшең тәхетен...

Әби булсам, матур булачакмын!
Шундый карар бирдем үземә.
«Нинди бәхетле бу карчык», диеп,
Соклансыннар карап йөземә!

***

Айкала да чайкала бу дөнья.
«Авыр, – дибез, – хәл юк түзәрлек».
Шартлар да бер сынар кебек кеше,
Егәр бетеп, богау өзәрлек...

Айкала да, чайкала бу тормыш...
Иртәләре кичкә ялгана.

Мең сурәтле тормыш базарында
Кемдер алдый, кемдер алдана...

Мәңге шулай чайкалыр ла җиһан...
Кемнәр кайдан табар юаныч?!
Айкалса да, чайкалса да дөнья –
Туар таңга калсын ышаныч!

***

Канаты каерылган күбәләк
Тәрәзәм төбенә чүмәшкән.
Күзләрен ачалмый, бәгырькәй,
Чарасы калмаган үлмәстәй...

Әйт әле, күбәләк, бармы ул
Канатсыз яшәүнең мәгънәсе?
Җәйге таң, чәчәкләр, дусларың –
Югалыр тормыштан һәммәсе...

...Учыма утыртып бәгырьне
Урамга – бакчага чыгарам.
Талпына, очалмый... Тырыша
Яңадан күзләрен йомарга.

Ничекләр яшәрсең дөньяда,
Иңнәрдә канатың тоймасаң?
Бөрешеп, наз көткән мәлеңдә
Күшегеп, җылыга туймасаң?

...Күбәләк кебек мин үзем дә –
Канатлы чагымда ягымлы.
Канатсыз калдырсаң, йа Хода,
Үзеңә ал, зинһар, җанымны!

***

Йомшак кына басып аяк очларыма
Башлыйм һәр көн шәһәр иртәсен.
Мияулама, песи, аһ, шаулама, чәйнек –
Йоклый әле тормыш иптәшем!

«Чү, диямен, тукта!» торган балаларга, –
«Бигрәк каты дөп-дөп басасыз!
Сөйләшегез әкрен, киенегез әкрен –
Йоклый әле сезнең атагыз!»

Тәмле коймак пеште, чәй дә кайнап чыкты,
Эшкә дә бар инде китәсем...
Кояш керде мәллә бу бүлмәгә, дисәм –
Торып чыккан тормыш иптәшем!

***

Мин язларны күбрәк яратамдыр:
Тирә-якта шатлык уяна,
Иркә кыздай йокысыннан торып
Киерелә урман, елмая.

Мин кояшны күбрәк яратамдыр:
Гафу, болыт, кояш сөйкемле!
Һәр яз саен миңа күзен кысып,
Йөзгә мулдан сибә сипкелне.

Гел яктыга, гел кояшка үреләм,
Саргаеплар килми бетәсем...
Язлар саен чирәм булып калкам,
Мин тормышка гашыйк, күрәсең...



Нәзифә
Кәримова

# ИЗГЕ АТ

хикәя

Тау итәгендә һәр көнне дип әйтерлек кичкырын бер ак ат барлыкка килә. Менә ул таудан юргалап килер дә колачлы канатлар чыгарып очып китәр төсле. Ерактан шулай күренә. Авылда атлар бетеп барган заманда шундый матур атның барлыкка килүе мине кызыксындырмый калмады.

– Хуҗасы бармы ул атның? Гел тау битендә. Кемнеке ул гаҗәеп матур аргамак? – дип сорадым.

– Һай! Бар кеше дә кызыга ул атка! Берәү генә ул безнең авылда шундый матур ак ат! Шәрифулла аты! Колыны да бар әле аның! Анысы да әнисе кебек сөттәй ап-ак! Шәрифуллага, сат әле, дип, чиратка басканнар инде берничә кеше. Әлегә тегесе кызыктыра гына. Әллә бәясен күтәрергә тырыша инде, белмәссең, – диде миңа энем. – Шәрипнең горурлыгы! Җикми инде ул аны. Үзенә печән җыярга көче җитсә, калганы матурлык өчен, изге ат ул минем, ди. Атының изгелегенә үзе дә ышанды бугай инде. Очраткан бер кешегә тәфсилләп шул атның тарихын сөйли. Атның шәҗәрәсен дә ясадым, ди. Ханнар заманыннан килә аның токымы, ди. Сиңа сөйләмәдеме әле?

– Юк, сөйләмәде әле. Чынлап та атның нәселе турында документлары да бармыни?

– Каян булсын инде! Сатып алуы турында бардыр булса, дөресен әйткәндә, күргәнем юк. Әйдә бәхәсләшәбез, әйдә бәхәсләшәбез дип, арттан йөргән иде. Бәхәсләшергә хирыс кеше ул. Аның белән бәхәсләшә башласаң! Теле оста, сүз белән ега да сала инде!

Шәрифулла абыйның аты турында «изге ат» дип, авылда башка кеше сөйләми, ул үзе генә әйтә. Ышанганы ышана инде. Ышанмаганы астыртын гына көлеп куя. Әйдә, сөйлә, янәсе. Шулай да гади атларга бер дә охшамаган шул. Сөт кебек ап-ак, яллары озын, койрыгы да көлтә кебек! Әкияттәге тулпар ат диярсең! Атлан да елгалар, таулар аша әкият иленә, матур патша

---

Нәзифә КӘРИМОВА (1947) – *язучы, драматург, «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре»; «Җәнлекләр кайта», «Карурманнан чыккан юлчылар», «Сагынасыңмы, дип сорыйлар» һ.б. китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

кызы янына оч та кит! Бу ат әкиятләрне искә төшерә... Хыялың гына җитсен! Ышанмаган җиреңнән ышанырсың.

– Ак ат һәрвакыт изге була, – ди Шәрифулла абый. – Әнә, шуңа күрә дә тышауламыйм да. Үзе чыгып китә, үзе йөреп кайта. Киткәндә сау бул, дип, кайтканда исәнме дип кенә әйтми! Кеше акыллары бар анда. Карап кына торам шуңа күрә!

Шул көе генә атның үзенә ышанып җибәрә ул аны болынга. Хәзер малларга рәхәт. Теләсә кайда болын. Иген чәчү кимеде. Ике фермер күпме җирне эшкәртә алсын? Хәзер якындагы урман тагы да якынаеп килә авылга. Җиләкле болынга әйләнгән элекке чәчү җирләрен әйткән дә юк инде. Күпме җирләр болынга әйләнгән, ә мал асраучысы юк. Авыл җирләре түгел алар хәзер. Кемдер сатып алган, бернәрсә дә утыртмый да, килеп тикшерми дә. Элек урманнан басу ясап, безнең бабайлар урман кисеп, агач төпләрен яндырып йөргәннәр иде. Ышна җирләре дип атала иде ул. Хәзер кая ул?! Шушы хәлләргә карыйсың да, менә битарафлык кайдан башлана, дип уйлыйсың. Авылда буш җирләр күрү кызганыч та, аяныч та. Ләкин ак ат бизи басуларны. Озын ялларын җилфердәтеп, кешни-кешни кайтып керүләрен карап торулары да күңелле.

Менә шул «изге ат» аркасында хәтәр хәлләр булып алды авылда. Иректә ат ризыкны үзе табарга өйрәнгән иде. Коймасыз бакчаларның кайда икәнлеген дә белә ул хәзер. Бакча коймасыз дигәч тә, хуҗасыз түгел бит ул... Әле ул бакчада колорадо коңгызларына манчылган булса да, бәрәңге бакчасы бар. Атка бар да бер! Ул юлын таба! Ул үзенең изге икәнлеген белми бит! Һиндстан сыерлары шикелле теләсә кайда йөрергә өйрәнгән.

Шәрифулланың «изге атын» бакчасыннан куып, Хәния арыды инде. Бәрәңге утыртуга йомшак җиргә кереп, ничә тапкыр аунады Шәрифулланың аты! Шәрифулла тыныч. Аның бакчасында аунамый бит ул!

– Юкка эчеңне пошырма, Хәния! Ат аунаган җирдә бәрәңге беләсеңме ничек олы булып үсәчәк?! Ат кадәр! Ат башы дип әйтүем! Изге ат бит ул! Ышанмыйсыңмы, әйдә бәхәсләшәбез?!

– Синең белән бәхәсләшергә. Әллә син мине теге!.. Нәрсәсе белән изге булсын ул?! Бакчамны ындыр табагына әйләндерде бит инде!

– Әй, Хәния! Гөнаһка батма! Үзең уйлап кара, теләсә кем бакчасына керми бит ул! Борынгы бабайлар, яңа авыллар, хәтта шәһәрләр салганда, иң беренче чиратта, үзләренә ошаган урынга малларны җибәрә торган булганнар. Безнең авылның урынын да менә минеке кебек ак ат билгеләгән дә инде!

– Кит әле моннан! Нинди ат та, нинди бабайлар! Син каян беләсең аны? Атыңны тый!

– Менә шуны аңла син! Синең бакчага гына керә бит! Монда ниндидер тылсым бар! Үзең уйлап кара! Әнә басуга иген чәчкәннән соң да каток белән үтәләр бит! Бакчага каток кертеп булмый! Рәхмәт әйтерсең әле! Менә коймагыз булса! Булса да, бәреп керер иде. Синең бакчаны яратты минем ат! Син шуны беләсеңме, тарихи урындыр ул синең бакча, башкача булмас! Атлар хәтере тирән ул. Юкка гына әйтмиләр бит, әнә ат уйласын, аның башы зур дип, – диде Шәрифулла, чын-чынлап талашырга килгән Хәнияне шаккатырып.

Хәниянең күптән инде мондый сүзләрне ишеткәне юк иде. Хәер, берничә

ел элек авылның 350 еллык юбилеен уздырабыз дип йөргәннәрен ишеткән иде ишетүен. Инде көнен дә билгеләгәннәр иде. Галимнәр килеп кушылган да, авылга документлар буенча 350 ел гына булырга тиеш түгел, иң кимендә мең ел дигәннәр. Шуннан бирле бөтен авыл халкы туган авылының мең еллыгын раслаган дәлилләр эзли башлады. Табарлар да. Берничәсе иске зират ташларын өйрәнеп, инде 760ка җиткергән иде. Менә ике ел инде шул саннан артык китә алмыйлар. Әгәр дә бу ат аркасында тагы бер-ике йөз ел өстәлсә! Килен генә булып килсә дә, авылның патриоты Хәния! Беркатлы нәрсә, ышана язды бит Шәрифулланың уйдырмасына!

Үзе әйтмешли, беркатлы, күлмәге белән генә ике катлы Хәния!.. Чынлап та мондый ат күргәне юк иде аның. Ап-ак ат! Бакчамны яратты, ди бит. Бәлки изгедер дә әле. Авылда Хәнияне яратучылар аз. Теле борычлы. Нәрсә уйлый, шуны әйтә дә сала. Ә инде үзенең сүзләренә үпкәләгән кешегә шаккатып йөри аннары. Нәрсәгә үпкәләргә, дөресе шул бит дип уйлый. Әнисенең әйткәне бар иде инде: «Син тиледән туры хәбәр, дигәндәй, кешенең йөзен ертып әйтмә артык сүзләр! Капчыкның төбен селкемә, әзрәк калсын. Барын-югын әйтеп бетерергә ярамый!» – дигән иде. Бар әле аның капчык төбендәге ачулары! Иренә бик әйтәсе килгән чаклары бар, телен тешли ул вакытта Хәния. Әйтеп, кая барсын, элек каты тормагач, хәзер генә үзгәртеп булмый шул. Әгәр дә ул ир булып, койманы корып куйган булса, бу Шәрифулланың аты аның бәрәңге бакчасын таптамас та иде. Аның ахыры да болай фаҗигале нәрсәләр китереп чыгармас иде... Күпме әйтте! Юк кына бит. Тегесе телефоннан аерыла алмый. Каян уйлап чыгардылар бу кесә телефонын?! Әнә шуның аркасында җимерелеп бара инде Хәниянең тормышы. Көне буе телефоннан хат яза ире. Бакча башына менеп китә дә! Йөргән кешесе бар, ахры, дип уйлый Хәния. Китеп йөргәне дә юк югын. Кем белән сөйләшә торгандыр ул! Эзенә төшәр әле төшүен. Тик әлегә бер генә дә вакыты юк шул. Бу ат белән эшне бетермәсә, бәрәңгесеннән дә коры калачак. Кыш көне нәрсә ашар бу ир дигән нәмәстә! Телефон тамак туйдырмый ул, акча гына сорап тора. Кара әле, каян таба икән бу ир нәмәстәсе акчаны? Хәзер менә печән әзерләү дә Хәния өстендә, сыер карау да, бәрәңге бакчасы да. Шәрифулласын да әйтер иде! Мине беркатлы дигәч тә инде... Уйламыйча, теленә нәрсә килде шуны кычкыра торган Хәниянең дә башына уй керде бит әле.

– Менә нәрсә Шәрифулла! – дип, сүз генә башлаган иде, Шәрифулла аның авызын да ачтырмады.

– Хәния, Хәния дим, үзең уйлап кара, син бит инде акылсыз хатын түгел...

Хәния Шәрифулланың бу сүзләренә аптырап китте. Бу сүзләрне ишетү бик рәхәт иде. Чөнки әле аның акылы турында шулай матур итеп әйткән кешене ишеткәне юк иде. Ире дә кирәксә-кирәкмәсә дә, урынлы-урынсыз, «тавык мие эчкән нәрсә!» дип ычкындыра. Үзе нәрсә миен эчкәндер, ата ялкау!

– Хәния! – диде Шәрифулла, аны уйларыннан бүлеп. – Син бит үзең дә күреп торасың, безнең авыл дүрт яктан да таулар белән уратып алынган.

– Таулар! Әйтерсең тагы! Нинди тау булсын инде ул! Бер калкулык инде. Син, Шәрифулла, сүзне читкә борма әле. Тауларның монда бернинди

катнашы да юк! Атың бакчага керә бит! Йөрсен иде ул тау битендә генә! Үз башына йөрми микән?

– Тукта-тукта! Атның башы үзендә! Менә тауларга кара әле син! Алары да изге таулар бит. Менә шушыннан башлана инде олы таулар!

– Әнекәем! Таптың сөйләр нәрсә! Бу таулар алыпларның чабаталарыннан төшеп калган түмгәкләр генә! Тау дип торасың!

– Әй, Хәния! Таптың кемгә сөйләргә! Синен бит тауларны күргән түгел, ишеткәнең дә юк! Менә бу тауларга әле чират җиткәне юк, аның эчендә бетмәс-төкәнмәс байлыклар ятканын беләсеңме син?!

– Байлык дигән була тагы! Әй, болары да үзәккә үткән! Урман дисәң дә, тауга мен, болын дисәң дә, тауга мен! Кыш булса, кары күмә, җәй булса – сазы, дигәндәй!

– Ә бит безнең таулар – изге таулар! Без генә ул хәзер чокырга кереп беткән. Ә ул таулар башында ханнар яшәгән! Борынгылар! Менә син үз исемеңә игътибар иткәнең бармы, Хәния? Ә, ханнар иясе! Белдеңме шуны! Синең исемдә дә бер сер бар, юкка түгел бу исем... Тау астыннан чишмәләр дә бит ханнар бетеп югалгач кына килеп чыкан. Алар тау эчендәге байлыкларны, алтыннарны-көмешләрне юып чыгаралар! Безнең чишмәләр шуңа күрә бозылмый да, саф та, изгеләр чишмәсе дип атала. Кыйблага карап чыккан чөнки! – диде ул, имән бармагын күтәреп.

– Безнең ишеләр ул вакытта да тау башында түгел, тау итәгендә булгандыр инде.

– Гади халык турында сөйләми бит ул тарих. Ул аксөяк, патшалар, ханнар турында сөйли. Ә менә исемеңә караганда, син тарихта буласы кеше дә бит. Яшең генә туры килми әлегә...

– Тарих? Кайдан беләсең син барысын да? Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, диләр.

– Менә шушы тау өстендә, Хәния, кара әле бу якка, күрәсеңме, хан сарае булган.

– Нишләп күрмәскә, иртән күзем ачсам, тәрәзәдән карап торган тауны кем күрмәсен? Нинди сарай тагы, малларын шунда тотканнармыни?

– Хан сарае!

– Сарай? Ханнар сарайда яшәгәнмени? Абзар диген тагын. Сарай, тфү, әгузебилләһи!

– Сиңа сөйләгән мин юләр! – диде Шәрифулла. – Әз генә тыңла әле акыллы сүзләрне, башыңны эшләт бераз!

– Сөйләмә дә, тыңламыйм да! Атыңны тый, бакчага кермәсен!

– Их Хәния! Синдә һаман бәрәңге кайгысы! Изгеләр чишмәсеннән су эчкәннәр, халыкны әйтәм, сау, таза булган, акыллы булган. Без бит хәзер дә шул чишмә суын эчәбез, туганнан бирле! Әй, син бит әле безнең авыл кешесе түгел, онытып торам. Килен кеше, барсын да белеп тә бетермисең. Сиңа кагылмый анысы. Тик, тарихны белергә кирәк. Бер бәрәңге белән генә яшәргә тиеш түгел бит инде кеше.

– Бәрәңгесез яшәп кара әле син! Без бит ханнар сараенда яшәмибез!

Шәрифулла тарих турында белгәннәрен кемгә сөйләргә генә белмәгәнгә сөйли башлаган иде Хәниягә. Тапкан сөйләр кеше! Сөйләми кая барсын? Тыңлый бит!

– Ханнар сараенда чишмәләр булмаган. Алар суны коедан алганнар. Чишмә тауга каршы акмый бит. Бервакыт җиде кыз коега суга килгән. Кичкырын булгандыр инде. Ләкин алар кире әйләнеп кайтмаган. Кызларны күпме генә эзләсәләр дә, таба алмаганнар.

Хәния дә кызыксынып китте. Бер мәлгә бәрәңге бакчасы да онытылды:

– Синең сүзләргә ышансаң, берәү генә дә түгел, җиде кыз бит алар! Кеше шулай юктан гына югалмый инде. Тапканнармы соң?

– Тарих бу, дустым, тарих! Тарих вагын-төяген язмый. Югалганнар кызлар! Хан сараенда кара кайгы. Шул вакытта алар бер мәлгә дошманнар турында онытып торганнар. Кызларны эзләгәннәр. Ә бит кызларның югалуы шул дошманнарның эше булган да! Алар җиде кызны үтереп, коега салганнар. Ә кызларның көмеш чулпылары, алтын беләзекләре – бөтенесе дә коега чумган!

– Дошманнар нәрсә дип үтергәннәр инде ул балаларны? Шул алтын-көмеш өчендер инде, нигә салдырып алмаганнар соң?

– Юк, дошманнарга менә шушы безнең җирләр кирәк булган. Безнең урман-басулар кирәк булган. Нәрсә ул чулпы-беләзек?! Менә шул вакыттан бирле ханнар яшәгән тау астында җиде чишмә бәреп чыккан. Әле ул чишмә турында тарих зур! Ул кызларны харап иткән дошманнар хан сараен да тар-мар иткән. Ханнар гына барлык алтын-көмешләрен шул коега ташлап өлгергәннәр. Дошманнарга тәтемәгән берсе дә. Шуңа күрә, әйткәнемчә, чишмә суы көмешкә бик бай, диләр. Суы да бозылмый шуңа күрә, диләр. Ә менә бу чишмә яннары киң сулы елга булган! Бирегә бит Сөембикә ханбикә дә парахудка утырып килә торган булган. Чөнки монда аның туганнары яшәгән.

– Туганнары! Кайдан беләсең син ханбикә туганнары турында? Әй, башымны катырасың да инде. Атың турында оныттырырга тырышасың, кара аны!

– Ханнар зиратын беләсең бит инде! Үзең Хәния булып йөрисең, ә үзең! Китап укы әзрәк! Ханнар зираты булгач, ханбикәнең туганнары да булырга бик мөмкин! Син фаразлау дигән сүзне ишеткәнең бармы?

И Шәрифулла! Кемгә сөйләп авыз суыңны корытасың?! Хәниянең башы җитми андыйларга дип әйтергә дә... Әйтер кеше юк шул. Менә авыл бәйрәмендә бөтен халыкка сөйләп шаккатырачак әле Шәрифулла. Тик менә аңа чаклы бу тарихны өйрәнеп бетерә алыр микән? Хәзер инде җыен надан гына калды авылда. Хәния ишеләр генә. Әгәр дә авылга мең ел икәнлеген исбатласа?! Бу тарихи авылга күпме делегация киләчәк! Экскурсияләр булачак! Галимнәр кайтачак! Әй, мине тыңларлык күпме акыллы башлар җыелачак, әле телевидение дә килсә! Ух, Шәрифулла, ак атына атланып, түбәтәен кырын салып сөйләячәк тә сөйләячәк туган авылының тарихы турында! – дип уйлады ул. Уйларыннан аны Хәния арындырып җибәрде.

– Әй, Шәрифулла! Нәрсә сүзсез калдың, хыялый! Атыңны тышаула инде, зинһар!

– Әй, безнең таулар ул! Хәния, менә алыплардан калган түмгәк дисең син тауларны. Ә уфалла арбасын тартканда, арбаң келтерәп кенә бара идеме? Өстери идең бит тауга каршы!

– Әй, искә төшереп торма әле ул вакытларны! Аллага шөкер, бетте инде ул арба тартулар!

– Хәлең җиңеләйдеме соң, Хәния?

– Кая җиңеләйсен? Сыерны асрарга кирәк бит! Печәне дә кирәк!

– Менә шулай инде без! Уфалла арбасы да – тарих... Авырлык һаман бетми безнең өчен. Күпме үзгәрешләр булмасын, авырлыкны табабыз!

– Нишләп без табыйк аны? Авырлык үзе безне таба!

– Уфалла арбасы тарткан чакта бәрәңге бакчасында кайгыбыз юк иде. Ә хәзер?

– Барысына да Әмирика гаепле!

– Их! Хәния! Син дә сәясәт белән шөгыльләнә башлаган, ахры. Депутатлыкка әзерләнәсеңме әллә?

– Нинди депутатлык! Шул Әмирикәдән килгән колорадо коңгызын җыеп үтә җаем. Таптап чыгып китсәң дә, үлми бит! Таш та таш, бу да таш! Сытсаң да үлми! Әнә кәрәчинле чиләккә җыям.

– Дөрес әйтәсең, аны Америка уйлап тапкан серле корал дип әйтәләр әйтүен...

– Корал? Кемгә каршы? Безнеңише бичара катыннарга каршымы? Шул бәрәңгегә генә карап тормасак та... Менә бәрәңгесез яшәп кара әле син! Корт ашый да бетерә бит!

– Агуы бар бит аның! Сиптер агуын!

– Бернәрсә белән дә юк итеп булмаган ул кортка агу сипсәң, үзебезгә нишләргә кала? Без бит әле ул бәрәңгене ашарга да тиеш.

– Ашарга зыяны юк, ди. – Ул бит сабакларны гына агулый. Әллә син бәрәңгенең сабагын да ашыйсыңмы, Хәния?

– Нишләп сабагын ашыйм, ди! Сабактан үсә бит инде ул бәрәңге. Агуы төбенә төшмәс, дисеңме?

Ничаклы бәхәсләшсәләр дә, бу ике күрше уртак фикергә килә алмады. Берсе, «койма тотыгыз» дип, икенчесе, «атыңны тый» дип аерылыштылар.

Их Шәрифулла! Никләр генә әйттең инде агу турында! Хәния шул көнне үк агу эзләп китте. Бар икән ул агу, кибеттә дә бар икән! Хәния ул агуны алып кайтты да, күршесе әйткәнчә, су белән болгатып, сиптергечтән көне буе бәрәңге бакчасын эшкәртте. «Бу сасы искә ат та кермәс, берьюлы ике нәрсәдән котылачакмын икән, Шәрифулла атыннан да, бу Әмирика кортыннан да», – дип уйлады ул.

Иң шаккаткычы икенче көнне булды. Бу бөҗәкләр нишләделәр икән дип, Хәния бакчага чыкса, Шәрифулланың ак аты бакча уртасында аякларын, башларын ташлап үлеп ята иде!

Хәния нишләргә белмәде! Башта кычкырып җибәрде. Атка кагылырга куркып, тирәли йөгерергә тотынды! Өенә таба йөгерде, кире килеп, тагы атка карады! Үлгән дә үлгән, бу да үлгән инде!

Ире һаман шул урынында бакча башында телефоннан сөйләшә. Ул аның янына йөгерде.

– Нәрсә уйлаплар йөрисең?! Нишлибез?! – дип кычкырды да, иренең һаман аерыла алмаган телефонын тартып алып, бәрәңге бакчасына ыргытты. – Шәрифулланың атын син генә үтердең!

Ире сүзсез калган иде. Ул, кулларын бутап, тегеләй-болай килде дә:

– Нинди ат? – дип сораудан башка сүз таба алмады.

– Ак ат, изге ат! Синең аркада гына! Койма корган булсаң, ат та керми

иде, үлми дә иде! Син үтердең, җавабын да үзең бир! Мин Шәрифуллага йөгердем! – диде.

Ире аның артыннан: «Кайда соң ул ат?» – дип кычкырып калды. Хәния кулын гына селтәде. Олы галушы белән сөрлегә-сөрлегә, тыкрыктан гына Шәрифуллаларга йөгерде.

Хәниянең сулышы капкан иде. Йөгергәндә ул: «Бакча башына кадәр менгән бит, бакча уртасында үлеп яткан атны күрмәгән, хайван!» – дип, үзалдына ирен ачуланды. «Шәрифуллага нәрсә әйтергә инде» дип, сүзләр эзли башлады.

Шәрифуллаларга керсә – ул ишегалдында сызгыра-сызгыра, колынга сөт эчертеп маташа. «Ул әле белми, ул әле белми!» дип уйлады Хәния. Керүгә «атың үлгән» дип, бик әйтәсе килсә дә, әйтә алмады. Бакчадан атны куган чакларда шушы сүзләрне әйтергә бик хыялланган иде ул. Бары тик: «Әйдәле, синең атың тагы безнең бакчада әллә нәрсә эшләгән...» – дип әйтергә генә көче җитте. Ул лапылдап капка төбендәге эскәмиягә ауды.

– Бәрәңгене үзең агуларга куштың, мин агуладым! Бәрәңгене, атны түгел! – диде Хәния ыңгырашып.

Шәрифулла инде болар бакчасына таба йөгерә иде.

Шулай да Хәниянең ире дә тик тормаган икән, мал табибын алып килгән. Ярый әле күрше авылга китмәгән, ярый әле машинасы бар мал табибы Рәхимнең! Берничә авылга берәү генә бит ул! Шәрифулла белән Хәния бакчага менеп җиткәндә, ул атның әле бер ягына килеп, әле икенче ягына төшеп, җансыз калган гәүдәсен капшады. Авызын ачып карады да: «Токсикация!» – диде.

– Нәрсә, үлгән дәмени инде? – диде Шәрифулла, елап җибәрергә әзер торып.

– Үлеп үк бетмәгән шикелле, хәзер укол ясап карыйм инде, бәхетегез булса, торып китәр. Әллә бәрәңге агуы, әллә ниндидер ярамаган үлән ашаган. Хәзер агуга каршы дару бирәм, – дип, зур калын энә белән атка берничә җирдән укол да салып җибәрде.

– Аучы Хәлимне дә чакырырга кирәк, ат интексә, атып кую хәерлерәк, – дип, сүзгә катышты Хәниянең ире. Ул арада бакчага ярты урам кешесе җыелган иде.

Ат янында ни эшләргә дә белми өтәләнгән Шәрифулла Хәниянең иренә ташланды:

– Бирермен мин сиңа мылтык! Аттырырмын мин сезгә! – дип, йодрык белән килә башлады. Тегесе бакча башына йөгерде.

– Хәлимне алып менәм вчүтеки, ат интегә бит, – дип кычкырды ул.

– Алла хакы өчен! – дип ялынды Шәрифулла Рәхимгә. – Атны кеше итсәң, колыны сиңа, валлаһи! – диде ул.

– Мин аны кеше итә алмам инде, ат ат булып калыр, менә тагы 15 минут көтик әле, – диде Рәхим. – Тик менә кемгәдер барыбер җавап бирергә туры киләчәк. Ат страховайт ителгәнме? – дип сорады Шәрифулладан.

– Кемгәдер! – дип кычкырды Шәрифулла. – Миңа түгел, кәнишне. – Мин агуламаган бит аны. Страховкасын да хәтерләмим. Сыер тучны страховайт ителгән.

– Сыер түгел, ат үләргә ята монда! Мал кемнеке?

– Минеке! – диде Шәрифулла.

– Нигә соң син үз малыңның кайда йөргәнен белмисең, син җаваплы! – диде мал табибы.

– Нигә алар бакчаларына киртә куймыйлар, ике ялкау. Бакчаларын сакласалар, алай булмас иде! – дип кычкырды Шәрифулла.

– Мин сиңа күпме әйттем, атың бакчадан такыр басу ясады дип! Менә хәзер инде калганын ярты авыл кереп таптады. Миңа кем бәрәңгесен бирер, берсе дә бирергә тормый! – дип кычкырды Хәния. – Нигә дәшми торасың, кая үзе, синең бәрәңге турында сүз бара, – дип кычкырды ул иренә. Ире баядан бирле бәрәңге рәтләре арасыннан Хәния атып бәргән телефонын эзли иде.

Менә китте бәхәс! Кем җаваплы да кем гаепле, дип, бер-берсенә сылтарга тотындылар. Бәхәснең иң кызган вакытында кинәт кенә кап-кара җирдә олы ак җәймә кебек яткан ат селкенеп куйды, бөтен гәүдәсе буйлап дерелдәү үтеп китте. Шул минутта барысы да телсез калды! Беренче булып, Хәния телгә килде:

– Җан керде! Җан керде! – дип кычкырды ул.

Шәрифулла атының өстенә ятып кочаклый башлады. Бары тик мал табибы өстери башлагач кына, урыныннан торып басты.

– Терелде, терелде! – дип кычкырды Шәрифулла. – Карале, Рәхим, син теге колын турында әйткән сүзне чынга алмагансыңдыр бит. Шаярта торган гадәтне беләсең...

– Тукта әле, тукта, ант иттең бит! Хәзер атың селкенде дә бит, биш минуттан җан тәслим кылырга да мөмкин. Кара аны, Ходай орыр! – диде Рәхим, чемоданын җыеп.

– Ярый, ярый, шаяртканны беләсең бит... Сиңа булыр колыны... Атны гына торгыз! Ята бит әле!

– Торыр, торыр! Ух! Бәхетең бар синең, – диде Рәхим, Шәрифулланың корсагына төртеп.

– Синең дә бүрең улады! – диде Шәрифулла. – Дурак та инде мин! Колынны вәгъдә ит инде, ә? Барысы да сезнең аркада, – диде Шәрифулла, Хәниягә йодрык белән янап.

– Ну, Шәрифулла! Атыңны терелттем бит! Синең рәхмәтең шушымы?

Бу хәлләрдән айнып килгән Хәния, үзенә генә хас тавышы белән чәчрәп чыкты:

– Син үзең! Агуны да син әйттең, атыңны да үзең җибәрәсең тышауламый-нитми! Тагы йодрык күрсәтеп тора! Күрсәтермен мин сиңа!

Күп тырыша торгач, ат торып, аякларына басты. Шәрифулла килеп, атының муенын кочаклап алды:

– Изге атым бит ул минем, ап-ак сөтем бит ул минем! – дип, төрле иркә сүзләр әйтергә тотынды.

Ат аягына басуга кешеләр дә таралышты. Тик бакча уртасында Хәния белән Шәрифулла гына кем гаепле икәнне ачыклап калдылар. Күрәсең, бу мәсьәлә тагы шул көе калачак. Чөнки аерылып киткәндә, Шәрифулла:

– Киртә тотыгыз! – дип кычкырды. Ә инде Хәния:

– Атың тагы бакчага керсә, икенче кат терелә алмас! – дип акырды.

Кич белән колынны алып китәргә дип кергән ат табибын Шәрифулла:

«Ришвәт дауламакчы буласың!» – дип оялтырга тырышса да, тегесе: «Шаһитләр алдында әйттең бит!» – дигәч кенә, колынны бирергә риза булды. Ләкин Шәрифулланы акылга утыртырга теләгән Рәхим генә әлегә колынны алмады.

– Көзгә калдырам, бәлки язга тай булгач бирерсең әле, сакла атларыңны, хәзер бәрәңге агулары хәтәр! – дип, Шәрифулланы бик сөендереп чыгып китте.

– Һәй, әле аңа кадәр, йә хан үлә, йә ишәк үлә, дигәндәй, – дип, Шәрифулла колынын кочаклап калды.

Ат чынлап та изгелеген тагы бер тапкыр исбатлады, дисәк, ялган дип уйламагыз тагы. Шушы хәлләрдән соң күп тә үтмәде, бөтен күк йөзен каплап, кап-кара болыт килде, дөнья караңгылыкка чумды, җил-давыл чыкты. Берничә минут эчендә шушы давыл күп кенә өйләрнең түбәләрен куптарып атты. Коймаларын аударды. Авыл буйлап такта, шифер, хәтта түбә калайлары каурый кебек кенә очып йөрде. Ул ауган агачларны санап та торасы юк! Хәтта олы кәүсәле карт алмагачларны да калдырмады давыл. Урман буйларындагы илле еллык наратларны да шырпы сындыргандай гына сындырып, аударып бетерде. Тик шунысы гаҗәп: бары тик Хәнияләр хуҗалыгына гына бер төрле дә зыян килмәгән иде. Хәния бер караганда үкенеп тә куйды. Чөнки ике тактасы купканнарга да 10 мең акча түләделәр. Ә инде Хәниягә анысы да тәтемәде. Ләкин койма корасы да, түбә ябасы да булмады аларга.

Шушы хәбәрне ишеткән Шәрифулла гына Хәнияне очратып:

– Менә белдеңме инде хәзер изге ат аунаган җиргә давыл да тимәгәнен! Рәхмәт әйт! Аппаккаем гына алып калды сезнең өегезне! Карап торсаң бит чәнти бармак белән дә аударырга була иде аны! Шуннан чамала инде. Атка рәхмәт әйт! Мин инде үземне кыстырмыйм, – диде Шәрифулла.

Бу тиклесен уйламаган Хәния сүзсез калды. Шәрифулланың сүзләренә дә ышанмаслык түгел иде шул. Авыл кешесе бик күп зыян күрде бу давылдан. Әллә ничаклы комиссия килеп, барысын да тикшереп тә йөрделәр әле. Ә инде Хәниянең йорты, ничек бар, шулай калды. Чөнки бирелгән акчага караганда, зыяны барыбер күбрәк иде давылның.

– И Шәрифуллакаем! Рәхмәтләр төшсен! Менә бит, изге ат җирдә ятса да, изгелек җирдә ятмый шул. Кабат бакчаны да агуламам, йөрсен атың үзе белеп. Бер дистә күкәй төшерермен әле үзенә. Башка бирердәй әйберем дә юк. Шуның белән бәхилләтермен атыңны. Эчертерсең чи көе туглап, атка файдалы, диләр.

Шәрифулла бу беркатлы Хәниянең чиксез юмартлыгына бераз сәерсенсә дә, үзе уйлап тапкан әкиятенә үзе дә ышанды.

Һәр көнне иртә белән тау итәгендә ике ат – берсе Аппагым, икенчесе инде аның тай булып өлгергән колыны утлыйлар. Бәлки, алар үзләре дә изгеләр нәселеннән икәнлекләрен беләләрдер. Чөнки кичкырын өйләренә кайтканда, алар ялларын җилдә җилфердәтеп, шундый горур атлыйлар, малкайларның матурлыгына сокланмаган кеше юк авылда!

Бәладән башаяк дип, Хәниянең ире дә бакчасына коймалар тотты. Шәрифулла да кичкә атын болынга җибәрми башлады. Болары кеше кулында, тик менә давыл гына булмасын! Анысы инде Алла кулында!



Фәйрүзә
Исмәгыйлева

# НИК ЯҢАРА ҖАНДА ШУШЫ МОҢ?

## Бу җырым

Бу җырым – илче ул. Яныңа
Җанымны илтүче сукмак ул.
Күзләреӊ нурында коенып,
Бусагаң төбендә туктар ул.

Иң рәхәт, ләззәтле тойгыдан
Күкләрем каршыңда тезләнер.
Хәрефләрмени бу? Йөрәкнең
Тәпиләп килүче эзләре.

Сөюдән тоткынга әйләнеп,
Мең кабат яныңа киленер.
Хисләрем күңлемне кол итәр,
Күңел ул – моң гаме иледер.

Һәр үлән, һәр яфрак, бөҗәккә
Серемне сөйлим дип бәйләнәм.
Бу мәлдә мин җирдә яшәмим –
Мин тоташ шигырьгә әйләнәм.

Бу җырым – илче ул. Җаныңа
Җанымны илтүче сукмак ул.
Ач күңел ишегең каерып –
Бусагаң төбендә туктар ул.

## Исәнме, шигырь!

Исән-саумы, Шигырь! Син, әйтерсең,
Өннән чыккан аю баласы.
Кышлар буе изрәп йокладың да,
Уяндыңмы, күзем карасы?!

---

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА (1963) – *шагыйрә; «Җанымда яз рәсеме» исемле китап авторы. Азнакай районында яши.*

Ниндиерәк төшләр күрдең, нинди
Уйлар белән чыктың кышыңнан?!
Боз-сөңгедән тамган тамчы сыман
Түгел әйдә каләм очыннан!

Йөрәк тибешемә кушыл, Шигырь!
Синең сәгать суккан, күрәсең.
Хуш киләсең! Күңелем аланына
Үзең хуҗа, үзең түрә син!

## Шагыйрь

Шәмдәлендә бии шәме,
Хисеннән балкый өй эче.
...Әзерли ул укучыдай
Аллаһ йөкләгән «өй эшен».

Язмыш диган көндәлеккә
Җан иңгәндә үк язылган.
...Тәүге кат шагыйрь сискәнә
Каурый алгач кыр казыннан!

...Йомшак... Үзе без күк очлы
Җанындагы серле каурый.
Шуңа шагыйрь мең терелә,
Шуңа шагыйрь мең авырый!

## Нинди моң бу?!

Нинди моң бу җанда?! Тоташ моң?!
Шушы моңнар җанны телгәндә,
Син, Фәрештәм, белсәң әгәр дә
Тәрҗемә кыл безнең телләргә?!

Ник яңара җанда шушы моң,
Очкан чакта күктә киекләр?!
Нинди моңда тирбәләсең, җан,
Җиде күктә чакта, биектә?!

Тамсын иде шул моң кәгазьгә –
И фәрештәм, каләмгә орын!
...Йөртәбездер күңел түрендә
Мәңгелекнең бер тирән моңын...

## Без уйлап чыгармаган

Юкка көям бугай кайчак,
Кайвакыт юкка сынам.
Гел-гел зарланып яшәүләр
Дөрес үк булмас сыман.

Егерме бердән – ачлыктан
Әбкәем дәшәр кебек.
– Кызым, икмәгең мул икән,
Әз генә бирче телеп.

Кырык бердән дәшәр әткәй –
–Ниләр бар ил күгендә?!
– Зарланмыйм, әткәем, шөкер,
Тыныч әле бүгенгә.

Йә, әйтегез, кайсы чор соң
Яшьләргә чыланмаган?!
...Нишлисең бит, бу дөньяны
Без уйлап чыгармаган...

## Гайбәт саттым

Бер тәэсиргә бирелдем дә
Кушылып гайбәт саттым.
Имеш, син тегенди-мондый,
Ә мин менә, һай, акмын.

Күзгә карап түгел, арттан
Сөйлим. Димәк, мин куркак?!
Авыр кургаш булып җанга
Уелып калды шул тап.

Балкып биргән сәламеңә
Башны түбән идем мин.
Үз койрыгын артка кыскан
Көчек сыман идем мин.

Сизми дә калдым – бер мәлдә
Шайтанга җаным саттым.
Инде менә тәүбә кылам –
Сүздә, уйларда сакмын.

Кеше түбәнсетеп, үзең
Өстен булалмау – хактыр.
Эретче авыр кургашны –
Сыенам сиңа, Яктым.

## Кешеләр

Кешеләрне күзләп йөримен мин,
Беренче кат күргән шикелле.
Һәрбер кеше матур бит үзенчә,
Һәм үзенчә генә сөйкемле!

Һәрбер җанда, әйтерсең лә, гүя,
Бай тарихлы гаҗәп Идел бар.
Күл төбендә яткан асылташ күк
Һәр күңелдә нидер, нидер бар!

Күпме кеше җирдән атлап узса,
Шуның хәтле язмыш агыла.
...Күңел күзең сау-сәламәт булса,
Һәр күңелдән җәүһәр табыла!

## Җирдәшем

Балачакта офык якын бик –
Җәяүләп җитәр кебек идем.
Шулчакларда Җир белән Күкнең
Серләрен чишәр кебек идем.

Хыялый булыймчы тагы бер –
«Офык якын», – диген. Ышаныйм!
Чиксезлекне иңләп куансын
Олы җанлы нәни кочагым!

Беркатлы, самими булыймчы,
Ни дә булса әйтеп алдале.
Күңелләрне син маҗаралы
Әкиятләр белән ялгале.

Бу мизгелдә син дә сабый бул –
Ихласыңнан ташы, түгел дә!
Алсуланып калыр дөньялар,
Биегәеп китәр күгең дә!

## Авылымда печән чоры

Шушы чорда күңел нечкәрә –
Авылымда печән чоры бит.
Кыңгыраулар зеңләп авалар –
Болыннарда чалгы чыңы бит.

Әй, саумы сез, чатырлар ясап,
Печән саклап кунган болыннар!
...Күптән инде эш атлары булган
Бездәй чабып йөргән колыннар...

Үзебез дә бүтән инде без –
Аһ, бу гомерләрнең үтүе!
...Йөрәк тибешенә кушылган
Әткәйләрнең чалгы чүкүе!

Бер моң булып күчкән күңелгә
Үлән шавы, кошлар тавышы.
...Ат күзенә сеңгән мәңгегә
Ул чакларның якты сагышы!

Йә килегез, ут тергезик бер,
Йолдыз алыйк әле күкләрдән!
Кайтавазы булып яшьлекнең
Балкып янсын әле үткәннәр!

***

*Алдагысын Аллаһ белә…*
Әбием сүзләре

Язмышым рәсемен ясадым,
Киндерен алдым да хыялның.
Алдагы көннең һәр мизгелен
Иң ачык төсләргә буядым.

Куйдым да тәрәзә төбемә,
Тынычлап йөрдем мин. Ә рәсем
Чыланган яңгырга. Җил белән
Ачылып киткән дә тәрәзем.

Буяулар томанлы – кушылган.
Тапланган ап-ачык рәсемем.
Моннан соң ясамас булдым мин
Туачак көннәрем рәсемен...

## Хушлашу

Килешәсеңме син дә – хушлашу җиңел түгел.
Ефәк тукыма кебек сыпылып китте күңел.
Кавышулар булган күк хушлашу да табигый.
Теләсәк тә, үзгәртеп булмый тормыш агымын.
Тик, белсәң, сыкрый күңел, бу халәт сиңа таныш.
Көн күк өмет балкыса, төн булып ойый сагыш.

## Минем үлем

Минем үлем –
Вальска чакырган егет сыман
Күзләремә карап тезләнер.
Мин сузармын кулым – сизмәм дә
Соңгы сулышымны өзгәнен.

Күзгә-күз төбәлгән көенчә
Иңләрбез Күкләрнең һәр катын.
Күкләр аһәңенә кушылыр
Җиремдә яшәүнең зур хакы.

Ә тантаналы бал сәгатен
Галиҗәнап Вакыт билгеләр.
Каршыларммын Олуг бәйрәмне –
Мәгълүм булыр барча билгеләр.

Минем Үлем җанны кайтарыр:
Танышсыңмы, Йортың бу, дияр.
Бармак очларымнан хушлашып,
Нәзакәтле итеп баш ияр.

Дулкынланып, ошбу «кунакка»
Ачкан чакта Йортым ишеген
Минем Үлем бәлки пышылдар:
«Фәрештәләр сине кичерер!»

«Бакыйлыкның иркен чиксезлеге!
Саумы, Йортым!» – дип кабатлармын.
Балкып, талпыныр сөенечтән
Җанның өрфия канатлары!

*Казакъстанның күренекле шагыйре, Абай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Казакъстан Язучылар оешмасының 1980 еллардагы җитәкчеләренең берсе Сырбай ага Казанга еш килә иде. Ул елларда аның шигырьләрен безнең аксакал шагыйрьләребездән Нури Арслан, Зәки Нури, Мәхмүт Хөсәен тәрҗемә итте. Шагыйрь 1922 елда туган, сугышта катнашкан. Яшьлегенең бер өлеше Кустанай шәһәрендә үткән, ул анда казакъ-татар мәктәбендә укыган. Шунлыктан аның иҗатында татарлык аһәңе дә чамалана, дип әйтә иде Нури ага Арслан.*

*1972 елда авторның очерк һәм юлъязмалар китабы басылып чыга. 1974 тә Алма-Атада булганда, мин ул китапны алып кайттым. Бакча күршем Нури абый аны укып чыккач та: «Бу китапка кергән «Җырлы Казан» әсәрен тәрҗемә ит, безнең укучыларга ошар ул», – диде. Аның киңәшен дә истә тотып, бу истәлек әсәрен укучыларга тәкъдим итәм.*

*Кереш сүз авторы һәм казакъчадан тәрҗемә итүче –*
**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**



Сырбай
Мәүләнов

## ҖЫРЛЫ КАЗАН

***(Бер сәфәр тарихы)***

Уфадан очкан самолёт бер сәгать үтәр-үтмәстән түбән төшә башлады. Стюардесса кыз самолётның Казанга килеп җитүен белдерде. Шәһәр өстен болыт каплаган, яңгыр ява иде. Аның энҗедәй эре-эре тамчылары асфальтка шыбыр-шыбыр итеп килеп төшә дә як-якка чәчрәп китә. Инде июнь ае башлануга карамастан, соры, төксе күк куенында әле кыш салкыны саклана кебек. Тәнгә тиеп киткән яңгыр тамчылары да сискәндереп җибәрә. Әйтерсең, әле күктә кар бураннары дулый да, шушы суык яңгыр тамчысы аның илчесе буларак, җиргә төшә иде.

– Өфедә көн аяз, кояшлы иде. Казан безне суык яңгыры белән каршы алды, – дип, бераз көлемсерәп әйтеп куйды безнең белән бер самолётта кайткан татар язучысы Гариф Гобәй.

Бу кеше инде алтмыштан узган. Шулай да аңа карап, һич кенә дә алай димәссең. Гомумән, ул барлык хәрәкәт-торышы белән бик ыспай, җитез абзый икән. Өстәвенә, әле бик-бик оста җырчы да. Башкорт язучыларының

мәҗлесләрендә бергә булганда, миңа аның шул күркәм сыйфаты да ачылды. Гариф абзыйның болытсыз аяз көндәгедәй саф тавыш белән җырлавы мине генә соклandырмады. Аның башкаруында «Нурия», «Гөлмәрфуга», «Галиябану»ларны тыңлаганда, хыялымда сылу-сылу кызлар күз алдыма килеп баскандай булды.

Мин, олы язучының әле генә әйткән сүзләрен яхшыга юрап:

– Җангыр җауса, җиргә көч-куәт өстәлер. Татарлар әйтмешли, укабыз коелмас, – дидем.

Шул арада сүзгә татарның иң өлкән шагыйре Хәсән Туфан да кушылды.

– Сез, кардәшләр, хәзер Тукай, Такташларның җылы җиренә аяк бастыгыз, – диде ул.

Күреп-белгән татар язучыларыннан безгә аеруча танышы шушы Хәсән акын иде. Чөнки ул безнең Кустанайда да, Алма-Атабызда да булган кеше. Дөрес, башкалабызга алар ишле бер төркем булып килгәннәр иде. Әмма иң хәтердә калганы, иң үзенчәлекле язмышлысы – шушы Хәсән ага иде.

Әйе, аңа чаклы бу шәһәрдә Тукай, Такташ яшәгән, шушында алар иҗат иткән. Бу исемнәр бала чагыбыздан ук безнең күңелләребезгә сеңгән, якын. Алар, әйтерсең, һәрчак минем янәшәмдә генә йөргәннәр. Әйтерсең, япан кырда безнең белән бергә атта чабышкан, кыр-далада бергә төн кунган, җыен-мәҗлесләребездә бергә утырганнар. Алар әйткән тапкыр сүзләр һәрчак күңел түрендә калкып чыккалар иде.

– Сез искә алган остазларны да хөрмәтләп, баш ияргә дип, бирегә килүем, – дидем мин, Хәсән ага Туфан белән күрешкәч.

Ул минем сүзләремне уңай кабул иткәннән соң тагын өстәп куйды:

– Тукай, Такташ – безнең шигърияtebезнең иң бөек шәхесләре, президентлары, – диде.

Шушы күрешү, сөйләшүдән соң көн дә бераз үзгәргән кебек булды. Алда безне Тукай, Такташлар көй-моңына төрелгән серле Казан, нурлы Казан көтә иде. Казан каласы казакъ халкының зыялы катламына элек-электән якын, мәгълүм кала. Алар аша аның исеме барлык дала кешесенә дә ирештерелгән. Казан төбәгеннән чыккан татарны далада белмәгән кеше юктыр. Борын-борын заманнардан бирле бу ике халык вәкилләре еш кына кан-кардәш буларак та яшиләр. Ә Казан шәһәре нәшриятларында минем милләтемнең беренче китаплары нәшер ителгән. Шуннан илгә таратылган. Димәк, бу шәһәр минем халкымның аңы, фикере үсешенә дә житди генә булышлык иткән кала. Хәер, татарның элгәрерәк чыккан үз әдәбияты да казакъ җирләренә, казакъ иле буйлап таралган мәктәп-мәдрәсәләргә күпләп китерелгән, укылган. Бу хәл исә бик борынгы чорда ук татарлар арасында аек фикерле һәм укымышлы кешеләрнең ишле булганлыгы белән аңлатыладыр. Элек-электән үк бит Казанның үзендә генә дә ике обсерватория, танылган уку йорты, китапханәләр булган. Унтугызынчы гасыр ахырларында монда татар телендә беренче романнар иҗат ителгән. Газета-журналлар нәшер ителгән.

Бүген без менә шул атаклы Казан каласы туфрагына аяк басабыз.

Монда мине тагын да рухландырганы – биредә бөек Ленинның үзе йөргән булуы! Ленинның аяк эзләре сакланган җир бит бу! Һичшиксез,

шушы изге җиргә аяк басу, ул даһи кеше сулаган һаваны сулау һәркем өчен изге теләк, асыл максаттыр.

Менә без Казан университеты каршында... Университет бинасы алдында унҗиде яшьлек Владимир Ульяновның һәйкәл-сыны басып тора. Әйтерсең лә, аның үз ишләре арасында атлый-йөгерә университетка килеше. Бинаның икенче катында Ленинга багышланган класс-музей. Бу аудитория нәкъ Володя Ульянов укыган вакыттагыча итеп сакланган. Ул утырган парта... Яшь Ленинның куллары тигән китаплар... Болар һәркем өчен иң кадерле әйбердер.

Шушы университетта уку чорында инде Ленин, моңарчы яшәп килгән иҗтимагый мохитне үзгәртеп корырга ниятләгән революцион яшьләр белән якынаеп, тәгаен марксист булып җитлегә дә. Шушында ул революцион көрәш юлына баса. Соңрак шушында әйткән ялкынлы революцион сүзләре өчен укудан чыгарыла һәм, кулга алынып, беренче мәртәбә сөргенгә җибәрелә.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: заманында Казан университетында атаклы язучы Лев Толстой, исеме-аты күпләргә таныш композитор Милий Балакирев, олы галим, үзенчәлекле математик Николай Лобачевский һәм башка бик күп талант ияләре укыган.

Университеттан ерак түгел – Ирек мәйданы. Мәйдан уртасында – Владимир Ильичның тагын бер һәйкәле. Казанлылар өчен ул да бик кадерле. Бу һәйкәл яныннан көннең-көне буе халык өзелми. Әледән-әле аңа үсмер балалар килеп баш ия. Мәктәп балаларын шунда – Ленин бабалары каршында зур тантана белән пионерга кабул итү чарасы уздырыла...

Биредән инде без пролетариат әдәбиятына нигез салган Максим Горькийның яшь чагында хезмәт иткән пекарнясына юнәләбез. Бу музей-йортның подвал өлешендә он тутырылган дәү-дәү капчыклар өеме. Яшүсмер Горький шул авыр капчыкларны иңнәрендә ташып көн күргән. Адәм ышанмаслык газапларны, авырлыкларны кичергән. Шул ук вакытта аны Казан пристанендә көнлекче грузчик буларак та еш күргәннәр. Әйе, Казан – аны, корыч эшкәрткән мартен мичедәй сугып-сугарып, киләчәк өчен, алдагы олы көрәш өчен чыныктырган кала. Шуңа күрә Алексей Максимович үзе дә «физик яктан Түбән Новгородта туган булсам, рухи яктан Казанда туганмын», дип язган. «Тормыш университетлары арасында Казан минем өчен иң кадерлесе», – дип тә тикмәгә генә әйтмәгәндер.

Узган гасырда Горький күреп белгән ярлы Татарстан җире бүген илдә иң алгы сафларда атлый. Татарстан бүгенге көндә җир куенынннан нефть табу һәм чыгару осталыгы белән күп кенә ил-төбәкләрдән өстен тора. Теләсә кайсы ил-төбәкне ярышка чакыра ала. Безнең ил күләмендә җитештерелгән кыйммәтле җир маеның шактый күп өлешен хәзер Татарстан бирә. Кайчандыр фәкыйрь саналган татар иленең «кара алтын» хәзинәсе бүген илебездән чит дәүләтләргә дә чыгарыла. Ул илләрнең хаҗәт-ихтыяҗларын канәгатьләндереп тора. Җир куенынннан нефть кудыручы корыч манаралар инде хәзер Кама елгасы үзәнен дә чолгап алган. Элек алар җир маен чыгаручы үзәк саналган Әлмәт шәһәре тирәләрендә генә булганнар. Әлмәт каласы исемен ишетеп белмәгән кеше, мөгаен, дөньяда

юктыр. Тирән җир куеныннан ургылып аккан «кара алтын» ташкыннары да, кыр-басуларны тутырып дулкынланган иген сабаклары да, яңа калыккан шәһәр урамнарындагы яшь тирәк яфрагының шавы да бүгенге Татарстан табигатенә хас күренеш.

М.Горький 1886-1887 елларда хезмәт иткән пекарня урынындагы музей да артта калды. Алдыбызда ак таштан төзелгән Казан Кремле биналары. Кремль капкасы чатындарак шагыйрь Муса Җәлилгә куелган һәйкәл тора. Бу сын-пәһлеванның кул-аяклары богаулы. Шулай да ул ярсу юлбарыстай алга, көрәшкә омтылган сыман, алгарак талпынган. Ул сын кыю һәм мактаулы көрәш юлын узган Мусаның нәкъ үзе. Биредә Муса Җәлил ярым ялангач, ялан аяк килеш ташка басып, бар торышы белән алга, киләчәккә омтылган. Аның үткен карашында өмет, җиңәчәгенә ышаныч нурлары чагыла төсле.

Муса Җәлил! Аның исеме хәзер ирек сөюче барлык илләрнең халыклары теленнән төшми. Хыялга тиң шәхес ул хәзер. Богаулы Мусаны күрү белән минем күз алдыма Волховның баткак урманнары, ничәмә айлар буена канлы бәрелеш кырына әверелгән Синявино калкулыклары, өсләренә тоташ ут-ядрә явып торудан хәрабә хәленә килгән шыксыз бистә-авыллар килеп басты. Шушы Волхов тирәлеге сазлыкларында бит инде 1942 елның җәй башында якында шартлаган снарядның һава дулкыны бәреп егып исәнгерәткән һәм каты яралаган мизгелдә көчсез-хәлсез шагыйрьне фашистлар камап алган, әсир иткән. Муса Җәлилнең соңгы пулясын үзенә атарга ниятләве, әмма пистолетының атмый калуын тасвирлаган үкенечле шигырен мин күптән казакъ теленә тәрҗемә иткән идем инде. Шунлыктан аның сугышып үткән җире Волхов тирәсе икәнлеге дә, ничек әсирлеккә төшүе дә миңа күптән билгеле иде. Ә инде Волхов фронтының, Волхов сазламыкларының ул көннәрдәге хәлен мин үз күзем белән дә күрдем. Кабат оештырылган Икенче Удар армия сафларында шунда ук без дә сугыштык. Шуңа күрә Муса Җәлил миңа аеруча якын тоела.

Ир йөрәкле шагыйрьне ил онытмады. Аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Шул ук көннәрдә аның кайнар каны белән язылган каһарманлык җыр-дастаны – «Моабит дәфтәре» җыентыгы илебездә иң яхшы әдәбият-сәнгать әсәрләренә бирелә торган иң югары бүләккә – Ленин премиясенә лаек булды. Ул китаптагы шигырьләр бүген дөньядагы барлык телләргә тәрҗемә ителгән.

Муса Җәлил һәм аның иҗаты хакында Азәрбайҗанның танылган шагыйре, совет поэзиясенең иң күренекле вәкилләреннән берсе саналган Самед Вургун элегрәк болай дип язып чыккан иде: «Бөтен дөнья һәм шул дөнья йөзендәге әдәбият исемнәре иҗатларының мәңгелек данына әверелгән күп кенә шагыйрьләрне белә. Ләкин шагыйрь һәм Герой Муса Җәлил кебек шигырь белән генә түгел, бәлки үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр бик аз. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең данлыклы халык шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил».

Муса Җәлилнең үзенә атап язылган шигырь һәм җырлар, дастаннар хәзер бик күп. Шулар арасында казакъ шагыйре Җубан Молдагалиев, татар шагыйре Нәби Дәүли поэмалары да герой шагыйрьнең батырлык,

фидакарьлегенә бер хатирә булып тора. Муса Җәлилнең үз шигырьләрен телдән-телгә тәрҗемә итүче һәм аны төрле телдә укучылар саны да елдан-ел арта бара.

...Без Кремльне, аның үзәгендә иркен җиһан киңлегенә үрелеп утырган мәһабәт Сөембикә манарасын карап, йөреп чыгабыз да Казан каласының кыл уртасында урнашкан Кабан күленә таба юл алабыз. Кабан күле янәшәсендәге бер бакчада, биеккә калкып, Тукай һәйкәле тора. Берзаман аны, сабый чагында, шушыннан ерак булмаган печән базарына китереп: «Асрамага бала бирәм! Кем ала?» дип тәкъдим иткән булалар. Кулдан-кулга күчеп йөргән ятим бала – бүген бөтен бер милләт хөрмәтенә лаек дан иясе. Шул халыкның сөеклесе, киңәшче-әүлиясе. Бүген ул үз югарылыгыннан җитди генә алга карап, уйланып тора... Кабер ташына шагыйрьнең шигъри юллары сырланган:

«Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә».

Егерме җиде яше тулмаган шагыйрьнең никадәр рухи көчкә ия булуын күрсәңче!

Кабан күле – каланың, әйтерсең, якты, зәңгәр күзе. «Казан вә Кабан арты» шигырендә Тукай менә ни ди бит аның хакында:

«Кай заманда, кайсы телдә искә алынса да Казан,
Искә керми калмый һич тә шундагы бер күл – Кабан.
Бу шәһәрне һәм бу күлне җырлыйдыр милләт теле
Бик яратып, әллә инде иске шөһрәт аркылы!»

Бу күл янәшәсендә моң-җырларын уйланып, Тукай күпме йөргәндер?! Һәм ничәмә-ничә яшь йөрәк шул күл буенда бер-берләрен табышып, йолдызлы күк гөмбәзе чатырына сыенып серләшкән, алтын айны моңа шаһит иткәндер... Шулай да, Кабан күле, бер карасаң, тынып калган күз яшедәй шул син...

Идел... Кабарган тамыр кебек ул, ничәмә-ничә порт-шәһәрне берләштергән зур су юлы. Ул үзенең аксыл төстәге пароходлары, пароходларында җилфердәгән ялау-флаглары белән күңелне үзенә әйдәп тора. Казан елга порты... Аның зур тәрәзәләре аша киң Идел тагын да матураеп, алланып күренә. Аргы як ярдагы Ослан таулары шул ил иркәсе Иделне саклап, каравыллап торадыр шикелле. Яр-кыяга тын гына бәрелгәләп, тын гына агып яткан Иделне һәрберебез Җир шарына бөек Ленинны биргәне өчен генә дә олыларга, күңелләребездә аңа карата йолдыздай якты хис сакларга тиешбез...

Казан елга порты – ул чын хезмәт мәйданы. Пассажирлар яисә йөкләр төягән бихисап пароходлар, баржалар бирегә килә тора. Икенчеләре исә моннан ерак юлларга китә торалар. Советлар иленең бу зур су юлы боларның барысын да үз күкрәгендә күтәрә, кирәк җиренә илтеп тапшыра. Кайчандыр Николай Некрасов җырларында телгә алынган бурлакларның оныклары бүген шул ук Идел киңлегендә зур-зур корабларны йөртә. Диңгез

кебек Идел дулкыннары аларны җай гына чайкалдыра. Ул дулкыннар бүген Стенька Разин бәетен генә түгел, зур Иделнең үзенә, аның хезмәтенә багышланган тантаналы гимннарны да тыңлыйлар.

Казан елга портыннан Ленинградка, Мәскәүгә, Куйбышев һәм Горький шәһәрләренә, тагын бик күп порт-калаларга барырга мөмкин. Зур Идел Совет Татарстанының башкаласын ерак-ерак җир, төбәкләр белән тоташтыра.

Иркен Идел өстендә җил уйный, тирә-юньгә көмеш тәңкә-күбекләр чәчә. Аларга алданган акчарлаклар шаулап, канат җәеп, биектән түбәнгә ургыла да, өметләрен өзеп, чаң-чоң килеп, читкә талпыналар. Ә су өстендә йөзгән каек-көймәләр, дәү-дәү кораблар артыннан дулкын эзләре кала. Ә аргы якта, суга мул Идел ярларында яшел постау кебек тоташ чирәм, яшеллек күренә. Шәһәр халкы үзенең ял көннәрен шул чирәмлектә аунап, үтеп баручы пароходлар артыннан күтәрелгән юаш дулкыннарга чумып уздырырга тырыша.

Ә ялланган катер белән Идел өстен гизеп йөрүе нинди рәхәт! Дулкын сине бер күтәрә, шул чакта синең уй-хыялларың да биеккә-биеккә ашкан төсле була. Икенче мизгелдә син үзеңне як-ягыңдагы су упкынына чүккәндәй хис итәсең. Катер шулай дулкыннар өстендә уйнаган кебек синең хисләр дә уйнап тора. Сәяхәткә дип, татар дусларыбыз алып чыккан катерда без, Казакъстан вәкилләре, икәү. Нургоҗа Уразов – безнең язучылар оешмасының Целиноград өлкәсе җитәкчесе. Нургоҗа чәчмә әсәрләр дә яза, шигырь дә.

Татар каләмдәшләребездән кемдер тальян гармунда уйный. Аның көенә Идел дулкыннары тагын да җәһәтрәк тирбәнәләр шикелле.

«Туган яктан ерак китеп,
Диңгезләр кичтем.
Сагыш дигән тирән күлнең
Суларын эчтем.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Тальян гармун моңы булып,
Җырыма күчтең...»

Нургоҗаны да җырга кушылырга өндәсәк тә, ул дәшмәде. Ә мин үзем татар җырларын бик якын күрәм. Үзебезнең Тургай каласында без Габдулла, Гыймади атлы татарлар белән күрше идек. Яшь чакта бергәләп, якындагы үр-тауларга иртә язда кыр суганы, соңрак дала чәчәкләрен җыярга йөри идек. Ул төркемдә күпчелеге татар егетләре белән татар кызлары була иде. Билгеле, егетләрнең берәрсе гармун ала. Кыр-далага чыгуга аны чыңлатып уйнап та җибәрә. Егет һәм кызлар аңа кушылып җырлый башларлар иде. Билгеле инде, күпчелек очракта моңлы-сагышлы татар көйләре уйналып, татар җырлары җырланыр иде... Шул чактагы күңел җилкенүләре, яшь йөрәкнең ашкынып тибүләре онытыламы соң?!

Безнең катер Идел дулкыннары өстендә чайкала-чайкала, алга бара. Ә безнең күмәк җыр, җилпү канатлы акчарлактай, ераклардан урап килеп, кабат баш очында яңгырый башлый:

«Таныш түгел юллар буйлап
Мин озак йөрдем.
Туган ягым күренерме дип,
Тауларга мендем».

– Әйт шуны! – дим мин җырны куәтләп, күңелем булып. Җыр тагын үз-үзенә көч-дәрт өстәгәндәй яңгырый төшә.

«Туган яктан еракта да
Мин дуслар таптым.
Ләкин яшьлек дустым калган
Илемә кайттым».

– Бу җырның авторы шагыйрә Гөлшат ханым Зәйнашева була инде, – диделәр татар юлдашлар.

Күрәмсез, татар сүзләре безгә никадәр якын. Казакъ халкының «Татарга тылмач кирәкми» дип әйткән бик борынгы мәкале бар. Бу мәкаль безнең ике кардәш халыкның бик күптәннән килгән дуслыгы, якынлыгына ишарәдер.

Төштән соң без, катерны елга ярында калдырып, җыйнаулашып, яр буендагы урманга кереп киттек. Каен белән карагай агачлары катнаш куе урман безне үз кочагына алды. Тар гына үзән сукмагы буйлап, без яр буеннан арырак почмакка юнәлдек. Урман һавасы сөзеп тондырылгандай саф, җиңел. Суларга бик рәхәт иде. Агачлардан искитмәле тәмле ис аңкып тора. Ул ак каеннар, карагай-наратлар арасында кичкә кадәр йөрдек. Әңгәмәбез исә гел әдәбият тирәсендә, Тукай, Такташ, Җәлилләр хакында булды. Кайбер татар каләмдәшләр белән ул шагыйрьләрнең истә калган аерым шигырьләрен ярыша-ярыша искә төшердек. Шулай гәпләшеп йөргән арада көн дә узып китте. Кич якынлашты. Бер мәлне мин:

«Җиктереп пар ат Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер суккалап та тарткалап»,

– дип, Тукай абыебыз әйткәндәй, әйдәгез, Казанга карап, җол тартаек, – дидем.

Катерга утырып кайтырга чыккач та, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимовларның язмыш – гомерләренә кагылышлы сөйләшүләр дәвам итте.

– Галиәсгар Камал белән Такташ икәве шәһәрнең Горький исемендәге ял паркында җирләнмеш икән. Анда барып, каберләрен зиярәт кылдым. Такташ баш очындагы кабер ташына кемдер язып киткән бер куплет шигырьне күчереп алдым, – дип, мин татар дусларыма блокнотымны ачып күрсәттем.

«Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була».

Шул арада без янә Казанның елга портына кайтып төштек. Тамак ялгап алу өчен Идел уртасында дулкынга чайкалып утырган «Җилкән» ресторанына керергә ниятләдек. Эчкерсез сөйләшү бередә дә өзелмәде. Әүвәл бер көлешеп алдык. Татар каләмдәшебез Мәхмүт Хөсәен Нургоҗаның балыкны чәнечкегә чәнчеп алырга азапланганын күреп:

– Тавык, балык, каз ишеләрне кул белән устауга кирәк, – дип көлдерде.

Шуннан соң гына Нургоҗа балык башына ике куллап ябышты. Аннары Ренат Еникиев сүз алып, казакъ шагыйре Таһир Жароковның «Каргиго» исемле шигырен татарчалап укыды. Сүзгә татар әдибе, безнең якташыбыз Нури Арслан да кушылды. Ул казакъ шагыйре Җакан Сыздыковның хәл-әхвәлен сорашты да:

–Тукай иҗатын үз итеп, бик яратып, бик күп шигырьләрен тәрҗемә иткән акын бит ул, –дип әйтте.

Әйтергә кирәк, Нури Арслан да – бик мөхтәрәм шагыйрь. Казакъ шигъриятенә дә әһәмият бирә. Өстәвенә, исеме дә җисеменә туры килеп тора. Нури – нурлы йөзле, мөлаем кеше. Ә чал кергән чәчләре чын арыслан ялларыдай кабарып, җилкәсенә үк төшеп тора. Ул чәчнең үзендә бер кодрәти-илаһи көч яшеренгән сыман. Һәм шундый чәчнең әйткәнгә күнеп, сыпырганга сыпырылып, чын ял булып ятуына мин хәйран калып утырдым.

Алда әйткәнемчә, Тукайның язмыш-гомере белән дә, шигырьләре белән дә яхшы ук танышмын. Шагыйрьнең үз истәлекләрен дә, икенче бер шагыйрь – Әхмәт Фәйзинең аңа багышланган күләмле әсәрен дә укыганмын. Чөнки минем өчен Тукай – иң олы шагыйрь, остаз. Казанга килү белән иң элек Тукай зиратын барып күрдем. Нури Арслановка шул хакта сөйләдем. Ул миңа җавап итеп:

– Без дә казакъ әдәбияты белән яхшы танышбыз, – диде.

– Шулай булмый ни, татар әдипләренең күбесе өчен Казакъстан – уртак ватан, – дидем мин, Нури Арсланов сүзләрен куәтләп. – Тукай да безнең Уральскида үсә, шунда беренче шигырьләрен яза башлый, шунда шагыйрь булып җитлегә. Соңрак та, авырып киткәч, янә безнең Кустанай өлкәсенең Карабалык районына килгән. Казакь казаныннан тәгам итеп, дәвага казакъ кымызын эчкән. Безнең нәселле атларда дала буйлап йөргән, гой. Татарның икенче бер танылган язучысы Кави Нәҗми, шулай ук безнең Кустанайда булып, Сәрвәрхан атлы сылу кызыбызны алып киткән.

– Анысы хак, – дип көлде Нури Арсланов. – Сәрвәр ханым бүгенге көнгә кадәр Кустанай казакълары җырын онытмыйча җырлый әле.

Ябырылып, Идел суыдай кара-соры төстәге төн килде. Идел җиле салмак-сабыр гына төнге эшенә кереште. Ресторан түбәсе аша күк йөзе күренмәсә дә, тирә-яктагы мөлдерәмә су өстенә ул күк барча йолдызының нурын чәчә иде. Бөрчек-бөрчек йолдыз сибелгән төнге Иделгә карап сокланып утыру үзе бер рәхәт тамаша икән! Бередән Казан каласы үзе дә, хәйран энҗе муенсаларын таккан татарның бер сылуы кебек, матур булып күренә иде. Шәһәр өстендә, күктән асып куелганнар, диярсең, биек-биек төзелеш краннары күренеше... Каланың төрле төбәкләреннән, яңа чор Алып батырларының сулышы кебек хезмәт итүчеләр гөрелтесе ишетелеп тора иде.

Без «Җилкән»не калдырып, калага юнәлдек. Кая карама төзелеш, өем-өем актарылган җир-туфрак иде.

– Казаныбыз Алып батыр адымы белән алга баручы баһадирларның берсе шул, – диде Нури Арсланов горурланып. – Бер ара күрми торсаң, шәһәрдәге үзгәрешкә хәйран каласың. Кайчан гына эшкә яраксыз саналып буш яткан урыннарда хәзер өр-яңа кварталлар калкып чыкты. Шәһәр картасы да, елдан-ел чыга торган төрле «Сәяхәтнамә»ләр дә әлеге үзгәрешләр артыннан өлгерә алмыйлар.

– Бөтен илебез шулай, барлык кала-шәһәрләребез шундый үзгәреш чоры кичерә гой, – дип, мин ирексездән татарның өлкән шагыйренең сүзләрен бүлдердем.

Нури Арсланов безнең яктагы үзгәрешләрне дә күреп белә икән.

– Хак әйтәсең, – диде. – Элегрәк мин белгән Иртеш елгасы яклары да нык үзгәргән хәзер. Берничә ел элек шунда барып чыккан идем. Павлодарны танымадым. Биек-биек йортлар калкып утыра. Зур-зур куәтле заводлар, очкын чәчеп, гөрләтеп эшлиләр...

Казан-Мәскәү вакыты буенча сәгать кичке унга якынлашкан иде. Мин, Нури Арсланов белән саубуллашып, «Таң» кунакханәсе янында машинадан төшеп калдым. Өч сәгатьтән минем юлга чыгасым – Ленинград – Алма-Ата самолётына утырып китәсем бар. Шәһәр уртасындагы аэропортка ул самолёт бик аз вакытка гына туктала. Кунак йорты хезмәткәрләре белән исәп-хисапны өздем дә Гариф Гобәй абзыйларга юнәлдем. Казанда миңа юлдашчылык һәм җитәкчелек кылып, бик күп нәрсә белән таныштырган, аралаштырган ул яхшы кешегә рәхмәт әйтеп саубуллашмый китүем егетлеккә саналмас дидем.

– Ничек соң, ошадымы Казан? Безгә рәнҗемичә генә Алма-Атаңа китеп баруыңмы? – дип сорашты әүвәл Гариф абзый.

– Рәхмәт инде барысы өчен дә, барыгызга да, – дидем мин. – Аеруча җиңгәй белән Сез күп хөрмәт күрсәттегез. Рәхмәт!

– Ул кадәр рәхмәтләр әйтерлек без нишләдек?! – диде җиңги аптыраган сымак бер гадилек белән, үз күреп, якын итеп.

– Ачык йөзегез, җаксы сүзегез безнең өчен бик җиткән, – дидем.

Озата чыккан Гариф абзый машинага ук утырды. Төнге Казанның үзәк урамнарыннан чабып үтеп, без аэропортка да килеп җиттек. Инде Казан өстендәге коңгырт күктә таң билгеләре шәйләнә иде.

Озакламыйча мин көткән самолёт та килеп җитте. Аның биек баскычына күтәрелгәч, мин төн юрганына төренеп яткан Казанны тагын бер кат күздән кичердем дә:

– Киләчәктә күрешкәнгәчә хуш, Казан! – дип, кул болгадым.

*Алма-Ата, 1972 ел.*

# ТЕЛ – МӘДӘНИЯТНЕҢ ТАҖЫ, СҮЗЛЕК ИСӘ – ТЕЛНЕҢ ТАҖЫ

***(Алты томлы аңлатмалы сүзлек басылып чыгу уңаеннан)***

*Сүзлек – сүзләр урманы,*
*Урманы-чытырманы,*
*Китапның гомер буе*
*Һаман укый торганы!*
Шәүкәт Галиев

Язмачылык традициясе булган төрки халыкларның сүзлекчелек эше шактый күптәннән югары үсеш алган дисәк тә, ялгыш булмас. Моңа мисал итеп, Мәхмүд Кашгарыйның XI гасырда төзелгән «Диваны лөгать әт-төрк» хезмәтен китерергә мөмкин. Анда хәзерге төрки халыкларның күбесе өчен уртак булган сүзләр байлыгы туплап калдырылган. Шулай да барлык төркиләрнең лексикографиясенең үсеш юлларын карау гаять күп вакыт һәм урын сорау сәбәпле, әлеге күзәтүебездә татар теле материалын яктыртуны максат итеп куйдык.

Узган гасырның беренче яртысында төрки телләрнең күбесе берничә тапкыр алфавитларын алыштырды. Язмачылыгы булмаган кайбер төрки телләр XX гасыр башында гына үз графикасын булдыруга иреште. Болар, башлыча, Себер һәм Ерак Көнчыгыш кече халыклары телләре иде. Шул ук чорда төрки халыкларның күп өлеше диярлек Советлар Союзы чикләрендә калды. Аларның һәммәсе кириллицага нигезләнгән язудан файдалана башлады һәм рус телен үзләштерде. Күпчелек төрки телләрнең элекке һәм хәзерге торышы арасындагы шартлы аерманы без нәкъ менә шушы чорда, ягъни XX гасырның беренче чирегендә күрәбез.

Сугыштан соңгы еллар күп кенә төрки телләрне, шул исәптән аларның гамәли лексикографиясен дә фәнни яктан өйрәнү һәм үстерү өчен иң уңышлы чор булды. Нәкъ менә шул чорда без тулы типтагы русча-төркичә һәм төркичә-русча сүзлекләрнең барлыкка килүен күрәбез. Бу хезмәтләр яңа сүзлекләр төзү өчен дә нигез булып кала бирәләр. Мәсәлән, 40 нчы еллар азагында дүрт томлы русча-татарча сүзлек басылып чыга. Артыннан ук ул вакыт өчен иң тулы татарча-русча сүзлек төзелә башлый һәм 1966 елда нәшер дә ителә. Бу проектлардан соң татар лингвистлары төркеме аңлатмалы сүзлек төзергә керешә.

Советлар Союзында күпчелек төрки телләрнең лексикографик хезмәтләре, күзәтүләргә караганда, әнә шундый юл үтеп барлыкка килгән. Илдә бер үк вакытта диярлек күпчелек төркиләрнең сүзлекләре төзелгән, грамматикалары язылган, диалектлары өйрәнелгән. Аларны бер-берсе белән чагыштырып тикшерү мөмкинлеге туган. Мондый планлы эшчәнлек бер үзәктән – СССР Фәннәр академиясе тарафыннан координацияләнгән. Бу уңай бәяләнергә хаклы тенденция.

Турыдан-туры татар теле сүзлекләренә килгәндә, телебезнең сүзлек хәзинәсе бик бай булуын ассызыкларга кирәк. Язмабызда аларның иң яңалары, безнең карашка, иң актуаль булганнары белән таныштырып үтәбез.

Татар телен фәнни яктан өйрәнү үзәкләре күп түгел. Алар, нигездә, барысы да Татарстанда, төгәлрәге Казанда формалашкан. Бүгенге көндә төп үзәкләр – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Казан (Идел буе) федераль университеты. Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында теоретик һәм практик лексикография белән шөгыльләнә торган лексикография бүлеге

эшләп килә. Татар теленең күпчелек норматив сүзлекләре әлеге бүлек хезмәткәрләре тарафыннан яки аларның актив катнашы белән төзелгән.

2000 нче еллар башында бүлек яңа күптомлы сүзлек төзергә керешкән иде. Башта хезмәт дүрт томлык булыр дип уйланылган иде. Эш барышында һәм басмага беренче томнарны әзерләгәндә, кулъязма материалны планлаштырылган томнарга сыйдырып булмаячагы ачыкланды, шуңа күрә томнар саны алтыга кадәр арттырылды. Хәзерге вакытта сүзлекнең алты томы да басылып чыкты. Бу мәкаләне язарга да татар теленең XXI гасыр башы сүз байлыгын чагылдырган зур күләмле, фундаменталь шул сүзлек этәргеч булды. Бу яңа «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» фән һәм мәдәният дөньясында зур һәм тарихи вакыйга булуында шигебез юк. Аны төзүдә төрле елларда егермегә якын белгеч катнашты. Шулардан кайберләре аерым томнарның аерым өлешләрен генә төзегән булса, кайберләре проектны гамәлгә ашыру өчен бик күп көч салды. Бу урында сүзлекне эшләүдә иң актив катнашкан авторларның һәм фәнни редакторларның исемнәрен әйтеп узу дөрес булыр, алар: Галимова О.Н., Гаффарова Ф.Ф., Саберова Г.Г., Сабитова И.И., Сафина Э.И., Сәфәров Р.Т., Таһирова Ф.И., Тимерханов А.Ә.

Алты томлы аңлатмалы сүзлек ничек төзелде соң? Чынлыкта, безнең белгечләр тарафыннан башкарылган хезмәтне болай гына санап чыгу бик кыен булыр иде. Әйе, безнең кулда алдагы буыннар калдырган шактый зур багаж бар иде барын. Әмма шуны да билгеләп үтәргә кирәк: академик типтагы татар теленең өч томлы аңлатмалы сүзлеге нәшер ителгәннән соң инде 40 ел узып киткән. Бу вакыт эчендә җәмгыятьтә зур үзгәрешләр булып узды: идеологик басым бетте, 90 нчы еллар башыннан милли үзаң үсеше башланды, фән-техника үсеш алды, балаларын татарча укыта торган мәктәпләргә бирергә теләүчеләр күбәйде. Табигый ки, әлеге процесслар телгә дә көчле йогынты ясады. Бу үз чиратында тел байлыгын һәм терминнар системасын яңача системалаштыруны һәм тулыландыруны таләп итә иде.

Әлеге һәм башка сәбәпләр өчтомлыкның хәзерге заман таләпләренә тулысынча җавап биреп бетерә алмавын күрсәтте, гәрчә ул иң абруйлы лексикографик басма булып кала бирсә дә. Яңа сүзлек авторларына исә яңа сүзләрдән һәм мәгънәләрдән, янә актив кулланышка кайтарылган искергән сүзләрдән һәм әйтелмәләрдән гыйбарәт гаять зур катламны тәртипкә салу бурычы куелды.

Нәрсә эшләнде? Бу сорауга җавапны кыскача гына берничә пунктта бирергә мөмкин.

1. Сүзлекнең лөгатьлеге 70 меңгә кадәр җиткерелде. Чагыштыру өчен: өч томлы сүзлектә ул 36 мең иде.

Лөгатьлекне формалаштыру өчен яңа сүзләр туплау эш башланган чорда матур әдәбияттан, фольклор әсәрләреннән, татар телендәге вакытлы матбугат материалларыннан, тәрҗемә ителгән дәреслекләрдән тоташ укып сайлап алу методына нигезләнгән иде. Ягъни лексикографның бурычы текстлардан элек бастырылган сүзлекләрдә теркәлмәгән сүзләрне мөмкин кадәр күбрәк табудан гыйбарәт иде. Соңрак, татар теленең электрон корпуслары барлыкка килү белән, яңа лексемалар эзләү ысуллары да үзгәрде: хәзер корпустагы бихисап сүз арасыннан сүзлекләрдә теркәлмәгәннәрен ачыклау, аларның дөреслеген тикшерү, сайлап алу алгы планга чыкты. Яңа технологияләрне кулланып эшләү бик күп лексик берәмлекләр табарга мөмкинлек бирде. Шуңа күрә соңгы ике том күләмлерәк, гәрчә томнарга материал баштан якынча тигез итеп бүленгән булса да.

2. Элекке сүзлекләрдә теркәлгән сүзләрнең мәгънәләре киңәйтелде.

Сүзнең мәгънәләрен ачыклау, аларны дөрес чикләү, иллюстратив материал белән исбатлау һ. б. – лексикографның төп эше. Ә инде яңа мәгънәләрне табу, тану, сүзлек мәкаләсенә урнаштыру – җентекле хезмәт нәтиҗәсе. Күпмәгънәле сүзләр өстендә эшләүне күрсәтү өчен игътибарны *кыз, таяк, май* һ. б. сүзләргә юнәлтер идем. Укучыга бу сүзләрнең мәгънәләре арасындагы аерманы аермачык күрсәтү өчен, аларның кайбер мәгънәләре рус теленә тәрҗемә итеп тә бирелде.

3. Сүзлек мәкаләләрендә сүзнең килеп чыгышы турында мәгълүмат бирелде.

Әлеге проблеманың әллә ни катлаулы булмавына карамастан, һәр алынма өчен этимологик тамга куеп баруның мәҗбүрилеге сүзлек авторына берникадәр кыенлыклар да тудыра. Әйе, этимологик сүзлекләрдә тасвирланган сүзләрнең килеп чыгышын бик җиңел билгеләргә мөмкин. Проблема яңарак сүзләрнең чыгышын билгеләгәндә барлыкка килә. Әйтик, *тюркизм* татар теленең үз сүзе түгел. Ләкин ул безгә кайсы телдән алынган? Кайсы телдә ясалган? Автор нинди билге куярга тиеш? Кулланучыга күренми торган мондый вак әйберләр сүзлекне төзегән вакытта бик күп булды.

4. Тезмә сүзләрнең чикләрен билгеләү һәм аларга мөстәкыйль сүзлек берәмлеге статусы бирү мәсьәләсе хәл ителде.

Барлык төрки телләр дә аналитик формаларны, шул исәптән тезмә сүзләрне дөрес язу һәм сүзлекләрдә бирү проблемасы белән очраша дип әйтсәк, ялгышмыйбыздыр. Бу аналитик формаларсыз бер генә сүзлек дә тулы типтагы сүзлек роленә дәгъва итә алмый. Мондый конструкцияләр төрки телләрнең төрле елларда нәшер ителгән төрле сүзлекләрендә төрле принциплар нигезендә теркәлгән: аларны фразеологизмнар алдыннан яки, гомумән, фразеологик берәмлекләр эчендә урнаштырганнар. Тәрҗемәле сүзлекләрендә аларны күпчелек очракта мисал итеп китергәннәр.

Яңа аңлатмалы сүзлектә мондый конструкцияләр, татар телен өйрәнүдәге яңалыкларны истә тотып, башка принципта урнаштырылды. Бөтен тезмә фигыльләр дә төп сүз астында урын алды, һәм шул баш сүз белән бергә алар бер оя хасил итә.

Күп кенә аналитик формалар, кушып язылып, мөстәкыйль сүз буларак вокабулага чыгарылды. Шунысын да билгеләп үтәсебез килә: бу мәсьәләдә тел белгечләре әлегә бердәм фикердә булмаса да, мәсьәләне хәл итү юлында сүзләрне шул орфографиядә бирү – иң дөрес вариант. Җәмәгатьчелек, тулаем алганда, элек тезмә дип каралган сүзләрне хәзер кушма итеп табуга бик шикләнеп караса да, тискәре мөнәсәбәттә булса да, лексикологлар бер үк модельдәге сүзләрнең язылышын тәртипкә салу ягында тора. Мәсәлән, *карабодай, аккош* сүзләре күптәннән кушылып языла. Ләкин *караелан* сүзен *кара елан* дип ике сүз итеп язалар, һәм моның ни өчен шулай икәнен беркем дә нигезләп аңлатып бирә алмый. Без аермачык метафоризация очрагында мондый сүзләрне кушып язарга кирәк, дип саныйбыз.

Әмма бу барлык тезмә сүз дә хәзер кушылып язылырга тиеш дигән сүз түгел. Компонентлары аерым язылырга тиешле мөстәкыйль берәмлекләр дә баш сүз буларак чыгарылды һәм сүзлек берәмлеге статусын алды (*үги ана яфрагы, бүре җиләге* һ. б. ш.).

* * *

Аңлатмалы сүзлекне төзегәндә, татар лексикографы юлыккан төп проблемаларга тукталып китми булмый.

Татар теле өчен генә түгел, күп кенә төрки телләр, бигрәк тә язмачылык традицияләре яшь булган төрки телләр өчен дә катлаулы мәсьәлә – ул орфография.

Теләсә кайсы телнең орфографиясе формалашуына язма традиция турыдан-туры йогынты ясый. Татар теленең күпгасырлык язма традициясе булуга карамастан, XX гасырда графиканың гарәпчәдән латиницага, латиницадан кириллицага ике тапкыр алыштырылуы әйтелеш ягыннан да, язылыш ягыннан да телдә проблемалар тудыра. Орфографик мәсьәләләрнең шактые әнә шул вакыттан бирле килә. Тагын шунысы да бар: гарәп графикасыннан латиницага күчүнең кайбер тарафдарлары татар телендәге бик күп гарәп алынмаларының гарәп орфографиясе кагыйдәләре нигезендә язылуын беренчел кимчелек дип санаган. Ләкин графика кириллицага күчерелгәч, лингвистлар шул ук тырмага басканнар, тик аерма шунда булган ки: барлык рус алынмалары, шулай ук рус теле аша кергән алынмаларны хәзер рус орфографиясе нигезендә язарга кирәк булган. Асылда хәзерге татар теле язуында ике тел кагыйдәләренә таяна: татарның үзенекенә һәм рус теленекенә. Ягъни рус теле кагыйдәләрен белмәү бик күп сүзләрне дөрес язмауга китерә.

Практик лексикограф нинди проблемаларны хәл итәргә тиеш соң? Әйткәнемчә,

татар орфографиясенең кагыйдәләре бары тик татарның үзтума лексикасын гына тәртипкә сала. Әмма хәзерге татар телен, башка телләр кебек үк, алынмалардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Шуңа күрә сүзлек мәкаләсе эшләнгәндә, лексикограф теге яки бу лексеманың адекват һәм фәнни яктан нигезләнгән аңлатмасын бирүдән тыш, әлеге сүзгә нинди кушымчалар кушылачагын да хәл итәргә тиеш була.

Берничә мисал гына китереп үтәбез. Татар орфографиясе кагыйдәләренә ярашлы, сузыклардан соң сүзгә *-сы/-се* тартым кушымчасы, калган очракларда *-ы/-е* кушыла: *әни-се, ата-сы* һәм *китаб-ы, дәфтәр-е*.

Әмма бер төркем алынмалар белән бу кагыйдә эшләми. *Чипсы, джинсы, виски, интервью* кебек чит телдән кергән сүзләр, сузык авазга тәмамланса да, *-сы/-се* кушымчасын кабул итми.

Башка төр проблема – ул кушма (тезмә) сүзләрне дөрес язу. Бөтен төрки телләр дә әлеге проблема белән очраша. Без бу хакта алдарак та телгә алган идек инде. Әлеге мәсьәлә барыннан да элек теоретик яктан аңлауны һәм эшкәртелүне таләп итә.

Төрки телләрдә төрле сүз төркемнәре өчен формаль күрсәткечләр юк, грамматик җенес категориясе юк. Аның каравы сүзтезмәдә һәм җөмләдә сүзнең катгый позициясе мөһим элемент булып тора. Нәкъ менә ирекле сүзтезмәне һәм тезмә сүзне аеру берникадәр кыенлыклар тудыра.

Төрки телләрдә тарихи яктан шундый процесс күзәтелә: күп кенә ирекле сүзтезмәләр баштан кулланууда тотрыклылык ала, аннары бөтенләй кушылып китеп, кушма сүзгә әверелә. Мәсәлән, *бил бавы > бил бау > билбау; сабан туе > сабантуй*.

Татар телендә дә, башка төрки телләрдә дә сүзләрне кушып язарга омтылу ниндидер яңалык түгел, бәлки тарихи яктан аклана торган бер күренеш булуы галимнәр тарафыннан исбатланган факт.

Сүз төркемнәрен аеру төрки телләрдә җитди фәнни проблема булып кала бирә. Мәсәлән, Николай Александрович Баскаков төрки телләрдәге сүз төркемнәрен тикшергәндә, исемнең, сыйфатның һәм рәвешнең мөстәкыйль сүз төркеме булмавын, ә «исем-сыйфат-рәвеш» дигән уртак сүз төркеме тәшкил итүен билгеләп үтә. Сүзлек төзегәндә, лексикографка моның белән турыдан-туры очрашырга туры килә. Әйтик, *матур кыз матур бии*. Бу мисалда кыз сүзен дә матур сүзе белән алыштырып була хәтта.

Кызганыч, төрки халыкларның үзләре тарафыннан язылган борынгы грамматикалары сакланмаган. Мондый мирас белән әллә ни күпләр мактана алмый шул. Иң борынгы грамматика – барлык һинд-европа телләре (шул исәптән рус теле дә) таянган латин теле грамматикасы. Гарәп теле грамматикасын да билгеләп үтәргә кирәк. Яхшырак истә калсын өчен, хәтта шигъри формада язылганнары да булган.

Беренче татар грамматикалары гарәп моделенә йөз тоткан була. XIX гасыр ахырында алар грамматистларны канәгатьләндерми башлый. XX гасыр башыннан татар теле грамматикасы, хәер, күпчелек төрки телләр кебек үк, урыны белән кыса, урыны белән кирәкле таләпләргә бөтенләй җавап бирми торган рус һәм һинд-европа моделе киеменә киендерелә башлый. Шулай итеп, төрки телләрдә дә сүз төркемнәре нәкъ әлеге һинд-европа телләрендәге кебек төрләргә аерыла. Әмма югарыда инде билгеләнгәнчә, мондый бүленеш тел белгечләрен канәгатьләндереп бетерә дип әйтеп булмый. Шуңа күрә сүзләрнең шундый катлаулы табигатен ачу максаты белән, аңлатмалы сүзлекләрдә күп кенә сүзләр бер үк сүзлек мәкаләсендә берничә сүз төркеменә аерып бирелә.

Сүзлекләрдә стилистик тамгалар системасын да аерым карарга кирәк. Татар теленең аңлатмалы һәм тәрҗемәле сүзлекләре теге яки бу сүзнең еш кына сөйләм һәм гади сөйләмгә каравын тамгалый. Барыннан да элек бу төрки телләрдә башка телләрдән ешрак очрый торган имитатив сүзләр (яки ияртемнәр) булуы белән бәйле. Бу күренешкә узган гасыр башында ук чуваш теле белгече Николай Ашмарин игътибар иткән булган. Безнең күпчелек имитативлар сөйләм стиленә генә хас дигән фикерне яклау ягында түгелбез, чөнки әлеге ияртемнәрнең бик күбесе, башка сүз төркемнәренә күчеп, яңа лексик берәмлекләр барлыкка китерә.

Югарыда әйтелгәннәрнең барысы да татар телен өйрәнүчеләргә генә түгел, теләсә кайсы төрки тел белән шөгыльләнүченең хәл итәсе фәнни проблемаларына турыдан-туры карый. Башка бер мәсьәлә дә бар: нәшер ителә торган белешмәлекләрнең аз тиражы. Алтытомлык «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында нәшер ителде. Бу программа ярдәмендә 2015 елдан башлап, ел саен 1000 данәлек тираж белән сүзлекнең берәр томы чыгып килде. Әмма белешмәлек басма өчен бу, әлбәттә, бик аз. Моннан тыш, әлеге томнарны сатуга да чыгарырга ярамады, аларны фәкать өләшергә генә мөмкин иде. Кызыксынган, ишетергә өлгергән кешеләр институт бинасына килеп, томнарны үзләренә ала алдылар. Ни кызганыч, бүген баланста сүзлекнең беренче һәм икенче томнары юк инде.

2020 елда республиканың дәүләт китап нәшриятында алтытомлыкны яңадан бастырып чыгаруга яңа юл ачылды. Шуның белән бергә сүзлекне тулыландыру, күзгә күренгән җитешсезлекләрен төзәтү мөмкинлеге туды. Шулай итеп, 2020 һәм 2021 елларда Татарстан китап нәшриятында икенче басманың беренче өч томы дөнья күрде, бу тираж белән проблеманы күпмедер дәрәҗәдә хәл итте, чөнки хәзер китап кибетләре киштәләрендә сүзлегебезне күрәбез.

Киләчәктә әлеге алтытомлык нигезендә, шуның сөземтәсе буларак татар теленең бер томлы аңлатмалы сүзлеген дә төзисе иде. Ул, үз чиратында, күп тапкырлар яңадан бастырып чыгару өчен нигез була алыр иде һәм лексикографик белешмәлек буларак куллану өчен кулайрак һәм җайлырак булыр иде. (Мәсәлән, казакъ теленең аңлатмалы сүзлеге баштан унбиш том булып дөнья күрде, шуның артыннан ук шул унбиш томның сөземтәсе итеп, бер томлы аңлатмалы сүзлек чыгарылды. Башка халыкларда да шундый схема күзәтелә).

Бүген без дә ана телебезнең этимологик сүзлеге бар, дип горурланып әйтә алабыз. 2015 елда Рифкать Газизьян улы Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге» ике томда дөнья күрде. Хәзерге вакытта мондый төрдәге сүзлекләрне, гадәттә, бер төркем галим төзи, һәм бу сүзлекнең төзү вакытын кыскарта. Бер галим тарафыннан төзелгәндә, моңа гаять озак вакыт кирәк була. Рифкать Әхмәтьянов та фәнни эшчәнлегенең беренче көннәреннән үк этимология белән шөгыльләнгән, татар телен чуваш теле белән чагыштырма планда өйрәнгән. Галим татар һәм рус телләрен генә түгел, немец һәм таҗик-фарсы телләрен дә яхшы белә иде, чөнки ул башлангыч һәм урта белемне Таҗикстан ССРда алган булган. Мондый бай багаж аңа чагыштырма тел белеме һәм, аерым алганда, этимологик сүзлек төзү белән шөгыльләнү өчен киң мөмкинлекләр бирүенә шигебез юк.

Әлеге сүзлектә тасвирланган материал телне өйрәнүчеләрнең генә түгел, бәлки шул тел вәкилләре белән тарихи бәйләнештә булган яки шул телгә нинди дә катнашы булган телләрне өйрәнүчеләрнең дә кызыксынуын уята дип ышанабыз. Күп кенә төрки телләрнең төп лексик фондының уртак булуы, бер-берсеннән нык аерылмавы һәркемгә мәгълүм. Шуңа күрә, әйтик, татар теленең этимологик сүзлеген башкорт теле өчен дә кулланырга мөмкин. Анда казакъ, нугай, кыргыз һ. б. кыпчак төркеменә кергән төрки телләр турында да бик күп мәгълүмат бар. Этимологик сүзлек нәкъ менә шушы үзенчәлеге белән күп телләрне берләштерә, моны башка бер лексикографик чыганак та эшли алмый.

Ике томлы «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә, күпсанлы вариантларны исәпкә алмыйча, 10300 сүзнең килеп чыгышы һәм ясалышы турында мәгълүмат бирелгән. Автор беренче нәүбәттә татар әдәби теленең лексик составына этимологик анализ бирү бурычын куя, шуңа күрә сүзлеккә 1977–1981 елларда чыккан өч томлы татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән барлык тамыр сүзләр дә кертелгән. Шул ук вакытта татар телен башка төрки телләр белән бәйләп торган диалекталь лексиканың һәм актив алынмаларның этимологиясе дә читтә калмаган.

* * *

Моңа кадәр сүз классик дип атала торган,  китап рәвешендә басылып чыккан кәгазь сүзлекләр турында барды. Кәгазь сүзлекләрнең гамәли лексикографиянең төп объекты булып кала бирүен таныган хәлдә XXI гасыр безгә үз шартларын куйганын һәм электрон сүзлекләрнең алгы планга үрмәләүләрен дә яхшы аңлыйбыз.

Менә шул электрон сүзлекләр турында да берничә сүз әйтү урынлы булыр. Беренчедән, электрон сүзлек дигәндә, сүзлек мәкаләләре булган билгеле бер мәгълүматлар базасы аңлашыла. Кагыйдә буларак, мондый сүзлекләр йә башта электрон рәвештә төзелә, йә кәгазь сүзлек мәгълүматларыннан файдаланалар, аларны цифрлаштыралар һәм кирәкле тәртипкә салалар.

Татар теленең оригиналь электрон сүзлекләре безгә мәгълүм түгел. Кәгазь сүзлекләрнең электрон формаларына килгәндә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе сайты базасында 2014 елда «Сүзләрнең электрон фонды» булдырылды. Бу фондка ел саен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында төзелгән һәм бастырып чыгарылган 4–6 сүзлек кертелә. Агымдагы елга анда 50 чамасы берәмлек урнаштырылган.

Телгә алынган тәрҗемәле, аңлатмалы һәм этимологик сүзлекләр барысы да шушы фондта урнаштырылган: http://suzlek.antat.ru/index.php.

Фондтан файдалануның уңайлы ягы шунда ки, кызыксындырган сүз турындагы мәгълүмат бер урында бирелгән. Ягъни эзләү юлына кирәкле сүзне кертү дә җитә, система бу сүзне тупланмага урнаштырылган бөтен сүзлекләрдән яки кулланучы үзе билгеләгән сүзлекләрдән табып бирәчәк. Монда сүз турында бер чиртүдә орфографик, орфоэпик, аңлатмалы, этимологик, терминологик, тәрҗемәле сүзлекләрдән мәгълүмат табарга мөмкин.

Һәр лексикографның хыялы – кулланучы конкрет лексеманың грамматик формалары да, тарихы да, килеп чыгышы да, аңлатмалары да, тәрҗемәләре дә, синонимнары да һ. б. турында тулы мәгълүмат таба алырлык сүзлек төзү. Зур күләмнәр һәм куллану җайсызлыгы сәбәпле, кәгазь сүзлекләр белән мондый максатка ирешү бик катлаулы эш. Электрон формат исә бу хыялларны тормышка ашырырга яңа юллар ача.

Тагын бер вак, әмма бик мөһим үзенчәлек: кәгазьдә басылган теләсә нинди чыганак дөнья күрүгә картая да башлый. Ул бөтенләй «картаеп бетмәсен» өчен аны вакыт-вакыт тулыландырырга, редакцияләргә, төзәтергә кирәк. Кәгазь сүзлектә моны эшләп булмый, шуңа күрә аларның кайчакта бөтенләй яңасын булдыралар, кайчакта искесен тулыландырып, төзәтеп төзиләр һәм кабат бастырып чыгаралар. Электрон сүзлекләрне исә бу яктан тере яки искерми торган дип атарга мөмкин, чөнки аларны төп материалга бер зарар да китермичә даими рәвештә редакцияләргә һәм тулыландырырга мөмкин, шул ук вакытта алар яңадан бастыру өчен чыгымнар да таләп итми.


Безнең уебызча, мондый универсаль характердагы электрон сүзлекнең һәр аерым өлешен үз белгече (этимолог, дериватолог һ.б.) төзи ала, ә сүзлек мәкаләсенең гомуми структурасын шул ук лексикографлар формалаштыра алыр иде.

Сүзлекләр телебезне өйрәнүчеләргә, татар телендә сөйләшүчеләргә телләрен камилләштерү өчен киләчәктә дә кыйммәтле чыганак булачак. Телне саклау һәм үстерүдә дә алар бәяләп бетергесез әһәмиятле роль уйный.

**Ринат СӘФӘРОВ,**
*ТР ФА ТӘһСИнең лексикография бүлеге мөдире,*
*филология фәннәре кандидаты*

*Бу QR-код аша «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең электрон вариантына керергә була.*

# ГОМЕР БҮЛӘК ИТҮЧЕ ГАЛИМ



Дөньядагы барлык мәдәниятләр өчен уртак бер генә әхлак законы бар: кеше гомерен кыю – иң зур гөнаһ, кеше гомерен саклап калу – иң олы дәрәҗә, дигән канун ул. Җир шарында тормыш дәвам итүнең төп шарты булган әлеге кагыйдә галимнәр арасында да аерым бер категория кешеләрне аерып чыгара. Гыйлем ярдәмендә гомерне озайтучылар, үлемнән коткаручылар категориясен.

Бүгенге язмабыз – шундый сирәк язмышлы, меңләгән кешеләргә икенче тормыш бүләк иткән галимнәрнең берсе, дөньяның иң күренекле нейрохирурглары арасында беренче унлыкка керә торган доктор, Төмәндәге федераль нейрохирургия үзәгенең баш табибы, медицина фәннәре докторы, профессор, И.М. Сеченов ис. Беренче Мәскәү дәүләт медицина университетының нейрохирургия кафедрасы мөдире Альберт Әкрам улы Суфианов турында булыр.

Милләттәшебез – дөньякүләм билгеле 100 нейрохирургны берләштергән Бөтендөнья нейрохирурглар академиясенең әгъзасы (бу урында, Россиядән бердәнбер дип тә өстәргә мөмкин булыр иде!). 2019 елдан – Көнчыгыш Европа илләре һәм Россиянең цифрлы анатомия проекты буенча ЮНЕСКО илчесе. Үзенең фәнни һәм гамәли-табиблык эшчәнлеге белән Альберт Суфианов нейрохирургия ярдәме кирәк булган авыруларның чит илләргә агылуын туктатып кына калмый, бәлки, алар өчен чит илләрдән – Россиягә юл ача. Авырулар гына түгел, дәвалаучылар белән дә шул ук хәл: бүген Себергә Җир шарының төрле төбәкләреннән осталык дәресе алырга киләләр. Кыска гына вакыт эчендә А.Суфианов Төмәнне иң билгеле нейрохирургия шәһәрләренең берсенә әверелдерә!

Беренче карашка, бу юл бик гади-гадәти башланып китә төсле. 1965 елның 7 мартында Иркутск өлкәсенең Вихоревка шәһәрендә туа ул. Әтисе белән әнисе бу җирләргә БАМ төзелешенә килгән булалар. Әнисе Татарстаннан, Чирмешән районы Урманасты Үтәмеш авылыннан. Баянда да уйный, машина да йөртә, төзелеш эшен дә белә иде, дип искә ала аны улы. Әтисе тумышы белән Самара өлкәсенең Шонтала станциясеннән; иртә вафат булып, малай әнисе белән үсә. Күп укый, баян буенча музыка мәктәбендә шөгыльләнә. Мондагы остазлары аңа шушы юлдан китәргә киңәш бирәләр. Әмма әнисе кешеләргә ярдәм итүнең иң кыска юлы – медицинада дип әйтә килә. Күренекле табиблар хакындагы китаплар, кинофильмнар тәэсире дә зур булгандыр. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Альберт Иркутскидагы медицина институтына укырга керә. 3-5 курсларда Ленин стипендиаты булган егет ординатурадан соң аспирантураны төгәлләп, вакытыннан алда кандидатлык диссертациясен яклый, Иркутскидагы балалар клиник хастаханәсендә врач-нейрохирург булып эшли башлый, 1996 елны Россиядә беренчеләрдән булып, балалар нейрохирургиясе бүлеген ача һәм җитәкли. Игътибар итик: иң катлаулылардан катлаулы һөнәр – нейрохирургияне сайлаган ул. Әле аның да нindие – балалар нейрохирургы. Кечкенә сабыйларның гомер җебен кулда тоту нинди зур җаваплылык та, кыюлык та, сабырлык та, гыйлем дә таләп

итә. Бу өлкәдә бары тик фән белән бергә үсәргә, гыйлем ярдәмендә перспективаны билгеләп, алга барырга мөмкин.

35 яшендә докторлык диссертациясен яклап, Альберт Әкрам улы Россия медицина академиясенең Себер бүлекчәсенә караган Медицина экологиясе фәнни үзәгендә эшли башлый, Америкада, Япониядә, Кытай, Австрия, Италия, Германия һ.б. илләрдә стажировка уза. Чит илләрдәге иң оста, күренекле хирурглардан өйрәнеп, аларның методикаларын илгә алып кайта, әмма үз юлын булдыра ул.

Аның беренче тапкыр чит илгә укырга китүе дә көтелмәгәндә килеп чыга. Иркутскига Германиядән нейрохирургия өчен җиһазлар кайта. Әмма аларны кулланырлык, алманча белгән һәм бу өлкәне аңлаган кеше булмаганга, көйләп җибәрү эше сузыла. Моңа алынып, яшь хирург Европадагы иң алдынгы нейрохирургия технологияләре дөньясына кереп китә. Җиһазлар җыела, инде алар белән эшләргә өйрәнү өчен А.Суфианов Германиядә үз хисабына стажировка сорый. Анда баргач, әлеге мөмкинлекне максималь файдалана: кызыксынучан, тырыш, өстәмә дежурлыклар алып өйрәнергә әзер яшь кешене күреп алалар. Альберт Әкрам улы исә үз юлын табу өчен башка остазларга, башка илләргә бару кирәклегенә төшенеп кайта. Кайсы илдә бу өлкә нык үскән, кайда танылган хирург-галим бар – шунда эшләп, осталыгын камилләштерә. Бүген инде нәкъ шулай – аны эзләп, Төмәнгә киләләр! А.Суфианов исә үз укучыларына «минем кебек эшлә!» дип төшендерә. Һөнәри үсеш өчен бүгенге иң алдынгы технологияне үзләштерү шарт, ди ул; остаз белән укучы бер-берсен үстерәләр, дип тә өсти.

2009 елны Төмән хакимияте Альберт Әкрам улын Нейрохирургия федераль үзәге төзелешен җитәкләр өчен Төмәнгә эшкә чакыра. Яшь табибны мондый картина каршы ала: хастаханә төзер өчен ат көтүләре йөргән яланда җир бүлеп бирелгән, аның әле нигезе-фундаменты гына салынып ята. Көне-төне төзелеш, бинаны нейрохирургия өчен яраклы итеп көйләү, иң заманча җиһазлар табу, кайтарту артыннан чабарга кирәк. Әмма тырышкан табар, диләр, тырышлыкта, максатчанлыкта җитәкчегә тиңнәр юк: бер ел эчендә төзелешне тәгәлләп, 2010 елның апреленнән А.Ә. Суфианов шушы Үзәкнең баш табибы булып эшкә керешә, тирәсенә менә дигән яшь белгечләр, үзе кебек үк Россиядә нейрохирургияне үстерү, дөнья фәне дәрәҗәсенә күтәрү теләге-омтылышы белән янган фикердәшләр туплый. Хастаханә башта ук дөнья масштабында караганда да яңача, әле кулланылышка кереп кенә бара торган технологияләр белән җиһазландырылган үзәк итеп күзаллана. Чөнки иң алдынгы методикалар файдалану өчен – өр-яңа җиһазлар белән тәэмин ителү мәҗбүри. Бигрәк тә бу методикалар аз-инвазив, ягъни тәнне кисмичә, аерым бер нокталардан, тамырлардан үтеп кереп, операцияләр ясау, баш миендәге яки нерв тамырларындагы шешләрне кисү өчен хезмәт итсә!

Шулай булып чыга да: бүген бу Үзәк дөньяның иң алдынгы медицина учреждениеләреннән санала. 2013 елны ул Россиядә югары технологияле ярдәм күрсәтүче иң яхшы Үзәк дип таныла. 10 ел эчендә монда 35 меңнән артык иң катлаулы операцияләр ясала. Бирегә ел саен төрле илләрдән дәвалау-терелтү мөмкин түгел дип саналган меңләгән пациентларны алып киләләр, алар үз аягы белән кайтып китә.

Бу Үзәктә Россия күләмендә генә түгел, бәлки, дөньяда иң алдынгы медицина җиһазлары тупланган, диләр. Мәсәлән, Россиядә бердәнбер, дөньяда 20-30 булган, компьютер томографлы «акыллы» гибрид операция бүлмәсе – шундыйлардан. Ул иң катлаулы очракларда да авыруларның гомерен саклап калырга ярдәм итә.

Монда бер секунд эчендә 640 яссылыктан рәсем күрсәтүче, чиктән тыш тиз сканерлаучы КТ – киләчәктән килеп эләккән төсле тоела. Шулай ук Россиядә бердәнбер булган МРТ операция алдыннан тикшеренүләрне, югары технологияле инвазив операцияләрне пациент «басып торган» килеш уздырырга мөмкинлек бирә. Шешләр һәм эпилепсияләр хирургиясендә кулланыла торган югары-энергетикалы лазер, чиктән

тыш нәзек эндоскоплар минималь инвазив нейрохирургия мөмкинлекләре хакында күзаллауларны тамырдан үзгәртергә сәләтле!

Боларны күзәткәндә, чыннан да, киләчәк турында төшерелгән фантастик фильмга эләккәндәй тоела башлый. Чөнки хирург үзенең баш миендәге «эш мәйданын» күз белән күрә алмый: башта һәр пациентның баш мие моделе әзерләнә, шул модель ярдәмендә баш сөягенә үтеп керергә мөмкинлек бирә торган нокта табыла, авыру урынга барып житү юлы сызыла. Бу вакытта Carl Zeiss, Leica, Pentero 900 микроскоплары, Zoring ультавыш аспирациясе системасы һәм Aesculap, Stryker, Medtronic югары ешлыктагы электр җиһазлары да ярдәмгә килә. Әмма иң мөһиме – хирургның үз-үзенә ышанычы, тәвәккәллеге, үз һөнәренә бирелгәнлеге түгелме икән?..

Бу үзәктә операция алдыннан тикшеренүләрнең иң алдынгы флуороскопия һәм ангиография методикалары, яман шешләрне кисеп алу белән бергә, интраоперацион фотодинамик терапия кулланыла. Әйтик, заманча Stealth Station, Brain Lab нейронавигацион комплексларына мөрәҗәгать итү оператив дәвалауның вакытын кыскарта, нәтиҗәлелеген күпкә арттыра. Шулай ук Sono Wand ультратавыш күзәтүе, Flex Focus 800 ультратавыш системасы оператив эшне күрмичә дә күз алдында тергезеп барырга ярдәм итә. Биредә барлык операцияләр 3D-визуальләштерү ярдәмендә эшләнә. Эндоскопик һәм экзоскопик нейрохирургия системалары, җиһазлар, мониторлар 4К рәсемендә эшли: бу операция бүлмәләреннән тапшырылган рәсемнең чиктән тыш ачык булуын тәэмин итә. Шушы җиһазлар яшь хирурглар әзерләүдә дә ярдәмгә килә, операциягә кадәрге әзерлек этабында да кулланыла.

Үзәкнең матди-техник базасы даими үзгәреп тора. Әйтик, 2013 елның көзендә монда Россиядә беренче булып Trenion 3D камерасы куллана башлыйлар, аның ярдәмендә иң беренче операция баш миендә тайпылышлар булган пациентка ясала. Җиһаз хирургның үзенә генә түгел, бәлки операциядә катнашучы бригадага тулы картинаны күрергә ярдәм итә, бер үк вакытта, 3D форматындагы язма уку-укыту классларына күрсәтеп барыла. Альберт Әкрам улы уку-укыту технологияләре бүген дәвалау технологияләреннән калышмаска, кайбер очракларда – алардан алда барырга тиеш дип саный. Шуңа да Үзәктә симуляцион укыту өчен 11 урынга исәпләнгән микрохирургия лабораторияләре булдырылган, аларның һәркайсы заманча нейрохирургия операция бүлмәсенең мини-аналогы булып тора.

Альберт Әкрам улы 2016 елны, Беренче МДМУ (Сеченов университеты) базасында клиник үзәге Төмәндә булган нейрохирургия кафедрасы ачып, аны җитәкли, уникаль 3D-лабораторияләрдә нейрохирурглар әзерләүнең тулы системасын булдыра. Бүген биредә дөньяның 38 иленнән 1500дән артык табиб әзерлек узган. Бу кафедрада илдәге шундый башка кафедралар белән чагыштырганда, иң күпсанлы ординатор-нейрохирурглар укытыла, аларның күп өлеше – чит ил гражданнары. Даими рәвештә дөньяның төрле илләрендә (Германия, Франция, Швейцария, АКШ, Пакистан, Таиланд һ.б.) нейрохирургия буенча лекцияләр укучы, мастер-классlар уздыручы да ул. Шәхсән үзе 100 югары квалификацияле нейрохирург, 1 фәннәр докторы һәм 8 кандидат тәрбияләгән.

А.Ә. Суфианов нейрохирургия фәнендә аз-инвазив методлар куллануны башлап йөрүчеләрдән санала. Аз-инвазив – ягъни мөмкин кадәр аз җәрәхәтләү, нәкъ менә зыян күргән ноктага гына «кагылу» авыруларның тиз сәламәтләнүен, гадәти тормышка кайтуын тәэмин итә. Альберт Әкрам улының бу өлкәдәге авторлык методикалары, патентлары – ачык, яручы «зур» операцияләр белән чагыштырганда – киләчәк технологиясе, фантастик алга китеш булып бәяләнә. Әйтик, баш миеннән шешне алу вакытында бала рәсем ясый, табиб белән сөйләшә, җырлый... Нейрохирурглар исә моны мәҗбүрият – пациентның хәлен күзәтеп тору өчен кирәк булган әмәл дип аңлата.

Әмма Альберт Әкрам улы тагын да еракка карый: җөйсез операцияләр – ягъни билгеле бер урынны тишеп, шул тишекләр аша шешне яки зарарланган урыннарны

«кисү» методикасын эшли, гамәлгә куя. «Җөйсез операцияләр» – нейрохирургиягә мин алып килгән, булдырган һәм куллануга керткән дәвалау тәртибе», – ди ул. Әмма бүген табибны бу ысул да тулысынча канәгатьләндерми, ул медицинада «контактсыз нейрохирургия» ысулын урнаштыру юлыннан бара. Бу юл табибны авыру кеше тәненә кагылудан тулысынча «азат итә»: билгеле бер нокталарга тупланган нурлар шешне яндыра, юкка чыгара ала. Үзәктә шундый җиһазлар бар инде, аларны куллану өчен махсус операция бүлмәләре әзерләнә, мондый эшнең фәнни нигезе корыла.

Гомумән алганда, аз-инвазив методлар кулланып, Үзәктә ел саен 4 мең операция ясала. Шуларның 800дән артыгын Альберт Әкрам улы үзе эшли. Шунысы да бар – Үзәктә башка табиблар өметсез дип баш тарткан, иң катлаулы авыруларны дәваларга алыналар. Әйтик, эпилепсия диагнозы куелган авыруларның хәле элек бары тик медикаментлар ярдәмендә җиңеләйтелә иде. Табиблар арасында, мондый авыруларга чит илләрдә операцион ярдәм күрсәтә алалар, бездә ул мөмкин түгел, дигән караш хөкем сөрде. Хәзер исә Төмәндәге Үзәктә аларны хирургия юлы белән дәвалау башкарыла: бу чирдән тулысынча котылу мөмкинлеге бирә. Балалардагы церебраль паралич, төрле сәбәпләр белән умыртка баганасына зыян килү, баш яки арка мие зарарлану, аневризма, мальформация һ.б. бик күп очракларда иң катлаулы, югары технологияләргә нигезләнгән операцияләр ясау авыруларны актив тормышка кайтара, күпчелек очракта – икенче гомер бүләк итә.

Бу операцияләрнең күбесе бүген заман чиренә әйләнгән – онкология авырулары белән бәйле. Табиб ясаган күп кенә операцияләр янында «уникаль», «тиңе булмаган» дигән сүзләр кулланыла. Әйтик, гемофилия – каны куермый торган авыру малайның баш миендәге авыру ярымшарын, сәламәт ярымшарга зыяны тимәсен өчен, эшләүдән туктату өчен ясалган операция шундыйлардан. Яки 2018 елны ана карынындагы «гидроцефалия» диагнозы куелган баланың баш миенә ясалган операция Россиядә – беренче, дөньяда икенче була. Шуннан соң үзәк нерв системасына ана карынында ук ярдәм итә торган операцияләр бередә тулы бер юнәлешкә, гадәти дәвалау ысулына әйләнә. Аның мондый казанышларын аңлаткан фәнни хезмәтләре дөньяның иң билгеле фәнни журналларында басыла. А.Ә. Суфианов – 415 басма хезмәт (1 дәреслек, 10 монография, 26 патент) авторы.

Альберт Әкрам улы сәләтле балаларны табу, аларны катлаулы заманча һөнәрләргә (нейрохирургия, медицина инженерлары, тикшеренүчеләр, медицина IT-белгечләре һ.б.). юнәлтү мәсьәләсе белән дә шөгыльләнә. Россиядә иң алдынгы мәктәпләрдән булган Төмән физика-математика мәктәбенә шәхсән ярдәм итеп килә; Россиядә беренче булып нейрохирургия буенча халыкара студентлар олимпиадасын уздырып, иң талантлы кандидатларны ординатурага сайлап алу эшен җайга салучы да – ул. Үзәк һәм Төмән индустриаль университетында бакалавриатта һәм магистратурада медицина инженерларын әзерләү инициативасы да аның исеме белән бәйләнгән.

А.Ә.Суфианов аеруча зур әһәмият бирә торган тагын бер өлкә бар – ул нейрохирургия өчен Россиянең инженерлар әзерләүче вузлары һәм чит илләрнең алдынгы компанияләре белән бергәләп, Урал, Казан, Мәскәү предприятиеләрендә яңа буын эш кораллары, җиһазлар әзерләү. Аларның авторы-уйлап табучысы буларак, бу юнәлештә дә гаҗәеп уңышларга ирешә ул: эндоскопик нейрохирургия, контактсыз ультратавыш нейрохирургиясе өчен дөньяда беренче роботны, яңа буын нейростимуляторларны эшләү аның исеме белән бәйләнгән.

Әйтик, ул уйлап тапкан югары технологияле авторлык электрохирургия пинцетлары 2021 елны, Екатеринбург шәһәрендәге индустриаль партнёр – ООО «ФОТЕК» базасында сынауларны уңышлы үтеп, серияле җитештерүгә җибәрелгән. Җайланма үзенең сыйфаты белән, Швейцария һәм Япония экспертларының бәясенә караганда, дөньядагы аналогларыннан күпкә яхшырак. Бүген инде аны, илдә файдалану белән бергә, чит илләргә сату эше җайга салынган.

2021 елны уникаль, амбициоз проект – автоном роботлаштырылган нейрохирургия комплексын булдыру эше дәвам иткән. Бу проектта индустриаль партнёр – «Казан электромеханика заводы», аны тормышка ашыруда Европаның (Германия) иң алдынгы нейрохирурглары һәм инженерлары катнаша. Дөньяда мондый нейрохирургия роботы эшләнгәне юк әле (биредә сүз манипулятор яки инструментларны «тотып торучы кул» турында бармый). Табигый, робот эндоскопик җөйсез операцияләр башкару өчен файдаланылачак.

2021 елны Альберт Әкрам улы иң яхшы табибларга бирелә торган «Кеше тормышын коткарган уникаль операция өчен» илкүләм «Талант» («Призвание») милли премиясенә лаек була. Дөньяда беренче булып, ана карынындагы гидроцефалия диагнозы куелган баланың баш миенә уңышлы ясалган операция өчен бирелә ул. 26 атналык, баш мие сыеклык җыелу сәбәпле үсүдән туктаган яралгы өчен ике генә юл бар: ул йә – һәлак булырга, йә – акылын җуеп дөньяга килергә дучар ителә. 2018 елның 7 маенда Екатеринбургта Альберт Әкрам улы өченче – гомерне дә, акылны да саклап калу юлы барлыгын исбатлый. Авырлы ананың карынында, баланың баш сөягендә бары бер тишек тишеп, баш миендәге сыеклык суырып алына. Бала вакыты җитеп дөньяга килә, бүген инде Ярослав исемле бу малай Ямал-Ненец округында әти-әниләренең олы куанычы булып үсеп килә!

Мондый операцияне күп илләрдә, күп кенә хирурглар ясарга омтылып карый. Әмма «уңышлы операция + уңышлы бала табу + баланың тормышын саклап калу» дигән барлык баскычларны үтү бары тик Альберт Әкрам улына насыйп була. Бу кеше ышанмаслык тәҗрибә мондый авырулар өчен, хәтта яралгы вакытында ана карынында булганда да, котылу, күп гомерләрне саклап калу мөмкинлеге барлыкны раслый.

Гомумән алганда, хәзерге көндә профессор Суфиановның балаларда гидроцефалияне эндоскопик дәвалау тәҗрибәсе ике мең операциядән артып китә. Шуларның нәтиҗәсенә таянып, 3 ел дәвамында кафедрада эндоскопик техника кулланып, хайваннарда фәнни тәҗрибәләр уздырыла. Өйрәнү өчен махсус эшләнгән модельләр дә кулланыла. Болар бөтенесе бергә уңышка китерә дә инде.

Бу бит әле – дәвалауның бер юнәлеше генә. Әйтик, Успенкадагы психоневрологик интернатта Альберт Әкрам улы һәм ул җитәкли торган Төмән Үзәге – эпилептологик хезмәт оештыралар. Аның нәтиҗәләре белән танышырга Швейцариядән, Япониядән килгән галимнәр эшне бик югары бәялиләр. Монда югары технологияле җиһазлар куелган иң заманча лаборатория булдырыла. Аппаратларның кайберләре, хәтта, Төмән Үзәгендә дә юк икән. Авыру балаларны даими күзәтү, аларга ярдәм итү проекты медицина фәнендә яңа эзләнүләр мәйданнарына алып чыга. Әйтик, эпилепсия диагнозы кую өчен биредә барлык шартлар тудырылган. Ә бу эш – үзе бик күп көч сорый: анда анестезиологлар, реаниматологлар, махсус уяну палатасында хезмәт күрсәтүчеләр... кергән тулы бер комплекс белгечләр булу таләп ителә. Шулай итеп, Успенка интернаты балалар өчен диагностик үзәк дәрәҗәсендә дә эшләп китә.

2018 елны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургалиевич Миннеханов А.Ә.Суфианов оештырган Үзәктә була, андагы нейрохирургия технологияләренең һәм уку-укыту эшенең үсеше белән таныша. Шуннан соң Альберт Әкрам улы Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең республикада яшәүчеләргә югары технологияле нейрохирургия ярдәме күрсәтү һәм Татарстанда нейрохирургия буенча кадрлар тәрбияләү программасының җитәкчеләреннән берсенә әйләнә. 2018–2021 елларны Казан медицина университеты һәм Казан федераль университетының чыгарылыш студентлары арасыннан конкурс нигезендә 12 ординатор кандидатурасы Төмәндәге үзәктә уку өчен сайлап алына. Аларның Сеченов университетында нейрохирургия буенча ординатурада белем алуын Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы финанслый. 2021 елны аларның 4се, укуларын тәмамлап, республикадагы нейрохирургия бүлекләренә кайта, 7се ординатурада укуларын дәвам итә, икесе –

аспирантурада. Шулай ук Үзәк базасында Татарстаннан 30дан артык табиб стажировка уза. Иң мөһиме – Татарстан Республикасыннан килеп, Үзәктә дәвалanучы пациентлар саны арта: 2017 ел белән чагыштырганда, бу үсеш 1000 % артыграк. Мондый хезмәттәшлек гаять файдалы: нейрохирургия ягыннан – бу заманча кадрлар әзерләү дигән сүз. Казаннан килеп, ординатура үткән табибларның бер өлеше Альберт Әкрам улы җитәкчелегендә аспирантурада укый, тагын бер өлеше анда керергә планлаштыра. Димәк, Татарстанда нейрохирургия практик яктан гына түгел, бәлки, фәнни кадрлар әзерләү ягыннан да ныгый дигән сүз.

Альберт Әкрам улының нинди генә шәрәфле исемнәре юк! Аларны санап чыгу гына да бер язмалык урынны алыр иде «Россия Федерациясенең атказанган табибы» исемен аңа Президент В.В. Путин үзе тапшыра. Татарстан Республикасының һәм Ингушетия Республикасының атказанган табибы булу – бу субъектлар белән ныклы хезмәттәшлек нәтиҗәсе. Дөньяның күп кенә күренекле университетлары аны үзләренең шәрәфле профессоры итеп сайлаганнар. Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы булу – аның Татарстан фәненә керткән гаять зур өлешен тану-бәяләү дип билгеләнә аладыр...

Күрәсең, мондый гамәлләрне башкару өчен гадәти кеше булу гына аздыр. Акылы, фигыле, рухы – табиб булган шәхесләр генә боларга сәләтледер кебек. Якты кеше, миһербанлы һәм олы җанлы шәхес – Альберт Әкрам улы Суфианов бу дөньяга башкаларның гомерен озайту, аларга тормыш бүләк итү өчен килгәндер кебек тоела. Туктаусыз камиллеккә омтылуы, туктаусыз гыйлем җыюы белән ул киләчәкне якынайта, идеалны чынбарлыкка әйләндерә.

Гаиләсе дә табибларныкы аның. Хатыны – профессор, Төмән дәүләт медицина университетында фармакология кафедрасын җитәкли. Улы «нейрохирургия» белгечлегенә укып, хәзер Мәскәүдә, Бурденко исемендәге Нейрохирургия институтында аспирантура уза. Кызы икътисад юнәлешен сайлаган. Ике оныгы бар. Ул гаиләсенең генә түгел – милләтенең, иленең горурлыгы булып яши!

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

*Бу QR-код аша кереп, милләттәшебез турында тапшыру карый аласыз.*

**Редакциядән:**

*Шушы көннәрдә Альберт Әкрам улы Суфианов Россия Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы булды. Милләттәшебезне котлыйбыз, аңа исәнлек-саулык, киләчәктә дә медицина фәнен, шул исәптән нейрохирургияне үстерүдә яңадан-яңа ачышларга, зур уңышларга ирешүен телибез!*

# КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА ИСЛАМ ДИНЕ

## Төрле диннәр һәм кануни кырлар

Болгар чорыннан башлап, Урта Идел буенда көн күргән мөселманнар арасында башка конфессия вәкилләренә түземле мөнәсәбәттә булган хәнәфи мәзһәбе киң җәелгән, берничә гасыр дәвамында ут күрше булып яшәгән традицион диннәр тарафдарлары, төрле кавемнәр белән тотрыклы һәм үзара килешеп яшәү традицияләрен булдырган.

Һәр этник төркем билгеле бер төбәктә тупланып көн итү сәбәпле, халыклар арасында актив аралашу, нигездә, кавемнәр янәшә яшәгән урыннарда күзәтелгән. Даими мөнәсәбәтләр мари, чуваш, удмурт һәм мукшы элита вәкилләре белән хан хакимияте арасында барган.

Мөселман дин әһелләре мәҗүси дин тотучыларны дәгъватләү белән шөгыльләнгәннәр, шул рәвешле ислам динен тыныч юл белән таратканнар. Әйтик, С.Герберштейн Түбән Новгород янындагы урманнарда яшәгән мариларның, Мәскәү дәүләтенә буйсынып Казан ханлыгына салым түләмәсәләр дә, Мөхәммәд пәйгамбәр тарафдарлары булуын билгеләп үтә (*Герберштейн С. Күрс. хезмәт. С. 164).*

Казанлыларның мәдәни һәм дини йогынтысы, суфиларның дәгъватләү нәтиҗәләре мәҗүси динендә булган халыкларның кайбер йолаларында, гореф-гадәтләрендә чагылыш тапкан. Тарихчы М.Худяков бу йогынтыны удмуртларда һәм мариларда җомганы атна бәйрәм көне итеп билгеләп үтүләрендә, кайбер татар изгеләрен олы ихтирам белән искә алуларында, шул исәптән, мариларда Бәйрәш һәм Иш-Мөхәммәд шәехләрне Шиквав һәм Ахпатыр исемнәре белән хөрмәтләүләрендә күрә (*Худяков М. Күрс. хезмәт. С.198*). Бу хакта Ш.Мәрҗани тәфсилләбрәк яза: «...бу илдә ислам хөкүмәте вакытында финнарның барысы да яки күбрәге ислам диненә кергән. Ләкин кайберләренең сәләтләре һәм мөселманнар белән мөгамәләләре аз булганлыктан, ислам аларда тамырлана алмаган, җәһаләтнең көчле булуы сәбәпле, әкренләп, үзләренең асыллары булган чувашлык, чирмешлек һәм арлыкларына кайтканнар. Җәбәлстанда (Татарстанның Тау ягы. – **автор**), Болгар һәм Казанның кайбер иске каберлекләрендә табылган ташларда чуваш, чирмеш сүзләре булу һәм аларда кайбер мөселманчылык гореф-гадәтләре табылу да шул сәбәптән булырга тиеш» (*Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 80 б.).*

Казан ханлыгы чорында Урта Идел төбәгендә православие дине тарафдарлары яшәү гадәти күренешкә әверелә. Беренче нәүбәттә, Казан дәүләтендә тәңкәләр сугылмау сәбәпле, ил базарында Мәскәү акчасы киң кулланышта булу хакында әйтеп китү мәслихәт. 1525 елга кадәр Казансу Иделгә кушылган урындагы утрауда ел саен июнь аенда уздырылган халыкара ярминкә Бөек Мәскәү кенәзлеге өчен Көнчыгыш илләр белән алаш-биреш итүдә төп базар була. Моннан тыш, Казан ярминкәсенә килгән рус сәүдәгәрләре ике дәүләт арасында икътисади мөнәсәбәтләрне активлаштыруга үз өлешләрен керткәннәр. Алар Казан дәүләте җирләрендә сәүдә иткәннәр һәм яшәгәннәр. (Казан сәүдәгәрләре исә даими рәвештә Түбән Новгородта һәм Мәскәүдә яшәгәннәр

һәм сату-алу белән шөгыльләнгәннәр. – **И.З.**). Эш шунда, ханлык хуҗалыгында Бөек Мәскәү кенәзлегендә җитештерелгән товарларга ихтыяҗ зур була. Киңрәк фикерләгәндә, аксөякләр төркеменең, сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең еш кына Бөек Мәскәү кенәзлеге белән тыныч һәм эшлекле мөнәсәбәтләр булдырырга омтылуында һәм Кырымнан килгән ханнарга каршы чыгуларында икътисади мәнфәгать алга куелган, дияргә мөмкин.

Рус протектораты елларында башкалада Мәскәү хөкүмәте вәкилләре һәм яугирләре дә яши. Шәһәрдә рус зираты була. Моннан тыш, Казанда әрмәннәр җәмгыяте оеша һәм чиркәве эшли *(Мухамедьяров Ш.Ф. Күрс. хезмәт. С. 182-192).*

Ханлык җирләрендә тагын бер төркем православие дине вәкилләрен казанлылар рус җирләренә ясаган һөҗүмнәр вакытында алып кайткан әсирләр тәшкил иткән. Аларның беркадәре, бигрәк тә сугышчылар, дөнья базарына кол итеп сатылган. Әйтик, Казан ханы Сәхиб-Гәрәй 1521 елгы уңышлы һөҗүмнән соң, әсирләрне Әстерхан каласы базарына сатарга озаткан.

Күпчелек кол-чура исә Казан дәүләтендә калган, һөнәрләре булганнары калаларда товар җитештерүгә җәлеп ителгән, күпчелеге бәкләр, морзалар, огланнар һәм казаклар хуҗалыкларында хезмәтче яки игенче хезмәтен башкарган. Иван IV заманында язылган «Казанская история» әсәренең авторы да әсирлеккә эләккәч, ислам динен кабул иткән, Сафа-Гәрәй ханнан күп яхшылыклар күргән, анда хезмәттә булган һәм 20 ел Казанда яшәгән шәхес була (*Казанская история / подг. текста, вступ. статья и примечания Г.Н. Моисеевой. М., Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1954. С. 44).*

Ханлыкта крепостное право булмаган. Австрия дипломаты С.Герберштейн сүзләренә караганда, алты ел эшләгәннән соң, бу әсирләр ирек алганнар, башка игенчеләр кебек үк, үз хуҗалыкларын булдырганнар, ләкин илдән китә алмаганнар (*Герберштейн С. Күрс. хезмәт. С. 175*). Бүгенге көнгәчә бу православ төркемнең саны буенча галимнәр арасында фикерләр төрлелеге яшәп килә.

Мөселман дин әһелләре бу төркемне дә дәгъватләгәннәр. Ләкин дин иреге сакланган, күпчелек әсирләр православ динендә калганнар.

Бүгенге көндә Рус православ чиркәвенең «изге шәһидләре» (святые мученики) исемлегенә Казан ханлыгында яшәп, христиан дине өчен гомерен биргән өч шәхес кертелгән. Аларның тарихларын язган һәм рәсмиләштергән кеше – Урта Идел буенда христиан миссионерлыгын җәелдерүгә күп көч куйган Казан архиепископы Гермоген. Бу текстлар буенча Яңа Иоанн – ислам динен кабул итәргә теләмәгән өчен 1529 елда мөселманнар тарафыннан һәлак ителгән рус әсире, ә Стефан һәм Пётр – чукынган һәм мөселманлыктан баш тарткан өчен 1552 елда үтертелгән татарлар (яңа керәшеннәр). Казан архиепископы Гермогенның тәкъдиме белән, бу шәхесләр 1592 елда Рус православ чиркәвенең «изгеләре» исемлегенә кертелгәннәр (*Загидуллин И.К. Празднование в России покорения Казани во второй половине XVI – начале XX веков // Казанское ханство: актуальные проблемы исследования. Казань: Институт истории АН РТ, 2002. С. 20-21*). Әмма бу «тарихлар»ның язылуы XVI гасырның соңгы чирегендә миссионерлык максатында – мөселманнарны яңа чукынганнар төркемнәренә каршы кую өчен дә эшләнгән булырга мөмкин.

Гомумән алганда, Казан ханлыгында конфессияләр һәм төрле дин тарафдарлары арасында киеренкелек күзәтелмәгән. Биредә урнашкан дин иреге күп кавемнәр яшәгән илдә дәүләтнең хөр тормыш нигезе һәм хан хакимиятенә барлык кавемнәрдә лояльлек тәрбияләүнең алшарты булган дип әйтсәк, ялгышмабыз.

Килешеп яшәүнең тагын бер мөһим элементы – мәҗүси дин тотучыларның гражданлык хокукы өлкәсендә ата-бабадан килгән гадәтләрне куллана алуы. Вак-төяк җинаятьләр дә шушы хокук системасы буенча хәл ителгән, авыр җинаятьләрне хан һәм башкарма хакимият тикшергән һәм карар чыгарган. Аерым очракларда Чыңгыз ханның Ясасы кулланылган булырга мөмкин (*Мухамедьяров Ш.Ф. Күрс. хезмәт.*

*С. 235).* Мәсәлән, ислам дине кануннарына каршы килеп, чыңгызлы ханнарны элеккечә табутта күмү тәртибе сакланып калган. Шул рәвешле, Казан ханлыгында төрле кавем һәм дин тарафдарлары арасында берничә хокук системасы кулланылган: шәригатьтән тыш, хан кануннарына, Чыңгызхан Ясасына һәм көндәлек тормышта һәм җир биләү мәсьәләләрендә гадәткә мөрәҗәгать иткәннәр.

## Сәедләр

Казан ханлыгында мөселман руханиларының рәсми җитәкчесе булып, баш сәед торган. Сәедләр гаиләләрендә тәрбияләнгән бер угылны хан руханилар өстеннән җитәкче итеп куйган. Димәк, шәригать һәм дөнья гыйлеме, дәүләт эшләрен аңлауны таләп иткән бу җаваплы вазифага балачактан ук хәзерләгәннәр. Күрәсең, сәедләр гаиләләрендә тәрбияләнгән һәм белемле башка угыллар да шулай ук әһәмиятле дини вазифалар биләгәннәрдер.

Казан ханлыгы сәедләренең исемнәре рус елъязмаларында теркәлеп калган: алар, нигездә, дәүләтара мөнәсәбәтләр һәм илкүләм вакыйгалар уңаеннан телгә алыналар. Эш шунда ки, сәед Казан дәүләте социаль иерархиясендә ханнан соң икенче баскычтагы кеше саналган. Аның югары дәрәҗәгә ия булуы ханлыкта хакимият кризисы вакытында, бигрәк тә тәхеттә хан булмаган вакытта бик калку күренгән. Баш сәед яңа хан сайлау мәсьәләсендә дә үзенең тәэсирле сүзен әйткән *(Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 104*).

«Галимнәрдән, хөрмәткә лаек габбасилардан һәм бөек сәедләрдән күпмедер шәхес булып, аларның башында нәкыйль-әшрәф (бөекләрнең җитәкчесе. – **тәрҗемәче**) дип танылган [...] зат тора. Ул ислам ханнары һәм шәһәр халкы алдында ихтирамга һәм зур хөрмәткә ия булган», дип шәрехли Ш.Мәрҗани (*Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 199-200 б.).* Җәмәгать урынында Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән дип кабул ителгән руханилар җитәкчесен ничек хөрмәтләгәннәрен С.Герберштейн җентекләп сурәтләгән: хан сәед каршына чыгып һәм баш иеп, аның кулына орынган. Башка түрәләр, бәкләр фәкать аның аягына, ә гади халык киеменә яки атына кагыла алган *(Герберштейн С. Күрс. хезмәт. С. 176).*

Тарих фәнендә иң яхшы өйрәнелгән ислам институтлары Кырым ханлыгына карый. Алтын Урда дәүләтендә салынган дини традицияләр урта гасыр татар ханлыкларында дәвам иткәнен һәм Казанда Гәрәй нәселе вәкилләре утырганын истә тотып, андагы кайбер элементлар Казан җирлегендә дә урын алган дип әйтергә мөмкин. Сәед, дәүләт эшлеклесе һәм руханилар җитәкчесе буларак, Кырым ханлыгында кебек (анда бу дәрәҗә биләүче мөфти дип аталган) беркадәр хезмәт хакы алган дип уйлыйбыз (Кырымда хезмәт хакы, шулай ук, кадиэскәр, ягъни гаскәрнең баш руханиена да түләнгән). (*Мусульманское духовенство Таврической губернии в конце XIX века: рапорт В.В.Вашкевича: сборник документов / сост., авт. предисл., прим. и сокр., сост. указ. И.К. Загидуллин. Казань: Государственный комитет Республики Татарстан по архивному делу, 2016. С. 31).*

Чыганаклардан күренгәнчә, Илһам хан тәхеттә утырганда, баш сәед булып Тәвәккәл исемле кеше торган. Аны Касыйм сәед алыштырган. Әйткәнебезчә, сәедләр, урта гасыр татар дәүләтләрендә билгеле һәм хөрмәт ителгән аксөяк катламы буларак, бер илдән икенчесенә күченеп тә йөргәннәр. 1489 елда Казанда булган Касыйм сәед 1490-1491 елларга караган рус елъязмаларында Нугай Урдасында телгә алына. Касыйм сәедтән соң 1491 елда Казанда Бараш сәед исеме атала: ул Казан ханы һәм Бөек Мәскәү кенәзе гаскәрләрендәге ике воеводаның берсе сыйфатында Олуг Урдага каршы сугышка чыккан Кырым ханы Миңле-Гәрәйгә ярдәмгә бара. Казан аксөякләре 1497 елда аны, Бөек кенәз гаскәриләре белән бергә яу чапканын искәртеп, дәүләтнең илчесе сыйфатында хан итеп җибәрүне сорап, Мәскәүгә язалар. 1507 елда ул Мәскәүгә

Мөхәммәд-Әминнең вәкаләтле вәкиле булып, ике дәүләт арасында яңа килешү төзү өчен бара.

1512 һәм 1516 елларда Казаннан Шаһхөсәен сәед Мөхәммәд-Әминнең вәкаләтле вәкиле сыйфатында дәүләт эшләре белән Мәскәүдә була. Күрәбез, ул Мәскәү яклы сәясәт уздыра, ә 1524 елда Казан тәхетенә утыртылган яшүсмер Сафа-Гәрәйне үтерергә теләүдә гаепләнеп, һәлак ителә (*Исхаков Д.М. Сеиды в Казанском ханстве // Кул Шариф и его время. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. С. 54-55*). Этнолог Д.М. Исхаков аннан соң Казан дәүләтенең баш сәеде Боерган исемле шәхес булган дип фаразлый.

1545 елда Казан аксөякләре мөрәҗәгате буенча Бөек Мәскәү кенәзе тәхеткә кабат Шаһгалине җибәргәч, җәй көне Казанга Әстерхан ханлыгыннан Мансур сәед килә. Сафа-Гәрәй үзенең берничә дистә яугирләре белән Казаннан Әстерханга кача. Әйтелгәнчә, Әстерхан ханыннан һәм нугайлардан гаскәр алып килеп, 1 ай узгач, тәхетен кире кайтара һәм баш сәед итеп, әлеге Мансур сәеднең улы Колмөхәммәдне билгели. Бу сәед 1550 елның февралендә шушы җаваплы вазифаны башкара, Казан кирмәне диварларында башка дәрвишләр һәм суфилар белән Бөек Мәскәү кенәзе гаскәриләренә каршы сугыша. Кабат Казан тәхетенә утырган Шаһгали 1551 елның октябрендә үзенә каршы заговорда катнашканы өчен 70 аксөякне үтертә. Күрәсең, бу төркемдә баш сәед Колмөхәммәд тә булган.

Казан тарихының хәлиткеч көннәрендә рус елъязмаларында «Кулшәриф мулла» исеме белән аталып килгән шәхес баш сәед итеп билгеләнә. Ул да Әстерхан сәеде Мансурның улы була. Колшәриф сәед 1552 елның 2 октябрендә Иван IV нең гаскәрләре Казан кирмәненә бәреп кереп, Хан сарае янына җиткәч, мәчет янындагы мәдрәсә шәкертләре, суфилар һәм башка дин әһелләре белән бергә канлы бәрелештә шәһид китә (*Полное собрание русских летописей (ПСРЛ). Т. XIII. Ч.1. С. 218*).

## Мөселман руханилары

Казан ханлыгында мөселман дин әһелләре дәрәҗәләре, гыйлемнәре һәм җәмгыятьтә тоткан урыннары буенча берничә төркемгә бүленә.

Беренче төркем – шәригать мәхкәмәсендә хезмәт куючы *казыйлар* турында инде сүз булды.

Һәрбер мөселманның изге бурычы саналган хаҗ сәфәренә – ерак һәм куркыныч юлга чыгу өчен зур теләк, күп акча, шәхси батырлык һәм сабырлык таләп ителгән. *Хаҗилар* мөселман җәмгыятендә һәрвакыт олы хөрмәттә булып, аларны тирән ихтирам күрсәтеп аерымлау социаль дәрәҗәләрен руханиларга тиңләштерүдә чагылган. Без хаҗга барып кайткан шәхесләрне халык арасында хөрмәтләп «хаҗи» дип йөртүләрен, әмма бу дәрәҗә рус чыганакларында чагылыш тапмауны инкарь итә алмыйбыз.

Казан ханлыгы белән бәйле берничә шәхеснең хаҗ кылырга китүе турында хәбәрләр тарихи чыганакларда сакланып калган. 1494-1495 елларда Нурсолтан (1519 елда үлә) хаҗ сәфәренә 50 кешедән торган хезмәтчеләр һәм яугирләрдән торган төркем белән бара, Мисырда һәм Гарәбстанда, Мәккә һәм Мәдинә калаларында булалар. Исән-сау әйләнеп кайткач, Бөек кенәз Иван III кә дуслык билгесе итеп, бүләккә ерак сәфәрдә булган атын җибәрә (*Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 180-181).* Сәхиб-Гәрәй ханның хаҗ кылу сылтавы белән Казан тәхетен Сафа-Гәрәйгә калдырып китүе билгеле. Шагыйрь Мөхәммәдьяр үзенең «Мәхмүд хаҗи углы» булуын күрсәтә.

Чыганакларда телгә алынган «*хафизлар*» дип, Коръәнне яттан белүчеләрне атыйлар. Бу исемгә лаек булганнарның күпчелеген мәдрәсәдә укыган яки остазыннан белем алганнар тәшкил иткән. Изге китап аятьләрен яттан укучы руханилар һәм суфилар халык арасында аеруча абруйлы саналган. Димәк, дәүләттә Коръәнне дөрес

итеп укырга һәм ятларга өйрәтүче мәктәпләр уңышлы эшләп килгән. Коръән хафиз арасында рәсми рәвештә рухани вазифасын башкармаган шәхесләр дә булырга мөмкин. Коръәнне укый белгәннәре өчен болар мәҗлеснең түрендә булып, төрле дини чараларда катнашканнар һәм, шулай ук, руханилар дәрәҗәсендә саналганнар. Бер үк вакытта хафизлар дип, канцеляриядә кәгазьләр күчерүчеләрне һәм, гомумән, укый-яза белгән кешеләрне дә атаганнар (*Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа. (Истоки, становление и развитие). Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. С. 226)*.

Кырым ханлыгында урнашкан тәртипне күздә тотып, без Казан дәүләтендә дә һәрбер руханиның үз вазифасы булган һәм ул башка дин әһелләренеке белән кисешмәгән дигән фикердә торабыз.

Алтын Урда суфи исламы Казан ханлыгында өзелмәгән. Чыганакларда суфи тарикатьләр вәкилләре «шәехләр», «шәех-задәләр», «ишаннар» «дәрвишләр», «суфилар» дип исемләнә. Бу исемлектәге шәехләр һәм ишаннар укучылар – мөридләр хәзерләгәннәр.

Нәкышбәндия тарикате вәкилләре диннең барлык өлкәләренә дә зур йогынты ясаганнар. Казан ханлыгы шагыйрьләренең язма мирасында суфичылык идеяләре мөһим урынны алып тору, традицион ислам институтларын гәүдәләндергән имам һәм хатыйбларның күпчелеге Нәкышбәндия тарикате тарафдарлары булган дип уйларга төпле дәлил булып тора.

*Имамнар һәм хатыйблар* кала һәм сала мәчетләрендә хезмәт куйган, биш вакыт намазга, җомга, Корбан һәм Ураза бәйрәмнәрендә җәмәгать намазларына җитәкчелек иткән. Алар, нигездә, вакыфлардан килгән табыш хисабына һәм җыелган сәдакага яшәгәннәр дип уйланыла. Кырым ханлыгындагы кебек, башкаланың берничә дәрәҗәле мәчет руханиларына хезмәт хакы түләнгән булуы мөмкин (*Мусульманское духовенство Таврической губернии в конце XIX века: рапорт В.В.Вашкевича: сборник документов. С. 31)*. Биредә сүз, беренче чиратта, хан сарае, дәүләт идарә оешмалары урнашкан Эчке кирмәндәге сигез манаралы Җәмигъ мәчете һәм Кол Шәриф мәчетләре турында бара. Имамнар һәм хатыйблар, шулай ук мәктәп-мәдрәсә мөгаллимнәре төркеменә чыганакларда очраган «мулла» һәм «мулла-задәләр»не (мулла уллары) кертеп буладыр.

Руханилар исемлегенә *остазлар* (мөгаллимнәр, укытучылар) кергән. Инде әйтеп үтелгәнчә, мәдрәсәләрдә укыган һәм аларны тәмамлаган кешеләр, укый-яза белүчеләр буларак, дин өлкәсеннән тыш, кәгазь эше белән бәйле башка өлкәләргә җәлеп ителгән. Ягъни мәдрәсәләр Казан дәүләтенең интеллектуал элитасын хәзерләү һәм укыту белән шөгыльләнгән. Аларда, шулай ук, аксөяк балалары да белем алган. Казанда урнашкан баш дини уку йортыннан тыш, башка олыс административ үзәкләр мәчетләренең күбесе янында мәдрәсәләр эшләгән дип фаразлана. Муллалар һәм имамнарның гыйлемлеләре мәдрәсәләрдә укыту белән шөгыльләнгәннәр. Шулай ук шәехләр укырга-язарга өйрәтүче мәктәп-мәдрәсәләр ачкан.

Күпчелек мәктәп-мәдрәсәләр һәм мәчетләр ханнар, бәкләр бүләк иткән вакыф җирләре хибасына яшәгән дип уйларга нигез бар. М.Худяков «Хуҗасәет», «Колсәет» исемле татар авыллары урнашкан җирләр – ханлык чорында сәедләрнең вакыфлары булган урыннар, «Мәмәтхуҗа», «Шәехзадә», «Арышхаздә», «Дәрвиш» (Дербышки) – төрле төркем дин әһелләренә бирелгән вакыф җирләре дигән фикер әйтә (*Худяков М. Күрс. хезмәт. С. 198)*. Идел-Урал буе халыклары арасында исламны җәелдерү буенча төп үзәкләрнең берсе булган Казанда үз заманы өчен зур таш һәм агач мәчетләр, күпсанлы мавзолейлар – «изгеләр», ханнар һәм башка шундыйларның төрбәләре төзелгән. Шагыйрь Мөхәммәдьяр үзенең «Нуры содур» әсәрендә Мөхәммәд-Әмин ханның төрбәсе янында мөҗавир-сакчы булып торганын искәртә. Мөселманнар мондый төрбә-каберләр янына «изгеләр» рухына намаз укып, үзләренең үтенеч-

теләкләрен җиткереп, якындагы чишмәдән су яки кабер туфрагын үзләре белән алып киткәннәр.

Ислам мәдәнияте турында сөйләгәндә, аның Алтын Урда таркалгач барлыкка килгән ханлыкларда уртак яклары күп булуын истә тоту мәслихәт. Бирeдә, Кырым ханлыгында кебек үк *(Зайцев И.В. Исламская культура Крымского ханства. Исламская организация // История крымских татар. Т.III. Крымское ханство XV–XVII вв. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2021. С. 630),* иң зур ислам бәйрәмнәренең берсе булган Корбан гаете зурлап уздырылган. Мондый олы дини чараның үзәк вакыйгасы бәйрәм намазына җыелган халыкка Коръән сүрәләрен вәкарь белән матур итеп көйләп укудан гыйбарәт. Әлбәттә, ислам мәдәниятенең бу өлкәдә дә үз мәктәбе, остазлары, осталары булган.

Ханлыктагы ислам язу традициясе хакында да әйтү сорала, чөнки дини белемнәрне саклау һәм таратуда кулъязма китаплар күчерү һөнәре мөһим урын тоткан. Сүз, беренче чиратта, Коръәнне һәм тәфсирләрне, шулай ук башка дини текстларны күчерү турында бара. Китапларның ислам тәгълиматын популярлаштыру һәм буыннан буынга тапшыру формасы икәнен искәртсәк, кулъязмаларның төрле төбәкләргә таралган, бер илдән икенчесенә күчеп йөргән иң күпсанлы һәм кыйммәтле дини артефакт икәнен аңлау кыен түгел. М.Г. Госманов Идел һәм Урал буйларында, Көнбатыш Себердә Кырымда язылган кулъязмалар очратканын искәртә *(Зайцев И.В. Письменная культура Крымского ханства. Исламская организация // История крымских татар. Т.III. С. 609).* Кулъязма китаплар, кыйммәтле язма байлык сыйфатында, галимнәр һәм мәдрәсәләр китапханәләрендә сакланган.

## Чыганакларда дини тәгълимат

Сакланып калган хезмәтләрдән, 1508 елда ук башкарылган «Коръән тәфсире», Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы, әйткән сүзләре (хәдисләр) җыелмасы (1552 ел) төбәктә дини фикерләүнең чагылышы булып киләләр. Бу кулъязмалар Казан дәүләтендә дин әһелләре арасында ислам тәгълиматын өйрәнү, фикерләү һәм тарату һәйкәлләре булып тора (*Давлетшин Г.М.Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа. (Истоки, становление и развитие). Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. С. 226).*

Мәскәүгә илче булып баргач, төрмәгә ябылган татар укымышлысы Адниш хафиз бине Мөхәммәд-Аднаш хафизның фарсы теленнән тәрҗемә итеп, Рабгузиның «Кыйсассел-әнбия» һәм авторы билгесез «Мәликә китабына» бик охшаш һәм суфичыл эчтәлекле «Сиражел-колүб» исемле дини-әдәби сюжетлы әсәр язганлыгы билгеле *(Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов А. Әднәш Хафиз. «Сираҗел-колүб» // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф.Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 149, 151 б.).*

Мөхетдин әл-Хаҗи Атмаҗиның «Мәҗмәгыл кавагыйдә гыйльме хисаб» («Арифметика фәне кагыйдәләре җыентыгы») хезмәтенең В.М. Беркутов 1542 елда язылганын билгели *(Беркутов В.М. Народный календарь и метрология болгаро-татар. Казань: Таткнигоиздат, 1987. С. 28.),* иртәрәк вакытка тәгаенләүче галимнәр дә бар.

Язма чыганакларга булган кытлык, чор дини тәгълиматының кайбер чалымнарын ачыклау өчен ул заман татарлары язган текстларга мөрәҗәгать итәргә этәрә.

Дәүләт кәгазьләрендә һәм идарәче чыңгызлыларның тамга-мөһерләрендә шәһадәт кәлимәсе кулланылу хакында Сәхиб-Гәрәй ханның 1523 елгы ярлыгы мисалында искә алган идек.

Галим-текстолог Зәки Вәлиди Туган 1965 елда Төркиядә тапкан һәм фәнни әйләнешкә керткән шагыйрь Шәрифи Хаҗитарханиның «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» (Казан иленең (дәүләтенең) җиңүе) исемле тексты – башкаланы 16 көн

дәвамында Мәскәү гаскәрләреннән саклап, җиңгәннән соң 1550 елның февраль аенда төрек солтанына яки Кырым ханына юлланган әдәби-публицистик әсәр – урта гасырларга хас җиңү турында реляция төзү кагыйдәсенә туры китереп, тантаналы төстә язылган. Беренче чиратта, бу текст рус чыганакларында «Казан ханлыгы» дип аталган дәүләтнең үз халкы тарафыннан «Казан вилаяте» дип йөртелгәнен хәбәр итүе белән кадерле.

Шәрифи әсәренең проза өлешендә Коръәннән 29 аять һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең берничә хәдисе китерелгән, алар, нигездә, авторның фикер-сүзләрен көчәйтү өчен кулланылганнар. Биредә авторның Коръән сүрәләрен, хәдисләрне бик яхшы белүен һәм урынлы файдалануын әйтү мәслихәт. Дини текстлардан тыш, әсәрдә 27 шигырь һәм шигырь фрагментлары урнаштырылган. Соңгылары арасында фарсы шагыйрьләре Фирдәүси, Низами, Сәгъди, Хафиз, Җами һ.б., шулай ук чыгътай шагыйрьләренең иҗат җимешләре бар (*Мустакимов И.А. «Зафер-наме-и валийет-и Казан» Шарифа Хаджи-Тархани: некоторые итоги и перспективы изучения // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2015. №5. С. 157*). Шулай итеп, автор текстта гарәпчә, фарсыча һәм төркичә җөмләләр тезә, аны гыйлемле кешеләргә адреслый.

Мәскәү белән 1540 – 1552 елларда барган Ватанны саклау сугышларында мөселман дин әһелләре идеологлар буларак чыгыш ясаганнар, сугышчыларны һәм халыкны рухландырып һәм үсендереп торганнар, Ватанны саклау фикерен мөселманнар өчен аңлаешлы дини категорияләр белән җиткергәннәр. «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» әсәрендә гаскәр башлыгы «денсез кәфер», «имансыз», «ике шайтанның берсе» дигән сүзләр белән характерлана (*Зафәрнамә-и вилаяте Казан (Победа Казанской страны) // Кул Шариф и его время. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. С. 17).* Аның сугышчылары Адәм нәселеннән булмыйча, Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ кавеменнән чыккан, ягъни борынгы татар риваятьләре буенча, ахыр заман җиткәндә чыгып, җирне кызыл балчык чыкканчы ашап килә торган каһәр *(Әхмәтҗанов М. Тәэсир // Ат тарихы язылган китап // https://tatar-inform.tatar/news/archive/08-02-2005/t-esir-at-tarihy-yazylgan-kitap-4946497. Мөрәҗәгать итү датасы 12.02.2022)* белән тиңләштерелә. Дәүләтнең башкаласын саклау мөселманнар өчен изге сугыш дигән фикер уздырыла (*Мелек Уйетгин. Ш. Шерифи. «Зафер-наме-и Вилайет-и Казан» // Гасырлар авазы - Эхо веков. 1995. Май. С. 89*). Ә Казанның ирекле булырга тиешлеге вилаятьнең һәр заман ханнар җире булганлыгы белән раслана.

«Зафәрнамә-и вилаяте Казан» әсәрендә, шулай ук, ханлык мөселманнарының биш вакыт намаз урынына дүрт намаз укулары хәбәр ителә. Ясигъ намазын Идел буендагы көн озынлыгы 17 сәгатькә җиткән айларда, офыкта шәфәкъ югалмау сәбәпле, уку мөмкин булмый дип санала. Вилаять дин әһелләре күзәтүендә булган намаз уку вакытлары күренекле ислам хокукы белгечләре Имам Мөхәммәд бине Идрис әл Шәфигый (руми 820 елында үлгән) һәм Әбү Йосыф (руми 798 елында вафат булган) фәтваларына нигезләнә. Шулай ук 1310 елда үлгән Хафизетдин бине Бәрәкәт әл-Нәсифиның «Кенз үл-дәкайык», «Әл-вафи фи-л форуг» һәм «Әл-кафи» китапларында китерелгән дәлилләр күздә тотыла (*Зафәрнамә-и вилаяте Казан (Победа Казанской страны). С. 16, 20).*

Сакланып калган текстлар бу чор иҗатчыларының – мөселманнар, укымышлы дин әһелләре, алай гына да түгел, суфилар булуы турында сөйли. Без телгә алган сәед Кол Шәриф үзенең суфи шагыйрьләр Әхмәт Ясәви белән Сөләйман Бакырганины остазлары дип санавы хакында искәртә. Кол Шәрифнең шигырьләре суфиның Аллага якынаю юлын сурәтлиләр: бу юлдагы тәүбә, зөһед, зикер турында сөйлиләр. «И Кол Шәриф, тынмагыл, төнләр йатып оймагыл, / Хак зикрене куймагыл, гафил йөрмә, һу тигел», ягъни төннәр буе Аллаһу зикерен әйт дип, үз-үзенә эндәшүче шагыйрь укучысын да Аллага якынаю юлына өнди. Яки Идел буенда XV гасыр уртасында яшәгән Өмми Камалның «Өмми Камал китабы»на тупланган, күпчелеге

икеюллыклар, дүртьюллыклар булган 140 шигырь шулай ук суфичылык мотивлары белән сугарылган.

Казан ханы Мөхәммәд-Әминнең «Гыйкаб» («Үч») дигән шигыре Аксак Тимер образын Болгарны – «ислам йортын» – җимерүче буларак тергезә. Бу әсәр әдәби иҗатның бик югары, ханнар шөгыле дәрәҗәсендә йөрүен искәртә.

Казан ханлыгы чоры әдәбиятының иң күренекле вәкиле булып танылган Мөхәммәдъяр (1497 ел тирәсе – 1552) үзеннән соң 2 зур әсәр – «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге», 1540) һәм «Нуры содур» («Күңелләр нуры», 1542) поэмаларын калдыра. Аларда Аллага мөрәҗәгатьләр, мәдхияләр үтәли күзәтелә.

7 хикәятне берләштергән «Төхфәи мәрдан» поэмасы яхшылыкның һәрвакыт явызлыкны җиңеп чыгуы турында сөйли, укучыны ислам дине кушкан әхлак кагыйдәләрен үтәп яшәргә өнди. «Нуры содур» поэмасы да һәрберсе бер әхлак сыйфатына багышланган 10 бүлектән тора: гаделлек, киң күңеллелек, юмартлык, кыюлык, тыйнаклык, сабырлык, сүздә тору, тугрылык, гафу итү һ.б. Бу поэмалар да ислам әдәбияты юнәлешендә, дини-дидактик характерда иҗат ителгәннәр.

Казан татарларында таш кисеп, бизәк ясау сәнгате кабер ташларында сакланган. Ханлыкның бүгенге көндә Татарстан, Чувашстан, Мари Иленә караган җирләрендә шушы дәвернең 297 кабер ташы билгеле. Кабер ташларына Коръәннән өзекләр дә, күренекле шагыйрьләрнең әсәрләре дә язылган. Шуларның 80ендә куелу вакыты, шәхеснең исеме, титулы турында мәгълүмат сакланган. 18 очракта җирләнүчеләрнең «кяфер кулындин», «Мәскәү» яки «Урыс явы килгәндә» шәһид китүләре искә алынып күрсәтелгән (*Гариф Н.Г. Казан ханлыгы чоры ташъязмалары. Казан: ТФА Тарих институты басмаханәсе, 2010. 12-38 б.).*

Урта гасыр татар эпиграфик һәйкәлләрен өйрәнү өлкәсендә зур белгеч Җ.Г. Мөхәммәтшин җирләнгән шәхесләрнең кабер ташларында язылган дәрәҗәләрен, шөгыль-һөнәрләрен, туган-тумачалык билгеләрен аерымлап чыкты. Шулар арасында дин әһелләренә караган түбәндәге исемнәр атала: сәед, шәех, ишан, суфи, дәрвиш, остаз, мулла, хафиз, хаҗи (*Мухаметшин Д. Эпиграфические источники Казанского ханства XV – первой половины XVI вв. // Средневековые тюрко-татарские государства. № 7. 2015. С. 112*).

Бу чорда иҗат ителгән күпләгән дастаннар, бәетләр, тарихи җырлар, риваятьләр, гасырларны узып, безгә дә килеп җиткән. Казан каласының корылуы, ханлыктагы тормыш, тарихи шәхесләр хакында сөйләүче риваятьләр һәм легендалар («Шәһәр нигә Казан дип аталган», «Сөембикә», «Шәриф-кол», «Иске Казан каласының корылуы» һ.б.) белән беррәттән, Казанның егылу хакындагы сюжет та («Казан алынганы», «Иван Грозный ничек итеп Казанга сугыш ачкан») еш очрый. Әйтик, «Казан алынганы» риваятендә «...мөселман ханнары вакытында Казан шәһәре бик төзек торды. Голәмалары вә мөдәррисләре вә һәм көтепханәләре күп иде вә талибләре күп иде», дип әйтелә *(Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 55 б.).*

Казан ханлыгы тарихына нисбәтле тарихи җырлар («Казан тарихы», «Сөембикә китеп бара», «Тоткын Сөембикә китеп бара»), бәетләр («Казан бәете», «Сөембикә бәете») дә Казан ханлыгы чоры вакыйгаларын тергезә. «Казан бәете»ндәге: «Газыйлары күп иде, меллалары чук иде, / Галимнәре күп иде, заманы Ядегәр ирдея» (газый – ислам дине өчен көрәшүче) тезмәләре шундыйлардан. Күләмле әсәрләр – *дастаннарда* («Чура батыр», «Җик мәргән», «Гайсә улы Амәт») Казан ханлыгы чорының тынгысыз вазгыяте үзәккә куела. Галимнәр фикеренчә, татар дастаннарындагы героика дини героика белән алышына башлый. Моңа кадәр үз көченә генә ышанган герой сугыш-көрәш картиналарында Аллаһка тапшырып эш итә, вакыт исәбе дә, хәтта намаз вакыты белән билгеләнә, намаз вакыты кергәч, сугыш туктап тора, мәчетләр телгә алына. Бу һәм башка элементлар әлеге конкрет-

тарихи эпосны исламга якынайта, Казан ханлыгындагы төп идеологиянең ислам кысаларында булуын искәртә *(Ибраһимова Л.Х. Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. 7–27 б.*).

Алтын Урда таркалгач, бу территориядәге элекке берлек элементлары булып, яңа оешкан дәүләтләрнең башында чыңгызлылар утыру һәм идарә системасының охшашлыгы тора. Сәяси институтлардан тыш, Алтын Урда заманында барлыкка килгән дини вазгыять һәм исламлашу утрак тормыш рәвеше алып барган төбәкләрдә тагын да көчәя. Ясәвия тарикатеннән чыккан, бу елларда көч алган һәм аны алыштырган Нәкышбәндия суфилары арасындагы рухи бердәмлек һәм аралашуны махсус атап китү сорала. Бердәм дини-мәдәни кырның төп элементлары дип язма телләр (гарәп, фарсы һәм төрки), дини менталитет, икътисади элемтәләр, сәүдә кәрваннары аша дини кулъязма китаплар һәм мәгълүмат таралу, мәмләкәтләрдәге уку йортларына төрле төбәк-илләрдән шәкертләр килү, шулай ук дәүләтара мөнәсәбәтләр кысаларында барган дини-мәдәни бәйләнешләр тора. Әйтик, 1412 елда Кырым ханлыгында булган күренекле галим, тарихчы һәм шагыйрь Ибн Гарәбшаһ (1450 елда үлә) биредә галимнәр һәм шагыйрьләр белән, шул исәптән Мәүләнә Мәхмүд әл-Болгари белән дә очрашуын язып калдырган *(Абдульвагапов Н.Р. Система образования в Крымском ханстве // История крымских татар. Т.III. С. 541).*

Бер үк вакытта дәүләт органнарының һәм руханиларның эшчәнлеге, даими диярлек булып торган тышкы куркынычка каршы тору, илкүләм мәсьәләләрне тикшерү һәм карар кабул итү өчен уздырылган Корылтайлар аксөякләрне һәм «кара халык»ны Казан вилаятен газиз Ватаннары итеп күрергә һәм аны яклап көрәшергә өйрәткән. Мондый караш мәҗүси диннәр тотучы кавемнәргә дә хас булган.

Казан дәүләтендә барча руханиларның тарикать әгъзалары булуы, «мөршид – мөрид» элемтәләренең ныклыгы югарыда аталган дини кырны ныгытып торган. Казан вилаятендә исламлашуның көчәюе хакимият кайгыртуы хисабына барган. Ислам тәгълиматы, дәүләт эшләрендә катнашкан сәедләр институты, мәктәп-мәдрәсә системасы аша руханилар һәм дәүләт оешмалары өчен укый-яза белүче катлам вәкилләрен хәзерләү, суфилар, мәчет-мәхәлләләр һәм вакыфлар Казан илендәге ислам мәдәниятенең төп элементлары дип күрсәтелә ала.

Башкаланың канлы бәрелештә җимерелүе һәм талануы, 1552-1557 елларда Урта Идел төбәгендә җәелгән милли-азатлык рухлы «Казан сугышы», элита вәкилләренең чит төбәкләргә качып-күченеп китүе һ.б. сәбәпләр дәүләт тарихына һәм мәдәниятенә кагылышлы кадерле язма истәлекләрнең юкка чыгуына китергән. Шуңа күрә бу өлкәдә әле күпсанлы ак таплар кала бирә.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*



Алмаз
Гыймадиев

# КИЛӘЧӘКТӘН КИЛГӘН МАЛАЙ*

ҮСМЕРЛӘР ӨЧЕН ПОВЕСТЬ

**«Көләргә җыенасызмы миннән?»**

Ниндидер чит-ят бүлмәдә уянып киттем. Зур тимер караватта ятам. Баш астымда – алагаем зур мендәр. Өстемә шакмаклы одеял ябылган. Бөтен тәнем сызлый. «Аллага шөкер, исән калганмын!» дигән сөенечле уй баштан сызылып үтте. Шулаен шулай, ләкин кайда соң мин? Авыл өе бугай. Стеналар бүрәнәдән. Бүрәнә арасыннан мүк, сүс кисәкләре тырпаешкан. Уңда – иске шифоньер. Аның янында өч зур көзгеле, мин моңарчы күрмәгән ниндидер йорт җиһазы. Почмакта дүрт нәзек аяк өстендә борынгы, дүртпочмаклы телевизор акаеп утыра. Баш миемнең барлык шөрепләрен эшкә җигеп, кичәге хәлләрне искә төшерергә азапландым.

...Апрельнең соңгы көннәре. Шәһәр җәйгә әзерләнә. Асфальтта карлар эреп бетеп, газоннарда быелгы яшь үләннәр борын төрткән вакытлар иде бу.

Дәресләр бетүгә, безне директорга чакырдылар. Икенче каттагы имән ишек янына җыелыштык. Директор апа безне көтеп тора иде инде:

– 9нчы «б»мы?.. Әйдә, рәхим итегез...

Стена буйлап тезеп куелган затлы урындыкларга кысыла-кысыла утырыштык. Директор йомшак кәнәфиеннән торып, тәрәзә янына килде. Язгы табигатькә бераз карап торганнан соң, безгә борылды:

– Ни өчен чакыруымны чамалыйсызмы?.. – диде ул, күзлеген салып, пыяласын нәни чүпрәк кисәге белән сөртә-сөртә. – Юкмы?.. Уку елы ахырына якынлаша бит. Күп калмады. Тиздән имтиханнар... Аннары... Әйдәгез, ачыктан-ачык сөйләшик әле, киләчәктә кем булырга телисез?.. Нинди профессияне сайларга җыенасыз? Садриев, синнән башлыйкмы?

– Банкир! – диде тегесе шунда ук, уйлап та тормыйча.

Апабыз күзлеген элеп, өстәлдә яткан кәгазь кисәгенә күз ташлады:

– Өченче класста «космонавт булам» дигәнсең...

Көлешеп алдык.

– Вәлиев, син?

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән конкурсның «Повесть (үсмерләр әдәбияты)» номинациясендә 2 урынны алган әсәр.

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ (1972) – *балалар язучысы; Абдулла Алиш, Шәүкәт Галиев һәм Шәйхи Маннур исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Без андый малай түгел», «Телефонлы кәҗә», «Селфи таягы» һ.б. дистәгә якын китап авторы. Казанда яши.*

– Менеджер...
– Менеджер кем соң ул, Вәлиев?
– Улмы?.. Костюмнан гына йөрүче, акчаны күп эшләүче әфәнде!
Тагын көлештек.
– Гатин?..
Бусы мин.
– Альберт?..
– Ә мин бу илдә калырга җыенмыйм! – дип ярып салдым мин, күземне дә йоммыйча. – Китәм! Германиягә! Йә Америкага!
Класс гөжләргә тотынды:
– Көтеп торалар, ди, сине анда!
– Мактанчык!
– Әйтмә дә...
Директор кулы белән генә ишарәләп, шау-шуны туктатты:
– Безнең илдә нәрсә ошамый инде сиңа, Альберт?..
– Минем кешечә яшисем килә! Байлыкта! Муллыкта! Бездә бит хәтта диңгез дә юк! Ә аларны карагыз... – Мин малайларга борылдым. – Нәрсә кыланып утырган буласыз, үзегез дә чит илгә таю турында хыялланасыз бит!..
Никтер бусында миңа каршы дәшүче табылмады.
...Караваттан күтәрелә төшеп, күзләрем белән тирә-юньне айкыйм. Стенага чуар кызыл келәм эленгән. Икенче стенада – борынгы сәгать. Теле як-якка чайкала, келт-келт итеп йөрүе ишетелә. Бер якта – өч бәләкәй тәрәзә. Икенче якта – ике. Алардан өй эченә сүрән яктылык сирпелгән. Әбиләрнеке төсле тәрәзә челтәрләре. Яран гөлләр...
...Кичә тагын ниләр булды соң әле? Директордан чыккач нишләдек? Берни эшләмәдек – өйләргә таралыштык. Кайтуга компьютерны кабыздым. Шулчак ишектә кыңгырау тавышы яңгырады. Әни. Сәер, эштән болай иртә кайтмый иде ул.
– Мәктәбеңдә булдым... – диде әни тонык тавыш белән. – Чакырдылар...
Нәрсә инде тагын?! Мин, гөнаһсыз кыяфәт чыгарып, аңа текәлдем. Ул урындык алып, каршыма утырды да куллары белән башын ике яктан кысып тотты:
– Кемгә охшап шундый булдың син, ә?
– Сиңа...
– Ерма авызыңны! – Әни шапылдатып, өстәлгә китереп сукты. – Ник телефонга төшердең Мәрьям апаңны?
Әһә! Иманда икән чикләвек! Анысын да әләкләп өлгергәннәр икән!
– География укытучысынмы? Кулымнан өстерәп, почмакка бастырырга маташты. Мин генә түгел, Рафаэль белән Юныс та төшерде аны. Интернетка куябыз дип куркыткач кына туктады.
– Почмакка бастыру түгел, коридорга куып чыгарыр идем әле мин сезне! Тагын дәрестә рәсем ясап утыргансыңдыр.
– Балаларга тияргә ярамый! Законы бар!
– Ашханәдә поварларга кычкыргансың...
– Дежурлар поднос кына ташырга тиеш. Ә алар безгә өстәлләрне тигезләргә кушты!
– Кулыгыз өзелеп төшә идеме тигезләп куйсагыз?
– Вообще-то, мәктәптә балаларны эшләтергә ярамый, бик беләсең килсә! Законы бар аның!
– Законнарны яхшы беләсең инде син... Әй бала, бала! Нәрсә җитми сиңа, ә?! Атаң кайтсын әле менә!..
Ләкин мин әти кайтканны көтеп тормаска булдым. Ишек төбендә торган электросамокатымны эләктердем дә чыгып сыздым. Арттан әнинең «кич белән серьёзный сөйләшү булачак!» дип кычкыруы гына ишетелеп калды. Беләм мин ул «сөйләшү»нең ни икәнен. Башта әни миңа кычкырачак, аннары әти аны тынычландырачак. Аннан икәүләшеп, миңа үгет-нәсихәт укыячаклар. Ә мин «бүтән

алай эшләмим» диячәкмен дә шуның белән вәссәлам! Миллион булды «серьёзный сөйләшү»ләр.

...И-и-их! Колак янымнан җил сызгыра, самокатның җиңелчә гүелдәве йөрәккә май булып ята. Үткән-сүткән кешеләрне аралап, зур тизлектә очам! Ачулы карашлар гына күземә чалынып кала. Йортлар, агачлар артка йөгерә. Битне йомшак җил иркәли, күздән яшь ага. Тротуардан баруы кызык түгел, юлга чыктым. Автомобильләрне узуы тагын да рәхәтрәк. Алар бөкедә утыра, ә мин – араларыннан выж да выж!

Кинәт дөньяның асты-өскә килде! Ничек болай килеп чыкты соң? Ни өчен бу хәлләр нәкъ менә минем белән булды?.. Бер мизгелгә генә светофорның кызыл уты, аннары уң яктан очып килүче мотоцикл күзгә чалынып калды. Бик каты бәрелүдән юл уртасына очтым! Көчле авырту. Аннары бушлык... Тынлык... Кояш сүнде... Бар дөнья караңгылыкка чумды...

...Ә шулай да, кайда ятам соң мин? Кемнең өендә? Самокат... Светофор... Мотоцикл... Берәр әби алып кайткан мәллә үзенә? Ә ни өчен больницага илтмәгәннәр? Берни аңлашылмый... Өйгә тәмле булып, коймак исе таралган. Кайдадыр икенче бүлмәдән радио тавышы ишетелә, диктор төгәл, матур тавыш белән сөйли: «...Сез «Социалистик Татарстан» газетасына күзәтү тыңладыгыз. Ә хәзер иртәнге концертыбызны башлыйбыз...»

Менә радио сөйләгән бүлмәдән савыт-саба шалтыраган тавыш ишетелде. Аннары... күземә күренәме дип торам... кулларын алъяпкычка сөртә-сөртә, ишектә әни күренде! Яныма килеп утырды.

– Уяндыңмы? – диде ул учын маңгаема куеп. – Төне буе саташып чыктың. Авыртамы аягың?.. Әй, бала, бала... Нәрсә җитми сиңа, ә? Ник мендегез ул иске ферманың түбәсенә? Ярый, егылып төшеп кенә котылгансыз, түбәсе өстегезгә ишелгән булса шунда?!

Нинди ферма? Нинди түбә? Нәрсә сөйли бу әни? Әни?.. Нишләп ул өстенә әллә нинди иске кофта кигән? Тырнаклары да буялмаган. Башында – яулык. Ул гомердә дә яулык бәйләми иде бит! Нәрсә соң бу?

Торып утырдым. Телефонымны эзлим. Юк бер җирдә дә.

– Әни, телефонымны күрмәдеңме?

Ул миңа сәерсенеп карады. Кабат кулын маңгаема куйды.

– Һаман саташасың, ахры... Температураң юк шикелле үзе... Нинди телефон турында сөйлисең, улым?

Аңкы-миңке күзләрем белән аңа төбәлдем:

– Ну... Минем телефон инде... «Айфон»... Самокатка менеп басканда, чалбар кесәсенә тыккан идем...

Әни аптырап, миңа карап торды да җайлап кына, кире урыныма яткызды:

– Уянып җитмәгәнсең бугай, ятып тор әле бераз! Хәзер, иртәнге нәрәдтән әтиең кайтып җитәр, бергәләп чәй эчәрбез, – диде ул ягымлы елмаеп һәм кабат теге, коймак исе килә торган бүлмәгә чыгып китте.

Тә-әк... Ниндидер «розыгрыш» бугай бу. Әти белән әни никтер мине больницага түгел, бирегә – чит-ят авылга алып килгәннәр. Сәер...

Шулчак шыгырдап, ишек ачылуы, әнинең «кайттыңмы?» дип дәшүе ишетелде. Әти тавышы. Менә алар мыдыр-мыдыр сөйләшергә керештеләр. «Ничек хәлләре, уяндымы?» «Уянды, саташа бугай, ниндидер телефон турында сөйли». «Ала-ай... Каты егылган, ахры, башына зыян килмәсә ярый...» «Духтырга күрсәтеп алырга кирәктер, әтисе...» «Шулай итик...»

Мин аяк-кулларымны юрган астыннан чыгардым. Исән-саулар. Хәтта җәрәхәт эзләре дә күренми. Ярар, болай ятып булмас. Киенергә кирәк. Ә кайда киемнәрем? Кайда «найк» дигән футболкам? «Адидас» дигән ыштаным кайда?

– Әни!

– Әү, балам? – әни теге бүлмәдән кычкырды.

– Кая минем киемнәрем?

– Шунда, урындык өстендә!

Урындык өстенә күз салдым. Анда тузып беткән иске кара трико белән бабайлар гына кия торган ак төстәге майка ята иде. Алар өстендә сүсәрә башлаган зәңгәр носки ауный. Точно көләргә җыена болар миннән! Инде киемнәремне үк яшереп куйганнар! Ярый, миңа соң… Бу иске авыл өендә иске киемнәрдән йөрсәң дә килешә торгандыр.

Торып киендем дә әти белән әни янына чыктым. Коймак исе килгән бүлмә кухня булып чыкты. Аның яртысын мин телевизордан гына күреп белгән алагаем зур мич биләп алган. Янәшәдә искерәк кенә газ плитәсе, анда чыжлап коймаклар пешә. Ирексездән төкерекләремне йотып куйдым. Уң якта тәлинкә, чынаяклар тутырылган ниндидер бәләкәй шкаф, бәләкәй генә өстәл, иске кызыл диван…

– Тордыңмы, егет?! – диде әти, аркамнан кагып. – Ну куркыттың син безне, ну куркыттың!

Әтигә күз салуга сискәнеп киттем – өстенә патша заманыннан калган сәләмә фуфайка кигән! Чалбары да әллә нинди зур, ямьсез, өстәвенә, машина маена буялып беткән.

– Бар, юын, ник аптырап торасың? – Әти башы белән почмактагы юынгычка ымлады. Аякларымны өстерәп, әкрен генә шунда киттем. «Мойдодыр» мультфильмындагы төсле умывальник. Суы краннан акмый, бәләкәй рычагын өскә этәргә кирәк. Юынтык суы да үзе агып китми, астагы чиләккә җыела бара. Фуу… Сасы. Сакланып кына, учыма су җыйдым. Әннекәем! Боз кебек бит бу! Ничек биткә тидереп булсын моны!

– Ничава, ничава! – дип көлемсерәде әти, минем мескен кыяфәтне күреп. – Армиягә барасың бар! Күнегә тор! Анда су җылытучы булмас сиңа!

Коймак белән чәй эчәргә утырдык. Каш астыннан гына әти белән әнине күзәтәм. Йә, әйтегез инде тизрәк бу тамашаның хикмәтен! Чишегез серне! Күпме сузарга була? Дәшмиләр. Берни булмагандай, шапыр-шопыр чәй эчүләрен беләләр. Үзләре сүз башлармы, әллә мин ялынганны көтәрләрме? Ниһаять, әти тамагын кырып куйды:

– Совхозга ике яңа комбайн кайткан, әнисе. Берсен миңа бирәчәкләр.

Әнинең йөзе яктырып китте:

– И-и… Менә бит! Эшләгән кешенең кадерен беләләр бездә! Күптән кирәк иде! Күпме чиләнергә була ул «Нива»ң белән!

Әтинең үтә дә җитди кыяфәтен күреп, ирексездән, авызым ерылып китте:

– Си-ин?.. Комбайн йөртәсеңме? – дидем авыз тулы коймагымны чәйни-чәйни. – Ай-ти программист комбайн йөртәчәкме?.. «Беспилотник»лар урынына комбайннар кайтарганнар мәллә Иннополиска?

Никтер миңа кушылып көлүче булмады.

– Бусы ни дигән сүз инде тагын? – Әти кашларын җыерды. – Нәрсә җыен тузга язмаганны сөйләп утырасың! Әтиеңнең алдынгы комбайнчы булуы белән горурланасы урында…

Булды! Түземлегем төкәнде! Минем сабырлыкның да чиге бар!

– Көләргә җыенасызмы миннән? – дидем мин, тавышымны күтәрә төшеп. – Көлегез, көл! Ярар… Мин гаепле… Самокатым да ватылгандыр… Мәктәптәге хәлләр өчен дә гафу үтенермен… Ләкин туктатыгыз, пажалыста, бу спектакльне! Һәм аңлатыгыз, без кайсы җәһәннәм тишегендә? Кайсы районда? Нинди караңгы авылда? Кемнең тараканлы өендә?

Әтинең кашлары бер күтәрелде, бер төште. Күзләре зур булып ачылды. Ул бар көченә кашыгы белән өстәлгә китереп сукты:

– Оятсыз! Бирермен мин сиңа тараканыңны! Синең башыңда ул тараканнар! Иртә таңнан кәефне бозмасаң! Көне буе теләсә кайда болганып йөрүегез җитмәгән, әле атаңа тавыш күтәрәсеңме?! Марш мәктәбеңә! Һәм туп-туры өйгә кайткан бул дәрестән соң!

– Көн саен кич чыгуыңны да туктат, улым, – диде әни йомшак тавыш белән. – Төн

уртасына кадәр йөрисез, йокың туймый, әллә нинди самакатлар, тилифоннар белән саташып йөрисең аннары көне буе... Бар, форманы ки дә элдерт мәктәбеңә! Соңга каласың...

## Ленин бабай туган көн

Үземә дә кызык тоела башлады әлеге квест. Каршы дәшми генә уенны дәвам итәргә булдым. Бу тамашаның ахырын, аның хикмәтен бик тә беләсе килә иде. Урындык башында караңгы-зәңгәр төстәге костюм-чалбар эленеп тора. Шуларны алып кидем. Форма дигәннәре шушы икән. Джинсы кебек үк матур түгел, аның каравы бик уңайлы. Костюмының сул як җиңендә нимес полицайларыныкы төсле күннән ясалган эмблемасы бар. Кояш һәм ачылган китап сурәте. Әни җилкәмә ниндидер сәер сумка асты – почтальон Нәсимә апаныкы төсле. Баскыч төбендә кроссовкиише нәрсә эзлим, күренми.

– Ботинкаң кичә балчыкка буялып беткән иде, юып куйдым, – диде әни аптырап торуымны күреп, – бүген галош киеп бар инде...

Галош?.. Миңа димәгәе... Ишек төбендә торган резин әбиләр галошын аягыма элеп, урамга атладым.

Шәһәрдә җәй иртә килә. Апрель ахырында асфальттан тузан оча башлый инде. Ә монда-а-а... Колеялы, тигезле-тигезсез пычрак юл. Юл читендә тар гына сукмак. Анысы коры. Йөреп була. Урыны-урыны белән бик нык баткак урыннары бар, андый җирләргә такта, таш кисәкләре салынган. Сикерә-сикерә, шул ташларга баса-баса, алга атладым.

Авыл күргәнем бар минем. Класс белән Болгарга, Зөя утравына барганда, авыллар аша узган идек. Ләкин бу ниндидер борынгы авыл бугай. Йортлар да искерәк монда. Коймалар да агачтан. Ә менә мәктәпләре ничава гына икән. Анысын эзләп табу авыр булмады – ике катлы таш бина әллә кайдан, ерактан балкып күренеп тора иде.

Ишек төбендә швабра тоткан апа утыра. «Тагын соңга калдың» дип шелтәләп алды ул усал карашы белән мине, аннары тугызынчы классның кайда икәнен әйтеп, физика кабинетына төртеп күрсәтте.

Каян таптылар икән 21 нче гасырда мондый ямьсез мәктәпне? Шыгырт-шыгырт килеп торган агач идәннәр. Ул идәннәрне, ачуым да бер килмәгәе, унынчы тапкыр буяганнардыр – буяулары катлам-катлам булып күпереп тора. Яшел төстәге агач ишекләр. Берсенә «Пионерлар бүлмәсе», икенчесенә «Профориентация кабинеты» дип язылган. Һе... Кызык... Тәрәзәләр дә пластиктан түгел, агачтан. Алары да муртаеп, кибеп беткән.

Мин чынлап та соңга калган булып чыктым. Дәрес башланган иде инде. Дистәләгән таныш түгел йөзләр миңа борылды. Такта янында кулына агачтан ясалган озын указка тотып, бер абый басып тора. Физика укытучысы дип аңладым. Ул сөйләвеннән туктап, елмаеп миңа текәлде:

– Гатин?..

– Исәнмесез... – дип мыгырдандым.

– Рекордны яңарттың, – диде укытучы абый, һаман да елмая төшеп. – Моңарчы 10 минутка гына соңга кала идең, бүген 20 минутка тутырдың... Молодец! Гиннесснның рекордлар китабына кертергә була үзеңне.

Колагыма пышылдаган тавышлар ишетелде:

– О-о-о, лётчик килгән!

– Ферма лётчигы!

– Парашютист диген...

Кемдер хихылдап куйды. Укытучы абыйның йөзе кинәт кырысланды:

– Утыр урыныңа, Гатин! Һәм бусы соңгысы булсын! Тагын бер соңга калсаң, мәктәпкә әти-әниең белән бергә килерсең!

Буш урын бер генә җирдә бар иде. Арткы парталарның берсендә, минеке төсле, ләкин бөгәрләнеп беткән форма кигән, тузган чәчле малай янәшәсендә. Соңрак

сөйләшә башлагач, аның әле алдагы бер теше сынык икәнлеге дә беленде. Ике дә уйламый, шуның янына атладым.

– Привет!

– Сәлам, Альберт!

Дәрес бара. Укытучы абый ниндидер молекуляр-кинетик теория турында сөйли. Ә мин шаккатып, тирә-юньне күзәтәм. Бөтен нәрсә ят монда. Сынык тешле малай кем ул? Ник ул исемемне әйтеп исәнләште, ә мин аны бөтенләй белмим?.. Уң якта, борын астында нәзек төкләр күренә башлаган усал карашлы малай – анысы кем? Ә сул яктагы коңгырт чәчле, зәңгәр күзле кыз?.. Кемнәр болар? Кемнәр арасына килеп эләктем мин? Нигә монда тактаны укытучы абый түгел, күзлекле, озын буйлы малай сөртә? Акбурлы юеш чүпрәкне җирәнмичә кулына тота бит әле! Нигә интерактив такта юк? Кайда компьютерлар? Кайда слайд-проектор, кайда экран? Нигә парталар шундый кәмит бу класста? Дәрес алдыннан бөтенебез телефоннарны җыеп, укытучы өстәленә куя идек. Нигә өстәлдә телефоннар күренми? Кесәләрендәме? Сораулар… Сораулар… Очсыз-кырыйсыз сораулар… Җаваплар гына юк.

Тырышып-тырышып, логик фикерләргә, кабат бу хәлләр турында уйларга тотындым. Соңгы арада әти белән әнидән «кеше чыкмас моннан», «йөгәннән ычкынды», «бетәчәк бу бала» дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә иде. Алар мине тәрбияләү өчен шушындый кәмит оештырмадылар микән? Алалар отпуск. Кайтып төшәләр бер караңгы авылга. Анда сөйләшеп куялар мәктәптәге укучылар, укытучылар белән… Давай, кеше ясагыз бу малайдан дип. Бүтән вариант башыма килми. Төш була алмый бит инде бу!

…Физикадан соң – биология, аннары алгебра, аннары татар әдәбияты керде. Миннән бер укытучы да өй эшен сорамады. Үзем дә артык сүз сөйләмичә, артык хәрәкәтләр ясамыйча гына вакыйгаларны күзәттем.

Җайлап кына, укучылар белән танышам. Әлбәттә, берсеннән дә «син кем» дип сорамыйм. Әгәр бу уен чынлап та алдан язылган сценарий буенча бара икән, мин бит инде биредә чит кеше түгел. Без – бер-беребезне күптән белә торган классташлар булып чыгабыз. Һе… Кызык… Башың җитмәс бу хәлләргә…

Сынык тешле малай Идрис исемле икән. Кайчандыр хоккей шайбасы эләккән бичараның тешенә. Күзлекле малай – Дамир. Отличник анысы. Ә теге зәңгәр күзле матур кыз – Гөлия. Класс башлыгы Айсылу исемле. Аны никтер «комсомол секретаре» дип йөртәләр. Усал карашлы малай – Марат. Анысы да ниндидер командир, ди. Нишләп ике командир бу класста? Шайтан белсен…

Идрис дигәннән, бу тамашада ул минем якын дустым ролендә, ахры – гел янымда бөтерелә. Тәнәфес саен «әйдә, штанга күтәрәбез» дип, спортзалга чакыра. Өеннән алып килгән, май ягылган, өстенә писүк сибелгән ипиенең яртысын сындырып, миңа сузып маташа. Тапкан ашар нәрсә…

Менә дәресләр бетте. Гардеробка ашыктым. Әмма Идрис җиңемнән эләктереп алды:

– Качарга җыенасыңмы? Тагын эләгәчәк бит үзеңә!

– Качмыйм… Өйгә кайтам.

– Нинди өйгә? 22 апрель бит бүген! Оныттыңмы әллә?

– Ну… 22 апрель… Шуннан нәрсә?

– Соң! – Идриснең күзләре очкынланып китте. – Ленин бабай туган көн!

– Бабаеңны туган көне белән котлыйм! Миннән дә сәлам әйт үзенә! – дидем чын күңелемнән. – Ләкин әти туры өйгә кайтырга кушты…

– Ярар, юләр сатма, – диде Идрис, авызын ерып, – әйдә, актлар залына! Анда өченчеләрне пионерга алалар бүген!

Ленин бабай… Пионер… Әйе, әйе… Ишеткәнем бар бу сүзләрне. Әти кайчандыр пионер булган минем. Әни дә. Әби-бабайларның утыннарын ярып йөрүләре, тимер-томыр, макулатура җыюлары турында сөйлиләр иде. Кызык булып китте. Идрис артыннан иярдем.

Актлар залына керүгә егылып китә яздым! Менә тамаша-а-а... Зал тулы муеннарына кызыл галстук бәйләгән укучылар. Үзләре ак күлмәкләрдән. Аклы-кызыллы түшләрдән күзләр камаша хәтта.

Без Идрис белән арткы рәттәге урыннарның берсенә кереп чумдык.

Шундый ук кызыл галстуклы, әмма озын буйлы, минем яшьләрдәге бер кыз сәхнәгә күтәрелүгә гөжләп торган зал тынып калды. Аның артыннан кулына быргы тоткан бер малай, шулай ук култык астына барабан кыстырган тагын берсе күтәрелде. Галстуклы кыз команда бирде:

– Дружина! Встать! Равняйсь! Смирно! Дружина байрагын каршы алырга әзерләнегез!

Барабан бәрә, быргы кычкырта башлады, без исә аягүрә басып, байрак йөртүчеләрне каршы алдык.

– Вольно...

Дөбер-шатор утырышып кына беткән идек, янә галстуклы кызның боерыгы ишетелде:

– Дружина! Встать! Равняйсь! Смирно! Отряд советы председательләре – рапортка!

Пионерларның да башлыклары бар икән. Һәр классның – үзенеке. «Отряд советы председательләре» дип атала. Колхоз председателе дигәнне ишеткәнем бар иде, ә мондыен – юк. Дачурта бит әле үзләре! Шул кызыл галстуклы «председатель»ләр кулларын маңгай турысына куеп, честь биреп, һәркайсы теге озын буйлы кызга рапорт биреп чыкты:

– Иптәш дружина советы председателе! Безнең Павлик Морозов исемен йөртүче отряд бүгенге тантаналы җыелышка әзер! Безнең девиз...

Шулчак аның отрядындагылар торып басып, хор белән кычкырды:

– Укырга, укырга һәм укырга!

– Безнең җыр!

– Ал җилкәннәр!

– Отряд советы председателе Илгизә Вәлиева!

– Вольно!

– Отряд, вольно!..

Бу тамаша хәйран озак барды. Нииндидер мин аңламый торган отчётлар укылды. Әти сөйләгән «металлолом», «макулатура» сүзләре телгә алынды. Аннары нииндидер куян фермасы, яфрак җыю турында сөйләштеләр.

Менә сәхнәгә бәләкәйрәк буйлы укучылар чыгып басты.

– Өченчеләр! – дип пышылдады Идрис колагыма. – Хәзер иң кызык җире башлана...

Әлеге бәләкәй малай-кызлар, чират-чират, дога укыгандай, бер үк текстны кабатладылар: «Мин, фәләнев фәлән фәлән улы, Владимир Ильич Ленин исемендәге Бөтенсоюз Пионер оешмасы сафларына кергәндә, иптәшләрем каршында тантаналы вәгъдә бирәм: Ватанымны яратырмын, Коммунистлар партиясе өйрәткәнчә, Бөек Ленин кушканча яшәрмен, укырмын һәм көрәшермен, Советлар Союзы пионерларының законнарын һәрчак үтәрмен!»

Шушы бармак буе балаларның төртелмичә, саташмыйча шундый авыр җөмләләрне әйтүенә шаккатып, хәтта бераз сокланып утырдым. Аннары сәхнәгә югары класс укучылары күтәрелде. Алар өченчеләрнең муеннарына кызыл галстуклар бәйләделәр. Теге озын буйлы кыз:

– Советлар Союзы Коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә әзер булыгыз! – диюгә, ярты зал кулларын янә маңгай турысына куеп:

– Һәрвакыт әзер! – дип кычкырдылар.

Да, мала-ай... Гаҗәеп күренеш иде бу. Бөтен нәрсә төгәл, әзерлекле, оешкан төстә. Һәр хәрәкәт матур, синхрон. Кинәт үзебезнең мәктәп өчен оят булып китте. «Беренче сентябрь»гә, «Соңгы кыңгырау»га тезелгәндә дә, тыныч кына басып тора белми бит

безнекеләр. Гарип кеше кебек селкенәләр, чайкалалар. Чүгәләргә дә мөмкиннәр. Стройдан бөтенләй чыгып китәргә дә…

Уйларымны бүлеп, баян аккорды яңгырады. Бер малай яңгыравыклы тавыш белән җырлап җибәрде:

*«Ялкынлан учак, дөрлә югары.*
*Без пионерлар – эшче уллары.*
*Киләчәк чорлар чакыра безне*
*«Һәрвакыт әзер» – пионер сүзе!»*

Аннары әлеге җырның русчасын суздылар:

*«Взвейтесь кострами, синие ночи,*
*Мы – пионеры, дети рабочих...»*

Җырны бөтен зал күтәреп алды. Җырның: «Клич пионера – всегда будь готов!» дигән җирендә янә салют бирделәр. Миңа гына каз тәннәре чыктымы, әллә башкалар да шундый хисләр кичердеме, анысын әйтә алмыйм, ләкин актлар залыннан чыкканда, һәммәбезнең авыз колакта иде.

## Мунча эче караңгы

– Кайттыңмы, ташбаш? – дип каршылады әти мине. – Исәнләш абыең белән!

Әни плитә янында нидер пешерә, әти исә олы якта таныш түгел бер абый белән икәүләшеп, теге борынгы телевизор янында кайнашалар иде. Телевизорны идәнгә егып салганнар да, «громкость» дип язылган боргычына «Шипр» дигән одеколон агызып маташалар. Бөтен өйгә тәмле ис таралган.

– Исәнмесез…

– Телевизор төзәтүче абыең бу! Казаннан ук килгән! – диде әти бер тантана белән. Аннары зарлангандай әйтеп куйды:

– Гыйнвардан бирле күрсәтми бу хәерсез нәмәрсә. Дүрт ай телевизор караган юк… Но ничава, аның каравы йокы туя…

– Хәзер, эшлибез… – Телевизор төзәтүче абзый мыек астыннан гына елмайды. – Бер лампасы янган. Хәзер, төзәтәбез. Ике канал да чип-чиста күрсәтәчәк.

– СТС белән ТНТ да булачакмы? – дип кызыксындым, аны-моны уйлап тормастан.

Оста эшеннән аерылмый гына елмаеп җавап бирде:

– Аларын белмим, но Мәскәү белән Казанны рәхәтләнеп карый алачаксыз.

– Бар, телеңә салынып торма монда! – Әти мине кухняга куып чыгарды. Әни тәлинкәгә итле аш салып бирде. Ипи. Чәй. Башка берни юк. Шоколадлар да, круассан да, һәрвакыт вазада була торган мандарин-бананнар да күренми өстәлдә.

– Әни?

– Әү, балам?

– Туктатыйк инде бу тамашаны, ә? Мин барысын да аңладым, төзәлермен.

– Нинди тамашаны, улым?

– Үзең дә беләсең бит инде…

– Нәрсәне?

– …

– Әйт инде, балам, ник дәшмисең? Нәрсәне беләм?

– Әни, кайда минем телефоным?

Әни борчулы күзләрен миңа төбәде. Авыр сулап куйды. Бераз тын торды. Аннан кулларымнан тотты:

– Ашыңны аша да йокларга ят, улым! Иртәгә больницага барып кайтыйк әле. Берәр җиреңә зыян килмәсен, тикшеренеп алыйк. Габбас абыеңа керербез. Бик әйбәт доктор, диләр үзен…

Каршы җавап бирүнең мәгънәсезлеген аңлап, рәхмәт әйттем дә өстәл яныннан

торып киттем. Эт булып арыган идем, караватка сузылып ятып, күземне йомарга да өлгермәдем, урам яктан «Альбе-ерт!» дип кычкырган тавыш ишетелде. Тагын Идрис! Кай арада килеп җиткән!

– Әйдә Дамирларга! – диде ул, бөтен җиһанга сынык тешен күрсәтеп елмаеп. – Фото ясыйбыз! Караңгы төшкәнне генә көттек...

Бер мизгелгә генә югалып калдым. Фото ясыйбыз?.. Фотоны ясарга кирәкмени аны?.. Хәер, шайтан белсен бу авылдагы кәмитләрне! Артык сораулар биреп тормадым. Үземә дә кызык иде – киттек урамның аргы очына.

Никтер өйгә кермәдек, туп-туры мунчаларына киттек.

– Без бу! – дип хәбәр бирде Идрис мунча өйалдына кергәч.

– Ишекне тиз генә ачып ябыгыз! – дип кычкырды Дамир эчтән. – Яктылык кертәсез алайса!

Кердек. Мунча эче дөм-караңгы. Хәер, дөм үк түгел – почмакта кызыл фонарь яна. Фото ясау өчен шулай кирәк икән. Бәләкәй өстәл, аңа ниндидер прибор беркетелгән. Эчендә ут яна. Янәшәдәге сәкедә бәләкәй ләгәннәр, анда ниндидер сыеклык җемелди.

– Бусында проявитель, – дип аңлатты Дамир, ләгәннәргә аптырап карап торуыбызны күреп. – Анда сурәт ясала. Ә бусы – закрепитель, ясалган сурәтне беркетә, ягъни «закрепляет». Ә бу прибор увеличитель дип атала, фотокәгазьгә пленкадан рәсем төшерә. Ә менә бусы карточка ясый торган кәгазь инде, анысын беләсез.

Идрис «беләбез» дип ым какты. Берни аңламасам да, мин дә «беләбез» дигән булдым.

– Фотоны башка ысул белән ясап булмыймыни? – Мин үземнең өч камералы «айфон»ымны, төсле принтерларны күз алдына китердем. – Бик озак бит бу...

– Бар андый нәрсә, – диде Дамир эскәк белән фотокәгазьне ләгәнгә батыра-батыра. – Казанда, туганнарда күрдем. «Полароид» дип атала. Вәт шәп әйбер! Ләкин бик кыйбат ул. Германиядәнме, Америкаданмы алып кайтканнар. Менә ул чын могҗиза! Фотога төшерүгә фотоаппарат астыннан сурәт килә дә чыга.

– Булмас! – дип сикереп торды Идрис. – Шыттырасың!

– Ант әгәр! Ипидер менә...

Дамирның һәр хәрәкәтен күзәтәбез. Проявительдәге фотокәгазьдән әкрен-әкрен кеше сурәтләре чыгуын карап тору чынлап та кызык икән.

– Бусы нинди маймыл тагын?!..

Идриснең маймыл дигәне Идрис үзе булып чыкты.

...Өйгә кайтып, караватыма сузылып ятканда, сәгать телләре төнге уникене күрсәтә иде инде. Нинди озын көн булды бүген! Сәер өй, сәер тормыш. Сәер әти белән сәер әни. Таныш түгел мәктәп. Классташлар... Пионерлар, быргы, барабан тавышлары... Күз алдында җемелдәгән кызыл галстуклар... Очсыз-кырыйсыз, җавап табылмаган сораулар...

## «Значит абый» янында

Икенче көнне мәктәпкә бармадым. Әни врачка алып китте. Больница дигәннәре бу авылның үзендә үк икән. Кызык, мин больницалар шәһәрдә генә була дип уйлый идем. Ә монда нәкъ авыл уртасында!

Бер катлы озынча таш бина. Тышы акшар белән генә агартылган. Бөтен җирдә искелек рухы. Череп аварга торган агач коймалар. Тактадан ясалган ямьсез чүп контейнерлары. Бер читтә кабина ишегенә кызыл хач ясалган көрән төстәге иске «УАЗик» тора. Көпчәкләре юк – машинаны каен бүкәннәргә утыртып куйганнар.

Эче тагын да шыксызрак булып чыкты әлеге бинаның. Мәгарә шикелле түгәрәкләп эшләнгән биек түшәмле коридор. Буяулары кырылып беткән стеналар. Кайбер җирләрдә штукатурлары ук коелып төшкән. Коридор буйлап, ак төскә буялган бүлмә ишекләре тезелеп киткән. Һәр ишек өстендә нәни генә пыяла тәрәзә. Алары үзенә күрә бер шомлылык өсти. Стеналарда хан заманыннан калган

плакатлар. «Пьянству – бой», «Содержите руки в чистоте...» «Лечите косоглазие очками» дигәнен күргәч, шаркылдап көлеп җибәрүемне сизми дә калдым. Әни кисәтү ясады.

Шактый озак чиратта утырганнан соң, табиб бүлмәсенә кердек. Габбас дигәннәре алтмыш яшьләр тирәсендәге, җыйнак кына ак сакаллы, ыспай кыяфәтле күзлекле абый иде.

– Менә, ферма түбәсеннән егылып төшкәннән бирле әллә ниләр әйтеп саташа! – Әни авызын учы белән каплап елап та җибәрде. – Әллә нинди кампутырлар, интернатлар турында сөйли. Ярдәм итегез, зинһар!

Доктор абый кулындагы саргаеп беткән медицина карточкаларын тигезләп, өстәлгә куйды да яныма килде:

– Ала-й... Значит... Егылып төштем дисең инде... – Ул башымны тотып, муенымны уңга-сулга борып карады. – Авыртамы? Юк?.. Ярый... Башына снимок ясатырбыз... Кул-аякларында җәрәхәтләр юкмы? Юк?.. Бик яхшы... Тынычланыгыз, апа. Куркырлык нәрсә күрмим әлегә. Бер минутка гына чыгып торыгызчы. Егетнең үзе белән каршы-каршы сөйләшеп алыйк әле.

Әни томырылып, миңа карады да яулык очы белән күзләрен сөртә-сөртә, ишеккә атлады. Ул чыгып киткәч, Габбас абый мине күзләре белән баштанаяк капшап чыкты. Аннан соң күзлеген салып, миңа төбәлде:

– Йә, егет, тыңлыйм сине! Һәммәсен чәчми-түкми сөйлә. Ләкин алдашма, яме!

Ә мин ялганларга җыенмый да идем. Киресенчә, шушы ак халатлы кешедә коткаручымны күрдем. Күп кенә сорауларыма шушы акыллы чырайлы абый җавап бирә алыр бәлки?

– Ничегрәк сүз башлыйм икән...

– Ничек бар, шулай башла.

– Мин сөйләгәннәргә ышанмассыз дип куркам.

– Ышанырга тырышырмын...

– Мин... Мин... киләчәктән килеп эләктем бугай биредә...

Докторның карашында аптырау чаткылары күренде:

– Ничек киләчәктән?

– Бу авыл, бу дөнья... Берсе дә минем заманныкына охшамаган...

Габбас абый, учлары белән иягенә таянып, җитди итеп, мине тыңларга әзерләнде:

– Йә, йә... Шуннан?..

– Кичә гомердә күрмәгән, чит-ят авыл өендә уянып киттем, – дип дәвам иттем мин. – Стенада ертып алына торган календарь эленеп тора. Андыйлар безнең заманда күптән юк инде... Календарьда 22 апрель числосы. Анысы туры килә. Директорга алдагы көнне – 21ендә чакырдылар безне, самокат белән авариягә дә шул көнне юлыктым... Әмма елы...

– Нәрсә елы? – доктор абый тишәрдәй булып миңа карады.

– 1985 дип язылган иде ул календарьда.

– Шуннан нәрсә? Мин монда гаҗәпләнерлек берни күрмим... – диде табиб. – 1985 нче ел бит инде хәзер!.

– Ләкин мин егерме беренче гасырда яшим, доктор абый... – дидем мин тонык тавыш белән. – 2020 елда. Бездә пандемия... Коронавирус...

Нәрсә сөйләвемне инде үзем дә аңламый идем, гаҗизләнеп, докторга карадым. Ул уйчан кыяфәттә күзләрен бер ноктага төбәде:

– Да-а-а... Значит... Вирус начар әйбер инде ул... Тәк тәк... Допустим, син киләчәктән килдең, ди. Ә әти-әниең? Больницага сине алып килгән кеше – әниеңдер бит?

– Әнием.

– Соң?

– Ләкин ул ниндидер бүтән әни... – Мин иңбашымны сикерттем. – Ул институтта укыта, доцент. Ну... безнең заманда инде... Ә монда ул китапханәдә эшлим, ди.

– Дөрес! Әниең авыл китапханәчесе синең. Бик хөрмәт итәләр үзен... Ә ни өчен «бүтән әни» дисең, усалракмы? Чит кеше төсле мәллә?

– Юк анысы... Шул ук. Ләкин әти дә, әни дә бөтенләй башка монда. Алар «вацапп»ның ни икәнен белми, «инстаграм» турында да ишеткәннәре юк, ноутбук турында әйтеп тә тормыйм инде...

Доктор абый миңа тагын да текәлебрәк карады:

– Ала-ай... Значит... Бик кызык бит әле бу. Ярар, допустим, мин сиңа ышандым ди. Допустим, син ничектер киләчәктән үткән заманга – ягъни безгә эләктең, ди. Сөйлә, алайса, миңа, 35 елдан нинди булачак безнең ил? Оча торган машиналар булачакмы? Айга теләгән һәркем менә алачакмы?

Җитди итеп сорадымы ул, әллә мине үртәве генә идеме, анысын аңлап җиткермәдем, шулай да:

– Андый машиналар да, айга менүләр дә булмаячак! – дип җавапладым. – Ә менә һәркемнең «мобильнигы» булачак!

– Анысы нәрсә?

– Шәхси кесә телефоны!

– Кит инде! – Габбас абыйның аксыл кашларын югары чөелде. – Бөтен кешенеке дәме? Каян номер табып бетерсеннәр ул тиклем халыкка?

– Җаен табарлар! – дидем мин ышанычлы тавыш белән.

Ышандымы миңа «Значит абый», юкмы, әмма аның белән күрешкәч, бераз җиңелрәк булып китте. Тиргәмәде ул мине, сүкмәде, башкалар кебек «тилердең мәллә?», «ялганлама инде», димәде. Әнине дә тынычландырды. Дәваларбыз, контрольдә тотарбыз, диде.

Миңа исә үземне кулга алырга кушты. «Һәр адымыңны уйлап эшлә. Киләчәктән килдем дигән сүзне ялгыш та авызыңнан чыгарма. Мәктәпкә йөр, классташларың белән аралаш. Алга таба ниләр эшлисен бергәләп хәл итәрбез», – диде. Ике көннән үзенә шалтыратырга кушып, кулыма өч урынлы телефон номеры язылган сары кәгазь кисәге тоттырды.

## Басудагы «кызык әйбер»

Озын тәнәфестә безне линейкага тезделәр. «Горбачёвка бер-бер хәл булган мәллә?» диеште кайберәүләр. Мин Горбачёвның кем икәнен белмим, аңа «бер-бер хәл булса» ни өчен линейкага тезелергә кирәклеген дә аңламыйм. Шуңа да артык сораулар бирми генә, башкалар янына барып төртелдем.

Директор абый ике минут чамасы безне күзләре белән капшап чыкты. Аннары салмак тавыш белән сөйли башлады:

– Хөрмәтле укучылар! Амбарда бәрәңге ярулар тәмамланды. Анысын булдырдыгыз. Молодцы! Инде суган утырту көннәре якынлашты...

Нинди амбар?.. Нинди бәрәңге?.. Нинди суган?.. Безне эшләтергә җыеналармы? Утыртмыйм суганнарын! Законнарны яхшы беләм мин!

Директор исә тыныч тавыш белән сөйләвен дәвам итте:

– Әйе... Туган совхозыбызга ярдәм итәргә кирәк булыр. Шул ук вакытта укуны да өзмәскә тырышыйк. Иртәгә... – ул завучка борылды. – Фәния Хәбировна, ничәнче класслар?..

– Тугыз-ун.

– Әйе. Иртәгә тугыз-уннар эш киемнәреннән, чиләк алып, парк янына җыеласыз. Иртәнге сигезгә. Җылырак киенегез. Туңа торган булмасын. Башка авыллар үзләре җыела торган урынга – сигезенче яртыга. Бүтән белдерүләр юкмы?.. Юк! Сораулар?..

Бездән уң якта торган уннар төркеменең уртасыннан берәүнең карлыккан тавышы ишетелде:

– Чыкмаганнарны нишләтәләр?

– Анысын инде, Гыйләҗев, белербез нишләтергә кирәген, – диде директор абый тыныч кына. – Юкмы сораулар? Булмаса, таралырга мөмкин.

Мин, аптырап, Идрискә карадым:

– Ничек суган утыртырга?.. Ә дәресләр?

Идрис бармагын чигәсе турында бораулады:

– Күктән төштең мәллә син? Нинди дәресләр?.. Атна буе суганда булабыз да, аннары бер дәрестә бишәр параграфны берьюлы дөмбердәтәбез! Шәп бит!

– Укучыларны эшләтергә ярыймыни?.. – дидем мин, күзләремне түгәрәкләндереп. – Ә законнар?.. Россия законнары?

Идрис сынык тешен күрсәтеп көлеп җибәрде:

– Әйтмә дә! Как они имеют право?!

Шунда мин янә ялгыш сүз ычкындыруымны аңладым һәм аңа кушылып көлгән булдым.

– Ну малай, рәхәт көннәр башлана! – диде ул, күзләрен ялтыратып. Иртәгә үк бер кызык әйбер ясыйбыз басуда!

...Көн суык. Ямьсез җил ыжгыра. Кояш бөтенләй күренми. Ашыгып-ашыгып йөзгән болытлар аны томалап бетергән. Салкын җил тузан-туфракны болын буйлап куып йөртә-йөртә дә, күзләргә, борынга, теш араларына тутыра.

Басу башына килеп бастык. Бер бураз нага – ике кеше. Өстә – телогрейка, кулларда тимер чиләкләр. Бураз налар буйлап фронт сызыгыдай тезелештек. Кем чүгәләп, кем баскан килеш иелеп, кара балчыкка орлык суганнарын төртәбез. Шаярышкан, көлешкән авазлардан, чиләк шалтыраган тавышлардан бөтен җиһан яңгырап тора.

Тиздән без Идрис белән «фронт сызыгы»ннан күпкә артта калдык. Артта калгач, билгеле инде, укытучыларның яртысы безнең янда. «Авырыйсыз мәллә?», «Тизрәк кыймылдагыз», «Суганнарыгызны турырак утыртыгыз...»

Идриснең башында – каешланып беткән сары солдат бүреге. Ул йә ачулы мыгырданып сүгенә, йә шат тавыш белән кемнедер үртәп ала. Менә аның кулындагы кантар ерактагы Маратның кәпәченә барып тия. Анысы «снаряд»ның кайсы яктан очып килгәнен аңларга тырышып, озак кына тирә-юньгә карап тора да, «дошман»ны таба алмагач, кабат бураз нага иелә.

– Эшләтеп үтерәләр инде балаларны! – дип куйды Идрис бераздан, һәркем ишетелерлек итеп.

Ул арада яныбызга класс җитәкчебез Газинур абый килеп басты:

– Эшләп кеше үлми! – Ул безгә булышырга тотынды. – Ә менә эшсезлектән үләргә мөмкин... Ну-ка, куып тотыйк әле башкаларны!

Яратабыз без Газинур абыйны. Усал түгел ул. Беркайчан тиргәми. Кирәкмәгән сораулар бирми. Бар нәрсәне җайлап кына төшендерә. Баштарак килешмәсәң дә, соңрак барыбер аның хаклы булуын аңлыйсың.

– Менә, бер авырлыгы юк бит инде! – Газинур абый кулында орлык суганнары фокусчы шарлары шикелле уйнап кына тора, аның җитезлегенә күз иярми.

– Без күргәнне безнең балаларыбызга күрергә язмасын инде, – дип мыгырданды аңа җавап итеп Идрис.

Берәр сәгать үтте микән, берзаман «я-а-ал!» дигән команда яңгырады.

– Шырпы кайсыгызда бар? Әйдә, учак ягабыз.

– Юк! «Ишәк-ишәк» уйныйбыз!

«Ишәк-ишәк» дигәннәре күңелле уен икән. Икәү ишәк була. Бер судья. Башкалар ишәкләргә атланырга чамалый. Тегеләр, билгеле, берәүне дә үзенә якын китермәскә тырыша. Ишәккә атланырга маташканда егылып төшеп, судья берәрсенең аягына басса, шул ишәк була.

Әрәмәлек ягыннан аңкыган су, тал, балык исләренә чирәмдә кемдер яккан учакның төтен исләре кушыла. Ул учакны завуч Фәния апа аягы белән таптап, сүндереп йөри. Ул арада Идриснең көр тавышы яңгырады:

– Егетләр! Килегез әле монда!

Берничә малай җыелдык. Идрис кесәсеннән ак төстәге вак ташлар чыгарды.

– Карбид! – малайларның күзе ялтырады.

– Киттекме әрәмәлеккә?

– Киттек!

– Только кызлар күрмәсен, әләклиләр алайса…

Карбидны беренче күрүем. Әмма алда ниндидер кызыклы хәл буласын сизенеп, күңел кытыкланып куйды. Разведкага барган партизаннар кебек, иелә-иелә, биш малай елга буена төшеп киттек. Яр буенда яшел төстәге иске пыяла шешә ята иде. Идрис аны елга суында яхшылап чайкады. Аннары шешәгә су тутырып, теге вак ташларны шунда тондырды. Башына агач бөке тыгып куйды. Тын да алмый күзәтергә тотындык. Биш минут чамасы вакыт узгач, шешә эчендә ниндидер ак күбекләр күренде.

Мин төшенә башладым. Бомба ясый бугай болар. Карбид дигәннәре бомбаның бер элементы, ахры. Менә ун минут узды, унбиш… Әмма бомба дигәннәре шартламый гына бит.

Дамир шешәне Идриснең кулыннан йолкып алды:

– Срогы чыккан бугай синең карбидыңның! Чиелдаган тавыш та юк ич монда!

– Чыккан, ди, менә! Кичә генә парктан алып төштем! Кая, бир әле үземә!

Шешә Дамирдан Идрискә күчәргә өлгермәде, «пак» итеп шартлау тавышы яңгырады! Әлеге тавышка малайларның җан өзгеч тавыш белән кычкырулары өстәлде.

…Икенче көнне Идрис тә, Дамир да мәктәпкә кулларын марля белән бәйләп килделәр. «Әле ярый күзегез чыкмаган!» дип, тел шартлатты һәммәсе. Идриснең «бер кызык әйбер ясыйбыз басуда» дигәне әнә шул булган икән.

## «Җомга»ны уйный беләсеңме?..»

Яңа тормышыма әкрен генә күнегеп киләм. Инде әти белән әнине дә юк-бар сораулар белән аптыратмыйм. Әгәр дә бу чынлап та «розыгрыш» булса, аларның шулай оста уйнауларына сокланырга гына кала. Алар гына түгел, бөтен авыл халкының… Ышанып булмый… Бер кеше – минем өчен шулай бөтен дөньяны үзгәртергә мөмкинме? Алайса нәрсә соң бу?.. Акылым җитми. Ул хакта уйламаска тырышам.

Аклы-каралы күрсәтә торган телевизорда нибары ике канал бар: Мәскәү һәм Казан. Аларында да бер юньле тапшыру юк. Көн саен теге көнне телгә алынган Горбачёв дигән абый сөйли. Компьютер белән телефонсызлыкка да күнектем. Бөтен җиргә җәяү йөрүгә дә. Мәктәптә дежур торуларга, класс идәннәрен юуга да. Чипсы дигән әйберне бөтенләй белмиләр бу авылда. «Дирол» белән «Орбит» та, «Сникерс» белән «Кириешки»лар да юк кибеттә.

Доктор абыйга, үзе әйткәнчә, ике көннән соң шалтыраттым. «Синең хакта Казанга хәбәр иттем, – диде ул. – Махсус комиссия көтәбез, алар килүгә хәбәр бирермен», – диде. Борчылмаска кушты. Дөньяда могҗизалар була алмый, бу хәлләргә дә җавап табылыр, дип тынычландырды.

Беренче Май бәйрәменә һәр класска концерт номерлары әзерләргә куштылар. Дәресләр бетүгә, актлар залына җыелдык. Сәгать буе җыен юк-барны такылдап утырдык. Идрис сәхнәдәге иске пианиноның капкачын ачып, клавишаларга арты белән утыра-утыра «уйнап күрсәтте». Көлештеләр. Концерт номерлары буенча бер юньле фикер тумады. Бераздан күрәм, кызлар тынгысызлана ук башлады.

– Монтаж шикелле әйбер эшлик мәллә? – диде комсомол секретаре Айсылу.

– Кит инде, бала-чага шикелле шигырь ятларга…

– Дамир фокус күрсәтсен!

Айсылуның борчылуы йөзенә чыкты:

– Җитте сезгә, кыланып утырмагыз, яме! Инде кайтыр вакыт җитә, бер юньле тәкъдимегез юк.

Зал почмагында аунап яткан иске гитараларга күптән күзем төшеп йөри иде. Дүрт-биш гитараның кайсының кыллары бөтенләй юк, кайсының «муены» сынган.

Арадан арурак дигәнен сайлап алдым да, тезләремә куеп, башымны кыңгыр салып, көйләргә утырдым. Көтмәгәндә, тынлык урнашты. Сәерсенеп, миңа төбәлделәр.

Гөлия яныма килеп басты:

– Әллә гитарада уйный беләсең инде? – диде ул, зәңгәр күзләрен түгәрәкләндереп.

– А как же! Хә-әзер, әнә тегесеннән бер кылны бусына күчереп куябыз да…

Һәр хәрәкәтемне тын да алмый күзәттеләр. Көйләп бетердем дә – да-даң! – залда тигез, матур «ля минор» аккорды яңгырады. Кызлар кулларын чәбәкләп куйдылар.

– Нәрсәне җырлыйм? – дигән булдым мин һәм җавап көтеп тормыйча Илназ Сафиуллинның җырын суздым:

*– Мин яратам сине-е-е...*
*Мин юксынам сине-е-е...*
*Яши алмам синнән башка-а-а...*

Мондый түгәрәк күзләрне күргәнем юк иде моңарчы. Тел шартлаттылар. Тиз арада мине уратып та алдылар:

– Кайчан өйрәндең?

– «Җомга»ны уйный беләсеңме?..

– «Су буеннан әнкәй кайтып килә»не?..

– Юк, лучше «Земля в иллюминаторе»ны!

– Любой көйне уйныйм! – дип шапырындым мин. – Моргенштерн кирәкме?.. Ә, юк, ул катлаулырак! Менә монысы җайлы: «Карандашым, пеналым…»

Актлар залы гитара зеңгелдәвенә күмелде. Ишеккә башка класс укучылары да өелеште. Күзләре ялтырый. Аю биетәләрмени!

Озын сүзнең кыскасы, ул көнне без хор белән «Шаулый урман»ны җырларга сөйләшеп, өйләргә таралыштык. Гитара «сопровождение»сендә, әлбәттә.

Мәктәптән чыкканда, ишек төбендә мине Гөлия көтеп тора иде:

– Ярыймы синең белән кайтсам? – диде ул, күзләрен серле итеп кыса төшеп. Чибәр кыз! Коңгырт чәчләрен ике толым итеп үреп куйган. Елмайганда, бит очында чокырлар барлыкка килә. Зәңгәр күзләренә карагач, диңгезгә чумгандай буласың.

– Безгә кайтмыйсыңдыр бит? Әнигә килен кирәк иде как раз! – Шәһәр малае мин, сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел. Оялттым бугай кызыйны – Гөлиянең бите уттай яна башлады. Ул читкә карап кына җавап бирде:

– Иртәгә кунаклар килә, әни түбән оч Халидә апалардан чәй сервизы алып кайтырга кушкан иде… Шуңа сезнең якка барышым…

– Үзегезнеке юкмыни?

– Юк шул…

Янәшә атлап киттек. Гөлия беренче күргәндәй, миңа карап-карап ала:

– Матур уйныйсың… Каян өйрәндең?

– Ә-ә-ә… Гитараны әйтәсеңме? Өйрәндем инде… Түгәрәктә…

Кызый миңа сынап карады:

– Безнең мәктәптә гитара түгәрәге юк дип беләм?

– Э-е-е… Юк шул. Ни… Шәһәрдән туганыбыз кайткан иде, шул өйрәтте.

Сизеп торам – ышанмады. Алай да каршы дәшмәде. Безнең капкага якынлаштык.

– Альберт, тукта әле!

Гөлия җиңемнән тотып туктатты да туп-туры күземә карады:

– Альберт! Әйт әле дөресен, нәрсә булды сиңа соңгы көннәрдә?

Мин аптыраган кыяфәт чыгардым:

– Нәрсә булган миңа?

– Менә мин сине ун елдан артык беләм бит инде, әйеме?.. Балалар бакчасыннан ук дисәң дә була… Ләкин…

– Нәрсә «ләкин»?

– Ләкин хәзер миндә шундый тойгы – әйтерсең лә, син мин белгән Альберт түгел… – Ул карашын читкә алды.

– Тәртипсез малайга әйләндем мәллә? – дип шаярткан булдым, эчемдә янган утны сиздермәскә тырышып.

– Ю-ук... – диде Гөлия уйчан гына. – Әйтерсең лә, син бөтенләй башка кеше!

Уч төбем, чигәләрем тирләп чыкты. Көчәнеп кенә елмайган булдым:

– Ник алай дисең инде, Гөлия?! Мин ич бу, мин! Менә, кулым, менә, аякларым... Менә, тотып кара ышанмасаң.

Гөлия елмаймады.

– Гитарада уйный белүең сәер... Андый әйберне яшереп йөреп буламы?.. Бусы – бер. Аннары, хәтерлисеңме, кечкенәдән үк син йөгерү буенча беренчелекне бирми идең?

– Хәтерлим... – дигән булдым.

– Ә кичәге физкультура дәресе? Йөз метрны 16 секундта да килә алмадың бит!

– Тәмәкенең зыяны... – Никтер тавышым карлыгып чыкты.

– Тартасың дамыни әле?..

– Мавыгып алган идем, – дигән булдым, – ташладым инде...

– Ә менә бу нәрсә? – Гөлия сумкасыннан шакмаклы дәфтәр тартып чыгарды.

Минем черновик! Дәрестә рәсем ясап утырырга яратам. Ул гадәтемнән монда да арына алмадым. Тик каян Гөлиянең кулына эләккән соң бу шакмаклы дәфтәрем?

– Үзең парта өстендә онытып калдыргансың, минем гаебем юк, – дип акланды Гөлия, уйларымны укыгандай. Дәфтәрне аннан йолкып алмакчы булдым, әмма ул кулын читкә сузып, аны бирергә җыенмады. Урам уртасында кыз кеше белән сугышып торып булмый бит инде.

– Йә, шуннан нәрсә? Рәсем ясарга да ярамыймы инде хәзер?

Гөлия сакланып кына дәфтәрнең беренче битен ачты:

– Мату-ур... Нәрсә соң бу, Альберт?

Беренче биткә зу-ур итеп компьютер рәсеме ясаган идем. Менә монитор, клавиатура, ике якта зур колонкалар...

– Бумы?.. Бу.. Э-е-е... Космик ракеталар белән идарә итү пульты! – тиз арада шундый оста җавап таба алуыма сөенеп куйдым.

Гөлия икенче битне ачты:

– Ә бусы кем? Бу нинди тәгәрмәч?

Монысында бер егетнең «моноколесо»да йөрүе сурәтләнгән иде.

– Бусы цирктагы клоун...

Гөлия дәфтәрнең уртасына җитте. Анда бер кыз портреты иде. Зәңгәр ручка белән ясалган.

– Ә бусы син... – дидем мин, аңа туп-туры карап. Гөлия озын керфекләрен түбән төшерде. Аннары дәфтәрне кулыма тоттырды да саубуллашмый-нитми генә ашыга-ашыга китеп тә барды.

## Салават

Теге вакытта ферма түбәсендә нишләп йөргәнбездер, анысын, әлбәттә, мин белмим, ләкин ул тирәгә бүтән бармадык без. Авылда язгы гөрләвекләр агудан туктап, җирләр кибеп беткән иде инде. Назлы итеп, май кояшы кыздыра. Хәзер без кичләрен мәктәпнең спорт мәйданчыгына җыелабыз. Кызлар озын агач эскәмиядә сөйләшеп утыра, кечерәк малайлар комда уйный, без велосипедта куышабыз.

Көннәр җылытты. Кичке як булса да, өстә бер кат күлмәк кенә. Һавада май коңгызларының выжылдап очуы, каяндыр чикерткә, бака черелдәүләре ишетелә. Кояш батып, күз бәйләнгәч кенә, өйләргә таралышабыз.

Кайчагында городки уйныйбыз. Гаҗәеп кызык уен. Дамир зур сумкага тутырып, цилиндр рәвешендәге агач фигуралар алып төшә. Ат тәртәсен кисеп ясаган ул аларны. 15 данә. Шул фигуралардан төрле әйберләр өябез: өй, пушка, телеграмм баганасы. Шуннан соң ун адым санап, артка чигенәбез дә кулга ярты метр озынлыктагы агач таякны алып, әлеге фигураларга ыргытабыз. Чәчелеп китәләр! Кемнеке ераграк

оча – шул җиңүче. Ул Дамир сулагайлап ыргытып җибәрә, мин сиңа әйтим, таягын, җирләр селкенеп куя!

Городки уены боулингны хәтерләтә миңа. Тик аерма шунда: анда егылган кегльләрне автомат күтәреп куйса, монда йөгереп барып, «пушка»ларны үзеңә тезәргә кирәк. Гомумән, күп нәрсәне үзеңә эшлисе бу авылда. Суны чиләк белән урамдагы колонкадан ташыйсы. Керне әни кул белән юа. Аннары иңнәренә чиләк-көянтә асып, аларны астагы инешкә алып төшеп чайкый. Газ юк, мичкә ягасы. Умывальник астындагы чиләкне чыгарасы. Тавыкларны, бозауны ашатасы. Тирес түгәсе. Бакча казыйсы... Санап бетерә торган түгел.

Кайчагында спорт мәйданчыгында мотоцикллар пәйда була. Кичке эңгердә «Минск», «Восход»лар фараларын яктыртып, үкереп атылып керәләр. Кереп туктап калсалар, бер хәл – куышлы уйный башлыйлар. Юри өстебезгә киләләр. Безгә сәпитләрне ташлап, койма башына менеп утырырга гына кала.

Ә беркөнне мәктәп ишегалдына кызыл төстәге, ялтыр-йолтыр килеп торган үтә дә «текә» бер мотоцикл килеп керде. Руль артындагы егет күн куртка, күн перчаткадан иде, башында кәттә шлем. Гадәттә, авыл малайлары мотошлем кими. Шуңа мондыен күрү бераз сәеррәк тоелды. Килеп тә керде бу, бар көченә газын акыртып, артыннан зәңгәр төтеннәр чыгарып, барган уңайга гына мотоциклының алгы тәгәрмәчен күтәртте. Шулай бер генә көпчәктә килеш йөз метрлап ара узды.

Малайларның күзләре янды.

– Серый... – дип сузды Идрис мотоциклдан күзен алмый гына.

– Кем соң ул? – дип сорап куйды берсе.

– Серыймы? Өске урамдагы Рашат абыйларга кайткан малай. Матае белән Казаннан ук кайткан.

– Нишләп Серый соң ул?

– Исеме Салават аның, – диде Гөлия, көлеп. – Серый – кушаматы гына.

Ул арада текә мотоцикл тузан туздырып, яныбызга килеп туктады. Рульдәге егет шлемының пыяласын күтәрде:

– Сәлам кызларга-егетләргә!

Шәһәр кунагын Идрис русча сәламләргә ашыкты:

– Прибыйт!

– Күңелсез түгелме сезгә монда? – Салават ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды.

– Син килгәнче күңелле иде әле! – дип төрттерде Айсылу.

Егетебез выж-выж иттереп, газ рычагын борды:

– Бу авылда усал телле кызлар да бар икән... – дип көлемсерәде ул. – Нәрсә, усал кыз, урам әйләнеп киләбезме соң? – Ул үткен карашы белән Айсылуны бораулап алды.

– Ә нишләп әйләнмәскә? – Тегесе ялындырып тормый гына, тиз арада мотоциклга менеп тә утырды. – Гөлия, әйдә, син дә...

Бераз икеләнеп торганнан соң, анысы да урыныннан торып, күлмәк итәкләрен рәтләде дә, ашыкмый гына, Айсылу артына елышты. Мотоцикл, көпчәкләре белән җирне тырнап, артыннан чирәмле кара балчык сиптереп, мәктәп капкасыннан атылып чыгып та китте.

Аның артыннан карап калучылар төкерекләрен йотып куйды:

– Их, шундый матаең булса, ә?

– Сиңа андыйны алырга әле... Мең сум тора ул, бик беләсең килсә!

– Кит инде!

– По блату гына алып була, ди...

– Чехословакиядән кайтарталар аны. «Ява» дигән матай!

– «Ява» түгел, «Чезет» ул!

Малайлар арасында бәхәс китте.

Мин исә мотоциклга кызыкмадым. Шәһәр тулы моның ише кеше куркытып, пытырдап йөрүчеләр. Күңелемне башка корт кимерә башлаган иде. Дөресрәге – ике

корт. Беренчесе – Гөлиянең утырып китүе. Кызлар шундый ялтыравык нәрсәләргә кызыга дип сөйлиләр иде, дөрес икән. Эх, күрсәтер идем мин сиңа үземнең соңгы модель «айфон»ымны! Матайга борылып та карамас идең аннары... Бу чандыр гәүдәле, шат күңелле, гел елмаеп торучы зәңгәр күзле кызга карата соңгы арада күңелемдә ниндидер җылы хисләр туа башлаган иде. Шуңа да ул тузан арасында күздән югалгач ничектер ямансу булып китте.

Икенче корт... Мотоциклчы егетнең күзләре бик тә таныш тоелды. Кайдадыр күргәнем бар, һич исемә төшерә алмыйм. Менә монысы чын мәгънәсендә сәер яңалык иде. Бу чит-ят авылда әти белән әнидән кала бөтен җирдә таныш түгел йөзләр, яңа кешеләр. Һәм менә сиңа мә! Ләкин бик тырышсам да, Салаватны моңарчы кайда күрүемне һич исемә төшерә алмадым. Әйләнеп килсәләр үзеннән сорармын дигән идем, ләкин алар шул китүдән башка күренмәде. Мин исә иртәгә үк аны эзләп табам дип, күңелемә беркетеп куйдым. Әмма ул икенче көнне шәһәргә киткән булып чыкты. Моны иртәгесен мәктәптә Гөлия әйтте. «Бер-ике көннән кайта», – диде аннары, серле генә елмаеп.

## «Отряд! Равняйсь! Смирно!»

Бөек Җиңү бәйрәме якынлашты. Парадка әзерләнергә тотындык. Ел саен 9 май көнне парад ясыйлар икән монда. Авылның үзәк урамында, билгесез солдат һәйкәле янында. Парадта һәр класс «строевой смотр»да катнаша. Ягъни «айт-два»га атлап йөриләр. Өстәвенә, быел түгәрәк дата – Бөек Җиңүгә 40 ел икән. Бәйрәм бик күңелле булачак, хәтта кино төшерүчеләр дә киләчәк, ди, имеш.

Көн саен дәресләрдән соң мәктәп ишегалдында репетиция ясыйбыз. Рәт-рәт тезелеп, кулларны уңга-сулга айкап, чын солдатларча, тигез итеп атлыйбыз. Класс белән җитәкчелек итү комсомол секретаре Айсылудан взвод командиры Марат кулына күчте. Менә ни өчен ике командир икән бу класста!

Взвод дигәннән, НВП дигән фән керә бу мәктәптә – «Начальная военная подготовка». НВП кабинетына килеп керүгә без класс та, комсомол отряды да түгел, без – взвод. Хәбир исемле абый укыта. Бик ошый әлеге дәрес. Автоматлар, гранаталар, окоп казулар турында ул. «Америка белән мөнәсәбәтләр начар, любой момент атом-төш сугышы булырга мөмкин», – ди Хәбир абый. Америка безгә бомба ташласа, нишләргә кирәген өйрәнәбез – респиратор киеп, мәктәп артындагы ике метр тирәнлектәге «блиндаж»га йөгерәбез, противогазның гофрлы торбасын кысып тотып, кем ничә минут сулый алмый торуын тикшерәбез. «Газовая атака» дигәне дә бик куркыныч нәрсә икән. Хәбир абый «Зарин», «зоман», «ви-газы» дигән «нервно-паралитический» газлар турында сөйләгәндә, шомлы булып китә.

Әнә, һавада командир Маратның карлыккан тавышы яңгырый:

– Взво-од! Равня-й-сь!.. Альберт!.. Равняйсь дим!.. Смирно! Строевым, прямо, шагом марш!

Идрис команданы ишетеп өлгермәде булса кирәк, арттан Дамир йомшак җиренә китереп типкәч кенә кузгалып китте.

Дөп-дөп... Дөп-дөп...

– Галиуллина, артта калма!

Көн кояшлы. Буявы коелып бетеп, кирпечләре ыржаеп күренә башлаган ике катлы мәктәп каршында шулай шак-шок атлап йөрибез. Класс җитәкчебез Газинур абый безне мәктәп баскычына чыгып карап тора. Ара-тирә «молодцы» дигәнне белдереп, баш бармагын тырпайта.

Марат кычкырып-кычкырып, команда бирә:

– Рраз, рраз, рраз, два-а, три-и... Взвод, смирнааа! Равнение! На-левааа!

Дөп-дөп... Кулларны туп-туры катырып, гәүдәгә кысып, атлап барган уңайга башларны сулга борабыз.

– Здравствуйте, товарищи!

9 майда узачак парадта «Здравствуйте, товарищи!»ны Хәбир абый кычкырачак,

без аңа «Здравия желаем, товарищ лейтенант!» дип җавап бирергә тиеш. Бүген исә Хәбир абый урынына – Марат. Аннары, бүген бит әле парад түгел. Кояшлы матур көн. Күңелләр күтәренке. Берәр кызык ясамыйча түзеп буламыни! Шуңа күрә...

– Здравия желаем...

Бусы бертавыштан әйтелә. Җөмләнең ахырын исә һәркем үзенчә кычкыра. Кызларның күбесе кыланмыйча «Здравия желаем, товарищ лейтенант!» дисә, малайлар «товарищ Марат!» дип акыра, Идрис исә барыннан да уздырып «товарищ поручик Галицын!» дип кычкыра.

Командирның кәефе китә:

– Ярарыгыз инде, бала-чага булмагыз... Рраз, рраз, рраз, два, трииии...

Взвод, песню запе-вай!

Маратның командасын ишетүгә, Дамир сузып җибәрде:

*– Што-то мою пулю долго отливают,*
*Што-то мою волю прячут, отнимают...*

Куплетның калган яртысын малайлар күтәреп алды:

*– Догони меня, догони меня...*

Бу – кичә генә клубта караган «Пацаны» киносындагы колония малайларының җыры иде. Аны җырларга тиеш түгел идек без, «Варяг»ны җырларга тиеш идек. Ну, болай кызыграк бит...

***

9 май иртәсе. Күк йөзе зәп-зәңгәр. Кояш күзне чагылдыра. Агачларда нәни яфраклар пәйда булган. Һавада май аенда гына була торган, татлы, күңелләрне иләсләндерә торган яшеллек исе. Ул татлы искә бераз көйгән үлән исе дә кушыла: кайдадыр узган елгы корыган агач-үләннәрне яндыралар булса кирәк.

Колхоз идарәсе каршына дистәләгән «отряд», «взвод»лар матур итеп тезелгән. Пионерлар ак күлмәк, кызыл галстуклардан. Башларында пилотка. Безнең өстә – форма костюмнары. Башыбызда яшел пилоткалар. Авыл халкы муеннарын суза-суза, әлеге тамашаны күзәтә. Идарә янындагы чирәмлектә – урындыклар. Аларга Бөек Ватан сугышы ветераннары утырышкан. Утызлап кеше. Өсләрендә – кара пинжәк, күкрәкләрендә орден-медальләр җемелди. Ветераннар янында, кызыл җәймә җәелгән өстәл. Монысы – президиум. Бусында колхоз рәисе, парторг абый, пионервожатый апа, килгән кунаклар урын алган. Шул тирәдә үк зур кинокамера тоткан көрән төстәге күн курткалы абый йөри.

Башта пионерлар атлап узды.

– Отряд! Равняйсь! Смирно! Прямо шагом марш!

Дөп-дөп. Дөп-дөп.

– Даю речевку: раз, два!

– Три, четыре! Мы шагаем по четыре!

– Раз, два! Тверже шаг!

– Пионерский наш отряд!

Отряд командирының:

– Знамя выше под-нимай, песню нашу зап-певай, – дигән сүзләреннән соң җиденчеләр җыр суза:

*Чулпан калка, таң ата,*
*Кыз сөйгәнен озата,*
*Исән барып, исән кайт,*
*Дошманнарны җиңеп кайт!*

Җыр күптән тукталган булса да, командирның:

– Отставить песню! – диюе кызык тоела.

Менә безгә дә чират җитте. Аяк астындагы комлы ташларга абына-сөртенә кузгалып киттек. Билгесез солдат һәйкәле янына җиткәндә, җыр аеруча көчле яңгырый иде:

*Наверх вы, товарищи, все по местам,*
*Последний парад наступает.*
*Врагу не сдаётся наш гордый «Варяг»,*
*Пощады никто не желает!*

Йөрәкләр дөп-дөп тибә, сөенечтән авызлар ерылган. Аңлатып булмый торган ниндидер бер рәхәтлек. Мондый хисне моңарчы кичергәнем юк иде. Белмим… ниндидер горурлык хисе дип әйтимме соң… Киләчәктә нидер эшләргә, ниндидер максатларга ирешергә өндәүче, әйтеп, аңлатып булмый торган көчле, тансык хис.

Парадтан соң клубка кердек. Сугыш турында ниндидер фильм күрсәтәчәкләр икән. Алдан ук сөйләшеп, Гөлия белән янәшә утырдык. Гөлиянең өстендә яшел солдат күлмәге, кара юбка, аякта – чем-кара сапожкилар. Күкрәгендә кызыл бантик. Башында солдат пилоткасы. Бүген ул аеруча сөйкемле, аеруча сүзчән. Муенын сузып, әле тегे, әле бу кеше белән сөйләшеп ала, ара-тирә матур гына елмаеп куя.

Менә кино башланды. Экранда зур язулар пәйда булды: «Иди и смотри».

– Һи, караганым бар минем бу фильмны, – дип шапырындым үзем дә сизмәстән. – Елата торган кино…

Гөлия миңа сәерсенеп карап куйды:

– Тагын башладыңмы?

– Нәрсәне?

– Сәерлекләреңне.

– Ник алай дисең?

– Бу кино яңа чыкты. Телевизордан да күрсәтмәделәр әле… – Гөлия үтәли тишәрдәй булып, миңа карады.

Бераз ык-мык килеп торганнан соң:

– Шаярттым… – дип мыгырдандым.

Экранга төбәлдек. Кино чынлап та бик тетрәндергеч иде. Күпләр елап утырды. Гөлия дә ара-тирә күз яшьләрен сөрткәләде. Үзе вакыт-вакыт шикләнеп, миңа карап алгалады.

## Тыңлаучан чана

Әни китапханәче дигән идем бит. Эш күп, үзем генә җитешмим дип, үзе янына булышырга чакырды ул мине беркөнне. Китапханәдә нинди эш булсын дип гаҗәпләндем башта. Әмма әнинең сүзе дөрес булып чыкты. Кочак-кочак газета-журналлар алдыралар. Бер көндә кимендә 10-15 гәзит-журнал почта ящигына төшкән була. Кем укый икән боларны? Алай дисәң, тузып, бөгәрләнеп беткәннәр. Димәк, укыйлар. Кеше өзелми, ди бит әни дә. Ул газета-журналларның һәрберсен подшивка ясап тегеп барырга кирәк. Аның өчен газетаның читен сабы кырылып беткән иске без белән тишәсе.

Әле шушы көннәрдә бик күп яңа китаплар кайтардылар. Аларның 1нче һәм 17нче битләренә мөһер сугып, номер язып чыгасы. Анысы да күп вакытны ала.

Китапханә зур. Рәт-рәт булып, китап киштәләре тезелеп киткән. Маҗаралы китаплар бүлеге үзе бер дөнья. «Нәни принц…», Жюль Верн томнары. Ә бусы татар язучыларының китаплары. Тукай, Такташ… Китапханәгә баруның икенче көнендә үк, ирексездән, китап дөньясына кереп киттем. Даниэл Дефоның «Робинзон Крузо маҗаралары»н бер көндә диярлек укып чыктым. Аннары Обручевның «Плутон иле»нә тотындым. Телефонда утыруларны шулай итеп китап алыштырды монда. Китап уку үзе бер кызык шөгыль икән. Смартфон экранын бармаклар белән җәеп зурайткан шикелле, онытылып китеп, китап

битен дә шулай зурайтырга азапланам кайчагында. Аннары гына үземнән үзем көлеп, тукталып калам.

Еш кына Дамир да килә китапханәгә. Ул күбрәк «Юный техник» журналын актарырга ярата.

– Һо! – диде ул беркөнне, чираттагы санны актарып. – Тыңлаучан чана ясарга өйрәткәннәр монда!.

– Нәрсә соң ул?

– Һо! Почти машина бу!

Икәүләшеп, борыныбызны журналга төрттек. Руле, тормозы булган чана ясарга өйрәткәннәр. Агачтан. Көлеп җибәрмәс өчен авызымны учым белән капладым. Кибеттә тулып ята бит мондыйлар! Агачтан түгел, җиңел пластмассадан ясалганнары. Шулчак кылт итеп, үземнең кайдалыгым исемә төште. Шып – ерган авызымны кире җыйдым.

– Әйдә, шуны ясыйбыз! – Дамирның күзләре очкынланып яна иде.

– Җәй башындамы?

– Булса ни! Кышка әзерләп куябыз. Аның каравы, кышын тау шуганда, һәммәсенең күзе шакмак булачак!

Көлемсерәп кенә, риза булдым. Иртәгесен Дамирларда эш кайный иде инде. Дамир кисә, Идрис белән мин тактаны тотып торабыз. Дамир ышкылый, без тагын тотып торабыз. Иң элек төп кисәкләрен – корпусын ясадык. Шуннан соң урындык, сөялгечләр, тормоз куйдык. Чанабыз тиз арада күзгә күренеп үсте. Табанын Дамир паркта ясатып алып төште. Тимердән.

## Походта

Әмма чананы ясап бетерергә бер көн җитмәде – болытлы җиләс иртәдә Газинур абый безнең классны походка алып чыгып китте. Поход турында сүзләр күптән йөри иде инде. Уку елы ахырында шулай табигатькә чыгу матур бер гадәт икән бирердә. «Ночевка» белән барыйк», – диеште малайлар. «Үзем әйтермен ночевка буламыюкмы икәнен», – диде. Газинур абый. «Кая барабыз», – дигәч, анысын да әйтмәде: «Ату козгыннар килеп җитә...» – диде. «Козгыннар»ның кем икәнен беләбез – авыл егетләре. Безнең класс кызларына кызыгып йөри торганнары.

Әни пешереп биргән дүрт йомырка, «завтрак туриста» консервасын, май ягылган ипине һәм пыяла шешәгә тутырылган баллы чәйне мәктәпкә йөри торган биштәремә аттым да мәктәпкә юл тоттым. Палатка алмаска булганнар. «Димәк, ночевкасыз?» – дип кызыксындым. «Пока билгесез әле», – диде Дамир. «Ник, палатка алмагач?..» «Шалаш ясарбыз, куна-нитә калсак...»

Барыбыз да җыелып беткәч, урманга кузгалдык. Гитараны да эләктердек. Анысын малайлар чират-чират күтәреп барырга булдылар. Юл буе мәзәк сүзләр сөйләшү, көлешүләр тынмады. Идрис барган уңайга баштүбән кулларында йөреп күрсәтте. Елга аша салынган агач басмада туктап, фотога төштек. Аннары үргә, урман юлына күтәрелдек.

Болытлар тәбәнәк. Сыек-сары төстә. Офык та шундый сагышлы. Әйтерсең, май түгел, әйтерсең, табигать сентябрьгә кереп килә. Кояш болытлар арасыннан күренеп-күренеп кенә китә дә кабат юкка чыга.

Май башында көннәр кояшлы торды да, соңрак һава кинәт алышынды, суытты. Күптән түгел явып узган яңгырлар үз эшләрен яхшы башкарган – урман юллары пычрак, ат тәгәрмәче эзләре су белән тулган.

Аякларда резин итекләр. Сакланып кына, алга атлыйбыз. Газинур абый дәшминитми генә классны алга әйди. Биш-алты чакрымлап барганбыздыр. Урманның түренә атлыйбыз. Куе, тыгыз булып үскән нарат агачлары. Чытырманлыклар. Бераз шомлы. Юл, әкренләп, уңга борыла. Менә алда – ачыклык. Ниндидер чишмәгә килеп чыктык. Чү, алда авыл күренә түгелме соң? Ну бу Газинур абыйны! Хәйләкәр дә соң! Урман

эчләреннән йөртте-йөртте дә кире авыл ягына алып чыкты. Үзенчә эз югалтуы инде, янәсе. «Козгыннар» монда икәнне белмәсен, диюе.

Учак ягып җибәрдек. Алай-болай яңгыр ява калса дип, берничә малай ылыс ботакларыннан шалаш әмәлли башлады. Кемдер чиләк асу өчен агачтан таяклар юнырга тотынды. Кызлар, «әбәт» хәстәрләү эшенә кереште. Берәүләр исә батарейкалы «Электроника» магнитофоны янында кайнашты.

Ашап алгач, тау битендә футбол уйнадык. Газинур абый, сабый бала кебек, үзе дә безнең белән бергә йөгереп йөрде. «Защита»га баскан Айсылуны чак бәреп екмады. Идрис белән Айсылуның туп өчен талашуын карап тору – үзе бер тамаша. Идрис никтер аннан тупны һич талап ала алмый. Аптырагач, «Ы-ы-ых!» дип, кызыйны ике кулы белән этеп ега да тупны алып чаба. Газинур абыйны гына күр син! Авыр резин итекләре белән лаштыр-лоштыр чаба бит! Идрис юри бөтен шартын китереп алдалый үзен, аннары безгә карап елмаеп, күзен кыса.

Тау астында күл бар икән. Малайлар су коенабыз дип маташканнар иде, Газинур абый рөхсәт итмәде:

– Ярамый, ярамый, җә салкын тидерерсез. Әле май гына бит…

Караңгы төшә башлады. Учак ягып җибәрдек. Магнитофоннан талгын көй агылды. Берничә кыюраклары кызларны танцыга чакырды. Күбесе учак тирәсенә елышты.

Кичкә таба көн аязды. Караңгы төшүгә күктә ярым ай күренде. Йолдызлар җемелдәште. Черт-черт итеп, зур учак яна. Килүгә күп итеп корыган агач ботаклары әзерләп куйган идек. Кырыйда утырган Марат учакка әз-әзләп утын өсти тора.

Классташларым җиргә сибелешеп, бер-берсенә елышып утырдылар. Кара, үзем дә сизмәстән «классташларым» дидем! Кызык булып китте. Хәер, классташлар булмый кемнәр булсын инде! Бер ай эчендә шулхәтле ияләшеп беттем үзләренә, гүя чынлап та гомер буе бер класста укыганбыз.

Кулыма гитара алдым:

*Изгиб гитары жёлтой ты обнимаешь нежно...*
*Струна осколком эха пронзит тугую высь...*

Бу җырны барысы да белә иде, рәхәтләнеп кушылдылар:

*Как здорово, что все мы здесь сегодня собрались...*

Газинур абый тезләрен кочаклап утырып, күзләрен еракка төбәгән иде. Җыр беткәч, ул тамагын кырып сүз башлады:

– Шула-а-й… Тагын бер ел укыйсыгыз калды. Әйдәгез, ачыктан-ачык сөйләшик әле… Киләчәктә кем булырга җыенасыз? Нинди профессия сайларга телисез?

Дерт итеп киттем! Таныш сүзләр… Шул сүзләрдән башланган иде түгелме соң минем маҗаралар?

– Мин заводка эшкә керәм.

– Ә мин авылда калам. Фермага төшәм.

– Мин – механизатор инде, тагын кем булыйм.

– Ә минем укырга керәсем, инженер буласым килә!

– Ә син, Альберт?!..

Нәрсә дип җавап бирим? Америкага китәсем килә димме? Тагын юләр хәлдә калыйммы? Аннан соң, дөресен генә әйткәндә, чит илгә китү теләге сүрелгән дә иде инде миндә. Теләсәң, монда да кызык итеп яшәп була икән бит! Көн бик озын тоела бу авылда. Иртәдән кичкә кадәрге тормыш – үзе бер ел кебек. Монда үткән бер көн – үзе бер маҗаралы фильм.

– Минме?.. Мин…

Әмма сүземне әйтергә өлгермәдем, тау башында фара яктысы күренде. Каяндыр пәйда булган мотоцикл выжылдый-выжылдый, көчле фараларын балкытып түбәнгә

төшә башлады. Безнең янга ук килмәде – йөз метрлар чамасы кала туктады һәм быкылдап сүнде. Яктылык көлтәсе дә юкка чыкты.

– Кем булыр бу? – диештеләр.

– Кем булсын, козгыннарыгыз! – Газинур абыйның тавышы ачулы иде. – Тәки эзләп тапканнар!

Ул кулларын рупор ясап, авыз турысына куеп, мотоциклчы ягына – караңгылыкка кычкырды:

– А ну, кабыз! Кабыз да кире кит! И штобы эзегез булмасын бу тирәдә! Авыл Советына җиткерәчәкмен! Штраф түләрсез аннары!

Каршы тарафтан ни «ә», ни «җә» – бернинди тавыш ишетелмәде. Тынлык.

Чү! Ялгыш ишетәмме – көтмәгәндә, мотоциклчы егет ягыннан, шомлы караңгылыктан кесә телефоны көе яңгырады! Нәкъ минеке төсле «айфон» тавышы! Саташаммы әллә?..

– Магнитофоны да бар, ахры, – диде Идрис ачулы тавыш белән. – Бик кәттә малай булды бу!

– Кайсыгызның егете? – Газинур абый ачулы кыяфәттә кызларга борылды. Тегеләр иңнәрен генә сикерттеләр.

Таныш рингтон кабат яңгырады. Димәк, саташмыйм! Еракта дисплей яктысы җемелдәде һәм тонык кына «алло» дигән тавыш ишетелде.

– Фонарь да алган әле, – диде Гөлия көлемсери төшеп. – Матай фарасы гына җитмәс дип уйлаган, ахры…

«Квест» ахырына якынлаша бугай… Аны-моны уйлап торырга вакыт юк иде, кинәт кенә сикереп тордым да бар көчемә мотоцикл янына йөгердем. Артымнан Газинур абыйның: «Тукта! Ярамый сиңа анда барырга! Ярамый!» – дип кычкыруы гына ишетелде.

Мотоциклга җитәргә берничә адым кала ул кабат зырылдап кабынды. Күзне ут көлтәсе чагылдырды һәм тимер ат үкереп өстемә килә башлады. Читкә тайпылырга өлгермәдем. Көчле авырту. Аннары бушлык… Тынлык… Кояш сүнде… Бар дөнья караңгылыкка чумды…

## «Ә сез мине каян беләсез?..»

Зур тәрәзәләрдән көлтә-көлтә булып кояш нурлары төшкән. Ап-ак бүлмә. Тирә-юньдә пипелдәп, приборлар эшләп утыра. Баш очымда да ниндидер аппаратның выжылдавы ишетелә. Кинәт кемдер уң як беләгемне йомшак кына итеп кыса башлады. Давление үлчәгәндәге кебек, чытыр-чытыр итеп. Аннары җибәрде. Кем булыр бу?

Шунда гына үземнең хастаханә койкасында ятуымны абайлап алдым. Бөтен тәнемне диярлек ниндидер чыбыкларга, приборларга тоташтырганнар. Беләгемне дә шул прибор кыскан, күрәмсең. Аяк-кулларымны хәрәкәтләндермәкче булам – селкенмиләр дә. Башымны чак кына күтәреп, тәнемә күз салган идем, әннекәйгенәм! Имәнеп киттем – бөтен гәүдәм диярлек гипста! Тиз-тиз генә башымны эшләтергә тотындым. Мин кайсы заманда?.. Сиксән биштәме?.. Ул елларда мондый приборлар бар иде микәнни?

Шулчак ишектә ак халатлы шәфкать туташы пәйда булды. Ул миңа күз ташлауга, атылып, яныма килде:

– Уяндыңмы, герой?! – диде елмаеп. Аннары сулы марля белән ирен кырыйларымны юешләтте дә тиз генә ишеккә барып, кемгәдер кычкырды:

– Габбас Нурович! Аңына килде!

Менә ишектә бер абый күренде. Доктор бугай. Яныма килеп утырды:

– Ничек хәлең? Түзәрлекме? – диде ул аталарча кайгыртучан тавыш белән. – Кай төшләрең авырта?

Җыйнак сакаллы, күзлекле бу абыйны кайдадыр күргәнем бар иде.

– Бөтен җирем… Авырта… – дидем мин мескен генә тавыш белән.

– Авыртадыр, аңлыйм… Значит… Ярар… Иң мөһиме – исән калдың!

Тукта! Бу бит... Бу бит... Авылдагы доктор абый! «Значит абый»!

– Габбас абый, сезме бу?!

Доктор миңа бераз сәерсенеп карады да күтәрелә башлаган башымны җайлап кына, мендәргә кире яткызды:

– Тынычлан, егет! Сиңа борчылырга ярамый. Әллә без танышлармы?

– Әлбәттә, танышлар! – дидем мин сөенеп. – 85нче ел! Авыл больницасы! Комиссия килергә тиеш иде мине карарга! Хәтерлисезме?

Доктор кабат миңа шикле караш ташлады:

– Шулайдыр... Бәлки... – диде ул сабыр гына. – Хәтерләмим... Тынычлан, егет.

– Балам! – шулчак бүлмәгә атылып, әни килеп керде. – Күз нурым!!! Уяндыңмы? И-и-и, бәбкәм... – Ул яшьле күзләрен сөртеп алды.

Әнине күрүгә, үземнең дә күңелем мөлдерәмә тулып ташты.

– Ике көн аңыңа килмәдең бит, балам! Аллага шөкер, барысы да артта калды... Савыгырсың, болай булгач, терелерсең, Аллаһы боерса!

Ике көн?! Димәк, мин комада булганмы? Ә авыл?.. Идрис, Дамирлар?.. Классташлар... Алар чынлыкта юкмыни?

– Сине иң заманча медицина җиһазларына тоташтырдык, – диде Габбас абый уйларымны бүлдереп. – Баш мие эшчәнлеген даими күзәтеп тордык. Гадәттә... – доктор абый бераз уйланып алды. Аннары әнигә борылды. – Гадәттә, мәрткә киткән кешенең баш миендә активлык күзәтелми... Значит... Андый кешеләр яшәү белән үлем чигендә була, төш тә күрмиләр, бернигә реакция дә бирмиләр. Ә сезнең улыгыз белән сәер хәлләр күзәтелде... Әйтерсең, ул комада түгел, әйтерсең, ул актив тормыш белән яшәде... Һәрхәлдә, баш мие нейроннарының функциясе кимемәде генә түгел, хәтта артып китте дип әйтер идем... Значит... Бер сүз белән әйткәндә, Альберт уйларында каядыр сәяхәт итте кебек. Бу әлегә фән, медицина өлкәсендә зур яңалык... Иртәгә консилиум җыябыз. Мәскәүдән профессорлар киләчәк...

Ике көн! Нибары ике көн! Ә тегендә айдан артык вакыт узды! Пионерлар... Җиңү парады... Фото ясау... Суган утыртулар... Гитара... Поход... Гөлия... Йөрәгем сулкылдап куйды. Ул да уйдырма кыз булып чыктымыни? Юк, юк, моның булуы һич мөмкин түгел! Аның зәңгәр күзләре, матур бит чокырлары... Шаян көлүләре... Андый әйберне уйлап чыгарып буламы?

Ләкин чынбарлык белән килешми мөмкин түгел иде. Димәк, мин аны бүтән беркайчан күрмәячәкмен... Димәк, ул бары хыялдагы кыз булып калачак. Көтмәгәндә, бик тә күңелсез, бик тә ямансу булып китте.

Мин яткан җир – реанимация бүлмәсе икән. Янәшәдә тагын бер койка тора. Анысы буш.

– Беренче көнне синең янда авария буенча «коллегаң» ятты, – диде Габбас абый көлемсери төшеп. – Мотоциклчы егет. Салават исемле. Аны кичә палатага күчердек. Хәле синекеннән җиңелрәк иде... Ну, самокат белән мотоцикл бер түгел инде...

Салават? Мотоциклчы? Башымда мең төрле уйлар кайнады. Монда да, тегендә дә шул ук егет. Баш җитми бу хәлләргә. Ярый, реанимациядән чыгуга һичшиксез эзләп табармын үзен. Гафу үтенермен. Мин гаепле бит. Кызыл утка мин кердем.

– Әни... – тавышым үтә дә хәлсез чыкты.

– Әү, балам?

– Китмим мин Америкага, әни... Үзебездә дә бик рәхәт миңа...

Әни мөлдерәмә тулы күзләре белән миңа төбәлде, сак кына чәчләремнән сыйпады.

***

Ике көннән мине палата күчерделәр. Хәлем әлегә җиңел түгел. Аяк-куллар гипста. Аларын тиз генә салдырмаячаклар әле. Салават белән күрештек. Аңлаштык. Ул үпкә белдермәде. «Андый хәлләр генә була инде, үзем дә кызу бара идем», – диде, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаеп.

Көн саен дару төймәләре каптыралар, авырттырып, әллә ничә тапкыр укол кадыйлар. Авыртуга исем китми анысы. Җанны башка нәрсә борчый. Бу вакыйгалар башыма сыймый. Хыялымдагы авыл чынлыкта бардыр, кайдадыр янәшәдәдер кебек. Әлеге авылның, андагы малай-кызларның юклыгына күңел ышанмый. Аларның маҗараларга бай дөньялары, юктан да кызык таба белүләре, янып-көеп яшәүләре күз алдымнан китми. Саф, эчкерсез сөйләшүләре әле дә колагымда яңгырый кебек.

Беркөнне «капельница» астында ята идем, палатага Габбас абый килеп керде.

– Кунак килгән анда синең янга… – диде ул, серле елмаеп.

– Кем ул?

– Улмы?.. О-о-о… Ул сиңа беренче ярдәм күрсәткән кеше. Ул булмаса… белмим… Авария булган җиргә беренче йөгергән, алай гына да түгел, кем өйрәткәндер үзенә – ясалма сулыш алдырган бит үзеңә… Значит… Ярый, эшләрем бар, киттем, каршыла кунагыңны… Ул булмаса, белмим…

Мин әлегә берни аңламый идем. Бераздан коридорда аяк тавышлары ишетелде. Палатага өстенә ак халат элгән кыз килеп керде. Бер кулында – чәчәк бәйләме, икенче кулына мандаринлы пакет.

Аны күрүгә күз алларым караңгыланып, башларым әйләнеп китте. Йа Хода! Бу бит… бу бит…

– Гөлия! – Мин, талпынып, урынымнан күтәрелдем.

– Исәнмесез, – диде кыз елмаеп. – Ә сез мине каян беләсез?.. Әллә берәрсе әйтеп өлгердеме исемемне?

Тәрәзә төбендә буш банка тора иде. Гөлия аңа краннан су агызып, сары хризантемаларны шунда утыртты. Мин томырылып, аның һәр хәрәкәтен күзәтеп яттым.

Озак утырды бу чандыр гәүдәле, зәңгәр күзле кыз янымда. Уртак телне тиз таптык. Уртак темалар да күп булып чыкты. Күптәнге танышлардай сөйләшеп туя алмадык. Шәфкать туташы кереп, сәгатенә төртеп күрсәтмәсә, тагын бераз утырган булыр иде әле Гөлия.

Менә ул китәргә дип, урыныннан торды.

– Гөлия, ә син минем янга тагын киләчәксеңме? – дип сорадым, үз кыюлыгыма үзем шаккатып.

Кызый бит очындагы шаян чокырларын балкытып елмайды:


– Киләм, әлбәттә! Син терел генә! Тизрәк терел, яме…

***Редакциядән:***

*Алмаз Гыймадиев, күп еллар «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе булып эшләгән коллегабыз, бу айда үзенең илле яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Без аны гомер бәйрәме белән котлыйбыз, тормышта зур уңышларга ирешүен, иҗатта балаларны алга таба да гүзәл әсәрләре белән сөендереп торуын телибез.*

*Мөхәммәдьярның тууына – 525 ел*

# АҢЛАМАС АКЫЛСЫЗ, АССАҢ ДА ДАРГА...



Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

*Быел Казан ханлыгы чорында иҗат иткән күренекле татар шагыйре Мөхәммәдьярның тууына – 525 ел. Шушы олы вакыйга уңаеннан тапшырулар әзерләү өчен радиобыз фондына мөрәҗәгать иттек. Әлбәттә, шагыйрьнең «Нуры содур», «Төхфәи мәрдан» кебек мәгълүм әсәрләре нәфис сүз осталары тарафыннан укылган, магнитофон тасмасына язып алынган. Тик менә «Казан утлары»н укучыларга тыңлатасы килгән иң кирәкле, иң мөһим язманы, кызганычка каршы, саклап кала алмаганбыз. Дөресен генә әйткәндә, мин аны көнкүреш магнитофонына гына яздырган идем, бәлки сәбәбе шул булгандыр.*

*Бу – әдәбият гыйлеменең аксакалы, гомерен урта гасырлар әдәбиятын өйрәнүгә багышлаган фидакарь зат Шакир Абилов белән әңгәмә. Шулай да әлеге югалган аудиоязмадагы фикерләрне үз вакытында кәгазьгә күчереп калырга баш җиткән. Әңгәмәнең кайбер урыннарына күз салыйк.*

**– Шакир ага, Сез Мөхәммәдьяр әсәрләрендә күрсәтелгән өч принципны – дәүләтне саклап калу өчен кирәкле өч шартны ачкан галим. Менә шушы принципларны аңлатып, шәрехләп бирсәгез иде.**

– Башта Мөхәммәдьярның тарихыбызда тоткан урынын, аның татар халкы өчен кем булуын искә төшерик. Ул, һич шөбһәсез, татар-төрки әдәбиятында зур гигантларның берсе. Әгәр дә без азәрбайҗан әдәбияты диюгә – Низамины, үзбәк әдәбиятында – Нәваины, фарсы әдәбияты турында сүз чыкса, бөтен дөнья тарихын иңләгән Фирдәүсине күз алдына китерәбез икән, Мөхәммәдьяр – шуларның тиңедер.

Мөхәммәдьяр Казан ханлыгының иң авыр, катлаулы, үтә дә каршылыклы чорында яши. Алтын Урда җимерелгәннән соң, Казан ханлыгы халыкны берләштерүче, аның тормышын көйләп яшәтүче үзәккә әверелергә тиеш булган, әлбәттә. Тарихның табигый агымы шуңа китергән дә булыр иде. Чөнки Казан дәүләте, кайбер галимнәр аңлатканча, Алтын Урда җимерелү нәтиҗәсендә генә барлыкка килмәгән. Аның тарихи тамырлары Болгар ханлыгы, хәтта аннан элегрәк оешкан төрки дәүләтләргә үк барып тоташа. Ләкин тарих мәсьәләне үзенчә хәл иткән. Алтын Урда җимерелүгә, Казанда хакимият өчен тарткалашучы төрле партияләр барлыкка килгән, берәүләре Мәскәү җырын җырлаган, икенчеләре Кырым, Төркия көен көйләгән. Аерым ханнар, кай якка карарга белмичә, аптыраштa калган. Менә шушы куркынычны, Ватанга дәһшәт килергә торуын тирәннән аңлап, тоеп яши Мөхәммәдьяр, һәм бу хафалану аның иҗатында да чагылыш таба. Әнә шуңа да ул үз әсәрләрендә хакимият өчен тарткалашудан ваз кичеп, барлык көчне бер максатка туплау-берләштерүне дәүләтне саклау өчен иң кирәкле шартларның берсе итеп куя.

**– Тик менә хакимият дигән татлы җимеш өчен көрәштән башка тормыш алга барырмы? Аннары кем тирәсенә тупланырга бит?**

– Мөхәммәдьяр Олуг Мөхәммәдтән килә торган хан нәселенең соңгы вәкиле Мөхәммәт Әминнән гайре бер хөкемдарны да якламаган. Ул 1518 елда вафат була һәм 1523 елдан Казан тәхетендә Кырым ханнары хакимияте башлана, аларга алмашка Мәскәү карашларын яклаучы Касыйм ханнары килә. Бу вакытта Мөхәммәдьяр, гәрчә сәясәткә катышмаган кебек тоелса да, ханнарга мөмкин кадәр тәэсир итәргә тырышкан.

Хәзер без бер яктан Кол Шәрифне зурлыйбыз. Ул – Сәид, зур дин башлыгы, дипломат та. Хәтта Иван Грозный бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү өчен аңа мөрәҗәгать иткән. Ләкин нәкъ менә шул шәхеснең абруе Казан эчендәге сәясәтне хәл иткән елларда мәскәүләр татар иле башкаласыннан нибары берничә дистә чакрымда – Зөя утравында көчле ныгытма салып куйганнар. Чөнки Казанның үзендә бердәмлек булмаган. Бу татар халкының тискәре бер адымы, кимчелеге, тарих тарафыннан үзенә салынган вазифага битараф каравы булган. Ә менә Мөхәммәдьярның нәкъ шул 1549 елда язган «Нәсихәт» дигән бер шигыре бар. Күләме ягыннан зур булмаса да, мәгънәсе, әһәмияте ягыннан калын-калын романнарга тиңләр идем мин аны. Эчтәлеге гади генә кебек: гөлчәчәкләр үскән бакчага сандугач килә, ләкин кунып сайрый алмый, чөнки бакчага тигәнәк үтеп кергән. Мин бу шигырьне һәр татар кешесе, бигрәк тә җитәкче урындагылар, депутатлар яттан белергә тиеш дип исәплим.

**– Тукайның «Туган теле» кебекме?...**

– Әйе. Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: Мөхәммәдьяр белән Тукай арасында бик тыгыз бәйләныш бар. Әгәр дә без, шигъриятебезнең чишмә башында Кол Гали тора, дибез икән, Мөхәммәдьяр – үзенә кадәр булган әнә шул мәдәниятне кабул итеп алган, үзләштергән, аны ислам цивилизациясе, гарәп дөньясы традицияләре белән баеткан, шул рәвешчә үзеннән соңгы мәдәният, әдәбият үсешенә зур йогынты ясаган әдип. Аның тәэсире, берничә гасыр үтеп, Тукайга кадәр килеп җиткән, аны шагыйрь һәм шәхес буларак шәкелләштергән һәм Тукай, шушы мирас нигезендә, үзенә бер яңа чор хасил иткән. Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Тукай – татар шигъриятенең, иҗтимагый фикернең өч кыясы, алтын баганасы ул.

**– Мөхәммәдьяр дәүләтне яшәтү өчен тагын нинди шартлар булырга тиеш дип исәпли?**

– Мөхәммәдьяр, бөек гуманист буларак, иң беренче чиратта кешене зурлый, аны, акыл көченә ия зат булганлыктан, үз язмышын үзе хәл итүче, дөньяны үзгәртүче итеп күз алдына китерә. Ул үз иҗатында тарихи мисалларга мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, «Төхфәи-мәрдан» әсәрендә VI гасырда яшәгән шаһларның берсе Һарун бервакыт үз янына 70 киңәшчесен чакыртып ала да, илне алга җибәрү өчен нәрсә эшләргә кирәк, сез миңа шуны әйтегез, ди. Тегеләр башта җыелышып, үзара киңәшләшәләр, аннары шаһка җавап бирәләр. Шуларның сүзен тотып, Һарун дәүләтен гаделлек нигезендә үзгәртә башлый. Озак та үтми ил чәчәк ата, бөлгенлек юкка чыга, халык муллыкта яши башлый, канәгатьсезлек бетә, шаһ казнасына төрле өлкәләрдән байлык агыла – ил алгарыш ала. Һәр тарафта – гармония. Мөхәммәдьярның үз сүзе белән әйтсәк: «Бүре белән сарык бергә су эчә, үрдәк белән карчыга бергә оча». Ил эчендәге халыклар арасында дошманлык бетә.

**– Өченче шарт?**

– Халыкның төрле шивәләре арасында каршылыкка юл куймау. Бу мәсьәлә бүген аеруча мөһим. Моңа Мөхәммәдьяр әйткән гаделлек принцибы нигезендә генә каршы торып була. Әйтик, тарих татарның урта диалектта сөйләшүче өлешенә башка төркемнәрне берләштерү, туплау бурычын куйган Ләкин менә шушы өстенлектән файдаланып, башкаларны читкәрәк тибәрү, һавалану, борын чөю булмады түгел бит. Күрәсез, Мөхәммәдьярның фикерләре бүген дә актуальлеген югалтмаган, аның әсәрләрендә дөньяның кая таба баруы аермачык булып аңлашыла.

*Әлеге QR-код ярдәмендә сез Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәрен тыңлый аласыз. Аны язучы һәм галим, нәфис сүз остасы Фоат Галимуллин укый.*

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# ӘРЕМ БИРСӘМ ДӘ – РИЗА

## Зирәк килен

Мендәр өсләренә басып, уралып җырга, көйгә,
Татлы балдан авыз итеп, киленнәр төшә өйгә.

Килен төшә тыйнак кына, һәммәсен иплəп-тыңлап.
Каената гармунын тарта, яшьлек көйләрен уйнап.

Гармун көйләренә бии каенана, туганнар.
Яшь  киленнән дә кадерле тагын монда кемнәр бар?!

Бәйрәм итә һәммәсе дә ак фатага сокланып.
Яшь киленнең үткенлеген мактый һәркем таң калып.

Каената кулларыннан һич төшерми гармунын.
Зирәк килен дә чамалый гармунның көен, моңын.

Тик гармун тарту киленгә үз туенда килешми.
Соңыннан уйнармын, ди ул, һич беркемгә бирешми.

...Туйлар тәмам, яшь пар баса олы тормыш юлына.
Гармун күчә каенатадан зирәк килен кулына.

Их, бу гармун, их бу туйлар, хәмерләре исертә.
Килен хәзер хәмерсез дә һәрбарчасын сикертә.

## Качалар

Олигархлар качып ята Лондонда,
Байлыклары булганга үз кулында.

Илне ташлап яши алар чит якта,
Бирешмичә, кызармыйча оятка.

Бездә дә шул – җаны-тәне азганга
Җитәкчеләр күчеп китә Казанга.

Валлаһидыр, билләһидер, бу  – хак сүз,
Дөрес күрә моны безнең зирәк күз.

Туган йортны ташлый алар мал өчен.
Нигез сатып, югалталар җан көчен.

Сизми алар читтә гомер үткәнен,
Әҗәл беркөн тәрәзәгә чирткәнен.

Васыять яза Казаннан зур түрәләр:
– Вафат булсам – Кулаткыга күмәрләр!

## Сәхия һәм Дәхия

*Шагыйрь Рөстәм Мингалимгә ияреп*

Олы шәхесләргә һәрчак
Тудыралар мәдхия.
Зур талантка бездә ия
Сәхия һәм Дәхия.

Язу-сызу белән алар
Шөгыльләнә. Бу – зур эш.
Һәр даһиның сәләтләре
Тарихка керү тиеш.

Шундый хыялга бирелеп,
Сәхия һәм Дәхия
Түләп китап бастырганнар,
Китап ул – зур һәдия.

Тик, кызганыч, язылмаган
Китапның кереш сүзе.
Мөхәррире дип куелган
Автор корткалар үзе.

Бакчачы кулы тимәгән –
Түтәл күк китап эче.
Укып баккан һәммәсенең
Көлүдән катты эче.

Моның белән чикләнмәде
Сәхия һәм Дәхия.
Җөрьәт иттеләр ясарга
Зурлап презентация.

Кызыксынган укучыга
Басма йорт биргән җавап:
«Безгә талант мөһим түгел,
Безгә – акчасы савап!

Акчаң булса – күзне йомып
Бастырабыз һәммәсен.
Ул китапны укучының
Башы туптай әйләнсен».

Түләп китап бастырганнар
Сәхия һәм Дәхия.
Бик күпләр әйләнә шулай
Даһи каләм әһеленә.

## Эш узгач...

Яшь вакытта йөрәкләрдә
Хисләр ташып тузына.
Мин дә гашыйк булып йөрдем
Шәрипҗанның кызына.

Ә Шәрипҗан – тегермәнче,
Оннан байлык агыла.
Кызы купшыланып йөрде,
Бар белгәне – мал гына.

Гөлчәчәкләр суздым аңа,
Борын чөйде, алмады.
Тегермәнчеләр рәтеннән
Үзенә яр сайлады.

Яшьлек узды, тегермән тузды,
Оннары очты күккә.
Тик чая кыз егет сайлап
Тәтемәде бәхеткә.

Гөлчәчәкләр сузып аңа,
Чиккәнмен күпме иза.
Үкенә кыз, хәзер аңа
Әрем бирсәм дә – риза.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
*Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы авылы*

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## САБАНТУЙ – 2022

Ульяновскида XXII Бөтенроссия федераль Сабан туе булып узды. Анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Сабантуйның баш батыры Сергей Павликка ТР Президентының махсус бүләге – «Лада Гранта» автомобиле тапшырылды. Пәһлеван машина ачкычын Рөстәм Миңнехановның үз кулыннан алды. Киләсе елда федераль Сабантуй Кемерово өлкәсендә узачак. Рөстәм Миңнеханов һәм Ульяновск өлкәсе губернаторы Алексей Русских бу бәйрәмнең «Тулпар ат» символын Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилёвка тапшырдылар.

Икенче көнне Сабантуй республикабызның башкаласы Казанда узды. Ул өч урында – Мирный, Дербышки бистәләрендәге каенлыкта һәм Аккош күле буенда үткәрелде. Мирный бистәсендәге бәйрәмдә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилёв, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Казан мэры Илсур Метшин булдылар.

## ПУШКИН ҺӘМ РУС ТЕЛЕ КӨНЕ

Быел А.С.Пушкинның тууына 223 ел тулды. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов шагыйрьнең Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәленә чәчәкләр салды. Чәчәк салу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин катнаштылар.

А.С.Пушкинның туган көне Халыкара рус теле көне буларак та билгеләп үтелә. Бу уңайдан М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында тантаналы чара булып узды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Шул ук көнне ул рус милли-мәдәни берләшмәсе активистлары белән дә очрашты.

## СӨЕМБИКӘГӘ – ҺӘЙКӘЛ

Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә Казан ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев Сөембикәгә һәйкәл ачу халкыбызның күптәнге хыялы иде, дип белдерде.

## СТЕЛА АЧЫЛДЫ

Шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Һади Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты, ТР өченче чакырылыш Дәүләт Советы депутаты Рөстәм Зәкуановның тууына 65 ел тулу уңаеннан туган ягында – Азнакай районы Үчәлле авылында мемориаль стела ачу тантанасы булды. Анда Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллин истәлек тактасын ачу тәкъдиме белән ТР Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе Лотфулла Шәфигуллинның чыгуын һәм бу эштә зур ярдәм күрсәтүен әйтте. Тантанада ТР Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев, язучылар Рафис Корбан, Вазыйх Фатыйхов, туганнары, якыннары чыгыш ясадылар.

## КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

Чистай каласында Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы региональ «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының күчмә утырышы узды. Ошбу сәфәр программасына язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллованың «Язмыш җиле» романын («Казан утлары», 2019 ел, 4 нче, 5 нче саннар) тәкъдим итү дә кертелгән иде. Күренекле татар хатын-кызларының берсе, Петербургта Бестужев югары курсларында белем алган, 1912 елда Балкан сугышында шәфкать туташы буларак катнашып, зур каһарманлыклар күрсәткән Чистай кызы Гөлсем Камалова турындагы бу әсәрнең бәйрәме 1847 елда төзелгән тарихи бинада – Чистай мөхтәсибәтенә караган «Камалия» ял итү-үсеш үзәгендә булды. Анда Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы региональ «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова, Чистай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Равил Мазгутов, Бөтендөнья татар конгрессының Чистай бүлеге җитәкчесе Фәрит Галимов,

авторның шәкертләре – «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев, «Сөембикә» журналы мөхәррире Эльмира Закирова һ.б. чыгыш ясады. Кызганыч ки, авырып тору сәбәпле, автор кичәдә үзе катнаша алмады.

* * *

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да язучы, галим Рәфкать Шаһиевнең «Элеккечә түгел без генә» китабын («ТАТМЕДИА» ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясеннән басылып чыккан уникенче басма) тәкъдим итү булды. Бу юлы әлеге чара бүләкләү тантанасы белән башланды. «Казан утлары»ның 100 еллыгы уңаеннан һәм тырыш хезмәт өчен журналыбызның җаваплы сәркатибе Ландыш Әбүдәрова белән машина йөртүче Наил Кадыйров – Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының, мөхәррир Гөлия Сәлахова «ТАТМЕДИА» АҖнең Рәхмәт хатларына лаек булдылар. Рәхмәт хатларын аларга Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев белән «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры Шамил Садыйков тапшырдылар. Аннары китап бәйрәме башланды. Шамил Садыйков сүзләренә караганда, «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясеннән чыгарылган китапларның 70 проценты тиз арада сатылып бетә. Моңа кадәр бу китапларның тиражы ике мең булса, хәзер – өч мең. Яңа китапны тәкъдим итү кичәсендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, «Матбугат.ру» җитәкчесе Данил Сәфәров, нәфис сүз остасы Инсаф Абдулла, галимә Гүзәл Батыршина, авторның сабакташлары, дуслары, Рәфкать Шаһиев үзе чыгыш ясады. Яңа китап тәкъдим итү бәйрәмен «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рафис Корбан алып барды.

* * *

«ТАТМЕДИА» АҖнең конференцияләр залында «Әхсән хатлары» китабын тәкъдим итү булды. Аның нигезен рәссам Әхсән Фәтхетдиновның шагыйрь Равил Фәйзуллинга язган хатлары тәшкил итә. Ул рәссамның әсәрләре, фоторәсемнәр белән бизәлгән. Китап бәйрәмендә ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкаручы директоры Нурия Һашимова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы урынбасары Фирдания Әхмәтҗанова, Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗев, сәнгать фәннәре докторы, шагыйрә Розалина Шаһиева, Чирмешән якташлык җәмгыяте рәисе Раушания Сәүбәнова, җәмәгать эшлеклесе Ринат Закиров, тележурналист, нәфис сүз остасы Илдар Кыямов һ.б. чыгыш ясады. Кичәне Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин алып барды. Фойеда Ә.Фәтхетдинов әсәрләреннән күргәзмә ачылды.

### ТӨРКИЯ МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВНЫ ӨЙРӘНӘ

Төркиядә Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев иҗаты буенча диссертация якланды. Инөнү университеты докторанты Фатма Җанполат-Җанал тарафыннан Рамилә Яруллина җитәкчелегендә язылган, «Хәзерге заман татар язучысы Марсель Галиев әсәрләрендә тел һәм өслүб» дип аталган бу фәнни хезмәттә әдипнең 20 шигыре, «Ак абага» әсәре тикшерелә.

### ШӘРӘФЛЕ ПРОФЕССОРЛАР

Уфада Мифтахетдин Акмулла исемендәге Башкортстан педагогика университетына – 55, аның татар теле һәм әдәбияты кафедрасына 30 ел тулу уңаеннан халыкара конференция булып узды. Анда Казаннан да кунаклар катнашты. Конференциядә Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташка һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллинга кафедраның Шәрәфле профессоры исеме бирелү турында таныклыклар тапшырылды.

### «КАЗАН УТЛАРЫ» – СУСЛОНГЕРДА

Соңгы елларда «Казан утлары» журналында һәм «К.У.» журналы китапханәсе» сериясеннән Бөек Ватан сугышы вакытында меңнәрчә солдатларны ачлыкка, газапка дучар иткән Суслонгер лагере турында әсәрләр (Фирдәвес Хуҗин. «Сугыш күләгәсендә», 5 нче сан, 2018 ел, Зиннур Хөснияр. «Мәдинәгә медаль бирәләр», 5 нче сан, 2021 ел, Фирдәвес Хуҗин. «Суслонгер», «К.У.» журналы китапханәсе» сериясеннән, 2022 ел.) басылып чыкканнан соң, редакция хезмәткәрләре Мари урманнарына сәфәр кылып, шушы лагерь урнашкан урынны, кайчандыр тәмугка тиң булган җирне үз күзләре белән күреп кайттылар. Кайтканда Иделнең аръягындагы «Татар авылы» музей-утарында булдылар.

***

Саха (Якутия) Республикасында Татарстан Республикасы көннәре булып узды. Бу хакта «Казан утлары»ның август саныннан укый аласыз.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман З.ХАКИМА «Сколько мгновений в одном часе?»;
рассказ Н.КАРИМОВОЙ «Святой конь»; поэма М.МИРЗЫ; стихи З.МАНСУРОВА, Х.ШИРМЕН, Ф.ИСМАГИЛОВОЙ.
Литературный конкурс «Майдан – для батыров»: документальная повесть Л.ГИБАДУЛЛИНОЙ «Кара батыр» .
«Литература родственных народов»: рассказ С.МАУЛЕНОВА «Певучая Казань. История одного путешествия» в переводе с казахского языка Л.ХАМИДУЛЛИНА.
«Наука»: статья Р.САФАРОВА.
«Соплеменник»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.
«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.
«Детская библиотека»: повесть для подростков А.ГИМАДИЕВА «Мальчик из будущего».
«Бесценные голоса»: статья к 525-летию поэта Мухаммедьяра.
Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
«Сенной базар»: рассказ Р.АРИФУЛЛИНА «Рад и полыни».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: памятник Садри Максуди в парке «Стамбул» г.Казани.
Фото И.Абрамовой.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by Z.KHAKIM «How many moments in an hour?»;
story by N.KARIMOVA «The Holy Horse»; poem by M.MIRZA; poems by Z.MANSUROV, H.SHIRMEN, F.ISMAGILOVA.
Literary competition «Maidan is for Batyrs»: documentary story «Kara batyr» by L.GIBADULLINA.
«Literature of kindred peoples»: story S.MAULENOV «Singing Kazan. The Story of a journey» translated from the Kazakh language by L.KHAMIDULLIN.
«Science»: article by R.SAFAROV.
«Tribeman»: article by D.ZAGIDULLINA.
«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.
«Children's Library»: story for teenagers «A boy from the future» by A.GIMADIEV.
«Priceless voices»: article on the 525th anniversary of the poet Muhammedyar.
The rubric is led by N.AKMAL.
«Hay Bazaar»: story by R.ARIFULLIN «Happy about Wormwood».
Diary of social and cultural life.
On our covers: monument to Sadri Maksudi in the park «Istanbul» in Kazan.
Photo by I.Abramova.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә: Казанның «Стамбул» паркында Садри Максуди һәйкәле. Ирина Абрамова фотосы.*